# казан утлары

1

ЯНВАРЬ-1977

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

1
ЯНВАРЬ
1977

## Бу санда

Г. АХУНОВ. Идел кызы. Роман . . . . . . . . 3
Х. ТУФАН. Иртәләрнең берсе. Шигырьләр . . . 65
Ф. ХӨСНИ. Күп балалы... бабай. Хикәя . . . . 74
Г. САДӘ. Яңа шигырьләр . . . . . . . . . . . 81
М. ХӨСӘЕН. Кояш җайдак... Шигырьләр . . . 84
Р. РӨСТӘМОВА. Ике нәсер . . . . . . . . . 87
Ә. РӘШИТОВ. Маяклар. Шигырьләр . . . . . 92
Н. МАДЬЯРОВ. Ашкынам болыннарга. Шигырьләр 95

КЛАССИК ПОЭЗИЯ ҮРНӘКЛӘРЕ

А. БЛОК. Тилгән. Шигырьләр . . . . . . . . . 97

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 101
А. ХӘСӘНОВ. Буровой юлларында . . . . . . . 103

МИРСӘЯ ӘМИРГӘ 70 ЯШЬ

Ф. МИҢНУЛЛИН. Талантлар юлы . . . . . . . . 111

ИСТӘЛЕКЛӘР

М. ФӘЙЗУЛЛИН. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән . . . . . . . . . . . . . . . . 116

ОКТЯБРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ӘМИРХАНОВ. Вакытлы матбугат һәм цензура . 123
М. АБДУЛЛИН. Мөселман социалистлар комитеты һәм буржуаз тарихчылар . . . . . . . . . 127

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

М. МӘҺДИЕВ. Ибраһимов әсәрләрендәге образларның прототиплары . . . . . . . . . . 131

КАЗАННЫҢ 800 ЕЛЛЫГЫНА

Д. ВӘЛИЕВА. Болгар сәнгате сәхифәләреннән . . 139

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Я. АБДУЛЛИН, Ә. ХӘЙРУЛЛИН.** Мәгърифәтчелек хәрәкәте карлыгачы Габденнасыйр Курсави . . 144
**Г. ХӨСӘЕНОВ.** Утыз Имәни Башкортстанда . . . 152

КИТАП КҮЗӘТҮ

Бер китапка өч караш . . . . . . . . . . . . 157

КОНКУРСКА КИЛГӘН РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Р. ЛОТФУЛЛИН.** Алгы сызыктан репортаж . . . 169
**Р. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН.** Офыклар артында ачышлар . 173

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Т. ДУНАЕВА.** Татарстан дәүләт исәп-теркәү библиографиясенә 50 ел . . . . . . . . . . . 175
**Б. Сирин** . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
**З. Ярмәки** . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
**М. ЗАРИПОВ.** Хезмәт — иң зур ләззәт . . . . 180

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

**З. ТУФАЙЛОВА.** Ватаным. Шигырьләр . . . . 182

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**З. НУРИ.** Чыршы бәйрәме уклары. Шигырьләр . 184

УКУЧЫ СҮЗЕ

**С. ХӘЙБУЛЛИН.** «Ташлардагы язулар» . . . . . 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/X-1976 ел. Басарга кул куелды 9/XII-1976 ел. ПФ 13273. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000 экз. Заказ К-348. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

Гариф Ахунов

# ИДЕЛ КЫЗЫ

РОМАН

**БЕРЕНЧЕ КИТАП**

БЕРЕНЧЕ БАШЛАМ

## I

Бу төнне Габбас мулла йокы күрмәде.

Таңга ерак иде әле.

Тышта буран үкерә. Инде өченче көн туктаусыз котырынган җил-буранның, әле йорт нигезенә үк килеп җитеп, ач бүреләр көтүе сыман, куркыныч авазлар белән улавы, әле бөтенләй ерагаеп, кайлардандыр әйләнеп кайтуы, чапан-чалмасын да салмастан, бозлы тәрәзә пыяласына, урам караңгылыгына төбәлеп утырган Габбас мулланың җанын тетрәтә иде. Буран тавышы тынып торган арада, ул, колагын шыңкайтып, зиһенен җыеп, икенче бер тавышны, инде кайчаннан бирле зарыгып көткән сабый бала тавышын ишетергә тели...

Аскы өйдә Шәмсениса абыстай бала таба алмый интегә.

Кичтән бирле интегә инде.

Аның янында кендекче карчык Сафура белән асрау карчык Миңлекамал (мулла йортында йөргән аты белән әйткәндә, Көмеш түтәй) мәш киләләр. Яшь мулла баш баласының исән-имин туусын килеп әйткән беренче кешегә Мәкәрҗә ярминкәсеннән кайтарткан ун аршын зәңгәр ефәк белән алма бизәкле кәшимир яулык бирәм дип адарынды.

Тик һаман сөенче алырга килүче юк иде шул әле.

Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн, адәм баласы адашып үләрдәй ачы суык буран әллә ниткән куркыныч хәлләр вәгъдә итә төсле. Әгәр Шәмсениса баласын таба алмый, аны Салагышка фельдшерга алып барырга туры килсә? Ат җигәрлек, кара туры айгырны бу буранда каты кул белән алып барырлык кеше юк. Юлдаш юк Габбас муллага. Ат караучы Бөкре Гафият (кирәк бит, юньсез!), нәкъ менә шул

көнне кичтән сәрхушлек өянәге кузгалып, каядыр китеп олакты! Ничәмә ничә кат күңеленә беркетте Габбас: эчүдән айныган көннең иртәгесен үк куып чыгарам, диде. Булдыра алмый. Гафият кебек ат җанлы кешене, мал-туарны җаныннан газиз күрүче икенче берәүне көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмассың.

Һай, шул сәрхушлеге булмаса!

Күпме күңелсезлек китерә бит ул мулла йортына. Авыл көтүчесенең хатыны Бибисара күз яше белән елап килде:

— Биздерсәңие, хәзрәт, шул бөкреңне бездән. Иремне эштән чыгара, кара җаяүгә калдыра бит инде. Ай саен чиреге белән көмешкә эчәләр. Өч йөз алтмыш йортлы Зартугайда бүтән беркем эчми, синең бөкрең эчә дә минем сантыем эчә. Ай саен бит ул! Өй тулы бала-чага: аяксыздан күтсез, дигәндәй... Бер көн эчә ирем — атна буе эче китә. Балаларны туйдырасы бар лабаса, йорт алып барасы... Хәер эстәргә чыгарыем, хәзрәткәем, өстемә кияргә бишмәтем юк...

Көтүчегә тәлинкә язып бирде Габбас мулла. Зәгъфран карасы белән язды. Сәрхушлектән биздерү догасы. Көтүче нишләгән диген? Доганы көмешкәгә кушып эчкән. Гафият бөкре белән икәүләп, көлә-көлә эчкәннәр! Шуның аркасында Югары мәхәлләнең указлы мулласы Сөләйман хәзрәт Түбән мәхәлләне кимсетә торган сүзләр әйткән. Мәчеткә җыелган картлар баш селкеп торганнар.

Ул гынамы? Гафият яшь мулланы узган айда бөтен авылга рисвай итте. Мари авылында көмешкә кайнатучы Ычтапан авырып киткән. Көтүче белән Бөкре кайгыга калалар. Көмешкә каян табарга? Көтүче әйтә Бөкрегә: «Пучинка Ычтапанда көмешкә бетмәгән әле. Түлке ул аны берәүгә дә бирми, үлемтегенә дип саклап тота. Күндерсәң аны син генә күндерә аласың, Гафият. Син бит, бөкре шайтан, телең белән имәнне юнып бирә аласың. Билләһи, якты кояшның чыраен күрмим әгәр! Әллә, мәйтәм, тәвәккәлләп бер барып карыйсыңмы? Күрүчеләр әйтте миңа, чирекле шешәне киез итек эченә яшереп асрый, ди. Онытмассыңмы?»

Гафият мамыгы бүселгән иске бүрекне башына чәпи, чикмән путасы арасына кыстырган тире бияләйне тартып алып кия дә, кулын-кулга шапылдатып:

— Йә, аллага тапшырдык, Ләлек мамык чыбыркы!— ди. Көтүчегә үзе кушкан ягымлы матур кушаматы белән дәшә. — Изге теләктә тор, яме. Мин кайтканчы сүгенә күрмә, сабырлыгыңны җуйма, иату исә юл уңмас. Мин әйткәннәрне исеңдә тот, Ләлек мамык чыбыркы!

Ул көтүче әшнәсенә күз кыса һәм туп-туры Ычтапаннарга юнәлә. Керә. Кычкырып сәлам бирә: «Иминлек булсын бу йортка!». Сәлам алучы юк. Ычтапан агач караватта ята. Бите су салырлык булып чокырайган, саргайган, тиресе сөяккә ябышкан. Әле генә әйләнә-тирәдә дан тоткан балта остасы, бурачы, беренче кул тугымчы һәм көмешкәче үзе сырлап ясаган агач караватта коры сөяккә калган тезләрен тырпайтып ята.

— Ник килдең, Кәфият? Самогонгамы? Юк самогон!

— Мин, Ычтапан Митрич, дөресен әйткәндә, самагунга дип килмәдем. Мин синең хәлеңне белергә дип килдем. Туктале, мәйтәм, дөнья йөзендә Ычтапан дәдәй бар бит әле — безне ничә мәртәбә бәладән коткарган кеше. Ул бит авырып ята. Гүәрдин кук ир чагында кадерне белүче күп булыр, мәйтәм. Авыргачыннан белергә кирәк кеше кадерен. Ә, мужыт, мин аңарга ярдәм итә алырмын. Терелтермен мин аны... Самагунга килгәндә... син гүли дә кайгырма, Ычтапан дәдәй, бар синең самагуның, әнә теге кызыл бизәкле киез итек эчендә ул.

Ычтапанның сүнеп барган нурсыз күзләре зур булып ачыла, житен сүсседәй ак сакалы дерелдәп китә. Ул, кинәт терсәгенә таянып, юклыбарлы хәле белән торырга итенә башлый:

— Ә син, Кәфият, каян беләсең? Изге мәллә син?

— Бу дөньяда мин белмәгән аз булыр, Митрич, Бохардагы таз булыр.

— Син мине ничек терелтәсең соң?

— Марфа түтәй, кил әле монда. Тартыйк әле шушы караватны. Вәт менә шулай. Ябык булса да авыр, рәхмәт төшкере, ир заты шул, эре сөякле...

Бөкре Гафият караватны буендагы мүктән капшанып нидер эзли. Марфа түтәй күзен дә алмый карап тора. Озак капшана Бөкре. Марфа түтәй, арып, күзен читкә ала. Гафият ул арада — ялт бер инәне мүккә! Киез итегенең балтырына кадап килгән икән.

— Әһә, явыз! Менә кайда ятасың икән син качып!! Китер әле, түтинкә, келәшшә!— Аякны идәнгә терәгән булып, бик хәтәр чирәшеп тартып чыгара Гафият инәне. Чыгара да әйтә: — Сихерләгәннәр сине, Ычтапан дәдәй!

— Булмас!— ди Ычтапан.

— Булган шул менә!

Марфа түтәй мүктән чыгарган инәгә, сихерләнгәндәй, күзен алмый карап тора. Ул арада Гафиятең янә дә ике күгәргән инәне кадап өлгермәсенме!

— Менә бит, әйттем бит мин сиңа, ә син ышанмаган буласың, Митрич!

— Нишләтим боларны?— ди Марфа түтәй, кулындагы өч инәгә, агулы елан тоткандай, куркып карап тора.

— Боларнымы?— ди Гафият, әлеге бүреге белән киңәш иткәндәй, башын кашый: — Боларны син болай ит, түтинкә: инәгә беләк буе җеп сапла. Тегәр җеп булсын, өзелерлек булмасын. Аннан ары килеп, җепнең кырык төшенә кырык төен төйнә. Икенче җепне дә шулай иттер — кырык төен төйнә. Әнәйт-теки килеп, өченче инәгә дә беләк буе җеп сапла, анысына да кырык төен төйнәп куй. Аннан ары китереп, өч инәнең өчесен дә бергә җыеп бәйлә, тагын барысына бергә кырык төен төйнә дә җиде төн уртасында, кеше аягы тынгач, мунча нигезенә төшереп күмәрсең. Аңнадыңмы?

— Аңнавым аңнадым. Аннары нишләрмен?

— Аннары бер нәрсә дә эшләмә, шыпырт кына көтеп тор. Ишетсен колагың: минем сүзне бирәүгә дә әйтәсе булма, мунча нигезенә инә күмгәнеңне берәүгә дә әйтмә, яме.

— Ник?

— Сихере кайтыр. Ычтапанның терелми калыр, аңнадыңмы?

— Аңнадым, Кәфият, бер кешегә дә әйтмәм. Бик зур рәхмәт сиңа. Кулың-аягың сызлаусыз булсын...

— Торып тор, түтинкә. Ә ул рәхмәттән исереп буламы соң?

— Була, Кәфият, була. Кәзер чыгарам мин сиңа ул әҗәл даруын.

...Габбас мулла шул көнне хезмәтчесенең көмешкәче Ычтапаннан бурлаттай кызарып кайтып керүен, аннары мари пучинкасында ни-нәмәрсәләр майтарып йөрүен исерек бер мактанчыклык белән сөйләп биргәнен исенә төшергәч, янә бер мәртәбә чирканып, калтыранып куйды.

Габбас мулла сихерчелек белән шамакайлыкны җен урынына күрә иде.

Бөкре Гафиятне ул бик хәтәр тиргәп ташлады. Гафият исә мулланың вәгазен, башын ия төшеп, үкенгән сыман, юаш кына тыңлап торды, аннары әйтте:

— Менә син, Габбас, мине бик тә эшәке кешегә, адәм актыгына чыгарып куйдың. Төптәнрәк уйлап карасак, син дә бит алланың кашка тәкәсе түгел. Син бит әле бер ел элек кенә хәерче Җамалетдиннең ундүртенче баласы иең. Кем сине мулла итте? Алып-сатар Габделхәлим. Төсең-битең, сакал-мыегың матур дип мулла итте мәллә?! Тот капчы-

гыңны! Кырык яшьлек тол абыстайга ир кирәк булды — вәт сине өйләндерделәр. Белдеңме? Син, нәрсә, тәлинкәгә дога язып җәннәткә керермен дип уйлыйсыңмы? Юк инде, мулла абзый, кермичәрәк тор инде, анда синнән дә битәр гөнаһлылар бар әле... җәннәткә керергә. Так ышту, хәзрәт, син миңа күзеңнең агын әйләндереп карама, без икебез тиң, бер үк эшне эшлибез. Син дә доган ярдәм итәр дип ышанмыйсың, мин дә мари дәдәйгә ясаган сихерем ярдәм итәр дип ышанмыйм!

Әмма дә ләкин Бөкре Гафият майтарган «сихер» Габбас мулла догасыннан көчлерәк булып чыкты.

Ике атнадан соң Бөкре Гафият, янә дә сәрхушлек өянәге кузгалып, мари картына барып чыкса, ни күрә: урыныннан кузгала алмый яткан агаебыз өстәл янында чәй эчеп утыра.

Могҗиза!

Китте даны Бөкренең! Авылда берәрсе авырып-нитеп куйса, беренче башлап зарларын мулла-мәзингә түгел, Бөкрегә сөйли торган булдылар. Тыңлый «табип», кинәше өчен аз да түгел, күп тә түгел, бер чирек ачы бал яки бер шкаллек көмешкә ала.

Боларның барысының авырлыгы бүтән беркемгә дә түгел, Габбас муллага төшә. Эчү өянәге кузгалмаган булса, Гафият бүген аның янында булыр иде, мулланың хәсрәт-кайгысын уртаклашыр, атын җигеп, юлга чыгарга әзер торыр иде... Юк бит, юк, юньсез!

Габбас мулла, эче пошудан нишләргә белмичә, кучкардагы җиделе лампаның утын көчәйтә төшеп, кулына Коръән алды. Ләкин зиһенен күпме генә җыярга тырышмасын, Коръән битендәге хәрефләр никтер мәгънәле сүз булып оешмыйлар, хатынының бала таба алмый интегүе, иң кирәк чагында хезмәтчесе Гафиятнең каядыр чыгып югалуы аның җанын үртәп тора иде. Өстәвенә, Гафиятнең теге чакта Ычтапаннардан кайткач әйткән сүзләре, янә дә исенә төшеп, йөрәгенә үткен хәнҗәр булып кадалды. Карт хатынга өйләндең, имеш. Җамалетдин хәерченең ундүртенче баласы, имеш!

Язмышың шулай булгач, ни хәл итмәк кирәк. Берәүнең дә тәкъдирдә язганны әйләнеп уза алганы юк әле. Мулла булам дип ашкынып тора идемени Габбас? Иш-Буби мәдрәсәсендә укып чыккач, ул бит Зартугайда калам дип тә черәшмәде. Казакъ даласына мөгаллимлеккә китеп барды. Барган җирендә яраттылар аны, өрмәгән җиргә утыртмадылар. Гадилеге, юаш холкы, аракы вә тәмәке ише хәрам нәрсәләр белән булашмавы, Коръән чыккан чакларда күңел кузгаткыч моңлы, матур мысыр мәкаме казакъ картларына бик тә ошый иде. Алар аны гомер бакый үзләрендә калдырырга, өйләндереп, йортлы-җирле итәргә дә ризалар иде. Тик... менә аларның согындыру дигән гадәтләре теңкәгә тия. Җиңнәрен терсәк тиңентен сызганып куйган казакъ агае агач табактан иң зур, иң майлы калҗаны уч тутырып ала да, Габбас мөгаллимнең авызына тыгып җибәрә. Мәдрәсә елларында ачлы-туклы яшәүдән эче көйгән, җелеге кибеп беткән шәкерт, майлы сарык итеннән үтләп, эче авыртуга түзә алмыйча, атна буе интегә. Анысы узып китәргә өлгерми, икенче урынга ашка чакыралар... Интегү бер хәл, аның өстенә бу фани дөньяда сагыш дигән тойгы да бар бит әле. Иш буйлары, пароход тавышына күмелгән Кама дәрьясы, син уйнап үскән болыннар, Тугыз буй урманнары... Юк, аларны онытырга мөмкинмени?.. Туган-үскән якларын үләр чиккә җитеп сагыну аны казакъ иле белән саубуллашып, янә дә үзе укып чыккан Иш-Бубига кайтып төшәргә мәҗбүр итте.

Нияте — халыкка аң-белем таратып, дөньяга мәгърифәт нуры сибеп яшәү иде. Ләкин син уйлаган белән генә түгел икән шул. Дөньяда Габделхәлим абзаң бар әле — Саранбайлар сәүдәгәре. Ул әнә синең алгы көнеңне матуррак итеп күрергә тели. Зартугайның икенче мәхәллә мулласы Гыйматдин вафат булган. Хаҗга барган җирендә, Мәккә белән Мәдинә арасында. (Ярабби, авыр туфрагы җиңел булсын!) Хәз-

рәтнең кырык ике яшьлек хатыны — Шәмсениса абыстай тол калган. Үзе тулып пешкән чибәр, үзе укымышлы, үзе череп чыккан бай, житмәсә, бала-чагасы да юк икән. Гыйматдин мәрхүмнән кара туры айгыр, ике бия, абзар тулы мал-туар, төлке толып, чарлаклап салынган алты почмаклы йорт торып калган...

— Менә синең, менла кем Габбас, рәхәткә тиешер көннәрең! — диде кызыл малчы Габделхәлим абзый.— Сасы мажик балалары белән мәдрәсәдә тынчып ятканчы, Гыйматдин хажиның варисы итәм мин сине, Түбән мәхәлләгә мулла итеп куйдыртам!

...Габбас, буран тавышы ерагайган арада, аскы өйдән килгән тавышларга колак салгалап, тыңлашып торды. Бик ерактан, әллә кайлардан килгән кебек булып, ыңгырашкан тавыш кына ишетелә, бала елаган тавыш ишетелми иде.

Габбасның үлеп тә шул яшь тавышны, дөнья ярып кычкырган бала тавышын ишетәсе килә. Тулгак өянәгеннән бөгәрләнгән Шәмсенисаны, башыннан сыйпап, юатасы килә. Шул бала дөньяга килсә, ул Шәмсенисаны ярата башлар кебек тоя иде. Көнчеленнән ул аны үз итә, аның ике баладан берсез калган чакларын, нәүмиз чакларын кызгана; никахлашкан елны Шәмсениса абыстайның, яшь мулла алдында чибәррәк, яшьрәк күренергә тырышып, иң матур калфагын, иң матур күлмәкләрен киеп, исләмайның иң кәттәсен сөртеп, гел дә менә ярарга тырышып йөргән көннәрен көнчеленнән кичерә; бала күтә-күтә тәкате калмаган Шәмсениса, тап-таза хатын, төннәрен яшь мулланы шашар чиккә житеп иркәли, кайнар тыны белән иренең муенын пешерә-пешерә, иң татлы, иң газиз сүзләрен пышылдый...

Шәмсениса остабикә буйга узгач, Габбас аңа йорт эшен дә эшләтмәскә тырышты. Киндерне авыл кызларыннан өмә ясап суктырды; бодай юып киптерү, каз-үрдәк өмәләрен абыстайдан сабак тыңларга йөргән кызлар башкарып чыкты. Каралты-кураны, мал-туарны Гафият карады, Гафият чыгырдан чыгып йөргән чакларда, атларга башакны Габбас үзе болгатып бирде, сыер абзарын үзе җыештырды, тумыштан крәстиян баласы булгангадыр, бу эшләр аңа бер дә авыр тоелмый иде.

Ат карауччы итеп Бөкре Гафиятне алган икән, ул аны эш эшли алмаганнан яки эшләргә гарьләнгәннән түгел, Сөләйман хәзрәт алдында абруен төшерергә теләмәгәннән генә алган иде. Мулла булсаң мулла бул — хезмәтчеләрең янында булсын!

Габбасның канына тоз салган, бертуктаусыз каныккан икенче кеше әнә шул Югары мәхәллә мулласы Сөләйман иде инде. Гыйматдин хажиның сәфәрдә үлеп калганын ишеткән сәгатьтән башлап, Сөләйман хәзрәт мәрхүмнең барлык мал-мөлкәтен көнчеленнән үзенеке янына кушып куйган, казакъ ягыннан кайткан йолкыш бер мөгаллим ул хәзинәгә нәфсесен сузар дип башына да китермәгән иде. Мөгаллим кайтты, барлык мөлкәткә ия булды, Сөләйман хәзрәт аңа карата көнчелендә зур бер төен төйнәп куйды.

Ул аны указлы мулла иттермәде.

Гомеренең азагына тикле ул аны указсыз килеш чиләндерәчәк.

Аш мәҗлесләрендә очрашырга туры килгәндә Сөләйман хәзрәт аңа булган дошманлыгын яшермн, бәхәсләрдә җиңеп чыгарга, сүз куерткаида кимсетергә тырыша иде. Ул үзенең Югары мәхәлләдә егерме елдан артык мулла булып торуын, эфисәр улының Алабугада патша хәзрәтләре кәнсәләрендә зур урын биләвен әйтеп мактанудан тыелып кала алмый, яшь һәм сабырсыз Габбас мулла андый чакларда: «Ә шулай да син, Сөләйман абзый, мактанчык һәм шыр надан!» — дип ярсынып уйлый иде.

Габбас туачак баласының малай булуын тели, ул хакта остабикәгә әйтми, әмма дә аның малай булуы Сөләйман хәзрәтнең бер өстенлеген киметү өчен дә кирәк иде.

Көтеп-көтеп тә сөенеч хәбәрен ала алмагач, пошаманга калып, Габбас аскы катка төшеп менәргә булды. Бохар чалмасын башыннан салды, чапанын чөйгә элде. Аягына киез итек, башына колакчын бүрек, өстенә тышлы тунын киде. Өстенә киенә башлау белән чамасыз дулкынлануын сизде: тунының төймәсен төймәли алмый аптырап бетте. Ниһаять, төймәләде. Ишекне ачып җибәрүгә бусагадан уң аяк белән атлап чыкмавы исенә төште. Мәдрәсәдә аны ишектән уң аякны атлап чыгарга, эшлисе эшне бисмилла әйтеп башларга өйрәткәннәр иде.

Чоланга чыгуга колагы буран тавышыннан шаулап тора башлады. Болдыр култыксасына тотына-тотына, аска төшә башлады. Буяулы култыкса кулны өшетерлек суык иде. Башта, тыңлаша-тыңлаша, акрынрак төште, тавыш-мазар ишетелмәгәч, адымнарын кызулатты. Аскы өй ишегенә килде, ишеккә колагын куеп тыңлады, анда ыңгырашу тавышы да, бала тавышы да юк, хатын-кызларның мекер-мекер сөйләшкәннәре генә ишетелә иде. Бөтен бер гомер булып, мәңгелек булып тоелган газаплы бер мизгелдән соң, ул ишектән аерылды, сулышы кысканын, йөрәге борчулы типкәнен тоеп, чолан ишегенә килде. Караңгыда кармаланып, башта өске келәне ычкындырды, аннары аратаны алды. Кинәт китереп бәргән буранлы җил аны ишеге-ние белән тышка йолкып атты, яка арасына «ә» дигәнче юеш кар тутырды, сулышын каплады. Ул тунын башыннан ук бөркәнеп, иелә төшеп, давыл белән көрәшә-көрәшә, лапас ягына таба китте.

Биредә аулаграк. Әмма җил тавышы өй эчендәгегә караганда ун мәртәбә көчлерәк иде. Бик кысталган иде — йомышын йомышлап кире борылды. Аяктан егып атарга теләп, аңар тагын дәһшәтле җил, юеш буран ябырылды...

Ә бит ул баш баласының дөньяга килер көнен ничектер кояшлы итеп, чалт аяз итеп күз алдына китерә, яки су кебек чиста ай яктысы булырга тиеш дип гоман кыла иде. Син теләгән белән генә түгел икән шул...

Чолан ишеген көч-хәл белән бикләп, югарыгы катка менеп барганда, болдырдан ашыгып төшүче берәүгә килеп бәрелде.

Караңгыда хатын-кыз тавышы:

— Хәзрәт... син түгелме?— дип каушап дәште.

— Көмеш түтәй, синме?

— Мин бу, бәбкәм...

— Шәмсениса бәбәйләдеме әллә?

— Кыз бала тапты.

— Кит аннан! Ай, син карале! Һи! Сөенчесенә ни бирим? Миңа керергә ярыймы инде?

— Ярый, хәзрәт. Сине алмага менгәнием. Җоласы бар бит...

Габбас мулла, җылы итеп ягылган һәм тымызык төче ис белән тулы аскы өйгә килеп керүгә, тамак төбенә утырган җылымса куе һавадан ишек төбендә туктап калды. Сәке ягына күз төшерде. Анда, өстенә ак җаймә бөркәнеп, йөзе көл кебек агарган, күзләре йомык хәлдә, Шәмсениса ята; кендекче Сафура, чытыр ак яулыгын артка чөеп бәйләгән карчык, кып-кызыл тәнле яңа туган баланың шапылдатып артына суга иде. Чарылдап кычкырып җибәргән тавыш Габбасның җанын айкап алды. Өстендәге тунын салырга да онытып, ул нәние янына таба китмәкче иде, кендекче Сафура, терсәк тиңентен сызганып куйган кулын селтәп:

— Өстеңне сал, өстеңне сал, кулыңны мичкә куеп җылыт!— диде.— Без сиңа уенчык түгел, диген, кызым. Без сиңа тере кеше. Көмеш түтәй, балны китер. Яле, балакай, кабып кара әле дөнья нигъмәтен. Менә шулай, бал кебек тәмле телле бул. Инде май кабып карыйк, май кебек йомшак фигыльле бул, әти-әниеңә бәхет алып кил! Инде бераз ачысыннан да татып кара, югыйсәм, җебеп төшкән әлләзи булырсың...—

Кендекче балага тоз каптырды бугай, сабый акырып ук җибәрде. Морҗа буенда кулын җылытып торган Габбас, эшләр алайга киткәч, түзмәде:

— Син нәрсә, Әбуҗаһил, сихер белән шөгыльләнәсең?! — дип, кызы янына атылды.

Сафура карчык кендекче булып узган озын гомерендә төрлесен күргән иде — каушамады, каударланмады, йомшак кына сөйләнүен белде:

— Син, әтием, бик шаулама әле, яме. Мәле, шушы канат белән кызыңның башыннан сыйпа әле. Әйбәтләп сыйпа, менә шулай. Канатлы булсын кызың, сазаган кыз булып өйдә утырып калмасын. Я, атын кем дип кушабыз?

Кыз бала көтмәгән Габбас ни дип әйтергә дә белми тотлыгып калды. Сәке ягыннан Шәмсениса абыстайның хәлсез тавышы ишетелде:

— Нурия булыр...

— Нурия! Нурия! Нурия! — дип, чигә тамырлары сулкылдады Габбасның.

— Нурия! Нурия! Нурия! — дип йөрәге тасырдап типте. Томырылып, туймастай булып нәниенә карады. Күңеленнән: «Кара чәчле. Минеке төсле бөдрә булыр», — дип куйды. Сабыйның күзләре йомык иде, эти кеше кызының күзе ни төсле икәнен белә алмады. Бала янә дә ныгытып елый башлагач, Габбаска китәргә ым кагып, баланы әнисе янына имезергә салдылар.

Габбас мулла, тунын кияргә онытып, чыгып китте.

Чолан салкыны аның күлмәкчән генә тәнен өтеп алды. Ләкин ул түбән өйгә кабат керергә батырчылык итмәде. Йөгереп диярлек югарыгы катка менде. Җиделе лампаның яктысы аңар бик зәгыйфь булып тоелды. Ул утызлы лампаны кабызып, аны өстәл турысына төшерде дә өстәл янына утырды.

Каурый каләмне кара савытына манды, вәкарь белән ашыкмый гына яза башлады:

«1901 сәнә, 17 гыйнуар, җомга көн, иртәнге сәгать алты. Кызым Нурия туды. Гасыр башында. Бәхетең белән, төкле аягың белән, балам!»

Ак кәгазь өстендәге зәгъфран караның кипкәнен көтеп, беркавым тың гына утырды. Бите буйлап аккан яшь тамчылары сумаладай куе сакал-мыегы арасында югала бардылар.

Аннары ул, башын өстәлгә салып, тавышсыз гына, мул яшь түгеп, елап җибәрде.

## II

Адәм баласы теләксез, дөнья җил-давылсыз тора алмый.

Шәмсениса абыстайның Габбас белән никахлашканда күңелендә туган теләге бер генә иде: «Тупырдап торган бер бала табып бирсәм иде...» Бала аңа ире белән үзе арасындагы яшь аермасын сиздермәү өчен дә, яшь һәм дәртле Габбасны үзенә каратып, бәйләп тота алу өчен дә кирәк иде.

Ничәмә айлар ул әнә шул теләк белән яшәде.

Касыгында зәгыйфь кенә тибешне тойган сәгатьтән алып, аның яшәү мәгънәсе шул бала хакында уйлауга китте. Ул аның исән-сау туууын теләде, гарип-гораба булмагае дип ут йотты. Аның өчен малай тамы, кызмы — барыбер иде.

Бала туды, кыз булып туды, әтисенә охшап туды, әмма шактый ук зәгыйфь булып, көчсез булып, авыру бала булып туды.

Шәмсениса абыстайның күңелендә түземсез яңа бер теләк кабынды. Исән калдыру! Исән калдыру! Нурияне исән калдыру өчен, Габбас бе-

лән икесен бер бөтен итеп кушып куйган шул сабыйны исән калдыру өчен ни генә эшләмәде Шәмсениса. Бала караучы Миңлекамалга күз яше белән ялварды:

— Берүк баламны күз уңыннан ычкындыра күрмә. Ни телисең, шуны бирермен! Алтын-көмешкә, атлас-җефәккә күмәрмен. Сакла баламны, Көмеш түтәй, сакла, кеше ит!

Балага ипи чәйнәп имезлек салдырмады. Күкрәк сөте имезде. Яшь сыер сөтен марлядан сөзеп, боламыкны үзе пешереп ашатты.

Төннәрен бала елаганны ишетсә, йөрәге туктар дәрәҗәгә җитеп, сискәнеп уяна торган булды.

Ходаның бирмеш көне, икенде белән ахшам намазында, тәңресенә ялварды:

— Йа раббем! Мәрхәмәтеңнән ташлама, без фәкыйреңне олыгаймыш көнебездә күз нурыбыздан аерма. Мең газап белән тапкан баламны гомерле ит, акылын бөтен, башын зиһенле ит. Җамалетдин углы Габбасның күңеленә йомшаклык индер, баласына ягымлы булсын. Йа раббем, мәрхәмәтеңнән ташлама...

Габбас мулла Шәмсенисаның бертуктаусыз, берөзлексез тәңрегә ялваруын ишеткәч, хатынын кызганып, аңа карата ягымлырак булырга, кызын кулына алган чакларда озаграк иркәләргә тырышты.

Шәмсениса абыстай, моны күреп, тыны-көне бетеп сөенә, әмма, сөенечен берьюлы түгеп ташламас өчен, көне буе басынкы йөри иде.

Нурия тәпи басып йөри башлаганнан алып курчак яратты. Башта әнисе алып биргән, Габделхәлим абзый китергән курчакларны күтәреп йөртте; йомшак фигыльле, базда үскән бәрәнге сабагы төсле ак чырайлы Нурия урамга чыкмый диярлек; көннәр, атналар, айлар буе түр тәрәзә каршысында курчаклары белән уйный: ул аларны тезеп утырта, аларга әнисе тегеп биргән матур күлмәкләрен киертә, барысын бергә тезеп йоклата, шулар белән беррәттән үзе дә чайкап йоклап китә; мондый чакта читтән кергән кеше аларның кайсы курчак, кайсы тере бала икәнен дә аера алмас иде. Нурияне әнисе курчактан ким киендерми иде.

Йокы аралаш Нурия ягымлы, көйле бер тавыш ишетә:

— Алтын кубәләгемдер шул. Былбыл-гөлемдер шул. Арып киткән булган бит. Шөгыльләре бигрәк күп булды шул аның...

Бу тавыш аның күңелендә әллә ниткән дөньялар тудыра: йомшак канатлары белән сыйпап, зәңгәр болытлар янына алып чыга, урамнар буйлап йөртә. Менә кыңгыраулар зыңлаган тавыш ишетелә башлый, әкрен генә ишетелә, ерактан...

Шул тавышка Нурия күзен ача.

Аяклы көзге каршысына бастырып, Көмеш түтәй аның чәчләрен тарый. Эчке бүлмәдән Шәмсениса абыстай чыга. Бала итәкле яшел атлас күлмәктән, бикасап камзулдан, чәмчәле, биек үкчәле читекләре белән шыкы-шыкы басып, ул Нурия белән Көмеш түтәй янына килә, Нуриянең җилкәсенә таралып төшкән шомырт кара дулкын чәчләренә сокланып карап тора, ак яулык эченнән энҗеле кызыл калфак алып, Нуриянең баш түбәсенә кадап куя.

Кыңгыраулар отыры якыная. Ат караучы Гафият урам капканы каерып ачып җибәрә. Ишегалдына, бер-бер артлы, җигүле өч ат килеп керә.

Шәмсениса абыстай белән Көмеш түтәй, урам як тәрәзәгә ябырылып, кем килгәнен карыйлар.

Нурия болдырга йөгереп чыга.

Арбаларда яшел печән, печән өстендә ак калайлы сандыклар, талдан үреп ясалган әрҗәләр.

Дегет исе килеп торган зур күн итекле, сакал-мыеклы Габделхәлим абзый Нурияне кулына күтәреп ала, аның калфагын, күлмәген, үзен мактый.

— Гарифулла бабай, кызыма дигән кызыл билле прәннек кайда әле? — дип, ак сакаллы бабайга дәшә.

Ак сакаллы бабай, аңа уч тутырып кызыл билле прәннек бирә, Нурия аны күлмәк итәгенә салып өйгә йөгерә.

Өйдәгеләр ах-вах киләләр:

— Кай арада чыгып киткән бу? Ничек күрми калдык? Суык тисә, күз тисә...

— Мин гаепле, мулла абыстай. Күрми дә калганмын! Менә син тамаша! — ди кәфен кебек агарган Көмеш түтәй.

Ул Нурияне җитәкләп икенче бүлмәгә алып чыга. Нуриянең анда утырасы килми. «Кунак абыйлар янына чыгыйк!» — дип шыңшый башлый.

Нурияне олы якка алып чыгалар. Кызыл билле прәннек биргән абый инде өстеннән юл кәҗәнен салган, башыннан кырпу бүреген дә салган, өстәл янында кара бәрхет түбәтәйдән, кыска җиңле казакидан утыра. Өстәлнең икенче башында ак сакаллы Гарифулла бабай, тырпайган бармаклары өстенә чынаяк тәлинкәсен куеп, чәй эчә. Тәлинкәне ул авызына таба китерә, авызы гел кыймылдап тора. Әйтерсең лә тәлинкәне сулышы белән тартып китерә.

Алты яшьлек Нурия, бармагын авызына кабып, Габделхәлим абзыйга килеп сыена. Тегесе аны тез башына утыртып, кытыршы зур кулы белән аркасыннан сөя:

— Туганым абыстай, соңга калмыйсызмы? Нуриянең колагын тишәргә вакыт түгелме?

— Вакыттыр. Минем колагымны биш яшемдә тишкәннәр ие инде. Җәллләп торам әле менә...— Шәмсениса күтәрелеп Габбас муллага карый.

Габбас мулла өстәл янында селкенеп куя, башындагы чуклы кызыл түбәтәйне ике куллап баса да тоньк тавыш белән:

— Колак тишү — катыннар эше, — ди. Кара бөдрә сакалын учлап, сүзсез кала.

— Шулай дисеңме, хәзрәт?

Кызыл малчы, туганым абыстайның күңеле булсынга, Габбаска шулай олылап, «хәзрәт» дип дәшә.

—Бик мәслихәт, алайса. Аллага тапшырып тиштер син аның колагын, туганым абыстай. Менә мин Нуриягә алка алып килдем.

Габделхәлим абзый, товар саткандагы бер рәхәтлек белән, Шәмсенисага ике бөртек көмеш алка тоттыра. Шәмсениса абыстайның чыраена мул булып сөенеч чыга: күзләре чаткылана, бит алмаларына алсулык йөгерә; аны күзәтеп торган Габделхәлим абзый күңеленнән: «Габбасны үзенә каратып торырлыгы бар әле монын», — дип уйлый.

Нурия барлык балалар кебек үк түземсез. Көмеш түтәйне тинтерәтеп, ул алканы колагына җеп белән тактыра, ләкин Габделхәлим абзыйсына күрсәтергә дип килгәч, колак яфрагындагы җепле алка төшеп китә.

Форсатны ычкындырырга ярамый иде. Шәмсениса абыстай, Нурия алка белән мәш килгән арада, кызының бер колагын тишеп алырга да өлгерде.

Нурия җан ачысы белән чарылдап кычкырып җибәрде. Сәгать буе ярсып елады. Хәзер аның икенче колагын тишүне уйларга да ярамый иде. Әнисе аңа уч тутырып конфет та бирде, яңа курчак та күрсәтеп карады, Нурия якын да килми.

Сабырлыгы төкәнгән Габбас мулла:

— Тинтерәтмәгез баланы, — диде.

Баланы тинтерәтмәскә булдылар.

— Гарифулла бабай,— дип дәште Габделхәлим абзый олау йөртү-

чесенә, — Нуриягә дип без нинди уенчык алып килгән иек әле? Куян баласы алып килгән иек түгелме соң без?

Нурия дөньясын онытты. Шундук куян баласын таптыра башлады.

Гарифулла бабай, ишегалдына чыгып, арбадан тал әрҗәсе алып керде, бөкрәя төшеп, әрҗә өстенә иелде: ак сакал баскан бите кояш кебек балкый иде. Менә ул әрҗәне ачты, мамыктай йомшак соры куян баласын ике колагыннан тотып, югары күтәрде, Нуриягә таба сузды.

Каушап киткән кызый башта тынсыз калды, әкрен-әкрен артка чигенеп, Көмеш түтәйнең итәгенә уралды. Башта әнисе, аннары Көмеш түтәй куян баласының мамыктай йоныннан, колагыннан сыпыргач, ул да шикләнеп кенә куян баласы янына килде, кулын бер сузды да бер тартып алды, куян баласы аңардан курыкмады, тешләмәде, шуннан соң Нурия кыюланды, «тере курчакның» башыннан сыпырды, күзләрен йома төшеп, песи генә булып Гарифулла бабай кулында утырган куян баласын үзенә алды; гүя тартып алуларыннан курыккандай, ике куллап күкрәгенә кысты. Башкалардан яшерде, янәсе. Ул исе китеп, таң калып куян баласына карап торган арада әнисе аның икенче колагын да тишеп алырга өлгерде. Әнисе моны шул хәтле тиз эшләде, Нурия хәтта еларга да өлгерми калды.

...Куян баласы Нуриягә килгән беренче зур газапны — колак авыртуны оныттырды. Иртән йокыдан торганнан башлап, кичен йоклап киткәнгә чаклы, Нурия — куян баласы янында. Ашата, эчертә, ишегалдына алып чыга, куышып уйный. Куян баласына чирәм кирәк, куян баласына тал яфрагы кирәк — Көмеш түтәй белән Нурия су буена, болын тугаена төшеп китәләр, кайчагында яртышар көн йөреп, тамаклары ачыгып кайталар. Кызыйның бите кояштан алсуланды, тәненә ит куна башлады. Шәмсениса абыстайга сөенеч. Курчак онытылды, яңа күлмәк онытылды!

Куян баласына Сорыкай дип ат куштылар. Сорыкай казна астына кереп китә, сәгать буе чыкмый утыра. Нурия, нәүмизләнеп, аны көтә, аны чакыра... Сорыкайдан да якынрак тагын кем бар?..

Җомга көнне Габбас мулла белән Шәмсениса абыстай, тарантаска утырып, ашка киттеләр. Шул көнне Сорыкай Нуриягә күңелсезлек ясады. Идән астына төшеп китте дә менәргә теләмәде. И чакырдылар, и чакырдылар. Башта Нурия чакырып утырды, аннары Көмеш түтәй, идән астының капкачын ачып, идәнгә озын итәкле күлмәге белән җәелеп утырып, башын өй астына таба сузып:

— Сорыкай! Чык инде, гөлкәем, Нуриягә күңелсез бит. Синең үзеңә дә караңгыда ни рәхәт бар инде, я? — дип, көйле тавышы белән сөйләнде, ялварды..

Куян баласы менмәде.

Шуннан соң ике сабый — алты яшьлек кыз белән алтмыш яшьлек Көмеш түтәй, ярдәм сорап, күршеләре Нәүширвән бабайларга керделәр.

Нәүширвән бабай бик карт, туксаннарда. Колагы ишетми. Ләкин әле ул гомерлек гадәтен — балта остасы булуын ташламый. Читәнкоймасын төз тота, җәен, балта осталары белән бергә, кешеләргә бура бурашырга да чыга. Дөрес, ул башкалар кебек җир җимертеп эшли алмый, әмма үзенең озын гомерендә җыйган зирәк акылы белән киңәш бирергә бик оста.

— Нәрсә, Миңкамал, сагындыңмы әллә? — диде ул мулла кызын кулыннан җитәкләп җил капкадан килеп кергән Көмеш түтәйгә.

— Сагындым шул, сине күрмәсәм, мулла йортының бер почмагы гел дә менә кыек,— дип, саңгырау Нәүширвән бабай ишетсенгә түгел, үз күңеле булсынга сөйләнеп куйды Көмеш түтәй. Авызын яулык белән капламады, туксан яшьлек картны ул инде ирләр чутыннан сызган иде.

Нәүширвән картның калын чал кашлары очынып югары күтәрелде, әле нуры качмаган яшькелт күзләре мутланып елмайдылар:

— Нәрсә дисең, мулланың күркәсе талады дисеңме?— Ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде, бүкән өстенә куеп юна башлаган себерке саплыгын, янәшәдәге тавыкларны куркытып, йомычка өеменә ыргытты. Үзе, кулын киндер алъяпкычы итәгенә сөртә-сөртә, бүкәнгә килеп утырды.

Нурияне үз янына чакырды. Тегесе килмәде, Көмеш түтәйгә карап кына алды да аның күлмәк итәгенә уралды.

Келәт астыннан «Ко-ко-ко!» дип кукраеп зур кара әтәч килеп чыкты, бу нинди кунаклар тагын дигәндәй, кызыл калфак төсле кикриген кыңгырайтып, энҗе күзен тасрайтып ачып карап торды, бәйләнүче булмагач, аллы-гөлле койрыгын югары тотып, эре генә китеп барды, өй нигезендә комда коенган тавыкларның берсен кычкыртырга тотынды.

Шул әкәмәтне күреп торган Нурия чыркылдап көлеп җибәрде. Аңар ияреп Нәүширвән бабай да көлде.

— Куян баласы өй астына төшеп китте...— диде Көмеш түтәй, картның бик җәелеп утырырга теләвен күреп.

Нәүширвән бабай кулын колагына куйды:

— Нәмәстә дисең?

— Салагыш базарында колак саталар, дим.

— Калак саталар? Нинди калак? Көймә калагымы?— Картның күзләре янә дә мутланып елмайдылар.

Нурия, түземлеге бетеп, Нәүширвән бабай янына йөгереп килде, аның колагына үрелеп, куян баласы турындагы гозерен әйтеп бирде.

Карт аның чатылдатып әйткән сүзләрен бөтен бите белән, сакалын селкетеп тыңлады, аннары әйтте:

— Син, кызым, болай ит: Миңкамал корткага әйт, идәнгә җәелеп утыр да кулыңны чәбәкләп тор, әби, диген. Куян баласы шуннан соң идән астыннан үзе йөгереп менәр.

— И-и-и шушының бер! Гомергә акыл кермәде. Аңа сөйләп торган без тиле!— дип, Көмеш түтәй кулын селтәде. — Киттек, кызым, әйдә.

— Туктале, Миңкамал, бик чәпчемә әле син,— диде Нәүширвән бабай,— мулла йортын каравылларга өлгерерсең әле...

Ул гомер буе Көмеш түтәйгә тыныч карый алмый иде. Үз аягы белән килеп кергән сөенечне тиз генә кайтарып җибәрәсе килмәде.

Көмеш түтәй кыбырсый башлады:

— Ярар, Нәүширвән, күзеңне бик очлайтма, телеңне чарлама. Озак юанмыйк. Кеше-караның әллә ни уйлавы бар. Күршеләрдән уңайсыз,— диде.— Уен-муен эш түгел бу сиңа...

Нәүширвән бабай кортканы таң калдырып:

— Ийе шул, уен-муен түгел, чуен муен, — дип елмайды.

Менә шуннан соң колакка каты дип йөр син аны, хәйләкәрне!

Нәүширвән карт, тап-такыр итеп себерелгән лапасның аргы башына ук барып, уенчык алып килде, аны Нуриягә тоттырды:

— Менә сиңа, мәхдүмә, канатлы кош, бераүгә дә бирмә, яме.

Уенчык тәгәрмәчле, тәгәрмәч өстенә нинидер кош кунаклаган, тәгәрмәч әйләнгән саен, кош канатын җилпеп, шап-шап сугып бара.

Нурия канатлы кошны лапас буйлап тәгәрәтеп алып китте. Бу минутта аның өчен куян баласы да, кара-каршы басып сөйләшеп торган Нәүширвән бабай белән Көмеш түтәй дә юк, канат чәпелдәтеп тәгәрмәчләр өстендә талпынып баручы зәңгәр кош кына бар иде...

Тагын бер атнадан, офык читенә аккош мамыгыдай ак болытлар өелгән, зәп-зәңгәр күк йөзеннән кояш балкып карап торган беркөнне, әтисе белән әнисе Нурияне тегермән буасы янына алып төшәргә булдылар. Көмеш түтәй өй сакларга калды.

—Көмеш түтәй, әбекәй! Сорыкайны әйбәт кара, яме. Идән астына төшермә. Мин сиңа чәчәк җыеп алып кайтырмын,— диде Нурия.

— Ярар, бәбкәм, ярар, гөлекәем. Бик әйбәтләп карармын. Идән астына да төшермәм, ишегалдына да чыгармам. Бер дә генә борчылма, бәбчеккенәем,— дип озатып калды аларны Көмеш түтәй.

Нурия сүзендә торды, чәчәкне күп итеп җыеп алып кайтты. Көмеш түтәй сүзендә тормаган, куян баласын әйбәт итеп карамаган иде.

Иң элек шунысы мәгълүм булды, алар кайтканда Көмеш түтәй, алъяпкыч итәге белән битен каплап, сәке йөзлегендә елап утыра иде. Нурия аның янына йөгереп барды.

— Әбекәй, ник елыйсың? Елама. Мин бит сиңа чәчәк алып кайттым!! — Ике куллап тоткан чәчәк бәйләмен Көмеш түтәйгә сузды.

Көмеш түтәй елавыннан әле һаман да туктый алмыйча, алъяпкыч итәге белән күзен сөртә-сөртә, борынын мышкылдатып:

— Бигрәкләр дә көтмәгәндә булды шул, балам. Намазга оеп кына киткәнием, кулыма сикереп менүе булды, сискәнеп, кулымны селтәп җибәрүем булды. Мәче булса, селтәмәгәен, ыргытып бәрсәң дә сырты белән төшмәс ие, мәче түгел шул, куян заты шул, бигрәкләр дә аңгыра беркатлы сабый шул, сырты белән идәнгә килеп төште дә тынсыз калды. Ни хәлләр итим, бәбчеккенәем, гөнаһлы булдым, көпә-көндез, күрәләтә торып җан кыйдым... — дип, тагын да ныграк үксеп елый башлады.

Нурия еламады. Үлем дигән нәрсәнең фаҗига икәнен ул әле белми иде. Бер почмакка кереп утырды да сәгатьләр буе дәшмәде.

Ул, күрәсең, башка дөньяда яши иде.

Кичен куянны югарыгы бакчага алып менеп күмделәр.

Габбас мулла көрәк тимеренә кәвеше белән басып чирәмле җирне каерып алды, тирән итеп чокыр казыды, чокыр төбенә кабык салды, кабык өстенә куянның мәетен куеп, янә кабык белән каплады, аннары чокырны күмде. Күмеп бетергәч, күтәрелеп Нуриягә карады. Нурия хәрәкәтсез басып тора, баш бармагын авызына капкан, күзеннән мөлдерәп яшь ага иде.

Кояш баеган иде инде, тик әле җир өстенә караңгы инмәгән, умарта өйләрен каплап торган сәрби куаклары, шулар янында озын булып үскән зифа ак каен, мунча буендагы кара-кучкыл шомыртлар, кичке эңгердә тоныкланып, моңсу булып күренәләр иде.

Габбас мулла, кызын кулыннан җитәкләп, кайту юлына борылды. Нурия башын игән, берсенә дә күтәрелеп карамый, һаман да әле бармагын авызына капкан килеш, әкрен генә кайта иде.

Дөньяның гаделсезлеген тою адәмнәр күңелендә шулай башланадыр инде.

Кайдадыр, Бояр урманы ягында бугай, күке кемнеңдер гомерен саный, югарыгы бакча куакларында сандугачлар чутылдаша. Габбас мулланың дөнья куып, күптән инде кошлар чыр-чуын тыңлаганы юк иде. Кызын җитәкләгән килеш, ул акрын гына кайтты.

Көне буена кояш нурында коенган бәрәңге сабакларыннан үзенә хас ачкылтым-җылымса ис килә иде.

Алар артыннан сүзсез генә ияреп йөргән Шәмсениса абыстай, тизрәк өйгә кайтырга ашыктыра башлагач, Габбас мулла юаш кына итеп:

— Йөрик әле бераз. Сәйранга чыккан юк бит, — дип куйды.

Шәмсениса да, алар белән тигезләшеп, кызын җитәкләде.

Өчәү бергә кичке бакча юлыннан бик озак йөрделәр.

Күрше Нәүширвән картларның бакча буендагы ялгыз ике нарат алсу-сары һавада каләм-кара белән сызып куйган төсле аермачык булып күренә иде. Зартугай кайчандыр кара урман эчендә булган, иген игәр өчен төп төпләп гомер буе интеккән дип сөйлиләр. Аерым кеше-

лэрнең бакчасында берэм-сэрэм калган карт наратлар, йөзэр еллык чыршылар шул заманнарның истэлеге, имеш.

Габбас мулланың күңеле эйтеп бетергесез моңсу иде. Аның кулыннан бэлэкэй кулы белэн тотып барган боек күңелле Нурия дэ, сэгатьлэр буе сүзсез йөргэн Шэмсениса абыстай да аның гаилэсе түгелдер, болар таң алдыннан керэ торган рэхэт һэм җиңелчэ бер төш кенэдер кебек тоела иде.

Габбас муллага нидер җитми, алсу офыктагы каралҗым наратлар да, еракта тоташ стена булып күренгэн Бояр урманы да эллэ кайлар-да, күгелҗем томаннар аръягында калган бала чакның серлэрен саклаучы, сагышларын көчэйтүче җанга газиз нэрсэлэр булып тоелалар. Мэңге кайтмас яшь гомер җанда үксеп елый иде.

Алсу офыкны, каралҗым наратларны, кошлар чыр-чуын тоташтырып, Тэкыймулла мэзиннең сузып-сузып азан эйткэне ишетелэ башлады.

## III

Шэмсениса абыстай хафага калды. Нурия боек, Нурия сөйлэшми, курчак тэтилэре белэн уйнамый. Вакыт-вакыт саташып, куркып уянгалый. Төшендэ мэрхүм куян баласын күрми микэн? Бигрэк нечкэ күңелле булып чыкты бу бала. Көмеш түтэйдэн җаны бизеп куйса? Башка сыймаслык хэл. Миңлекамал бит бөтен гомерен аларда уздырды, кияүгэ чыкмый картайды. Җаны бизсэ — эш харап. Гыйматдин хэзрэт заманыннан бирле аларда яши бит ул. Аңардан да гадел, аңардан да турылыклы, балага ягымлы асраучы тагын каян табасың. Энэ бит, мал-туар яратканы өчен дип, Габбас сэрхуш Гафияткэ дэ түзеп тора.

Шэмсениса абыстайны борчулы уйларыннан янэ дэ Габделхэлим абзыйсы килеп коткарды.

Печэнгэ төшэр көннэр якынаеп килэ, Зартугай халкы ашыга-ашыга чалгы саплый, тырма ясый, тэкэ симертэ; кыз-кыркын ак алъяпкычлар тектерэ, елтыравыклы кэвеш ала, кэвеш алырга рэте булмаганы чабатаны тугызлыдан, унберледэн үрдерэ; тула баса, киндер бэлэкли, көннэр буе инеш басмаларында бэлэк суккан тавыш ишетелеп тора; башка чакта иртэ-кичен гомерлек көтүче Лэлек мамык чыбыркының иртэлэрен, быргы кычкыртып, курай уйнап, көтү җыйганы ишетелсэ, хэзер инде инеш буйларыннан киндер бэлэклэгэн, җыйнаулашып, Чуртанкүлдэн мунчала чыгарган тавышлар ишетелэ.

Печэн өсте — Габделхэлим кебек кызыл малчыга лафа вакыт. Калайлы сандыкларда шыплап тутырган ситсы, сатин, ефэк. Талдан үргэн эрҗэлэрдэ пыяла муенса, кара йөгерткэн белэзек, чулпы бавы, зэңгэрле-кызыллы тасмалар. Кыз-кыркын энилэренең эчкэрге янчыкларыннан акча таптыра, акчасы булмаганы дистэсе белэн күкэй күтэреп килэ. Гарифулла бабай белэн икесе җигүле атларны печэнгэ кушып, каравыл өе янындагы мэйданда Габделхэлим абзый сэүдэне гөрлэтеп җибэрэ.

Кичен кояш баегач, бушап калган бер арбаның сандык-эрҗэлэрен сүс бау белэн ныгытып бэйлэп, Габбас мулла йортына килеп туктадылар.

Сары буяулы урыс капканы Гафият ачты.

Габделхэлим абзый арбадан җиңел генэ сикереп төште, дилбегэне Гафият кулына ыргытты.

— Саумы, Гафият! Мулла өйдэме? Туганым абыстайның кэефе ничек?

Гафият, ямьшэйгэн соры киез эшлэпэсе астыннан сэүдэгэрнең тук һэм якты чыраена сөзеп карап, каты төк баскан, кырынмаган иңген сыпырып куйды:

— Яшь мулла кәефсез. Син китергән куян үлде. Бәләкәй мәхдүмә көйсезләнә, — диде.

«Моның сәрхушлек өянәге кузгалыр чак җиткән шай, чырае бик караңгы», — дип уйлады Габделхәлим абзый, Бөкренең сүзләрендәге мыскылчанлыкны сизмәгәнгә салышып әйтте: — Тот дилбегәне, тугар атларны. Су эчерми тор, ишетәсеңме? Божрага бәйләп тот бер сәгать, аннары сугарырсың. Буш итмәм, яхшы кара атларны.— Аннары олаучысына күңелле итеп дәште: — Мәхдүмә көйсезләнә диме? Яшь мулланың хәсрәте бар диме, хе-хе-хе. Габделхәлим барында көйсезләнә алмаслар!— Юл кәҗәненең чабуларын җилфердәтеп, күн итекле аяклары белән каты-каты басып, болдырга таба китте. Бу юлы олаучысын өйгә чакырмады.

Мулла йортында аны тыенкы гына каршыладылар.

— Нәрсә, менла кем Габбас, әвенең яндымы әллә?

Габбас мулла кулына тоткан «Сөембикә» журналын өстәлгә куйды, ике куллап килеп күреште. Сүз куертмады.

Йортка килгән кайгыны бик зур итеп, чамадан тыш күпертеп, Шәмсениса абыстай сөйләп бирде.

Габбас мулла, ирене белән мыек очын чәйнәштергәләп, җиңсез кара камзулы өстеннән кулын кушырып, мич буенда сүзсез генә басып торды.

— Мәхдүмә кайда?— диде Габделхәлим абзый җитди итеп.

— Үз ягында. Тамагына капмый. Боекты. Ашаудан калды,— дип,— Шәмсениса абыстай, ситсыны пыртлатып ерткандай, бик кызу сөйләп китте.

Габделхәлим абзый ак йон оекбашы эченә чалбар балагын рәтләп тыкты да өстәл буена килеп утырды. Ашыкмый гына өй эчен: челтәр пәрдәләрне, тәрәзәләр арасындагы чуптарлы сөлгеләрне, матчага буйдан-буйга эленгән эре бизәкле зәңгәр кашаганы, бөтен стенаны тотып торган аяклы сәгатьне, сәке өстендә, идәндә — төрле урында күз явыңны алырдай булып тезелгән шыңгырдап ачыла торган яшел сандыкларны, алтын путаллы көзгене, сырлап эшләнгән шкафны, шкаф тулы кытай чынаягын күздән үткәреп: «Ни тиклем байлыкның хуҗасы иттем. Ул әле мине караңгы чырай белән каршыларга азаплана, мәгънәсез»... — дип, каты күңел белән уйлады.

Шәмсениса абыстай, туганым абзыйсының каршы алуга риза түгеллеген шундук сизеп, ыгы-зыгы килә башлады.

— Нишләп торам соң әле мин чәй әзерләргә онытып? Иң кадерле кунагыбыз килгән, көне буе эш белән йөреп сусап беткәндер. И дөнья, и хикмәт!— Ул биленә алъяпкыч, башына яулык бәйләп, самавыр күтәреп чоланга чыгып китте.

Ул киткәч, Габделхәлим абзый, каты гына тамак кырып, селкенеп куйды.

— Гарифулла бабай сиңа бер әрҗә бирер. Зәмзәм суының җиллесен алып килдем. Чәйнеккә салып чыгарырсың. Сөйләшеп утырырбыз. Төшенденме?

— Төшендем.

— Остабикәне әйтәм, инә хәтле борчуны дөя хәтле итеп сөйләде. Бик нечкәләргә өйрәтмәгез баланы. Дөнья бу. Тагын әлләниләр булыр әле. Үзеңнең хәлләр ничек, менла кем Габбас? Сөләйман хәзрәт бик каныкмыймы?

— Бу арада каныкканы юк, — диде Габбас мулла, Габделхәлим байга рәхмәтле күз белән карап алды. — Вазифамны мин җиренә җиткереп үтим, Сөләйман мулла кебек комсызланмыйм, халыкны таламыйм, үз көнемне үзем күрергә тырышам.

— Үз көнеңне? Анысы ни дигән сүз тагын?

— Халык белән бергә печәнгә чыгарга дип торам әле. Сагындым рәстиән эшен. Яңа чапкан печән исе иснисе килә...

— Напрасны!— Кызыл малчы Габбаска күзенең агын әйләндереп аралы, йонтәс чал кашлары тетрәнеп киттеләр. — Мин сине, мажикар белән печән чабып, сыер койрыгы юып йөрер өченгә мулла итмәем! Бар, алып кер кәрҗинне.

Габбас кәрҗинне алып керде.

— Аулак якка алып чык, — диде Габделхәлим.

Алып чыктылар. Фарфор савытлы ике коньякны Габделхәлим абзый үзе барлап алды.

— Чәйнеккә салып куй берсен, икенчесен шкапка яшер. Корткаларның күргәннән күрмәгәне хәерлерәк.

Көмеш түтәй каклаган каз турап алып керде. Габделхәлим абзый аңар ияреп сөйләнә-сөйләнә кергән Шәмсенисага:

— Туганым абыстай, безнең сөйләшәсе сүз бар. Гаеп итмә, икенче вакытта, бүген хәзрәт белән икәү генә утырыйк әле, яме, — диде.

Шәмсениса абыстай, иренен турсайтып, ана үрдәктәй ава-түнә чыгып китте.

—Дөньялар үзгәрә, Габбас, — диде Габделхәлим абзый, чәйнектән беренче чынаякны агызганда. — Хөррият заманнары килә. Пайтәхеттә, Мәскәүдә чуалышлар бара. Казан нирситетында ыстудиннар гауга куптара. Әтрәк әләмнәр әйтәсе килгән сүзен өендә әйтми, урамга чыгып акыра. Китапны күп итеп басарга, кара халыкны агартырга дип сөйлиләр, завуд-фабрикаларда сигез сәгатьлек эше көне даулап, эш ташлап йөри башлаганнар. Кырмыска оясы кебек болгана дөнья... Тотыйк әле шуны, суынмасын! — Башын артка ташлап, чынаяктагы коньякны бер сулышта авызына койды, «оһ» дип сулышын ала алмый торды, мыек чылгыен җиңе белән сөртеп алып, каклаган каз калҗасын авызына алып капты, озаклап, тәмләп, күзләрен йома төшеп чәйнәде, коньякның чымырдый-чымырдый тамырларга йөгергәнен сизгән хәлдә, талгын рәхәтлеккә бирелеп утырды.

Габбас мулланың коньяк ише әйбер эчкәне юк иде. Ул, моның ни икәнен белмәгәнлектән, чынаяк читенә иренен генә тидереп куймакчы булды, Габделхәлим бай, аның чынаягын кулы белән этеп, көчләп диярлек эчертеп бетерде:

— Син нәрсә, кияү, Габделхәлим сәүдәгәр белән уен уйнарга җыендыңмы? Сиңа, якын итеп, туганыдай үз күреп бирәү килгән икән, олы башын кече итеп алдында утыра икән...

Габбас мулла матур гына, ямьле генә булып башы әйләнә башлавын сизде. Аракы булса, шундук күзне әчеттерә башлар иде. Хикмәти хода, җәннәт җимешеннән ясаганнардыр моны...

— Сәүдәләр барамы соң, Габделхәлим абзый? — диде Габбас, сүзсез утыруны уңайсыз санап.

— Сәүдәләрме? Әмәлен белсәң бара ул, менла кем Габбас. Әмәлен белергә кирәк, хе-хе-хе. Безнең Саранбайларның тиречe Әхмәтҗанны беләсеңме?

— Улы Балтач боярында ат карауч булып тора диләр, шулмы?

— Нәкъ үзе.

— Авыл саен тире җыю кибете ачканые былтыр, шулмы?

— Коеп куйган үзе.

— Соң шул нишләгән?

— Мәскәүгә барып, зар җылап кайткан. «Тиремне алмыйлар, дөрес суймагансың, иң затлы җирен бозгансың, ди икән ярманнан килгән тире җыючы. Инде кая барырга? Син ала алмассыңмы? дип килгән. Алдым. Мәскәүгә сата торганның чирек бәясенә алдым. Өч мең сигез йөз тире алдым. Сизденме минем кесәгә күпме табыш кергәнне!

— Мәскәүләргә ярамаган сиңа ничек ярый соң ул?

— Ә бит ярманнан килгән мимечкә мин әйттереп куйганыем аны. Балтач боярының управләйушшие аркылы әйттердем, Әхмәтҗан тиреченең тиресе бер тиенгә дә тормый, дөрес суелмаган, тирене мин үзем китерәм, уптым китерәм дип әйттердем.

— Мөселман кардәшне кәкре каенга терәтү булып чыга түгелме соң бу? Ходай тәгалә риза булмас бит синең бу эшеңә, Габделхәлим абзый...

— Сәүдә ул шундый шөгыль, Габбас...

— Нинди шөгыль? — диде кәефе киткән Габбас мулла.

— Сәүдәгәрлек борын-борыннан килгән бик тә кирәкле, затлы кәсеп ул, менла кем Габбас. Иканумиканы белмәү аркасында син ялгыш сүз сөйләп утырасың. Әгәр сәүдә булмаса, һөнәрчеләр һөнәрләреннән файдалана алмаслар ие. Ярминкәләр, базарлар шыр бушап калырые. Аучылар атып алган җәнлек тиреләрен өй идәннәренә генә җәеп тотарга мәҗбүр булырларые. Сәүдә ул, менла кем Габбас, әгәренки бик беләсең килсә, кешене хайваннан аерган ике шөгыльнең берсе.

— Икенчесе нәрсә?

— Икенчесеме? Икенчесе — иген игү. Әгәренки иген игү булмаса, адәм баласы, хайван кебек, ялангач йөрерие. Мал-туарын суеп, аның итен чи килеш ашарые. Киндер үстермәсә, мамык үстермәсә, гаурәтен ябарга кул яссуы кадәрле дә нәрсә таба алмасые.

— Элек тапканнар бит.

— Нәрсә тапканнар?

— Кием урынына тире ябынып йөргәннәр.

— Дөрес әйтәсең, аучылык-сунарчылык — адәм баласын хайваннан аерган өченче шөгыль. Коеп җибәр булмаса, күтәреп куйыйк.

— Тукта, мин чәй китертим, — диде Габбас мулла, ишектән башын тыгып, Көмеш түтәйгә дәште.

Көмеш түтәй бу бөркеп торган бәләкәй ак самавырны күтәреп керде, аны, дык итеп, бизәкле кара подноска утыртты, хәзер ак май кертәм, бавырсак кертәм, дип чыгып китте дә хәбәрсез югалды.

— Нишләп озаклады бу кортка, әллә туганым абыстай кертмиме үзен, бар белеш әле, — диде Габделхәлим абзый.

Белешергә чыккан җиреннән мулла бик күңелсез килеп керде. Анда Нурия йокысыннан уянган, көйсезләнә башлаган, Шәмсениса белән Көмеш түтәй икәүләшеп аны юатырга тотынганнар, һич кенә дә юатып бетерә алмыйлар икән.

Габделхәлим абзый сүзсез генә ишеккә юнәлде, Габбас мулла да аңа ияреп чыгарга мәҗбүр булды.

Бик уңайсыз сизеп чыкты үзен Габбас.

Хәмердән авыз иткән булуы, кызының көйсезләнүе, Габделхәлим байның тирече Әхмәтҗанны төп башына утыртуы белән мактануы — болар барысы аның кәефен алган, шуның өстәвенә өч-дүрт олы кешенең бер көйсез кыз белән булашулары бер нинди киртәгә дә сыя торган хәл түгел бит.

«Сәүдә кануннары урлашырга да, алдашырга да кушмый. Чын сәүдә тугрылыкка иман китерә», — дип, үзалдына үртәнеп уйлады ул.

Нурия, Габделхәлим абзыйсын күрүгә, атылып-бәрелеп аның янына килде, тезе буйлап үрмәләп, югары менеп китте, чытырдатып аны муеныннан кочаклап алды. Моны күреп торган олылар тынып калдылар.

Нурия, сәүдәгәр абзыйның колагына якын ук килеп, борчулы чырай белән Сорыкайның үлгәнен әйтте. Аны олы бакчага, каен астына күмгәннәрен, аның бүген төшенә кергәнен, икесе бергә Зартугай болынында таллар арасында йөргәннәрен сөйләп бирде.

Аннары кинәт тынып калды, күзләренә моңсулык иңде. Габделхәлим абзыйсы, аның баш түбәсенә, чәченә бәйләп куйган ак тасма банти-

гын — күбәләген рәтләде, зур җылы кулы белән аркасыннан сыпырып әйтте:

— Син бер дә кайгырма, үскәнем. Куян баласын урманнан тагын тотарбыз. Өстәвенә әле мин сиңа бик матур күлмәк тә җибәрермен, яме. Андый күлмәк бер генә кызда да булмас.

Нурия каршы килмәде, бармагын авызына капкан килеш, ярар дип баш селкеде.

Аны әнисе белән Көмеш түтәй үз ягына алып чыгып киттеләр.

Габбас мулла белән Габделхәлим бай янә үз якларына чыкты. Сүз җилемен булдырыр өчен чәйнектән тагын берәрне салып эчтеләр. Бу юлы Габбас та кыстатып тормады.

Бераздан аңа күңелле булып китте.

Җыр җырлыйсы килә башлады.

— Җырламый тор, — диде Габделхәлим бай, — сөйләшәсе сүз бетмәде әле. Менә нәрсә... — Ишек ягына күз төшереп алды, башын Габбаска таба сузып, шыпырт тавышка күчеп сөйли башлады: — Туганым абыстай булса да әйтәм: катыннарның барысы да бер төсле, барысы да чүпрәк баш. Шәмсениса кортканың булмавы хәерлерәк. Беләсеңме нәрсә... Таминдар бай Тураев белән сөйләштем. Зартугайга мәптек-шкула салып бирергә ризалыгын белдерде. Әмма да ләкин, ди, ул мәптек-шкулада укыту рәтен белә торган учитель вә һәм дә мөгалимнәре булса гына салдырам. Кышның кыш буе һәфтияк ятлатып, мендәр атышып ята торган корчаңгы шәкертләр өчен мәптек-шкула салдырмыйм, ди...

Габделхәлим бай, Габбасның сумаладай кара куе бөдрә сакал баскан битенә бик кискен төбәлеп, тегенең ни уйлаганын белергә теләде.

Габбас, алсуланган ирене белән мыек очын чәйнәштереп, беркавым дәшми утырды, аннары кәнәфидән торды, биленә таянып, идән уртасында басып калды.

— Андый мәктәпне Таминдар бай, акыллы булса, былтыр ук, өченче елны ук салдыра башларга тиеш иде. Илгә эшмәкәрләр кирәк, акча куучылар, синең кебек сәүдәгәр... Әле без бала чакта гына Чулманда күпме пароход бар иде? Күпме? Көненә бер пароход шаян малай кебек сызгырып узса, шуңа исебез китеп, авыз ачып карап кала торган идек. Хәзер пароход белән Чулман өсте тулды, иртән дә кычкырта пароход, кичен дә кычкырта, төн уртасында да аның сагышлы тавышын ишетәсең. Хөррият заманасы килә, татарның да күзе ачылырга тиештер бит инде... Пароход хуҗалары Стахеевлар гына булырга дигәнмени? Әнә Стахеев гасыр башында попларга, дьяконнарга хатын әзерли башлады — хәләл җефет. Алабугада шулар өчен махсус уку йорты җиткезергә әмер бирде. Үзе үлгәч, хатыны салдырып бетерде шул йортны. Урыс авылларында күпме чиркәү бар, күпме вак чиркәү кырларда утыра... Имеш, мөгаллим булмаса, Таминдар бай мәктәп салдырмый. Салдырмаса үзенә начар, ул тотасы пароходларны, ул ачасы заводларны кем эшләтер? Сөләйман хәзрәт тал чыбыгы ашаткан мокыт шәкертләрме?

Туры Тукай чыкты дөньяга, китапларны кара, Казан басмаларын. Уңга-сулга кылыч айкаучылар бар, Салсал батыр кебек, бил алышырга теләүчеләр!

Габбас мулла бик аз гына тынып торды, башын үгездәй үҗәтлек белән алга бөгеп, ике кулын берьюлы алга сузып, йомарлап сөйли башлады:

— Күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бернәрсә дә; селкенмәдек таш төсле без, җилбер-җилбер җил бәрсә дә. Яшь көннәрне наданлыкка корбан иттек тә чалдык без; суган саттык, борчак аттык, бәрбәр булдык: сач алдык без. Очраса безгә тол карчык, хатыннар гәр, йортка кердек; гөнаһ һич кылмасак та без, җәһәннәмгә, утка кердек...

Габбасның бите алсуланган, кысык күзләренең кабаклары ябыла

төшкән, әмма җанында тыелгысыз бер көч белән, чаптар ат йөрәгедәй, дәрт-дәрманлы ярсу йөрәге кага иде.

— Гомер буе игелекле булдың син миңа, Габделхәлим абзый...

Габделхәлим бай, баягы «тол карчыкка йортка кердек» дигән сүзне дә, хәзер генә әйтелгән «игелек» сүзен дә үз бакчасына таш ату дип аңлап, яшь мулланың аңардан көлүе дип аңлап, урыныннан сикереп торды.

— Син әле миннән көләргә җөрьәт итәсеңме?

— Көлмим мин синнән, нишләп көлим, үземнән көләм мин, көчсезлегемнән көләм, Габделхәлим абзый... Җыру җырлыйммы сиңа? Әйт, җырлыйммы?

Рөхсәт иткәнне дә көтмәстән, матур, моңлы күкрәк тавышы белән, җаннарны айкап алырдай иркен зур тавыш белән җырлап җибәрде:

**Базарларга барсаң, һай, ак тула ал,**
**Бәяләрен, абзый, үзем түләрмен.**
**Әҗәлләрең җитсә, һай, әйт үземә-ә-ә,**
**Габделхәлим абзый,**
**Синең өчен үзем үләрме-е-ен...**

Габделхәлим бай җырны башын иеп тыңлады, җыр беткәннән соң да башын күтәреп багарга базмады. Аның бите буйлап рәхәт кайнар күз яше ага иде...

Шәмсениса абыстайның үз өйләрендә күптән җыру җырлаганны ишеткәне юк иде инде. Җыр тавышы ишетелә башлауга ул эчкәрге кечкенә бүлмәдә мулланың Габделхәлим абзыйсы белән чәйнектән зәмзәм суы эчеп утырганнарын аңлады. Җырны Габделхәлим абзыйсы түгел, Габбас җырлый, андый матур, моңлы, иркен тавыш бер Габбаста гына...

«Йа раббем, хәерле кыл. Күпкә генә китмәсә ярарые... Җамалетдин углы, чапан-чалмасын онытып, авылга рисвай итеп кенә куя күрмәсен...»

— Әни, әнкәем... Безгә Габделхәлим абзый яңа күлмәкне ничек итеп җибәрер икән соң? — диде Нурия.

Әнисе аны йоклаган дип уйлаган иде инде. Ул сабый да җыр тавышына колак салып ята, ахрысы.

— Үзе җаен табар әле, — диде Шәмсениса, җырдан аерылырга теләмичә.

— Әни дим, әнкәем... Габделхәлим абзый күлмәкне бик каты селтәп атса, ийеме?

— Селтәп атса... Туктале, балам.

— Ул аны селтәп атса, күлмәк агач башларына эләгеп калса. Ул бит әйтте: Бояр урманында йөзәр яшьлек чыршылар бар, имәннәр бар, диде.

Күңеленә тулган талгын моңны һәм очсыз-кырыйсыз хәвефле уйны куып җибәрер өчен, Шәмсениса абыстай кызына тиз-тиз аңлата башлады:

— Гарифулла бабаң Салагыш базарына килер. Сандыкларын төяп... Габделхәлим абзаң сиңа күлмәкне арбага салып җибәрер. Сандыкка салып...

Төн урталарында чолан ишеген кактылар.

Тавышка Көмеш түтәй чыкты.

— Нишләп йөрисең кеше куркытып? Өченче этәч кычкырыр вакыт җитә бит инде, — диде ул башын чикмән якасы эченә тыгып торган Гафияткә.

— Муллалар йокламадымы әле?

— Сиңа ник кирәк ул? Йокламаса...

— Шаулама син, Миңлекамал. Габделхәлим абзыйны күрәсе бар. Керт әле.

— Юк инде, бәбчеккенәем. Керми тор. Былагайланып йөрергәме исәбең? Сине кертеп башыма бәла аласым бар икән тагын.

— Уу, җен карчыгы! Эстерәпкә! — диде Гафият, юаш кына сукранып.— Мулла йортын гомер буе каравыллап утырырмын дип уйлый торгансыңдыр. Кергәнең калмагач, артыңа тибәрләр әле. Әнә көзгегә бак: урысларның почмакка куеп чукына торган Мәрьям аналары кебек саргайгансың бит инде.

— Ләхәүлә, эстәгафирулла, иманыңны ук эчкәнсең икән, иблис токымы!

## IV

Бик иртә иде әле. Йортның мәчет ягы тәрәзәләреннән таң нуры өй эченә кыюсыз гына үрелә башлаган, казна буйларында күләгә ята иде.

Соңгы атнада йокысы качкан Сөләйман хәзрәт таң шәүләсен көчкәл белән көтеп алды да, аягына киез катасын эләктереп, юл уңаенда чапанын бөркәнә-бөркәнә, ишегалдына чыкты. Комганын оныткан икән, каһәр, кире керергә туры килде. Җылы су да салып куймаганнар, дөмеккерләре, тәмаммы хөрәсән ялкавына әйләнеп бетте бу асраулар.

Җиз комганын күтәреп, ишегалдының аулаграк, чирәмлерәк төшенә барды — битен юды, колакларын юды, авызын чайкады, аннары тәрәксез тәбәнәк урындыкка чүмәшеп, аппак чиста ыштанын тез тиңентен сызганып, аяк бармакларын аралый-аралый, озаклап юып утырды.

Юынганнан соң күңеле пакьланып киткәндәй булды, озаклап, һичбер иренмичә, чуптарлы сөлге белән сөртенде. Кечкенә өйгә керде дә, мәчет ягына каратып, намазлыгын җәйде, тезләнеп утырып, ике бармагын ике колагына тыгып, иртәнге намазны укый башлады:

— Илаһи ният кылдым, аллаһы тәгалә вә тәбәрәкәнең ризалыгы өчен иртәнге намазымның ике рикнагат сөннәтени үтәмәгә йөземне юнәлдердем кыйбла тарафына... хәлисән илаһи тәгалә аллаһы әкбәр. Собханикә аллаһыма вә бихәмдикә вә тәбәрәкәсмөкә... Намазны борынгы заманнарда кырык фарыз дип таныганнар. Ахыр заман җитмәгәе, эшлисе эшләребезне без мөэмин-мөселманнар эшләп бетерә алмыенча калмагаек, дип курыкканга күрә, мөселман өммәтендәгеләр пәйгамбәребез Локман Хәкимнән ялварып сораганнар, син тәңрегә якынрак кеше, кырык фарыз намаз бик күп, безгә биш фарызы да бик җиткән, сора, гозерлән, дигәннәр, ди... Бисмиллаһы иррахман рахим ми малики яуметдин якәнә әгузе нә эстәгыйн и дине нәсирәтән мөстәкыйн.. Тәки кайтмый бит Динислам, ходаның рәхмәте төшкере. Шулай инде ул, ата-ана аларга үзләре аякка басканчы, тернәкләнгәнче, баш-күз алганчы гына кирәк... Әллә, минсиңайтим, авыру-сырхау булып ятамы бу бала? Зыян-зәвер күрде микән әллә?..

Иртәнге намазына фани дөнья мәшәкате бик күп булып кысыла башлагач, күңеле рәнҗеп, эшен тизрәк очларга ашыкты: ике як җилкәсендәге ике фәрештәгә борылып сәлам бирде. Аннары:

— Илаһи ният кылдым иртәнге намазымның ике рикнагат сөннәтени үтәмәгә йөземне бордым кыйбла тарафына...— диде, барлык пәйгамбәрләрнең исемнәрен атап чыкты, намазын алар рухына багышлады, үлгән бабаларының, бабаларының бабаларының исемнәрен телгә алды, бик күп еллар элек муллалыгын улына калдырып үлгән әтисен

— Җәгъфәр мулланың исемен бик олылап тәкрарлады, ягъни таң нурлары белән җәннәткә барып ирешәчәк догасын аңар багышлады..

Торды, укыганнарын тәңрегә пышылдап ирештерде, чүгәләде, тагын торып басты, тәрәзә төбендәге шкатулкадан тәсбихын алды, инҗир җимешенең төшеннән тезеп ясалган һәм ничәмә ничә мәртәбәләр бармак битеннән шуып, асылташлардай шомарып беткән тәсбих төшләрен янә бер мәртәбә кулыннан һәм күңеленнән уздырырга керешге. Бу юлы инде аның фикер агышы салмак һәм төпле бер тәртиптә иде.

«Йоклый дөнья. Әллә инде гафләт йокыларын йоклый? Асраулар йортында да тавыш-мазар юк. Остабикә дә, кондырлы кодача кебек, савырын сала да утыра, сала да утыра. Утырган җирендә дә йоклый, яткан җирендә дә йоклый. Хикмәти хода, каян чыга икән ул йокы?»

Сөләйманның йокысы юк.

Таминдар бай Зартугайга яңача шкула-мәптек салдырам дип аваз салган көннән башлап хәзрәтнең йокысы качты. Ул шкула дигәннәре бөтен авылга бер буласымы, әллә Түбән мәхәлләгә генә микән? Түбән мәхәлләгә генә була торган булса, Сөләйман хәзрәтнең абруе төшәчәк бит. Мужик Габбасның бүресе улый ул чагында. Болай да бит ул Таминдар бай фәтвасы белән Гыйматдин мәрхүмнең нинди мөлкәтенә баш булып алды. Тьфу, тьфу, әстәгафирулла, уйлый башласаң, әллә ниләр уйлап гөнаһлы булырсың! Хуҗа булмасые, Таминдар байда Шәмсениса кортканың туганнан туган сеңлесе. Бу дөньяда, минсиңайтим, акча булган белән дус-иш булганнан гына түгел бәхет, агай-эне ак мыек, бер-беребезне какмыек булганнан да! Кемгә кияүгә чыгасын белгән сафсата, Шәмсениса кортканың тиле-миле сеңлесе. Инде менә шул сәбәпле Таминдар Тураев Шәмсениса дип кенә тора, Габбас дип кенә тора. Ә бит Таминдар Турай — олыста череп чыккан бай. Таминдар — меңләгән дисәтинә урманга хуҗа, спирт забутына хуҗа, тирәяк авылларны дер селкетеп торган Таминдар минем чыбык очы туганым гына булса да, нишләргә икәнен белерием мин. Динисламны әйтерием, Алабуга чаклы Алабугада җантимерләр идарәсендә утырып, шул Таминдар белән уртак тел таба белми. Акыллыдан акылсыз туган сафсата! Менә хәзер Таминдар Турай шкула-мәптекне Сөләйман хәзрәт мәхәлләсенә түгел, мужик Габбас мәхәлләсенә салдырачак. Күр дә тор, бай абзаң Габбас мужикны указлы мулла итәргә тырыша башлар... Яңача салынган, яңача укытыла торган шкула-мәптеккә авылның иң хәлле кешеләре балаларын китерерләр... Авылның иң хәлле кешеләре Габбас мужикка сәдака ташырлар.

Сөләйман хәзрәтнең затлы чапаны кесәсенә төшәсе көмеш тәңкәләр гомерлек мужик малае Габбас кесәсенә коелыр.. Йа хода, кая бара бу дөньялар?!. Габделхәлим купис элегрәк елларны гошер-фытыр сәдәкасын Сөләйман хәзрәткә китерә торганые. Габбас чучка белән икәүләшеп, кече якта яшел чәйгүннән хәмер чөмерә башлаганнан бирле Габделхәлим купис сәдәкасыннан җилләр исте! Затлы мал, кызыл мал Габбас мулла йортына килә. Килә, аннан кире чыкмый. Үләрсең, валлаһи, гарьлегеңнән. Ичмасам, Динисламы да кайтмый. Сиңа кирәк түгел чагында урыс-улак әфисәрен җыеп йортны бөлдереп ятты. Корбан чалырга дип китергән ике бәрән ычкынды. Минзәлә ягыннан кайтарткан ящик-ящик кымызны чөмереп киттеләр. Киңәш-табышка кирәк булгачыннан малайның эзе дә юк! Алабуга ерак җирме, борын астында мыек дигәндәй, тимер күгенә атланып, «ә» дигәнче кайтып җитәрие, туган-үскән нигезен бер күреп китәрие. Юк шул, юк — бер кирегә китсә, гел кирегә китә...

Хәзрәтнең шул уйлардан эче көеп китте. Үлеп тә чәй эчәсе килә башлады. Куянканыдай куе итеп. Ә ясап бирүче юк чәйне.

Пыяла шкафтан чәй савытын барып алды. Ике учны бергә куйган-

да да сыймаслык зур калай савыттагы сурэткэ, эле яңа гына, беренче мәртәбә генә күргәндәй, исе китеп карап торды.
Кәрван чәй. Йа хода, күпме күңел хатирәләре синдә!
Тезелешеп дөя кәрваннары бара. Комлы чүлләр, эсседән көйгән чүлләр. Дөя үркәчләрендә чыпта төкләр, төкләрдә — хуш исле бөртек чәй. Еракта, еракта, кояш чыгышы якларында яшәгән җылы якларның кояшын, җилен, җир ямен китерә торган чәйләр. Нигә аларны чыпта капларда ташыйлар икән? Ә, әйе, менә син, сафсата, шуны да белмә, имеш: чәй бит ул бик нечкә, бик нәзберек эчемлек, ул сина хәмер-мазар түгел, ис-посны яратмый. Юкә мунчаласыннан да чистаракны тагын каян табасың? Чыпта төкләрдә, дөя үркәчләрендә килә Рәчәйгә чәй! Өркет дигән Себер каласы аны чыпта төкләрдән энә нинди калай савытларга бушата. Ә ул калай савытларны Себер байлары Казан каласына тиклем китереп җиткезә. Казан каласыннан аны Габделхәлим купис алып кайта, алып та кайта, икеләтә бәягә, — өчләтә үк булмаса әле! — арттырып та сата...
Хәзрәт, чәй савытын кулына тоткан көе, дөя кәрваннарына карап асрауларны чакырырга, самавыр куйдырырга кирәген дә онытты. Дөяләр аңа яшь чагын, Мәккә-Мәдинәгә хаҗга барган утыз яшьлек тап-таза, сау-сәламәт чагын искә төшерделәр. И дөньялар, кырык ел гомер аккан су кебек кенә узып киткән. Кырык елда ул күпме никах укып, күпме яшь-җилкенчәкне кавыштырды; ясин чыгып, күпме мәетне теге дөньяга озатты; япон сугышында үлеп калганнарга ничәмә-ничә мәртәбә бөтен коръән чыкты. «Без картаймый кем картайсын!» — диярпе берәү булса. Заманалары да бит аның син теләгәнчә генә, тыныч кына торамы! Бүген закунның берсе чыга, иртәгә икенчесе...
Абзарда кызганыч тавыш белән сыер мөгрәп куйды, аңа башмак тана кушылды. Авылның теге башыннан көтү алып килә.ләр бугай, курай тарткан тавышлар да ишетелә башлады. Ә безнең хөрәсәннәр сыерларны саумаганнардыр да әле..
Кинәт берьюлы бөтен өй купты. Асраулар, ат караучылар әрепләшә, табак-савыт, комган-ләгән шалтырый башлады.
Бурабзардан кемнедер юксынган кола бия кешнәп җибәрде.
Ул да түгел, урам як капканың бастырыгы шалтырап җиргә төште, капканы бөтен иңенә каерып ачып җибәрделәр.
Баш өстеннән үк кара япма бөркәнгәнгә карчыга төсле булып күренгән җайдак озын торыклы тимер күк айгырда килеп керде. Капка ябылып бетүгә егетләрчә бер җитезлек белән җайдак иярдән җиргә сикерде, дөньяны тетрәтеп кешнәгән айгырның йөгәне һәм җайдак өстендәге кара япма шундук Мотыйгулла кулына күчте.
Мундирлы, биек фуражкалы эфисәрне күрүгә Сөләйман хәзрәт аһ итте, улы Динислам кайтты лабаса!
«Йа аллам, кодрәтең киң дә соң синең, әйткән сүзем фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килде бугай, улым кайтып та җитте!» — дип, туганнарча бер рәхәтлек белән уйлады.
Хәзрәт болдырга чыкты.
Шпорлы итекләре белән басмачаларга каты басып менеп килгән улына сокланып карап торды, әмма Динисламның чыраендагы салкынлыкны күргәч, тәне өшеп киткәндәй булды.
— Исәнлекме, атакай, авырмыйсызмы? — Эфисәр, «атакайга» кул биреп күрешергә дә онытып, туп-туры өйгә узды.
Хәтере калган Сөләйман хәзрәт, киез катасын шыштырдатып, аның артыннан иярде.
— Нишләптер бик кырыс әле син бүген, улым, әллә мөселманча сәламләшү гадәтен дә оныткансың инде?
— Сез бит, атакай, улыгызга ярдәм итәргә теләмисез! — Эфисәр, чал керә башлаган чибәр кара мыекка кулы белән кагылып, иренен кыс-

ты, куе кара кашлары астыннан үтәли тишеп карый торган бәркет карашы күңелгә шом салып куйды.

— Ничегрәк аңнарга боерасың бу кыланышыңны, Динислам? Әгәренки син атаңны ихтирам итмисең икән, һич югы, дин әһелен, мәхәллә башлыгын танырга тиеш иең.

— Бәйрәм ашы — кара-каршы, дип кем әйтә? Мөэмин-мөселман. Нишләп хат юк? Хәбәр юк? Синең подопечныең, ягъни күзәтү эше сиңа беркетелгән Шәяхмәт Айдаров кайда йөри? Сал агызачакмы быел? Аңа кемнәр килә? Ни өчен боларның берсе дә безнең идарәгә мәгълүм түгел? Полковник галиҗәнабләре мине маңка бер малайны тиргәгән төсле тиргәп ташлады. Сез, атакай, күрәсең, улыгызның гомер буе поручик чинында интегүен телисез. Штабс-капитан кебек чиннар сезнең колакка ят ишетелә бугай.

Хәзрәтнең ак җитен сакалы тетрәп китте:

— Менә син, ә... карале, ә... Әллә нишләп бу арада зиһенем таралып китте. Таминдар бай шкула-мәптек салдырырга керешкәннән бирле...

— Нәр-сә-ә-ә?! Школа?!

— Әйе. Саклау урманында диләнкә кисәләр. Чикалта кирбеч забутыннан кирбеч кайтара башладылар.

— Нишләп аны мин белмим? Полковник белми? Безнең Алабуга идарәсенә учетка баскан чакта кем патша хәзрәтләренә вә һәм дә уртак ватаныбыз Россиягә турылыклы булырга дип кул куйды? Алай бик тиз онытa торган булсагыз, искә төшерүчеләр табылыр.

Сөләймән хәзрәт, эшләр болайга киткәч, соң дәрәҗәдә рәнҗеп, кимсенеп һәм аптырап сүз башлады:

— Туктале син, улым Динислам, нәрсә, син мине башы себер китәргә тиешле кәтерҗәнне дапруслагандай дапруслыйсың? — Алар тавышына олы якка килеп кергән остабикәгә — баладан бөкрәеп калган олы яшьтәге хатынына җикерде: — Керми торыгыз. Ирләр сүзе бу. Яп ишекне, нәрсә Салагыш хәерчесе төсле канат җилпеп торасың? — Остабикә: «Тәүбә, әстәгафирулла, бар икән күрәселәрем», — дип авыз эченнән мыгырданып чыгып киткәч, тагын да ярсына төшеп, рәнҗегәнен тагын да ныграк сиздерергә теләп, гыжылдап чыккан тавыш белән сүзен дәвам иттерде: — Әгәренки инде олы кешене бу мине карапбагып үстергән эти дип ихтирам итә белмисең икән, авылның мулласы, мәхәллә башлыгы итеп...

— Кыскарта төш! Ул хакта әйттең бит инде! Дөнья һаман да бер төсле тора дип уйласаң, бик ялгышасың, сәяси хата ясыйсың. Хөрлеккиңлекләр кысылып бара, атакай! Хөррият сүзен хәзер чат саен әләм итеп күтәреп йөрмиләр. Чистайдан, Чаллыдан, Минзәләдән унбер кешене сөргенгә озаттылар. Кайсын Ырымбур даласына, кайсын Казан төрмәсенә, икесе Себергә үк китеп барды. Пәнҗәрдәге Мифодий Турчановны оныт, белдеңме?

— Аңа ни булган?

— Крамола өчен безнең идарәгә эләкте, эше судта. Базарга-нигә барган чакта ул тирәгә сугыла күрмә. Ул йорт махсус күзәтү астында. Юкса, миңа мөэмин-мөселман дип авыз суларын корытучы атакаемнан допрос алырга туры килмәгәе....

— Тәүбә, әстәгафирулла диген! Әллә нишләп кайткансың син, улым Динислам. Ислам диненә ничә мәртәбә тел тидердең инде. Сезнең идарәдә шулай дип өйрәтәләрмени? Дин-мәгыйшәт юлында корбан булганнарны оныттыңмыни?

Шуннан соң хәзрәтнең эфисәр улы йомшый төште.

— Ярар, әҗи, корыны бушка аударганны яратмыйм мин. Әйт анда, ашарга кертсеннәр. Әче балың юкмы? Төне буе ат кудым, эт булып арылган.

Асрау хатын Фахирә, авызын яулык белән каплап, самавыр кертте. Чәй янында бер-берсен уртәми торган тынычрак тавыш белән сөйләштеләр. Чымырдап утырган әче балдан авыз итеп, каклаган каз ише ашамлыклар белән күңел тапкач, Динислам этисенә нелә төшеп әйтте:

— Себер рудниклары, Россия төрмәләре политкаторжаннар белән тулы. Хөррият, революция дигәненең бугазына ат суя торган пычак китереп куйдылар. Патша хәзрәтләренең мәнфәгатен, уртак ватаныбыз Россияне афәттән коткару эшенә без, ягъни син әйткән мөэминмөселман, үзебездән өлеш кертмәсәк, җиңү бәйрәмендә урыныбыз түрдә булмас.

— Нишләргә боерасың?

— Иң әүвәл: Таминдар Тураев. Школа салу ничек бара? Нинди осталар катнаша, каян? Аңладыңмы?

— Ә мин аларны каян белермен?

— Мәчет ни өчен? Намаз картлары ни өчен? Мөритләрең?

— Йа рабби, нишләп син безнең изге динебезне...

— Атакай, син мине чыгырдан чыгарма, ярыймы? Каз булсаң симез бул дип кем әйтә торган иде? Алабуганың жандармерия идарәсенә мин синең фатихаң белән кердем. Тагын бер тапкыр исеңә төшерергә рөхсәт ит. Шулай булгач, рәхим итеп...

Поручикка тавышын күтәреп бүтән сөйләшергә туры килмәде. Чыраеннан каны качкан хәзрәт, самавыр янында торган «кәрван чәй» савытына берни күрмәс күзләре белән төбәлеп, үзе тикшереп барачак, «җантимерләргә» хәбәр итеп торачак кешеләрнең исемнәрен күңеленнән барлап утырды. Барлап кына түгел, күңеле ачытып. Кем соң ул хәзер? Дин-мәгыйшәт юлында җанын корбан итәчәк хаҗимы, әллә авыл өстенә төшкән афәтме? Нахак бәлаләр ягарга, гаепсезләрне гаепле итеп чыгарырга дучар итмәсәңие, ходаем. Ярабби, үзең ярлыка...

Динисламны ул капка төбенә чыгып озатты. Кара япмадан карчыга төсле бөкрәеп озын торыклы тимер күк айгырда китеп барган әфисәр улының артыннан мәчет чатыннан борылганчы карап калды.

Өенә кереп китәм дип торганда күрше капкадан Зартугайның гомерлек диванасы Майттыпыра килеп чыкты. Кылган гамәле белән бер генә дивананы да хәтерләтми торган бу тиле җәен өстенә тун, аягына киез итек киеп йөри, кышкы чатлама суыкларда ялан аяктан, каз тәпие кебек булып кызарган көе, авыл саен сүс җыя, сүстән кибән өеп, булачак кәләшенә чаршау-чыбылдык ише нәрсәләр суктырырга хыяллана иде.

Менә шул гомерлек дивана, Сөләйман хәзрәтне әллә каян күреп алып:

— Мулла бабай, мулла бабай, бер төрерлек тәмәке бир әле! — дип кычкырып килде.

Хәзрәт, болай да тәңре рәнҗеткән бу дивананы тагын бер кат рәнҗетергә теләмичә, чапан кесәсеннән биш тиенлек бакыр чыгарды:

— Син, изге җан, урам бетереп кычкырып йөрмә. Тәмәке тарту мөэмин-мөселман эше түгел ул. Менә сиңа сәдака, дога кылып ал.

Майттыпыра, ачык авызын ябарга онытып, хәзрәтнең чалмасына бик төбәлеп карап торды да акча биргән кулын кире этте.

— И мулла бабай, тәмәке бирмисеңмени инде? — диде.

— Бирмим, — диде хәзрәт.

— Алайса, абыстаеңны бозау яласын яме! — дип шаркылдап көлеп китеп барды.

«Бу ниткән алла каргаган көн булды соң? Бу тилесенә хәтле мине мыскыллап китте», — дип моңаеп уйлады хәзрәт.

## V

Көн артыннан көн үтә, ел артыннан ел.

Нурия әтисеннән укый-язарга өйрәнде.

Зураеп, буйчанланып китте. Чәчен баш түбәсенә күбәләк кадап түгел, ике толым итеп үреп йөртә башлады.

Әтисе белән алар бик дус. Көн саен бер мәртәбә сабак тыңлатып, матур язу дәресе үткәргәннән соң, әтисе аңар Тукайның берәр шигырен ятларга куша.

Нурия китапны шап иттереп яба да аяклы зур көзге артына кереп кача. Әтисе бүлмә бетереп, тавышланып, аны эзли, эзләп тапкач, шаулап сөенә, көрәктәй зур куллары белән кызын тотып ала. Башыннан сыйпаган чакта Нурия әтисенең бармаклары кәкре-бөкре булуын күрде.

— Әтием, ә нигә синең бармакларың кәкре? — ди Нурия.

— Мин бик озак урман кистем, кызым, агач төпләдем,— ди әтисе.

— Ә нигә агач төпләдең?

— Ягарга утын кирәк булды.

— Ә нигә менә бу бармагың кыска?

— Без, кызым, бабаң белән кышкы суыкта утын кисә идек, мин бик туңдым дә өйгә керик дип шыңшый башладым. Бабаң керми дә керми. Мин балта белән ярырга дип әзерләгән утын пүләненә кулымны куйдым да: «Кисмик инде бутән», — дидем.

Бабаң балтасын селтәп өлгергән икән, тотып кала алмады, минем менә шул бармагымны өзеп чыгарды.

Нурия әтисен кызганудан нишләргә дә белмәде.

— Әти, мин сиңа шигырь сөйләп күрсәтәм, яме? — ди.

— Күрсәт, балам,— ди әтисе.

Нурия күзен йома, башын артка кайшалдыра, иркен зур бүлмәдә аның тавышы яңгырап ишетелә:

> Кыш. Буран. Салкын һава. Яфрак кадәрле кар төшә.
> Җил куа карны, һаман да кар төшәм дип тартыша.

Кар бураннары эченнән биек манаралы мәчет килеп чыга, кызыйның яңгыравыклы нечкә тавышы мәчет янына дөм сукыр бер картны китереп куя; картны кызганудан аның тавышы өзелеп-калтыранып китә, күз төпләренә әчеттереп яшь бөялә.

Ул тавышы кысылып туктый.

Әтисе аны, күкрәгенә кысып, аркасыннан сыйпый, Нурия инде зур — ун яшендә, аркасыннан сыйпаганга ояла, тартыла, урындык алып, әтисе янына утыра.

Әтисе башыннан кичкәннәрне сөйли.

Йомшак, куе тавыш Нурияне, тирбәтеп, әллә кайларга, ерак дөньяларга алып китә. Иксез-чиксез казакъ даласы ак болытлар төсле ак тирмәләр белән чуарланган. Яланнарны тутырып сарык көтүләре йөри, көтүченең чыбыркы шартлатканы ишетелә, ала мүкләк муенындагы кыңгыраулар чыңлый. Казакъ даласын, сарык көтүләрен Нурия үзләренең Зартугай болынына, Бояр урманы буйларына кайтарып куя. алар белән бергә Ләлек мамык чыбыркы озын чыбыркысын өстерәп йөри, Солтан — күрше Садыйк абзый малае, Актырнак исемле этен ияртеп, уҗымга чыгып барган сарыкларны куып алып килә.

Бояр урманы янына, көтү йөргән урыннарны карарга барганда и рәхәт тә соң Нуриягә. Солтан җирне казып учак яга, көлгә күмеп бәрәңге пешерә.

— Мулла кызы, бәрәңге ашыйсыңмы?— ди.

Солтан зур такыр башлы, каты куллы малай. Нурия, кайбер көннәрне аңа ияреп, тегермән буасы янына төшә.

Тегермән буасы янында вак бака күп. Нурия аларны, и бичаралар, туганcыз бит! дип, учына тутырып, тыны белән җылыта-җылыта, өйгә алып кайта. Җамаякка су салып, бака балаларын шунда җибәрә. Иртән инде бака балалары корсаклары белән өскә әйләнеп, агарып яталар.

Нурия аларны югарыгы бакчага алып менә, куян баласын күмгән төсле, кабер казып, Көмеш түтәй өйрәткән догаларны укып күмә.

Әнисе аның бу эшен бер дә яратмый.

— И гөлкәем, ник булашасың бака белән? Ир малай түгел бит син. Ичмасам, чигү чигәриең. Кулың үнәргә өйрәнә торырые...

Әтисе Нурияне яклап чыга:

— Тимә. Баланы балалыктан мәхрүм итмә. Җан иясен ярата белгән бала җүнсез бала булмас ул.

Әтисе белән әнисе, нәрсәдер бүлешә алмыйча, дәгъвалашып китәләр. Бу елларда алар гел тавышланышып торалар. Тату чагында да әтисе гел боек йөри, ул нәрсәдәндер, кемнәндер риза түгел.

Нурия күңеле белән әтисе яклы, ул аны үпкәләтмәскә тырыша, аның боек йөргәнен күрәсе килми. Шуңа күрә ул хәзер күбрәк вакытын урамда, су буенда, ир малайлар балык тоткан урыннарда үткәрә.

Нуриягә нинди сабак укыту турысында да әтисе белән әнисе уртак тел таба алмадылар. Әтисе кызын, Салагышка йөртеп, җәдит мәктәбендә укытырга тели. Әнисе моңа теше-тырнагы белән каршы төшә:

— Юк-бар белән баланың башын катырмасана, хәзрәт! Син аны укый-яза белергә, ун эчендә исәп-хисап йөртергә өйрәттең бит инде. Шул җитмәгәнмени? Болай да бит ул саулыкка туймый. Төннәр буе китап өстендә күз бетәштереп, йөз саргайтып утырганчы, мин аны үзем йорт алып бару үнәренә өйрәтермен.

Тыштан караганда юаш кына күренсә дә, әтисе таякны тоткан җиреннән сындырырга ярата. Әнисе белән ул озак бәхәсләшми, үз дигәнчә эшли дә куя.

Мең тугыз йөз унынчы елның декабрь урталары. Җир-су туңган. Мул булып кар яуган. Зартугайның 362 йортыннан сыкылы күгелҗем һавага, туп-туры булып, төтен баганалары күтәрелә, янган салам исе, яңа пешкән икмәк исе таралган иде.

Габбас мулла йортыннан кара туры айгыр җигелгән артлы чана Салагышка таба җинел генә элдереп китте.

Чанага аркасын терәп, төлке толыплы Габбас мулла утыра; аңа каршы көпәш кебек итеп төргән, мамык юрган эченнән алсу бите генә күренеп калган Нурия бара.

Сары каеш кебек сузылган саргылтым юлдан, чана табаннарын чыжылдатып, авылны элдертеп кенә чыктылар да атны сул тарафка — Салагышка таба бордылар.

Юлда Саклау урманы аша уздылар. Әтисе атны куаламады, дилбегәне кулына нык тотып, җай гына алып барды. Тоташ актан киенгән имәннәр, юл чатларына басып, озатып кала, урман юлы баш әйләндергеч дәрәҗәдә аулак иде. Шыкырдап очып киткән озын койрыклы саескан, юл буена ак шәлләрен бөркәнеп тезелгән чыршылар, тел белән әйтеп бирә алмастай тынлык Нуриянең күңелен биләп алды.

Ул әтисенә карап түгел, кышкы урманга карап барды.

Кара туры айгыр урман юлыннан хуҗа булып бара, аның гөрселдәтеп йөрәк какканы ишетелә, баш очындагы алма бизәкле калын дуга — бару уңаена — селкенеп-селкенеп куя иде.

— Кызым, туңмыйсыңмы? — диде әтисе.

— Ю-у-ук,— дип, иркәләнеп җавап кайтарды Нурия.

Әтисе дилбегә кагып чөңгереп куйды.

Ат аягы астыннан каты кар кисәкләре очып, тирә-якка чәчрәде, куәтле тыгыз җил, биткә бәрелеп, күздән яшь чыгарды.

Шулай да Нурия артына борылмады.

Каты шаулап сызгырып барган чана, атның баш очында инде тизрәк атына башлаган алма бизәкле дуга, каршы җилдән тузган ат ялы— болар барысы яңа, күңел кузгаткыч яңа иде.

Ат, җилдәй очып, урманнан кар даласына килеп чыкты.

Чуртанкүл болыннары башланды.

Инде хәзер Нуриянең күңелен чана юлы офыкка барып тоташкан урын биләп алды. Анда күк йөзе алсу-күгелҗем, кайдадыр болытлар артында кояш нурлы йөзен күрсәтә алмый интегә, шул урында алкаланып килгән саргылт бер балкыш хасил булган иде.

Нурия юл офыкка тоташкан урынны байтак вакыт күзәтеп килде. Аңар анда, юл барып тоташкан күгелҗем офык артында, ак тирмәле казакъ даласы җәелеп китәдер, яки хур кызлары яши торган җәннәт башланадыр кебек тоела иде. Хур кызлары турында аңар Көмеш түтәй сөйләде. Алар җир йөзендәге кызларның берсенә дә охшамаганча матур, барысы да бер төсле аппактан яки бертөсле сарыдан киенгәннәр, аларның чәч толымнарында бөтен тәңкәләр, көмеш чулпылар чыңлый, алар алма бизәкле чиләкләр белән, барысы бергә тезелеп, фәрештәләргә су китерәләр, үзләре җәннәт җимешләре белән генә тукланып торалар, аларның баш очында мең төрле кошлар сайрый икән...

Нуриянең хур кызлары төсле матур буласы, билгә җиткән ике толым чәч үстерәсе, кашына асыл ташлар куйган көмеш чулпылар тагып йөрисе килә.

Ул Ырымбурга, туганнары янына кайтып киткән Көмеш түтәйне үзәкләре өзелеп сагынып куя. Ник кайтмый икән инде ул? Киткәндә бер айга гына дип, утырмага гына дип киткән ие, ярты ел узды инде, һаман кайтканы юк...

Ул булмагач, Нуриянең кадерен белүче дә, аяклы зур көзге каршысында аның чәчен тараучы да юк. Әнисе дә тарамый. Әнисе, буш вакыты чыккан саен, әтисе белән тавышлана. Ни җитми икән соң аларга?

— Әти дим, әтием... Көмеш түтәй кайчан кайта соң инде безгә? — дип, кинәт, әтисен аптырашта калдырып, сорый Нурия.

Әтисе толып якасын кайтарып куя, кара бөдрә сакаллы ияген алгарак суза, озак кына дәшми.

— Я, әйт инде, әтием, — ди Нурия сабырсызланып.

— Ул бәлкем безгә кайтмас та инде...

— Ник, әтием?

Әтисе сорауга туры җавап бирми.

— Әнә Түбән очның Рамазан абзый безгә төпчек кызы Хәнифәне биреп торам ди әле.

Нуриянең йөзенә курку чыга, кинәт, бала чактагы төсле, бик хәтәр киреләнәсе килә башлый.

— Әйем лә... Көмеш түтәй булмагач, кирәк түгел!

Габбас мулла, кызының янә дә караңгыланып, нәүмизләнеп киткән чыраена карап торды, бер сүз дә әйтмәде.

Алар Салагышка килеп керделәр. Авылның урта урамыннан элдертеп кенә бара башладылар. Габбас танышлары янында озаклап туктап торырга, бигрәк тә мәрхүм Гыйматдинның тол калган остабикәсе турында сөйләргә теләми иде.

Урамның ике ягыннан йортлар, коймалар, рәшәткәләр, читәннәр йөгереп уза башлады. Баерак йортларның түр бакчасындагы агачлар, урмандагы кебек, кар мендәрләре күтәреп утыра, йорт түбәләренә, урыс капкаларның такта түбәләренә ярты аршын кар утырган. Читәннәр күбрәк, урыс капкалар азрак. Тыкрыклардан су күтәреп көянтә чиләк белән бии-бии кайткан яшь киленнәр күзгә чалынып калды.

Пожар каланчасы янында кемдер ат җигеп маташа иде.

Мәчет урамына килеп чыгуга урам тулы халык күзгә ташланды, Габбас атын тыя төшәргә мәҗбүр булды.

Халык җомгадан кайтып килә.

Култык астына саламнан үргән мәте, чигүле намазлык кыстырган, кайсы башына колакчын, кайсы мескен бүрек кигән, чикмәннәрен, ямаулы каеры туннарын кызыл пута белән буып куйган агайлар, аякларына я киез ката, я бизәкле кызыл чирмеш итеге, я чабата башмак кигән крестьяннар әкрен генә кайталар, әкрен генә сөйләшәләр иде.

Атлы юлдан кайтканнары читкә чыгып юл бирә, Габбас мулланы таныганнары: «Әссәләмәгаләйкүм, хәзрәт!» дип исәнләшеп узалар.

«Вакытсызрак чыктым, алланың рәхмәте...» дип борчылып уйлады Габбас мулла.

Салам, печән калдыкларыннан чуарланган һәм кар белән укмашып каткан базар мәйданыннан узгач, урыс капка төбәсенә: «Салаушское русско-земское училище» дип, кара калайга ак буяу белән язган бер катлы зур агач йорт янында Габбас мулла атын туктатты.

Йөгән тезгенен дугадан чиште, аркалыкны бушатып куйды, камыт бөяте астына кулын тыгып, атка камыт сукмаганмы икәнне белде, аннары хайванга печән салды.

— Я, балам, аллага тапшырып төшик. Син укыйсы мәктәп шушы була,— диде.

Нурия, мамык юрганнан арынып, чанадан төште, киез итекле аягы белән кар өстендә таптанып:

— Ә минем букчам кайда?— диде.

— Букчаң шушында булырга тиеш.

Күпме генә эзләсәләр дә, букчаны таба алмадылар.

Әнисе, Нурияне, юлда туңмасын дип, кат-кат төрә торгач, букчасын салырга онытکан икән.

— Гөлекәем, бүген әле сиңа букча кирәк булмас. Иртәгә иртүк китереп бирермен, яме.

— Әйем, мин букчасыз мәктәпкә кермим,— диде Нурия киреләнеп.

Шул мәлне мәчеттән кайтып килгән мескен бүрекле, чикмәнле ике карт, чукмар башлы таяклары белән ат юлына каты-каты төртеп, мыекларын мәче кебек тырпайтып, болар янына килеп туктадылар.

Аларның берсе, ярым йомык сул күзен кул аркасы белән ышкыйышкый:

— И йөзең кара, бәдбәхет!— дип чыелдык тавыш белән кычкырып җибәрде. — Балаң урыс сабагы укымыйм дип җир тырмаша. Ә син, иблис токымы, иманыңны чукынган урыска саткан нәмәстәкәй, газиз балаңны зар елатып, үз кулың белән көферлеккә илтеп тыкмакчы буласың!!!

Белер-белмәс көе арага килеп тыгылган өчен этисе ул кысык күзле кешене эттән алып еткә салып сүгәргә тиеш иде. Никтер алай итмәде. Әнисенә аңлаткан кебек, сабыр, юаш тавыш белән иплән кенә аңлатырга кереште:

— Син, Минҗан абзый, юкка алай дип әйтәсең. Минем кызым дин сабагын Габденур хәзрәттән тәртипле рәвештә укып барыр. Кирәк булса, әнисе Шәмсениса остабикә дә өйрәтер аны. Ә менә Зартугайда әле дөнья гыйльмен өйрәтерлек мөгаллим юк. Мәктәпне дә әле салырга җыенып кына йөриләр... Сезнең бит монда Юныс мөгаллимне әйләнәтирәдә мактап сөйлиләр.

Ләкин Кысык Минҗан да, аның белән басып торган чикмәнле икенче карт та Нуриянең этисен тыңлап бетерергә теләмәделәр, тагын да ачырак тавышлар белән каргана-каргана, таякларын Габбас мулла өстенә селкеп, бәддога яудыра-яудыра китеп бардылар.

Нурия хәтта этисеннән ник букча таптырганына үкенеп куйды. Кара

инде бер: нинди карангыланды этисенең чырае, мыек очлары сәлперәеп, аска салынып төште...

Нурия Салагышта ике кыш укыды.

Шул вакыт эчендә Нурия үзе дә, этисе дә шактый үк үзгәрделәр.

Этисе аны шимбә көннәрендә кичен ат белән килеп ала, дүшәмбе көнне иртән янадан ат белән китереп куя иде. Беренче елдагы кебек, кызына ул юлда әкиятләр сөйләми, толып якасына борынын төртә дә, йоклап киткән төсле, бер сүз дәшми кайта, я булмаса әкрен генә җыру җырлый. Сүзсез генә моңлана. Әллә кайгысы бар инде аның...

Өйдәге тормыш та әллә ничек көйсезләнеп китте. Этисе белән әнисе элекке төсле тату гына сөйләшеп йөрмиләр, озаклап намаз укымыйлар. Намазлык җәеп утырсалар да, тизрәк битләрен сыпырып, торып китәргә ашыгалар. Алар чамадан тыш кычкырып сөйләшәләр, бер-берсен үртиләр. Барысы да шул Хәнифә түтәй килгәч булды. Көмеш түтәй бар чагында бер дә алай түгел иде...

Бер көнне Салагыштан кайткач, түр тәрәзә буенда чәй эчеп утырганда әнисе усалланып әйтте:

— Белеп тор, Габбас, әгәренки ул эшне минем рөхсәтемнән башка эшлисең икән, гомер бакый игелек күрсәтмәм! Кул аркам белән битемне сыпырып: «Аяк-кулларың корысын!» — дип бәддога кылырмын!

Этисе әкрен генә каршы төште:

— Нинди көфер сүз сөйлисең син, Шәмсениса? Ике хатын асрарга украм котырып торамыни минем? Табып бир син миңа бер малай, дөньяның бер изгесе булырсың. Минем дә бит, кеше кебек, варислы буласым килә.

— Әстәгафирулла, тәүбә, тьфу! Шул да булдымы сүз?! Син бит үзең, этисе, көфер сүз сөйләп, сабый бала көлдереп утырасың!!! Илле биш яшемә җиткән чагымда мин сиңа нинди малай табып бирим? Син бит моны миңа үч итеп әйтәсең, табып бирә алмаганымны белә торып!

Этисе белән әнисе ак өйгә чыгып киттеләр. Анда аларның шаулашкан тавышлары бик озак ишетелеп торды.

Нурия, йөрәге дөпелдәп типкән хәлдә, этисенең кемгәдер өйләнәчәген аңлап алды. Кемгәдер дигәне Хәнифә түтәйдер әле! Ул моның ни рәвешле булачагын күз алдына китереп карады. Этисе белән Хәнифә түтәсе, кулларын-кулга тотынып, аяклы зур көзге каршысында басып торалар. Этисе Хәнифә түтәйнең чәчен тарый. Әнисе бер читтә карап тора һәм күз яше белән елый. Юк, моның булуы мөмкин түгел! Була калса, ул Хәнифә түтәйгә әйләнеп тә карамас, аның белән бергә өйне дә җыештырмас, аңардан чәчен дә үрдермәс..

Дөньялар бик кинәт үзгәреп китте.

Этисе Нурияне, Салагыш мәктәбеннән алып кайтып, Зартугайдан унсигез чакрым ераклыктагы Пәнҗәр авылына илтеп бирде.

Пәнҗәрдә Габбас мулланың танышы Митрәй дәдә бар икән. Нурия шуларга урнашты. Озын сары чәче муен чокырына чаклы төшеп җиткән, кайчан карама биленә корымлы киндер алъяпкыч, аягына күн итек киеп йөри торган Митрәй дәдә белән «куфты-юпкалы» Груша түтәй Нурияне үз итеп торсалар да, аларның Нуриядән ике яшькә олы кызлары Маруся Нурияне яратмады, җәфалап җанына тия башлады. Я ул Нурияне ишегалдына алып чыгып дуңгызга ашатам дип куркыта, я кичләрен, йоклар алдыннан, йөгереп килеп мендәрен чукындырып китә иде.

Нурия, коты чыгып, бисмиллаларын әйтә, белгән догаларын укый, әмма чукындырылган мендәргә ятып йокларга тәне тартмый. «Мин монда ничек йоклыйм инде?»— дип елап утыра башлый...

Бүлмәгә Митрәй дәдә үзе килеп керә.

— Ник җилыйсың, доченька?

— Маруся мендәрне чукындырды, а-а-а...

Митрэй дэдэ кызын ачуланып куып чыгара, татарча сүз эзләп, иплэп кенэ әйтә:

— Син җилама, доченька. Миндарны кире якка әйләндереп җукла.

Мендәрне кире ягына әйләндерсә дә, йоклап китә алмый Нурия. Әтисе турында, әнисе турында, Хәнифә түтәй турында уйлап ята. «Син, Хәнифә түтәй, нигә минем әтидән чәченне үрдертәсең?» «Үзе үрергә теле бит әтиең, үскәнем». «Мало что тели, синә үз ишләрең беткәнмени?» «Үз ишләрем дә бетмәгән, мин бик ярлы шул, сезгә килгәндә минем өстемә киярга җүнле күлмәгем дә югые». «Күлмәгең булмаса, киндер сук, киндер бәләклә. Әнә бит авыл кызлары барысы да киндер бәләклиләр». «Минем киндер күлмәк киеп йөрисем килми. Мин дә әдәм баласы бит», — дип тарткалаша Хәнифә түтәй.

Нурия үзен-үзе ярсытып, Хәнифә түтәй белән әрепләшеп озак ята. Тынычлана алмый аптырап бетә.

Аннары ул урам як күрше Садыйк абзый малае Солтанны күз алдына китерә. Солтанны ул матур итеп уйлый. Уйлагач — елмая...

...Солтан алар янынннан дәү корсаклы сары биягә атланып уза. Нуриянең, бизәнеп-ясанып, чәмчәле читекләрен киеп, капка төбендә басып торганын күргәч, ялан тәпиенең үкчәсе белән биянең корсагына типкәләп ала:

— На-а-а, үләт ялагыры! Чисти ялкаулыкка чыктың, мөртәт!

— Солтан, кая барасың? Тырмагамәллә?

— Тырмага иртә әле. Басуда кар бетмәгән. Атны йөртеп кайтам. На-а, корчангы! На-а, рәхмәт яугыры!

Солтан атын юырттырып китеп бара. Нурия аның ат сыртында дырк-дырк сикергәләвен Солтан чаттан югалганчы карап озата...

Солтан бөтен Зартугайны бер итеп Сары биядәрен чаптырып йөри. Чаптырып аргач, янә дә Нуриялар йортына килеп туктый. Аттан сикереп төшә дә Нурияне бик җинел генә итеп, читекләре-ниләре белән, энҗеле яшел калфаклары белән, чулпылы озын толымнары белән күтәреп ала, Сары бия өстенә атландыра. Үзе сикереп атлана. Алар далага чыгып чабалар. Энҗе калфак астыннан кисея яулыкны җил җилфердәтеп җибәрә, Сары биянең ялы җилдә тузгый, канатка әйләнә, алар ак болытлар яныннан, Чуртанкүл болыннары, Саклау урманнары өстеннән очып китәләр. Егылып калмас өчен, Нурия Солтанны аркасыннан кочаклап утыра. Солтан: «На-а, үләт ялагыры! На-а, рәхмәт яугыры!» дип, ялангач тәпиләре белән Сары биянең мичкә чаклы корсагына типкәләп ала. Әтисе, әнисе, Хәнифә түтәсе, кулларын каш өстенә куеп, аларның йорт турысыннан очып киткәннәрен карап калалар...

Хыял, хыял! Нинди көчле синең канатларың!

Хыял, хыял! Нинди көчсез синең канатларың!

Нурияне менә очыртып йөрдең-йөрдең дә җиргә төшердең. Солтан менә тагын атсыз калды. Нурия менә тагын борсаланып ята. Күзенә йокы керми. Солтанны ул тегермән буасына барган чактагы төсле итеп күз алдына китерә. Озынча ак чырай, кыл кебек каты коңгырт чәч, төерчекле йомры борын. Күзләр зәп-зәңгәр — аяз күк йөзе төсле. Солтан ялан аягының берсен-берсенә ышкып басып тора, аягы «чебиләп» яргаланып беткән. Шушы зәп-зәңгәр күзле, ялан тәпиле, бер караганда оялчан, икенче караганда прииот малайлары кебек усал, каты куллы малай аны үз итә.

Әнисе аңа нигмәрә-нигә тапкыр: «Нигә шул хәерче Садыйк малаена мөкиббән киттең? Уйнасаң кызлар беткәнмени сиңа?» — дип тә әйтеп карады. Нуриягә яшьтәш кызлары белән уйнау күңелсез, Солтан белән бергә булу — рәхәт.

Аның белән бергә булган чакта Таминдар бай малайлары да: «Мулла, мулла, мул ыштан, мулла кия күн ыштан, корсак кашый узыштан, бәлеш ашый тумыштан!» — дип үчекләп кала алмыйлар.

Үчекләп карасыннар, Солтан яңак төпләреннән ут чыгарыр!

Солтан шәп малай, батыр малай. Ул ялан аяк килеш кышкы суык кар өстеннән авылның бер башыннан бер башына чаклы йөгереп чыга ала, ялан аяк килеш язгы ташу суларын ерып йөри ала. Үзеннән икеөч яшькә олы Салагыш малайлары белән ут уйнатып сугыша ала, борыны канаса да еламый.

Нурия Солтанны үзен яклый алырдай кеше итеп белә. Тик менә хәзер Солтан гына аның нинди кыен хәлдә икәнен белми. Аны барысы да кыерсыта, барысы да рәнҗетә: Маруся да, әтисе дә, Хәнифә түтәсе дә... Аны берәү дә җәлләми, берәү дә кызганмый.

Нуриянең күңеле тула, ул тавышы чыкмасын өчен мендәргә капланып елый. Тагын бер атнадан — юллар өзелгәнче Пәнҗәрдән Зартугайга кайтасын, терәкле чанада ястыкка күмелеп утырасын, кайткач, Солтанны күреп, аңа барлык үпкәләрен, рәнҗешләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирәсен күз алдына китереп, очсыз-кырыйсыз уйларыннан арып-алҗып, йокыга китә...

## VI

Аксагыз тауларының аръягыннан, башкорт далаларыннан, атна буе язгы тыгыз җил исеп торды. Авырайган, авыл өстенә үк салынып төшкән соры болытларны аралап кояш карады.

Шул җитте!

Башларына салкын ак чалмаларын урап, кышның кыш буе кукраеп утырган тау түбәләре ашыга-ашыга чалмаларын салырга, кара бәрхет түбәтәйләрен кияргә тотындылар.

Кайдадыр тирәндә, иңкүлекләр төбендә, тонык кына гөжләп, кар сулары җыела, язгы дымнан бүрткән караңгы чырайлы Зартугай өйләре язгы авазларны тын гына тыңлыйлар иде.

Ягарына утыны, кияренә киеме юкның күңеленә җылы иңә, урамнарга сибелгән бала-чаганың чыркылдык шат авазларына яз алып килгән сөенеч өстәлә.

«Яз килде, кояш яз алып килде!» — диләр кешеләр.

«Яз килде, җилләр яз алып килде!»— диләр кешеләр.

Зартугай малайларын алдый алмассың: язны кояш та, җилләр дә алып килми, язны тегермәнче Чишмәнтәй алып килә.

Моннан күп еллар элек көнлекче Хисмәйнең унөч яшьлек ятим улы Каюм, Аксагыз тавы астыннан чылтырап агып яткан җиде чишмәнең суын бергә кушып, тегермән тарттырырга, Таминдар байныкы төсле зур бер су тегермәненең хуҗасы булырга хыяллана иде. Өй түбәсенең чергән такталарын алмаштырырга дип, күз карасы кебек итеп саклаган берничә тактаны улак итеп ясап, чишмәләрнең төбен тирәнәйтеп, хыялында йөрткән тегермәннең канавын да казырга керешкән иде ул.

Ләкин көнлекче Хисмәй малаена ярты чакрымлы канауны казып чыгарлык көч каян килсен дә тегермән чаклы тегермән салдырырлык акчаны ул каян алсын!

Таминдар байга башлы малай ошап куя. Ул аны үз тегермәненә өйрәнчек итеп ала, үсеп егет булгач, картаеп сукырайган Гарапша урынына тегермәнче итеп куя.

Тегермән хуҗасы була алмады Каюм, гомер буе Таминдар бай бурасын ишәйтүче булып калды, өстәвенә бик әйбәт кушаматлы да булып калды. Зартугайда аны олысы-кечесе тегермәнче Каюм дип түгел, тегермәнче Чишмәнтәй дип кенә беләләр.

Зартугай малайларына язны тегермәнче Чишмәнтәй алып килә. Инде тау түбәләре кара бәрхет түбәтәйләрен киеп өлгергәннәр, инде урамнардан, тыкрыклардан, тау битләреннән гөрләвекләр ага, инде Солтан иптәш малайлары белән бергәләп алдавыч чокырына Нәүширвән бабайны, Бөкре Гафиятне, кендекче Сафураны төшерделәр.

Суга баткан Сафура, чабата башмагына тулган суны түгә-түгә:
— Муеныгыз астына килгерләре! Мине төшермәсәгез, төшерер кеше беткәнмени сезгә, җәпәтникләр! — дип карганып узды.
Зартугай малайларының яртыдан артыгының диярлек кендеген кискән бу кортканың аларга үпкәләсә дә хакы бар иде.
Ни генә булмасын, чын яз алда әле. Солтаннар, Шәрифҗаннар, Югары һәм Түбән оч малайлары аны көн саен, йокларга яткан саен көтеп яталар. Чөнки чын яз Зартугай малайлары татлы йокыда чакта килә.
Быел да шулай булды.
Шимбә көнне Солтан көне буе абзар артларындагы канауларны кинәйтеп, базга салудан арткан карны ишегалдыннан урамга чыгарып уздырды. Иптәше Шәрифҗанны да, Пәнҗәр ягыннан сабактан кайткан мулла кызы Нәркәйне дә күрә алмады.
Кичке кысыр умачны ашап, караңгы төшкәч тә әле капка буенда болганган Солтанны әтисе Садыйк куып керттe: «Йокларга вакыт, иртәгә иртүк җәтмәне ямарбыз. Быел ташу суы мул булырга охшап тора. Икәүләп әзрәк балык тота алмабызмы»,— диде.
Йокысы килмәсә дә, Солтан кереп ятарга мәҗбүр булды.
Таңга чаклы борсаланып ятты. Күңеле нидер сизенә, нидер көтә иде.
Бермәлне, чайпап кына йокыга киткәч, йокы аралаш бер өн ишетте. Баштарак ул өн, урманда адашып йөргән кеше тавышыдай, ерак һәм тонык иде. Тора-бара көчәйде, иркенәйде. Солтан, күзен кулы белән уа-уа, ялан аякларын сәке йөзлегеннән салындырып, торып утырды.
Ныгып, көрәеп җиткән куәтле тавыш, Зартугай урамнарына гына сыеша алмыйча, шәрә ябалдашлы агачлар, салам түбәле тәбәнәк йортлар, каравыл өе түбәләре өстеннән узып, Таминдар байның калай түбәле, ике катлы йортларына, таш кибетләренә, Аксагыз тауларына һәм ерак урманнарга бәрелеп, шаңдау булып кире кайтты.
— Зартугайлар, торыгыз! Яз башлыйбыз, яз ясыйбыз!
Солтан тула оек өстеннән күтәрмәле чабатасын киеп, өстенә ямаулы бишмәтен, бүреген эләктереп урамга атылды.
Авыл йокысыннан уянган. Тәрәзәләрдә утлар кабына. Шыгырдап капкалар ачыла. Югары оч белән Түбән очны тоташтырып этләр өрә. Озын саплы багор, балта-көрәк, тимер лом тоткан агайлар, быдыр-быдыр сөйләшеп, тыкрыкларга җыела башлаган; капка астыннан, коймачитән башларыннан бала-чага коела; тау астыннан инде урта урамга күтәрелгән кодрәтле тавыш халыкны урта урамга, каравыл өе янына туплый.
Солтан каравыл өе янына килеп җиткәндә, халык төркеме кара яу чаклы булып җыелган иде. Солтан баш өстенә күтәреп фонарь утын болгаган Чишмәнтәйнең әзмәвердәй олы гәүдәсен күреп калды.
Халык Чишмәнтәй артыннан тегермән буасы ягына юнәлде.
Солтан, аяк астында буталган ваграк бала-чаганы узып, үзенә кирәкле кешене эзли башлады.
Аяк астында төнгелеккә чыйраган юка бозлар чытыр-чытыр ватылып кала, төнге салкыннан ныгыган, утырган кар чабатаның биек агач күтәрмәсенә шакылдап бәрелә иде.
Ниһаять, ул аны күрде: мулла кызы Нәркәй биек үкчәле читеге, нечкә билле бишмәте белән фонарь яктысында күзгә чалынды. Аны шундук куып җитү, аның белән янәшә атлау, аның белән җитәкләшеп алдан чабып китү тойгысы тыелгысыз бер дәрт белән Солтанны алга ашкындырды. Ләкин урам тулы халык иде, Нәркәй-Нуриянең өстендә затлы кием иде, ә үзенең күтәрмәле чабатадан, ертык бишмәттән икәнен тоеп бару Нурияне куып җитеп, сүз дәшүдән тыеп калды аны.
Ул халыктан арткарак калып төште Иш буена. Учаклар яккан, таганнар аскан җиргә якын да килмәде.

Мулла кызы Нурия гел тагannaр аскан җирдә, учаклар кабызган урында чуала иде.

Чишмәнтәй, авылның гүәрдин егетләрен сайлап, елга ярына тезеп чыкты. Типсә тимер өзәрлек тимерче Лотфины арык ачучыларга башлык итеп куйды, аннары субайларны боздан сакларга ун егетне сайлап алып, Шаукымлы Шәяхмәтнең аларга башлык булуын сорады; язны, ташу сулары акканны үлеп яратучы Шәяхмәт бу эшкә бик теләп риза булды, күн итекле аяклары белән күлләвек суларын чәчрәтеп баса-баса, шундук субайлар ягына китеп тә барды.

Боз ватып торучылар аерым әртилгә оештылар.

Тагын да арырак киткәч, таякларын корсакларына терәп, гайрәт орып торучы картларга Ләлек мамык чыбыркы командалык итә, шатлыклары эченә сыймаган бала-чага янында Солтан белән Шәрифҗан мәш килеп йөриләр иде.

Чишмәнтәй баш өстенә күтәргән фонарен янә болгап җибәрде.

— Санилә-ә-ә-ә-ә-ү-ү-ү, үзе бара, үзе бара, сама пайдут, әйдә һо-ооп! — дип, арык ачучылар җыр сузды.

Боз кантарларын субай араларыннан этеп чыгаручылар җырны бердәм тавышлар белән күтәреп алды.

Эшче-гаскәр һөҗүмгә күчте: боз ватты, субайларны боздан аралады, тегермән буасының арыгын күтәрде.

Чишмәнтәйнең яз башлавын Зартугай йортлары танга чаклы ишетеп торды.

Кыш буена боз астында зарыгып яткан Иш суы, дулап-гүләп, арыклары ачылган капкага ташланды.

Яр буендагы Зартугай кешеләрен тыелгысыз бер тойгы — ташкын су белән уянган яз тойгысы биләп алды.

Яз башлау йоласының иң матур өлеше башланды. Ел саен кабатлана торган гадәт буенча, яшь-җилкенчәк, буаның түбән ягына чыгып, боз кантарларына салам көлтәләре куеп, ут ягып җибәрә башладылар. Иш өсте кып-кызыл ялкын бөркеп, әкрен генә агып барган бозлар белән тулды. Шул утларга карап, картлар узган яшьлекләрен искә төшерделәр, җаннарына беренче мәртәбә яшьлек тойгысы кабынган үсмерләр балкып янган утларга, аларның су өстенә сузылган шәүләләренә таң калып карап тордылар.

Нуриянең дә җанында ялкын дөрли, аның да шул ялкынны ут итеп язгы ташкын сулары белән агызып җибәрәсе килә иде.

Күрше Садыйк абзый малае Солтанның башкалардан аерылып, түбәнрәк киткәнен күрде ул, күрде һәм аңа ут җибәрәсе килде.

Аның беренче җибәргән уты Солтанга барып җитә алмады, ун метрлар баргач, бөялеп торган бозлар янында яр буенда туктап янып бетте.

Ләкин аның үз утын яр буенда гына яндырып калдырасы килми, Иш суының урта бер җиреннән җибәрәсе килә, ул утны барлык Зартугай халкы күрүен тели иде.

Нурия, кулына салам көлтәсе тотып, үсмер егетләрдән дә уздырырга теләп, бер урында бөялеп торган бозлар өстенә кереп китте.

Корсакларын таякларына терәп, гайрәт орып торучы картлар аны күреп алдылар да куркышып кычкырып җибәрделәр:

— Бу ниткән башсызлык?!

— Карагыз әле, кара, харап була бит!!!

— Йөгерегез, ачык авызлар! Нәрсә карап торасыз?

Халык яр читенә өелде. Бөкре Гафият, Нуриягә исеме белән дәшеп, кире чыгарга куша, Ләлек мамык чыбыркы, киресенчә, аргы якка чыгып җитми торып, туктамаска киңәш итеп кычкыра башлады.

Боз ватучы, субай саклаучы егетләр эштән туктады.

Бәлагә тарыган кызны кайгыртып, халык шул тугайга агылды.

Ләкин Нурия үзенә дәшкән тавышларны ишетми, кулына тоткан салам көлтәсен селти-селти, тар басмадан чыккан кеше кебек, әле бер, әле икенче якка авышып, боздан-бозга күчә, эчкәрәк керә бара иде.

Хәвефләнү көчәйде.

— Харап була! Кем кызы бу башсыз?

— Габбас мулланыкы.

— Кит аннан, вәт ирдәүкә!

Нурия ай-вайга карамый, тавышларга колак та салмый.

Аңа таба бик дәү боз кантары кузгалды.

Яр буе өнсез калды. Нурия басып торган боз өентесе дә кыймылдый башлады. Халык аһ итте. Инде башсыз кызга дәшмиләр, яр буена өелешкән егетләрне тиргиләр иде.

— Нәрсә карап торасыз, ачык авызлар?!

— Чистый! Күрәләтә кызны харап итәләр!

— Керегез инде тизрәк!

Хәвефне Нурия үзе дә сизеп алды. Каушады. Әрле-бирле сугыла, кире борылырга итә башлады. Ләкин кире борылырга юл калмаган иде инде.

Нурия, бозлар кыймылдашкан урынны әйләнеп узып, тынычрак бер урынга — боз күперенә барып чыкты.

Яр буе иркен сулап куйды.

Ләкин тынычланырга иртә иде әле. Кызый, озак та үтми, халыкны тагын ут йотарга мәҗбүр итте. Ул, саламына ут төртергә дип иелү белән, һич көтмәгәндә, зур гына боз кантары су астыннан килеп чыкты. Нурия басып торган урыннан унбиш адымнар гына ары калыкты боз кантары һәм Нурия басып торган бозларга якынлаша башлады.

Нурия аны күрми, көлтәсенә ут кабыза алмый азаплана.

Боз кантары отыры якынлаша.

Түбән очның ике егет, тегермәнче Чишмәнтәйгә ияреп, боз өстенә сикерделәр. Алар янына Шаукымлы Шәяхмәт тә сикереп килеп төште. Унөч яшьлек үсмер кызны бик җиңел үткәреп җибәргән боз күпере, дүрт ир-атны берьюлы күтәрә алмады, алар төшкән урында боз янтаеп китте дә, егетләр суга төшә язып, ашык-пошык кире чыктылар. Өстәвенә бу саксыз хәрәкәт бөялеп торган бозларның тынычлыгын алды. Алар селкенешә, кыймылдый башладылар.

Моны Нурия дә сизде. Чырыйлап кычкырып җибәрде.

Нурия тавышы Солтанның җанын айкап алды. Аны-моны уйлап торырга вакыт юк иде, кулына багор тотып, аерым-аерым аккан бозлар аша сикерә-сикерә, Нуриягә таба китте. Үзе өчен курку аның башына да килми, нидер киңәш итеп кычкырган тавышларны да ишетми, аның бөтен уе Нуриядә, бары тик Нуриядә генә иде.

Ул килеп җиткәнче, Нурия белән ике ара ерагайды.

Хәзер ул аны теге ярга чыгып коткарса гына коткара ала иде. Бөтен ихтыярын ул теге якка юнәлтте. Сикереп булырдай җирдә сикерде, сикереп булмастай җирдә боз кантарын багоры белән үзенә тартып китерде. Ничек итсә итте, теге ярга Нурия агып барган боздан алдарак барып җитте.

Боз яр читеннән бер метрлар ары йөзеп бара иде.

Солтан, багорын сузып: «Ябыш! — дип кычкырды.

Нурия ябышты.

Солтан Нурияне бозы-ние белән яр буена тартып китерде, әмма яр буенда вак бозлар җыелып тора, яр читенә үк бозны китереп җиткерү мөмкин түгел иде.

— Сикер! — диде Солтан.

Нурия сикерде һәм шапылдап яр буендагы суга килеп төште.

Солтан аны шундук яр читенә тартып чыгарды.

Нуриянең бишмәт итәгеннән шабырдап су ага, биек үкчәле чәмчәле читегеннән баскан саен чупырдап су чыга, аның янына йөгереп, күпер аша чыгып җиткәннәр аны учак янына барырга, киемен киптерергә кыстыйлар иде.

Нурия, дер-дер калтыравыннан, халык арасында лычма су булып басып торуыннан уңайсызланып, өйләренә таба йөгерде.

Байтак йөгергәч, Солтан килмиме дип, борылып карады.

Юк, Солтан килми, Солтан куч булып бер урынга өелгән халык арасында калган иде.

...Капка келәсе шылтырап төште. Нурияне курку биләп алды. Әтисе ни дияр аңа, әнисе? «И хәсрәт өчен туган бала...» — дип тиргәрләрме? Шуларны искә төшергәч, эченә янә суык йөгереп, бөтен тәне калтырый башлады.

Ләкин гаҗәп хәл: берәү дә тиргәмәде аны. Ишек ачарга да чыгучы булмады.

Нурия бикләнми калган чолан ишегеннән гаҗәпсенә бирел эчкә узды, текә баскыч буйлап югарыгы катка күтәрелде.

Ишек төбендә бер генә мизгел юанып торды.

Өйдән бер тавыш та ишетелми иде. Ишекне ачып эчкә керде. Кучкарда җиделе лампа яна, аның филтәсе бик бәләкәй генә калдырып кысып куелган. Сәкедә, кабартып салган зур мамык түшәктә, әтисенең урыны буш, әнисе мамык юрганны башыннан ук бөркәнеп яткан, әнә шул әнисе яткан урында юрган никтер селкенгәләп тора иде.

Нурия бик аптырап:

— Әни, әнием, — дип дәште.

Юрган әкрен генә ачылды, аннан әнисенең ак ситсы яулык бөркәнгән башы күренде. Ул өстен чишенми яткан, яшел атлас күлмәге бөгәрләнеп беткән. Муенындагы сары гәрәбәләре бер-берсенә бәрелешеп, әкрен генә шылтырашып куйдылар.

— Кайларда югалып йөрисең син, бәхетсез бала? — диде әнисе, яшьле күзен сөртеп.

Ул күптән елый иде бугай: бите шешмәкләнгән, күз төпләре кызарган, иңбашлары дерелди. Үксеп җибәрүдән ул үзен көч-хәл белән генә тыеп тора, җебеп киткән борынын әледән-әле мышкылдатып тарта иде.

Нурия су буенда булган хәлләрне шундук онытты. Тәне кызыша башлады. Сәке буена ук килеп:

— Ни булды сиңа, әнием? — диде.

Бу сорау Шәмсениса абыстайның соңгы ихтыярын җимереп ташлады. Кызының җилкәсеннән кочып, сулкылдап елый-елый, такмаклап тезеп китте:

— Бигрәк бәхетсез икән бу башкайларым, а-а-ай... Ни хәлләр итим, кайларга барып сугылыйм? Кеше күзләренә ничекләр күреним, ы-ы-ы-ы...

— Ни булды соң, әнием-бәгърем, әйт инде?

Шәмсениса абыстай кискен бер хәрәкәт белән күз яшен сөртеп алды:

— Хур итә бит әтиең безне. Янмаган утларга сала бит, мөртәт. Яшь катынга өйләнә бит... — Бите буйлап аккан күз яшен, кулы белән битенә сылый-сылый сөйләнеп аргач, кинәт исенә төшеп, Нурияне ашыктыра башлады. — Нишләп болай юеш соң син? Ник алыштырмыйсың соң бу киемнәреңне? Ник аптырап торасың, тилебәрән орлыгы ашамагансыңдыр бит?!.

Ул, беразга гына булса да хәсрәтен онытып, Нуриянең өс-башын салдырды, кием шкафыннан аңар коры киемнәр алып килеп бирде; таушалып беткән яшел атлас күлмәк итәге белән идәнне себереп, яу-

лык астыннан таралган кара чәчләрен тузгытып, ул берүзе бөтен өйне бетереп йөри иде; йөри торгач, арды, алҗыды, лып итеп сәке йөзлегенә килеп утырды, тагын кинәт йомшап китеп, кызын кочаклап алды, кайнар күз яшьләре белән Нуриянең битен чылатып, сыгылып төште...

## VII

Иш елгасы белән мул сулы Каманың бергә кушылган төшендә — иксез-чиксез болыннар, әрәмәләр, зур һәм кечкенә күлләр белән чуарланган коба таллы тирән ерганаклар, тарлавыклар арасында йокымсырап кына утырган бер авыл күрсәгез, ул Зартугай булыр.

Бик күп еллар узганнан соң Солтан белән Нурия тәрҗемәи хәлләрен «Туган авылым Зартугай» дип башлап җибәрерләр. Хәзергә Зартугай бер генә ягы белән дә тирә-күрше авыллардан аерылып тормый: чәчү чәчә, печән чаба, ашлык суга, ел яхшы килгән чакларда каз өмәләре үткәрә, йорт җиткезә, көзге тук айларда йортка килен төшерә. Болар — сала мужигының ел да саен кабатлана торган төп эшләре. Шуннан соң кышкы озын төннәрдә һәм күзгә дә күренми уза торган кыска, буранлы көннәрдә авыл янә дә бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре белән яши: казна салымнарыннан башы чыкмый иза чиккән ярлы-ябагай кулы белгән һөнәргә тотына: итек баса, чыпта суга, дуга бөгә, мунчаладан һәм сүстән бау ишә, чабата ясый, чана карамалый, ишле гаиләсен киендерергә киндер суга, җеп эрли, тузган-искергән чикмәненә кырык беренче ямавын сала...

Агачларны сыкы сарган кышкы суык иртәләрдә авылның өч йөз алтмыш ике морҗасыннан, туп-туры булып, аксыл төтен баганалары күтәрелә; кышкы нурсыз кояш сыкы томаннары арасыннан, күгелҗем алка белән уратылган битен сузып, тимер табанлы чаналарның каты сызгыртып кышкы юлдан узганнарын, авыл мужикларының суыктан сукрана-сукрана, Саклау урманына утын кисәргә киткәннәрен карап озатып кала.

Кыш — күңелсез вакыт: төннәре чамасыз озын, көннәре чамасыз кыска. Югары мәхәлләдә Сөләйман хәзрәт, Түбән мәхәлләдә Габбас мулла авыл балаларына һәфтияк ятлаталар; мал-туар абзарын чистарттырып, утын кистереп, ишегалларын көрәтеп ир малайларның җанын алалар. Кыз балаларның гомере Сөләйман хәзрәт йортында җеп эрләп, йон язып, идән-сәке юып уза.

Әчпошыргыч дәрәҗәдә күңелсез вакыт кыш: өскә кияргә җылы кием булмагач, урамга чыга алмыйсың, чана шуа алмыйсың; халыкны каравыл өенә җыярга чыккан Нәбкәй старостаның кырпулап кама тоткан кара бишмәте өстеннән түбәтәй чаклы ак калаен асып, капка саен таягы белән сукканын тәрәзәдән генә карап утырырга кала. Староста артыннан авыл куштаннары юыртып баралар.

Кичке якта, икенде һәм ахшам намазлары алдыннан, Югары һәм Түбән очта ике мәчетнең икесендә дә мәзиннәр, бер-берсен уздырып, азан әйтә башлыйлар. Төннәрен Нәүширвән картның агач шакылдавыгы, каракларны-бурларны куркытып, илгә иминлек чакырып, ярты төн узганчы, таң әтәчләре кычкыра башлаганчы шакылдап йөри.

Шакылдавык дигәннән Солтан Нәүширвән картның төне буе йөргәнен әтисе сөйләве буенча гына белә иде. Габбас мулла кызы Нөркәйне язгы ташу суына батып үлүдән коткарып кайтканнан соң үзе дә ишетә башлады. Төн уртасына чаклы күзенә йокы кермичә, язгы тын авазларны тыңлап, йокламавын әтиләренә сиздермәс өчен, чикмәнне башыннан ук бөркәнеп яткан Солтан, төн урталары узуга, ерактан ук шакылдавык тавышын ишетә, тыны белән суырып алырдай булып, аны үзләренә якынайтып китерә.

— Тук-та, тук-та, тук-та! — дип уза Нәуширвән бабай бер узганда. Икенче юлы инде ул:

— Йок-ла, йок-ла, йок-ла,— дип, Солтанга киңәш итә.— Нурия-Нәркәйне күз алдына китереп, газаплы сагышларга батып ятма,— ди.— Мулла кызы сиңа тиң түгел, мулла кызы сиңа тиң түгел,— дип каныга.

Шундый газаплы сагыш белән, язның йокысыз төннәре белән, Нәуширвән картның шакылдавык тавышын тыңлап бер атна уза, ун көн уза, этисе бер дә бер көнне Солтанга әйтеп куя:

— Йокларга иртәрәк ятарга кирәк, малай! Иртәгә таң белән кырга чыгасы!

Солтан кырга чыгуның нәрсә икәнен белә. Узган елны да, аның элекке елны да кырга чыкты инде ул. Авыл малае хафасыз тормыш өчен, татлы хыяллар өчен яратылмаган. Ун яшеннән сине тырма артыннан йөгертә башлыйлар, унике яшендә, җирнең хуҗасы итеп, сука башы тоттыралар. Солтаннарның озын яллы, атылып чыгарга торган шәмәхә күзле Сары бияләре сырт өстенә атланып йөргәнне яратмый, аның артыннан дилбегәгә ябышып, йомшак җиргә бата-бата, көне буе чабарга туры килә. Узган елны арып-алҗып, дилбегәгә асылынып бара башлаган иде, Сары биянең башын чайкап җибәрүе булды, Солтан корсагы белән җиргә капланды...

Дилбегәгә тотынган килеш, җир өстеннән сөйрәлеп бару — хурлык. Хурлык... Хурлык... Сине бөтен басу карап тора. Сары бия бара да бара... Синең каршыңа сыерлар мөгрәп килә, синең каршыңа атлар кешнәп килә, Сары бия һаман бара. Ак болытлар өелгән офыкны узып китәсең, Сары бия, тоякларын атлап барган кебек кыймылдатып, күккә күтәрелә. Солтан да дилбегәгә ябышкан көе бик җиңел генә күккә күтәрелә. Ак болытлар аның әле уң ягыннан, әле сул ягыннан узып торалар, битләренә бәрелеп, каз канаты белән сыйпагандай рәхәт сыйпыйлар. Ул, торналар шикелле, киек казлар шикелле, кулларын канат итеп оча. Ә бит ул ни гомерләр очарга, авыл кешеләре алдында күккә күтәрелеп, канатлар җилпеп очып китәргә хыялланып йөргән иде. Бактың исә бу эш бик җиңел икән. Аның өчен Сары биянең дилбегәсенә генә тотынып барасы икән. Тукта, Сары бия кая китте соң әле? Этисе ачуланыр бит, суканы Сары биясез ничек сукаларбыз, тырманы ничек тырмаларбыз?

Солтан болытлар өстеннән япа-ялгызы оча.

Болытлар артыннан аккош килеп чыкты. Кеше төсле сөйләшә белә, имеш.

— Солтан, син мине эзләп очасыңмы?

Солтан: «Мин сине эзләп очам»,— дип әйтергә тели, ләкин әйткән сүзе ишетелми... Аккош аның янына ук килеп канатын суза, Солтан аның канатыннан тотып ала, караса... аккош дигәне аккош түгел, аппактан киенгән, башына энҗеле ак калфак кадаган, аягына аппак тула оек белән чабата кигән Нурия-Нәркәй... Чабата аңа шундый килешә, ул башка чакта бик сирәк кына читек-кәвеш киеп йөри икән. Чабатасының баулары кояш нурында шундый җемелди, шундый сары булып күренә... Чабата баулары гына түгел, Нәркәй үзе дә алтыннан койган кебек сары булып күренә. Караса — табак чаклы сары кояш, нур сибеп, аларга каршы оча, аның нурыннан күзләр камаша, күзләр камаша...

Алар Нәркәй белән икәүләп әкрен генә түбән төшәләр, йортлар түбәсеннән көтү мөгрәп чыгып барган урам өстеннән очалар.

Астан этисе кычкыра:

— Солтан, тор, малай, тор. Йоклап ятар чак түгел!

Солтан куркып күзләрен ача, тәрәзәдән иртәнге кояш нуры күзгә бәрә, өстенә киңдер күлмәк, алача ыштанын кигән, тула оек өстеннән

чабата бәйләп куйган этисе, сары сирәк сакалын сыпырып, сәке буенда басып тора.

Солтан бер генә минутка күзен йома, төш рәхәтлегеннән аерылырга теләмичә, иркәләнеп ята.

Әтисе аның өстеннән чикмәнне тартып ала, Солтан күзләрен уып торып утыра.

Ак яулыкны өчкелләп бәйләгән, бала итәкле зәңгәр ситсы күлмәген бөрмәсенә кыстырып, җиңнәрен сызганып куйган әнисе, кулына табагач тотып, почмакта мич каршысында кайнаша, аның бите мич кызуыннан алсуланган, җыерчыклары язылган.

«Әни кабартма пешерә. Чәчүгә чыгабыз икән», — дип уйлый Солтан.

Ул, ишегалдына чыгып, лапас артына барып килгәч, комганнан әнисе тутырып куйган җылы су белән битен юа. Юынган чакта читән аркылы Габбас абзыйлар ягына күз төшергәләп ала. Ул тарафта хәрәкәт-мазар сизелми, мулла йортында йоклыйлар булса кирәк әле, тәрәзә капкачлары да ачылмаган, урыс капкалары да бикле. Бар дөньяда рәхәт кешеләр...

Солтан белән этисе, сәке йөзлегенә кара-каршы утырып, ипи белән бәрәңге ашыйлар. Башка көннәрне бәрәңгене шул көе генә ашый торганнар иде, бүген, кырга чыгасы булгач, әниләре туң май кыздырып китерде.

Солтан чырага кадаган бәрәңгене кыздырылган майга тыгып болгап ала да авызына кабып җибәрә. Кайнар икән каһәр — ул бәрәңгене, ах-ух килеп, авыз эчендә әйләндергәләп суытырга тотына.

— Кая шул хәтле ашыгасың? — ди этисе. — Иплəбрәк кылан.

Солтан каршы сүз дәшми, икенче бәрәңгене озаклап кабыгыннан әрчи, кисәкләргә бүлеп ашарга керешә.

— Тизрәк бул әле син, малай! Кеше эшен бетергәндә без басу капкасыннан чыгып барсак, бер дә күңелле булмас.

Солтан үзалдына елмая: аны бүген бер нинди шелтә дә чыгырыннан чыгара алмый. Таң алдыннан күргән төше әле һаман күз алдында балкып тора.

Тагын ярты сәгатьтән Сары бияне кабык арбага җигеп, арба өстенә тимерле агач сабанны, тырманы салып, ата белән улы кырга барырга җыеналар. Көндезгә дигән ризыкны Мәүдүдә җиңги шакмаклы тастымалга төреп алып чыга.

— Кара аны, Садыйк, сиңа әйтәм, кулыңа гына тотып бара күр, яме. Арбага куя күрмә, катык йөртә торган бердәнбер чүлмәгем, ишетсен колагың, ватып кайта күрмәгез, ике кулсыз итәрсез,— ди. Анннары ул көндәлек мәшәкатьтән, иренә дәшү кебек гади сүздән тәңресенә күчә. Шуңа күрә сүзе әкренрәк, серлерәк булып чыга.— Илаһи рабым, хәере белән булсын. Игеннәр уңсын, ил өстенә ачлык килмәсен. Бәла-казадан үзең сакла, ходаем...

Ул аларны читән капканы ачып озатып кала.

Мулла капкасы төбенә Бөкре Гафият чыккан.

— Кузгалдыкмы, Садыйк абзый? — ди Гафият.

— Кузгалдык әле, күрше. Сезнекеләр ничек соң?

— Безнекеләр дә кузгалыр, боерган булса... Мулла абзыйның намазлык өстеннән төшкәнен көтеп торам әле.

Солтанның уеннан яшен тизлеге белән узып китә: әллә Нурия дә барамы? Ул үзалдына әкрен генә елмая. Нигә барсын, кызларга сука сукалаган җирдә ни калган...

Аксагыз тавы өстеннән тәртә буе күтәрелгән кояш читән коймаларны, урыс капкалардан берәм-берәм чыккан җигүле атларны, арбага бөкшәеп утырган агайларны алсу нурга мана. Йокыларыннан соң уянган карт әтәчләр, игенчеләр белән саубуллашып калырга теләгәндәй,

тамак ярып кычкыралар; өстенә иске плүш бишмәт кигән бер карчык, көтүдән соңга калган сыерын тал чыбыгы белән куып, ашыктырып алып бара; читәннәр буена төртеп чыккан беренче яшел чирәм өстендә сары бәбкәләрен иярткән ана каз чүпләнеп йөри, аның янында ата каз, муенын бик хәтәр сузып, Солтаннар атына ысылдап калды.

Солтан, иртәнге салкыннан куырыла төшеп, арбадан аякларын асылындырып утыра. Авыл башына килеп җиткәч, этисе:

— Бар, капканы ач, — диде.

Йөгереп килергә җай табылуга сөенеп, Солтан арбадан җиргә сикерде, кыйшаеп җиргә чүккән галәмәт дәү капканы көчәнеп ачып, ат узгач, шыгырдатып кире япты, сүсәргән мунчала бавын баганага эләктереп куйды.

Бер чирек сәгатьтән басуга килеп җиттеләр.

Басу өсте буш иде әле.

Этисе башта басу башындагы бөгәлҗә тамганы карап килде, бер аршын зурлыгындагы тамга үз урынында икәнне күргәч, күңеле тынычланып, Сары бияне арбадан туарды, сукага җигә башлады. Солтанны эрәмәлектән чыбык-чабык җыеп килергә җибәрде.

— Учак ягарбыз, әбәткә чәй кайнатырбыз, — диде.

Алар шул эшләр белән кайнашкан арада Кола биясен кабык арбага җиккән Хафиз солдат та килеп җитте. Бер аягын япон сугышында калдырып кайткан бу аксак солдат муенга тубал асып чәчү чәчә алырлык түгел иде. Садыйк абзыйга ул: «Без бергә-бергә эшлик инде. Мине ярдәмеңнән ташлама, Садыйк», — дип гозерләнгән иде.

Шуннан бирле җир кишәрлекләре янәшә килгән Хафиз солдат белән Садыйк абзый һәр язны суканы бергә сукалыйлар, тырманы бергә тырмалыйлар; Садыйк абзый икесенең дә җирен чәчеп бирә.

Хафиз солдат, Кола биясен җигелгән килеш үз кишәрлегендә калдырып, агач аягын селти-селти, басу өсләтеп, Садыйк абзый янына килде.

— Әссәләмәгаләйкүм. Исән-сау гына килеп җиттегезме?

— Вәгаләйкүмәссәләм. Хәзергесе көнне исән-имин. Быел менә малайга сука башы тоттырып карарга исәпләп торам. Син ничек уйлыйсың, Хафиз, булдыра алырмы? — диде Садыйк абзый, атын сукага җигеп бетереп.

Бик зур чытырман өемен бау белән бәйләп, аркасына күтәргән Солтан килеп җитте. Хафиз солдатның яңаклары чокырайган какча йөзенә, Солтанны күрүгә, нур йөгерде:

— Уһу-һу! Гүәрдин егет булган бит бу! — дип, үсмер малайның аркасыннан какты. Бу аның Садыйк абзый соравына җавабы да иде бугай.

Вакытны бушка үткәрергә ярамый иде, кыскача гына хәл-әхвәл сорашканнан соң, Хафиз солдат үз биясен тырмага җикте.

Ул арада басу өсте күз күреме җирдә кара туры, сары туры, алмачуар, тимер күк атлар белән, арбалар белән, чикмәнле, бишмәтле, чабаталы агайлар белән тулды.

Бия күргән айгырлар, сыннарын тетрәтеп, ярсып, кешнәп җибәрәләр, аларның язгы дәртле авазлары Аксагыз тауларына, Саклау урманнарына бәрелеп, шаңдау булып кире кайта иде.

Ызаннардагы узган елгы әремнәрдән, чыбык-чабыктан басуның төрле урынында учаклар ягып җибәрделәр. Кыш буена салкыннан бөрешеп, кышкы озын караңгы төннәрдән күңелләре түнеп беткән ир-атның, карт-корының, егет-җилкенчәкнең язгы басуда, дымлы җир исе, беренче буразналар актарылганда өскә калыккан тамыр исе, янган учаклардан аңкыган төтен исе күңелләрен кузгата, әйтеп бетергесез

рәхәтлек, биек зәңгәр һава белән, ак болыт өемнәре белән, сабан тургайлары моңы белән кушылган иркенлек, киңлек, хөрлек тойгысы уяталар; кешеләр, язны көтеп алган, кояшка күкрәк киереп, беренче бөртекне көтеп яткан шушы җир белән уртаклыкларын тоеп, эшкә тотындылар.

Садыйк абзый, улына сука башын ничек тотарга икәнен күрсәтеп биргәч, бисмилласын әйтеп, ат башына таба китте. Солтанның, сабан туе көрәшчесе кебек, колач җәеп, ике куллап сабан сабына тотынуы, аннары алга иелә төшеп, җай гына атлап китүе, аның артыннан җемелдәп кара буразна сызылып калуы аның өчен дөньядагы барлык куанычлардан да куанычлырак иде. Бу көнне озак көтте ул. Олы улы Мөхәммәтша Ижау заводына эшкә киткәннән бирле көтте. Инде менә аның кул алмашчысы үсеп житте, шөт иншалла, ул аннан аерылмас, ул аның картаймыш көнендә туйдыручысы булыр.

Сәгатьләр буе дәшми-тынмый эшләделәр.

Кола биясе өстенә иске бишмәт ябып, бөгелми торган агач аягын тырпайтып утырган Хафиз солдат, авыз эченнән ниндидер борынгы моңлы көйне көйләп, алар артыннан ашыкмый гына тырмалап килә.

Буразнада актарылып чыккан татлы тамырга, корт-суалчанга кара каргалар, сыерчыклар ябырылып төшә. Алар, һич тартынып тормастан, Солтанга бөтенләй диярлек ияреп баралар, тырак-тырак сикерешәләр, атлар җир башында борылган чакта дәррәү очып китәләр дә тагын көтүләре белән буразнага ябырылалар...

Кояш, шактый югары күтәрелеп, баш өстендә кыздыра башлады. Буразналардан, тырмалап узгач күпереп калган җир өстеннән аксыл пар күтәрелә иде.

Әбәткә туктарга булдылар.

Садыйк абзыйның киндер күлмәге — арка һәм күкрәк турысында — юешләнеп тәненә ябышкан, җыерчыклы муеныннан, җилдә җилфердәп торган сары сакалыннан, сәленке мыегыннан пар чыга, авызы ачыла төшеп, гыжылдап сулый иде.

Хафиз солдат, атын тышаулап, ызанга җибәрде, ат өстенә атланып йөрүдән юешләнгән алача ыштан төбен сыпыргалап, аксый-туксый ызанга килеп ятты.

Тастымалдан каймаклы катыкны, Мәүдүдә җиңги пешереп биргән арыш кабартмасын алып бик әйбәтләп мүкелдәтергә тотындылар. Өзлексез сука башы тотып йөрүдән, гадәтләнмәгәнлектән, Солтанның ике кулы да талган, бөгелмәслек булып каткан иде.

Хафиз солдат кыршылып беткән күн букчасыннан башлы суган белән тозлы балык алып, кара ипи чыгарып уртак табынга куйды. Ят ризыкка бик теләп үрелделәр.

Таганнан корымлы чиләк белән чәйне алып килгәндә, озын буе белән сузылып, Шәяхмәт килеп житте. Шомырт кара мыеклы, кояшта янган алсу, сау-сәламәт йөзле бу кеше сөрелмәгән җирне күн итекле аяклары белән үлчәп килгәндәй, салмак атлап аркылыга ярып чыкты да шаулатып сәлам бирде:

— Эшләрегез уң булсын, игенчеләр!

— Бергә-бергә булсын, — диде Садыйк абзый. Ул моны кычкырып түгел, авыз эченнән ботка пешереп кенә әйтте.

Бертуган энесе булса да, Садыйк абзый Шәяхмәтне бигүк өнәп бетерми. Җиргә берекмәгән кеше Шәяхмәт. Язгы чәчүне дә, урып-сугуны да бик әллә ни теләп эшләми, ач калмагаем дип кенә эшли. Халык арасында Шаукымлы Шәяхмәт дип даны чыккан бу кеше, беренче кар төшү белән, Таминдар бай Тураевтан әҗәткә акча алып, әртил җыя, шул әртиле белән кышның кыш буе Тугыз буй урманнарында диләнке кистереп ята. Кама суы ярларына кайтып төшкәч, җәй буена Чаллы белән Чистайга сал куа. Тирә-якта аны сал өстенә салып куйган зәңгәр-

сарылы йортларыннан-карванкаларыннан таныйлар, егетлеген, чаялыгын мактап:

— Шаукымлы Шәяхмәт кузгалды. Чулманга ямь керде! — диләр,

Зартугайга кайткан чакларында ул Садыйк абыйсы янына чирегe белән аракы күтәреп, Мәүдүдә җиңгәсенә кәшимир яулык алып килә. Абыйсы аны башта сагынып каршы ала, берәр кружка төшереп алгач, малны табып та тота белмәгәнe, ат койрыгына такканы өчен тирги.

Менә бүген дә, ызанга кырын төшеп, калай кружкадан мәтрүшкәле кайнар чәй эчкән чакта, Садыйк абзый энесенә шул яктан суктырды:

— Салларың әзерме соң, Шәяхмәт?

— Әзер, абый. Ә нигә?

— Күпмерәк табыш алырмын дип исәплисең?

— Хатын белән үземә кыш чыгарга җитәр әле.

Садыйк абзый кружкасыннан бер йотым чәй уртлап куйды, киндер күлмәк җиңе белән мыегын сөртеп алды, аннары ашыкмый гына әйтте:

— Кулларың алтын бит синең, зимагур. Синең урыныңда мин булсаммы? Һи, җүләр! Синең урыныңда мин булсам...

— Я, я, син булсаң нишләр идең? — Шәяхмәт ызанда кырын яткан жиреннән торып утырды, папирос алып кабызды, Хафиз солдатка тәкъдим итте, тегесе алмады, «кәҗә сыйрагы» төреп, ирене белән чылатып ябыштырырга керeште. — Я, абый, син булсаң нишләр идең? Сөяктән сарай салыр идеңме? — Хафиз солдатка күз кысып алды.

Садыйк абзыйның хәтере калды. Эчә торган чәйле кружкасын ул үзеннән читкәрәк этеп куйды, ходай тәгалә кызганып кына биргән сирәк сары сакалын дәү кара кулы белән учлап, ачуланып сөйли башлады:

— Сөяктән сарайны сарбай салсын. Мин Таминдар байныкы ише аяклы амбар салдырырыем. Балтач алпавыты белән кампанҗәгә кереп, өязне агачка күмеп ташларыем. Менә шуннан соң Таминдар хаҗи ярышып карасыные минем белән! Булдырырыемы? Ай-һай! Биш йөз ел буе яшәп килгән Тәфкилефләр нәселе диләр аны! Балтач алпавыты белән нитукмышты Таминдар бай, бөтен Рәчәйгә атаклы Акчуриннар да ярыша алмый, ди. Ярышса Габдрахман бай Ишморатыфлар гына ярыша ала, ди. Аларның Казан тулы читсы фабриклары, Себер тулы алтын шахтылары бар дип сөйлиләр. Патша тикле патша киңәшә икән алар белән! Белдеңме? Ә син: «Сөяктән сарай салырыеңмы?» Сөяк белән әллә кая китә алмассың. Тамагыңа торыр сөяк...

Шәяхмәт чибәр кара мыекны бармак белән сыпыра-сыпыра елмая.

— Гомерең малга кызыгып үтте синең, абый. Нәрсә ул дөнья малы? Я, әйт әле, нәрсә? Дуңгыз каны бит ул. Үлсәң үрәтниккә кала. Гомер буе чирәшеп җыясың, бетмәгәе, урламагайлары, пожарда янмагае дип кан калтырап яшисең. Баеган саен байыйсың килә. Ә азагы? Я, әйт әле, нәрсә белән бетә азагы? Үтереш, суеш, талаш! Тьфу! Шул да булдымы тормыш? Нигә кирәк миңа дөнья малы? Идел дәрьяларын гизеп, башымны салларга салып йөрүемә ни җиткән?! Кил әле, энем Солтан! — Солтан уңайсызланып кына килде, Шәяхмәт абыйсы аны җилкәсеннән кочып үз янына утыртты. — Менә кем бәхетле дөньяда! Минем шундый тавышым булсамы? Дөнья малы нәрсә ул. Яле, үскәнем, айкап җибәр әле «Иделкәем алтын» көйләрен!

Солтан әтисенә карап алды, Хафиз солдатка карап алды. Әтисе дәшми, Хафиз солдат хуплап, күз кысып тора:

— Җырла, иркәм, каткан күңелләр җебесен әле бер!

Солтан муенын җыерып этенеп тора башлады.

Ләкин Шәяхмәт абыйсының да, Хафиз солдатның да җыр тыңламый урыннарыннан торырга исәпләре юк иде. Моны күреп торган Садыйк абзый да урыныннан калкына биреп:

— Я, ярар, берне җырла инде, алайса, күңелләре булсын,— диде.

Солтан күзен йомды, башын артка кайшалдыра төште, башта әкренрәк бер моң белән, аннары басу өстен яңгыратырлык ачык тавыш белән җырлап җибәрде:

Ай-һай да гынай дими көйләр килми,
Кайгылар ук күрми ир булмый,
Нинди дә генәй итеп сөйләсәң дә,
Чит-ят илләр туган ил булмый...

Хафиз солдат, әсәрләнеп, Солтанның яз кояшыннан каушакланган борынына, кылдай каты чәчле йомры башына, түгәрәкләнеп ачылган авызына күзен дә йоммый карап тора. Җырның соңгы авазлары сагышларга уралып тынгач, авыр гына көрсенеп куя:

— Һай да матур итеп өздең соң үзәкләрне, иркәм! Гомерле бул, яме... — ди, бу сүзләрне ул, дога укыган кебек, әкрен, шыпырт тавыш белән әйтә.

Шәяхмәт әле бер сүз дә әйтми, торaташ кебек катып утыра.

Садыйк абзый беренче булып аңына килә:

— Ярар, туганнар, булмаса кузгалыйк. Җыру җырлап кына җир сөрелмәс безнең...

Ул, кулына таянып, күтәрелә башлый. Аны күреп, Шәяхмәт тә күтәрелә, абыйсының каршысына ук баса, ашыгып, инәлеп диярлек сөйли башлый:

— Абый җаным... Тыңлале сүземне. Бир син миңа бер генә җәйгә Солтанны.

Садыйк абзыйның чырае карангылана, күзләре усал елтырап китә:

— Син нәрсә, Шәяхмәт?! Соңгы өметемне кисмәкче буласыңмы? Юк, энем, анысы булмас! — ди ул кискен итеп, хәтта йодрыгы белән күкрәгенә сугып куя. — Җанымны сора, җанымны бирәм, әмма ләкин Солтанны бирмим!

— Ни өчен, абый? Ник син аны миннән күпсенәсең? Мин бит аны ач итмим, ялангач итмим, мин бит аңа дөнья күрсәтәм.

— Беләм мин синең ничек дөнья күрсәткәнеңне? Юк, туганым, үзең зимагурлыкта йөргәнең дә бик житкән. Солтан — минем төпчегем. Ул да зимагурлыкка чыгып китсә, Айдар Садыйгының нигезен кем алып барыр?

— Нәсел дисең син, йорт дисең. Йортың бит инде ишелергә тора.

— Ишелә, каһәр суккыры! Тимерче Лотфи ике ел элек эчендә егерме булт ясап бирде. Эчтән-тыштан шул бултлар белән генә тарттырып торам... — ди Садыйк абзый кинәт юашланып.

— Ә мин сиңа йортлык бүрәнә бирсәм?

Ул абыйсының җан җиренә басканын аңлый. Садыйк абзый кинәт икеләнә башлый, күзгә күренеп мескен хәлгә төшә:

— Кайчан бирәсең? — ди ул, ниһаять.

— Хет иртәгә. Саллар Таминдар байның аяклы амбары янында тышауда тора.

Кирәк тирәкне ега. Садыйк абзый, тешен кысып, дөньясын каргап, аның белән килешә. Шәяхмәтнең тужурка җиңенә асылынып, соң дәрәҗәдә гозерләнеп әйтә:

— Нужа дигәннәре сакалдан учлап тотмаса якын да килмәсием. Сүзем шул сиңа, Шәяхмәт, малайга юк-барны сөйләп, башын катырма, патшага тел-теш тидермә, эчү мәҗлесләренә катыштырып, күңелен азар-бизәр китермә. Менә, Хафиз солдат шаһит, әгәренки малайны жир эшеннән биздерә торган булсаң, кулымны күтәреп бәддога укыйм!

Башкорт далалары ягыннан жылымса жил исә, кайдадыр атлар кешни, сукачылар, әбәттән кузгалып, атларын жигә башлыйлар. Солтанның күңелендә, өермә булып, хисләре давыллана. Ул абыйсы белән сал агызырга китәчәк. Ишеттегезме, таулар? Ишеттегезме, урманнар?

Солтан Кама иделеннән сал агызып алып төшәчәк. Солтан зәңгәрле-сарылы йортларда торачак. Моны Нурия-Нөркәйгә әйтергә кирәк. Андый сөенечне бер ялгызың эчеңдә саклап торып буламыни?..

## VIII

Шәмсениса абыстай, көнчелектән янган йөрәген баса алмыйча, кызы Нурия алдында ачы күз яшьләрен түксә дә, Габбас мулланың асрау кыз Хәнифәгә өйләнүе аның фатихасыннан башка эшләнмәде.

Шәмсениса абыстай бишенче дистәне узып барганда Габбас муллага нибары утыз гына яшь иде әле. Ул кап-кара мыеклы, түгәрәк кара сакаллы, битләре алсуланып, үзе гайрәт сулап торган ир уртасы кеше иде.

Бар нәрсәне алдан күреп, акыл белән эш йөртә торган зирәк хатын булгангадыр, мулланың иртәме-соңмы яшь хатынга өйләнәчәген ул белә иде. Череп чыккан берәр бай кызына, яки теле-телгә йокмый торган берәр әрәмтамакка өйләнеп куйса — ни хәлләр итәрсең? Ул чагында бит йортның хуҗабикәсе Шәмсениса түгел, әнә шул әрәмтамак булачак. Шәмсениса карчык белән аның җандай газиз кызы Нурия югарыгы агөйдән түбән өйгә төшсеннәрме? Моңа юл куярга ярамый! Һич! Шәмсениса якынаеп килгән никахны тагын да тизрәк якынайтырга, үзенә файдалы итеп якынайтырга тиеш.

Мулла йортында гомер буе асрау булып торган Көмеш түтәй, Нурия кулдан төшкәч, үзенең монда кирәге калмавын тоенып, Ырымбурдагы туганына китеп барды. Аңардан соң мал-туар багарга килгән Фатыйма исемле саңгырау бер сазаган кызны Шәмсениса абыстай үзе яратасы итмәде. Чисталык-пөхтәлек ягы Фатыймада чамалырак иде. Өстәвенә ул төскә-биткә дә әллә кем түгел, моңа Габбасның күзе төшмәс дип уйлады. Югары мәхәлләдәге ишле балалы Рамазан абзыйның төпчек кызы Хәнифәне асрау итеп алдыртты.

Асрау кыз белән Габбасның икесен аулакта калдыргалап, башта иренең нәфсесен чамалап карады.

Бар да ул дигәнчә бара. Асрау кыз — Шәмсениса тегеп биргән алсу күлмәктән, канатлы ак алъяпкычтан, күбәләктәй очынып, йорт эшләрен эшләп йөргәндә, Габбас аңардан күзен дә алмый. Шәмсениса килеп керсә, китапка багынып утырган була: янәсе, аның Хәнифәдә эше юк. Иблис! Белмиләр дип уйлый торгандыр.

Сакал-мыек нигә көн саен сөннәтләнелә? Кышкылыкка утын нигә Бөкре Гафият белән түгел, Хәнифә белән киселә?

Башка елларны мәчеткә китсә, халыкка вәгазь сөйли-сөйли, хәзрәтең дүрт-биш сәгатьсез кайтмый торган иде. Хәзер — бер сәгать узамы-юкмы, тишекле бер тиен кебек, капкадан Габбас тәгәрәп килеп керә.

Шәмсениса карчык, күнел түрендә кабынган көнчелек утын басып, асрау кызны хәреф танырга, язу язарга, хисап хисапларга өйрәтә башлады. Яшь абыстай мулла йортына кызыллык китерерлек булмасын! Һич кенә дә иренмичә, ел буе өйрәтте ул аны. Өйрәтеп бетергәннән соң башта Габделхәлим абзыйсына, аннары Зартугайны кулында тотып торган Таминдар байга сүз салып, Габбас мулланың яшь хатынга өйләнүе мөмкинлеге барлыгын, ул эшнең остабикә рөхсәте белән эшләнәчәген, шәригатькә хилаф эш түгел икәнлеген аңлатты.

— Йорт-җир алып барулары ялгыз башыма авырайды. Бу елларда олаебрак киттем. Актык көнемә тикле авыл балаларын укытып, савап кылып үләсем килә. Рөхсәт итегез, аллага тапшырып, хәзрәт өйләнсен, — диде.

Иң кыены Хәнифәнең үзен күндерү иде. Шәмсениса абыстай, соңгы хәйләсенә керешеп, түшәк өстенә ятты. Нуриядән Хәнифәне чакыртып китерде.

— Гөлекәем, утыр әле яныма. Башымны тотып карале. Кайнармы? Менә шул-шул. Минем инде яшисе хәтле яшисе калмагандыр. Аркаҗилкәләрем дә сызлаштырып тора. Үлем ике килми, берсеннән котылып булмый, дигәннәр. Әҗәл бит агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, гөлекәем. Аллаһы тәгаләнең кодрәте киң: кайчан тели, шунда үз янына ала. Анысы өчен курыкмыйм, дөньяда гөнаһ кылып яшәмәдем, кеше әйберсенә тимәдем, балалар укытып, савап өстәдем. Ходай үзе кабул итсен. Бер үкенечем бар: кызым кала, Нуриям. Кем аның әнисе булыр, кем аны җыласа юатыр. Гөлекәем, тыңлале сүземне...

Хәнифәнең битеннән каны кача.

— Син ни сөйлисең, абыстай? — ди ул калтыранып.

— Белеп сөйлим мин, гөлекәем. Мулла абзаңның сиңа күзе төшеп йөри. Яшь әле ул, көчле. Минем гомер буе җыйган байлыгым рәхмәтле кешегә калсыные. Камчат бүрекләрем, штуф күлмәкләрем, чәмчәле читекләрем — барысы да сиңа.

— Әйем лә, Нуриягә бирерсең, — ди Хәнифә балаларча беркатлылык белән. — Мин андый читекләрне киеп йөри дә белмим лә...

— Нуриягә аларның берсе дә кирәк булмас. Ул бит укыган бала. Исән-сау үстереп җиткереп, кияүгә бирсәң, аның гомере кала җирендә узасы...

Тәмле тел дигәндә Шәмсениса абыстайны өйрәтеп торасы юк, икеөч көн «авырып яткан арада» ул тәмле теле белән Хәнифәне иренә кияүгә чыгарга күндереп бетерә алды.

Иң соңгы чара — Рамазан картны — Хәнифәнең әтисен күндерү иде. Монысыннан Шәмсениса абыстай бик борчылып, бик шүрләп тора: ник дисәң, Рамазан картның ун елдан артык патша солдаты хезмәтендә, кайдадыр Каф тау артларында торып кайтканын, чамадан тыш намуслы, үзсүзле кеше икәнен белә. Рамазан карт ишле гаиләсен җәен-кышын балта эше эшләп, эштән бушаган чакларында ауга йөреп туйдырып килә иде. «Юк, бирмим, сез безгә тиң түгел!» — дисә ни хәл итәрсең? Аннары бит Хәнифәне асрау итеп тоту да кыенга киләчәк.

Шәмсениса абыстай, ике көн бик нык баш ватып, үз акылы белән үзе киңәшкәннән соң, яучылыкка берәүне дә җибәрмәскә, Рамазан картларга үзе барырга булды. Яучы җибәрсә, Габбас мулланың яшь хатынга өйләнү хәбәре сәгате-минуты белән авылга фаш булачак, никахлашу булмас борын ук кеше теленә керәчәк, кеше теленә кергән хәбәр, бик тә мәгълүм, бик нык арттырылып, күпертелеп сөйләнелә торган була. Хәнифәнең үзенең дә, әти-әнисенең дә ул хәбәрләрдән гайрәте чигеп куйса, яки Сөләйман хәзрәт кебек кешеләр, Габбаска үч итеп, аларны кирегә үгетли башласалар...

Ни булса булды, Шәмсениса абыстай тәвәккәлләп үзе кузгалды. Гафият аны кара туры айгыр белән тарантаска утыртып Рамазан картларның җил капкасы төбенә китерде дә, тагын берәр сәгатьтән кире килергә вәгъдә итеп, борылып чапты.

Тарантас хәтле тарантас капка төбенә килеп туктаган икән, каршы чыкмый хәлең юк.

Башына каешланган кара түбәтәй, өстенә киндер күлмәк белән алача ыштан кигән, йон оекбаш белән чабата башмакны аягына элгән Рамазан карт кунакны каршы алырга үзе чыкты, җил капка төбендә яшел атлас күлмәктән, энҗеле калфактан басып калган Шәмсениса абыстайны күргәч, бераз сәерсенеп, хәтта югалып калды.

— Әнисе, сиңайтәм, чык әле, кунак бар, — дип өйгә борылып кычкырды.

Яулыгын тамак астыннан китереп бәйли-бәйли, какча гәүдәле, чабата-оеклы, түше уңган яшел күлмәкле хатын килеп чыкты.

Авызын уңайсыз бөрештереп, ничектер яны беләнрәк басып, Шәмсениса абыстай белән күреште. Аның йөзенә курку чыккан, абыстайның ул ни йомыш белән килгәнен белми, олы кунакны сыйларлык сые да юк иде.

Хәлнең мөшкеллеген аңлап, Шәмсениса абыстай өйгә узарга ашыкты. Рамазан картлар каршысында ук Югары мәхәллә мәчете, аннан ике өй ары Сөләйман хәзрәт йорты, мәчеткә йөргән картларның һәм Сөләймән хәзрәтнең бик нык төпчене башлаулары мөмкин иде.

Бусаганы атлап керүгә Шәмсениса абыстайны ике нәрсә таң калдырды. Берсе — бу йорттагы бушлык, әйберсезлек. Үзләре өендәге борылып та йөреп булмаслык шкафлар, сандыклар, берсе өстенә берсе өйгән түшәк-ястыклардан, аяклы көзгеләрдән, доңгырдатып суга торган сәгатьләрдән соң, стеналары буш тәрәзә араларын күрү, геренә тимер-томыр аскан гади генә сәгатьне күрү аны таң калдырды. Аннары аны тәрәзә төбендә күкрәп чәчәк аткан яран, бохар кынасы, исле гөл таң калдырды. Гөлләр барысы я яртысы киселгән комганга, я зур кара чуенга, я борыны төшкән чәйнеккә утыртылганнар, түр тәрәзәдән кергән кояш нуры, яран яфракларын челтәр-челтәр итеп, сәке өстенә шәүлә төшергән, сәке үзе чыра пычагы белән кырып юа торгач, сөяк кебек сап-сары булып калган. Идән дә шундый ук күз явыңны алырлык чиста, сөяк кебек сары иде.

Шәмсениса абыстай бер генә мәлгә аяк киеменнән атлап китәргә шикләнеп торды. Ләкин аңар берәү дә өй башмагы тәкъдим итми, ул, юаная башлаган олы гәүдәсе белән иелеп, чәмчәле читеген сала алмый иде.

Иң башлап аның күңеленә култык астына кыстырып тотып торган зур табакны Рамазан картның хатынына бирергә кирәклеге исенә төште, буш кул белән килмәскә дип ул үзе белән гөбәдия пешереп алган, тастымалга кәгазьле конфет, кызыл билле прәннек төргән иде.

Ләкин ул Рамазан картның хатыны ни исемле икәнен белми иде.

— Туганым җиңги, исемеңне белмим, әйтеп җибәрче, — диде ул иң әүвәл.

Ишек төбендә чабата башмагын салып азапланган Рамазан карт, абыстайга, чал кунган калын кашлары астыннан, төптә-тирәндә утырган җете күзләре белән төбәлеп:

— Мотахара, — диде.

— Бәрәкалла, бик матур исем. Менә шушы кечкенә генә күчтәнәчне алып җибәр әле, Мотахара түти, — диде абыстай. Аннары, көрсенеп, сәкегә таба атлады.

Мотахара, түенчекле зур табакны кулына тоткан килеш, авызын уңайсыз бөрештереп, әле һаман бер урында баскан килеш тора иде. Рамазан карт беренче булып аңына килде:

— Абыстайның астына киез куй, — диде.

Мотахара түти, табагын ялт кына почмак якка куеп, аннан төрле бизәкле ситсы кисәкләреннән кормаштырып ясаган урындык киезе алып килеп, сәке буена җәйде.

Шәмсениса абыстай, итәген кулы белән күтәрә төшеп, шул киез өстенә җәелеп утырды.

— Ярабби, бу йортка бәрәкәт бирсен, иминлек, әйдәгез бер дога кылып алыйк.

Өчәүләп, авыз эченнән дога укып, битләрен сыпырдылар.

— Ни хәлләрдә яшәп ятасыз, Рамазан абзый? — диде Шәмсениса абыстай, туп-туры йорт хуҗасына төбәлеп. — Авырмыйсызмы, басудагы җирләрегезне чәчтегезме? — Күзе казан буендагы ян тәрәзәгә төште, аның пыяласы ватылган бер бүлемена карындык тарттырылган иде.

— Ярый, бер көе... Зарланган юк. Безнең анын җир димәсән хәтере калыр, уч төбе хәтле нәрсә... Ходай ир малайны кызгангач, шулай инде ул, тугыз баланың өчесе малай булып туган иде, аларның да икесе үлеп китте, берсе, үзем кебек, солдат хезмәтендә чери, — дип әйтеп куйды. Зарлануны абыстай килештермәс дип уйлады бугай, Мотахара түтигә борылып: — Сиңа әйтәм, бик җәелеп утырма, самавыр куй, — диде.

— Ай аллам... мөнә син... самавырымны бакырчы Әфләтунга илтеп биргәнием бит әле... Борыны агып интектерә... Мөнә син ә... нишлим икән соң, күршеләрдән алып чыгып торыйммы?..

— Кирәкмәс, мәшәкатьләнмәгез. Озак торырга килмәдем мин, — диде Шәмсениса абыстай. — Мин, Рамазан абзый, синең белән киңәштабыш итәргә дип килгәнием.

— Нинди киңәш ул, абыстай?

— Киңәш бик зур, Рамазан абзый... Ничек дибрәк башларга да аптырап торам. Кызыгыз Хәнифә безнең күңелгә бик ятышып тора бит әле. Эшкә уңган, төскә чибәр дигәндәй...

— Бәракалла, бирсен ходай, суң шуннан... — диде Рамазан карт.

— Шуннан шул, Рамазан абзый: кызыңа хәзрәтнең күзе төште. Аллага тапшырып, башлы-күзле итикме, әллә атычабы чыкканчы бездән алып китәсезме?

Мотахара түти, яулыгы белән авызын каплап елап җибәрде.

Рамазан карт аны: «Житте сиңа!» — дип кырт кисте.

— Ул ниткән сүз ул аты-чабы? Без сезгә ефәк күк кыз бирдек. — Картның күзләре зурайды, чаларган каты мыегы кабарып чыкты. Шәмсениса абыстай аның стенага элеп куйган ау мылтыгына карап торуын күреп, миңгерәүләнеп калган картка айнып җитәргә ирек куймыйча, һөҗүмгә күчте:

— Картайдым, Рамазан абзый. Мал-мөлкәтемне ышанычлы кулларга калдыралсам ие дип көн дә саен тәңрегә ялварам. Синнән яшерен-батырын түгел, кызым Нуриягә чаклы бер малай, бер кыз тапканыем, ходай тәгалә үзе бирде, үзе алды дигәндәй, бер яшь тулар-тулмаста гүр иясе булдылар. Варисыбыз юк. Гаиләбездә ир бала булган булса, ни әйтериен кана, юк бит, булмагач булмады инде... Инде мин үзем бала табарга картаеп калдым. Хәнифә Габбас хәзрәткә ир бала да табып бирсә, үз балам кебек кадерләп кенә үстерерием, өрмәгән җиргә дә утыртмасыем. Мал-мөлкәтебез дә аңар калырые...

— Шулаен ул шулайдыр, — диде Рамазан карт, тирән җыерчыклар белән буразналанган нечкә муенын боргалап. — Синең сүзләреңдә, бәлкем, хаклык та бардыр. Мин сиңа, остабикә, олы башың белән алдалашып торасыңдыр дип әйтә алмыйм, әммәдәген халык бар бит әле, мәхәллә бар. Халыкның бит аның авызын тастымал белән томалап куеп булмый. «Асрау кыз хәзрәтнеаздырды, асрау кыз остабикә хәтле остабикә өстеннән кияүгә чыкты!» — дип, минем күземне ачырмый башласалар?

— Күңелең тыныч булсын, Рамазан абзый, аллаһы боерган булса, сөйләмәсләр. Никах мәҗлесендә үзем тиешенчә аңлатып бирермен. Аннары килеп, мәһәренә... синең атсыз тилмергәнеңне күреп торам... Кара байталны бирербез дигәнием. Йортың да тузып бара түгелме?

— Йортны анысы әйтмә инде, бүген авамы, иртәгәме дип яшәгән көн. Әнә шул Хәнифәнең мәһәренә өйлек бура алып булмасмы дип өмет итәдериек. Мөнә син, рәхмәт яугыры, бик кисәк булды бит әле бу, остабикә. Бик уйламаганда булды. Тез астына китереп сукты бу минем...

Шәмсениса абыстай тимерне кызуында сугуны кирәк тапты.

— Атың булса урамда, хәсрәтең юк буранда, дигәннәр борынгылар. Атлы булу — өйле булу дигән сүз инде ул, Рамазан абзый. Урманнан

диләнке сатып алып, иркенләп торып салырсың йортны. Туганнашып китсәк дигәндәй... без дә булышырбыз, боерган булса... — Шәмсениса абыстай, иркен итеп тегелгән атлас күлмәгенең эчке кесәсеннән бумажник тартып алды, аннан өч кисәк кәгазь акча чыгарып Рамазан картка сузды: — Менә монысын ала торыгыз әле. Әзрәк өегезне рәтли торырсыз...

Рамазан картның каушавы чал төк баскан битенә үк чыккан иде. Кулына алган акчаларны кая куярга белмичә әвәләргә тотынды...

Җәйге эшләр башланырга торганлыктан, никах мәҗлесен озакка сузмадылар. Шәмсениса абыстай кеше-кара җыюны кирәксенмәде.

Кунаклар бик чикле чакырылды: Шәмсениса ягыннан — Габделхәлим абзый, Габбас ягыннан — абыйсы Әхмәтзыя, Хәнифә ягыннан — этисе Рамазан карт.

Югары мәхәллә мулласы Сөләйман хәзрәт никах укыды.

Ул барлык затлы киемнәрен киеп, башына кибән чаклы бохар чалмасын утыртып, чукмар башлы кара таягына таянып килгән иде. Үзен бик эре, бәйсез тотты.

Шаһит булып килгән Әхмәтзыя никах алдыннан кияү белән кызның ризалыкларын сорады:

— Җамалетдин улы Габбас, Рамазан кызы Хәнифәне хәләл җефетлеккә риза булып аласыңмы?

— Алам, — диде Габбас көр тавыш белән.

— Бәрәкалла, — диде Сөләйман хәзрәт, түгәрәк ак сакалын сыпырып.

— Рамазан кызы Хәнифә, Җамалетдин улы Габбаска хәләл җефетлеккә риза булып барасыңмы?

Чаршау артыннан тавыш ишетелмәде, чаршау гына селкенеп куйды.

— Яшь бит әле, ояла, — диде Габделхәлим каршы әйтмәслек итеп.

— Ояла шул...— дип көрсенде Сөләйман хәзрәт. Кан дошманы булган Габбас мулланың ни хәтле мал-мөлкәткә хуҗа булуы өстенә авылның күз өстендәге кашыдай чибәр кызын кече хатынлыкка алуы аның янә бер мәртәбә эчен яндыра башлаган иде. «Кара син аны, мөртәтне! Кәкре каенга терәтте бит бу мине, дәһри! Тәүбә-əстәгафирулла, гөнаһлы булып бетәрсең», — дип ярсып уйланды ул.

Ата-бабадан килә торган гадәт буенча, дәшмәүне ризалык билгесе юрап, никахлашучыларны тиешле дога белән беркеттеләр. Сөләйман хәзрәтнең тавышы көчле, буйсындыручан иде.

Әхмәтзыя белән Рамазан карт, кушырган кулларын битләренә якын ук тотып, доганы авыз эченнән кабатлап бардылар.

Тук мәче күк киерелеп утырган Габделхәлим, тыныш араларында, стена сәгате сукkандай доңгырдатып:

— Амин! — дип әйтеп куя иде.

Утызлы лампа белән яктыртылган түгәрәк өстәл өстендә ризыкнигъмәт күп. Хәзрәт белән шаһитлар никахлашучыларга тәүфыйк, татулык, тигезлек теләп, олы хатынны да, кече хатынны да, шәригать кушканча, бердәй тигез күрергә, берсен дә рәнҗетмәскә, гадел булырга кирәклеген Габбас мулланың исенә төшереп бирәр сәгать утыргач, таралыштылар.

Габбас мулла гомерлек дошманы Сөләйман хәзрәткә, дога кылганда биргән сәдәкалардан тыш, кайтырга кузгалгач, юлда туктатып, алтын акча белән аерым сәдәка бирде.

Икесе тиң йөзлек кырыена утырып, бер-берсен күрәлмәс дәрәҗәдә озаклап дога кылдылар.

Дога арасында Сөләйман хәзрәтнең күңеленә янә дә вәсвәсә килеп кысылды. «Бәхете булса да булыр икән сасы мажикның. Җефәк кебек

кызның хуш исле кочагына керә бит, мөртәт!» — дип уйлады ул һәм, гөнаһка батмас өчен, догасын ашыгып очлады.

Кунаклар таралышкач, башына энҗеле калфак, өстенә ак атлас күлмәк кигән, битен яулык белән каплаган Хәнифә, чәч толымнарындагы көмеш чулпыларын чылтыратып, чаршау артыннан чыкты да түбән өйгә төшеп китте.

Нурияне Нәуширвән бабайларга керткәннәр, мәҗлес таралгач кына кайтырга кушканнар иде. Кунаклар китүгә ул атылып кайтып керде. Әнисенең бурлаттай кызарган битен күреп:

— Әнием, битең нишләде? Пештеме әллә? — дип сорады.

— Мич алдында озак тордым, балам, бәлеш пешергәндә кызарып киттем әле, — диде Шәмсениса абыстай, йөзен читкә борып.

Башка көннәрне Габбас мулла кызы янына утырып озаклап хикәя укый, я кызының укыганын тыңлап тора иде, кызы йокларга үз бүлмәсенә чыгып китми торып йокларга ятмый иде.

Нурия аның бүген нигәдер дулкынланган булуын, сүзен дә ничектер ятышлы итеп түгел, ашыгып, өзек-тәтек китереп сөйләшүен күрде. Әтисенең зофаф кичәсенә ашыкканын абайламыйча:

— Әти, мин сиңа Габделхәлим абзый алып килгән китаптан хикәя укып күрсәтимме? — диде.

— Бүген соң инде, балам, иртәгә укырсың, яме, мин бик арып киттем әле, — диде Габбас мулла.

Соңгы сабырлыгын җыеп, әрле-бирле йөреп торган Шәмсениса абыстай, бер мизгелдә күлмәк итәгенә абынып, егыла язып калды һәм кинәт чыгырыннан чыгып:

— Ни пычагыма шул хәтле әтәләнәсең? Итәгеңә ут капмаган бит, өлгерерсең әле! — дип кычкырып җибәрде.

... Төн урталары идеме икән, әллә таң алдымы — Нурия әнисенең пышылдап дәшкән тавышына уянды. Аның үлеп тә йокысы килә, күзләре әчетә, тирә-як әле караңгы, шомлы иде, келт-келт итеп йөргән сәгать тавышы бу шомлылыкны арттыра төшә кебек иде.

— Кызым, балакаем, тор әле, тор инде, балам...

— Ник инде, әни? Йокы килә лә...

— Безгә, кызым, ишегалдына чыгарга кирәк.

Ул Нурияне кочаклап, җылы урыныннан торгызды, өс-башын киенергә булышты, балкон тәрәзәсен ачып, шунда чыкты, Нуриягә дә үзе артыннан барырга кушты.

— И әни, нигә соң без, мәче төсле, тәрәзәдән йөрибез?

— Шаулама, кызым, безгә ишектән чыгарга ярамый.

Алар балкон баскычыннан бер-бер артлы ишегалдына төштеләр.

Түбән өйнең тәрәзәләрендә ут сүнгән, пәрдәләре тартып куелган, анда берни дә күрерлек түгел иде. Шулай да Шәмсениса абыстай, кызны ишек янына сакка куеп, үзе кулларын җәеп, тәрәзәгә капланды, тәрәзә йөзлегеннән купмыйча, күзләре талганчы эчкә карап торды.

Аннары алар төшкән юлларыннан кире менеп киттеләр.

Өс-башларын чишенеп, икесе бергә яткач, Шәмсениса абыстай кызын кысып кочаклады һәм кайнар бер пышылдау белән:

— Балам, үскәнем, күз нурым... төнлә ишегалдына төшкәнне берәүгә дә әйтмәссең, яме, алтыным, — диде.

## IX

Никах мәҗлесеннән соң бер атна узуга, Хәнифә ерак чишмәгә суга барган җиреннән чәчен-башын туздырып, елап кайтып керде, баскыч төбендә үк көянтәсен ыргытып:

— Суга бармыйм бүтән! Катыннар әйтә, без алган җирдән су алма, урамга чыгып, кеше күзенә күренеп йөрисе булма, диләр. Оятсыз,

диләр, ыштыр каплаган бит, диләр, ничек син Шәмсениса остабикә өстеннән, үзеңне укыткан кеше өстеннән кияүгә барырга батырчылык иттең, диләр.

Шәмсениса абыстай әле унҗиде яше генә тулып килгән кызның ярсыныл-рәнҗеп әйткән сүзләрен тыныч кына тыңлап торды да, Хәнифәнең янына ук килеп, йомшак һәм көйле тавыш белән әкрен генә әйтте:

— Син бер дә борчылма, гөлкәй. Мин күрше-коланга әйтермен. Хәзрәт минем рөхсәтем белән өйләнде, Хәнифәне этисеннән мин үзем сорап алдым, диярмен. Шуннан соң алар сиңа бер авыр сүз дә әйтә алмаслар, әйтсәләр, мин аларны каргармын.

Шәмсениса абыстай моның белән генә котыла алмады әле.

Әтисенең нигә икенче хатынга өйләнгәнен таптырып, аны Нурия тинтерәтә башлады.

— Нигә соң без генә Хәнифә түтәй белән торабыз? Авылда бер генә кешенең дә ике хатыны юк бит.

Шәмсениса абыстай бик кыен хәлгә калды, үз ирке белән эшләткән бу эшне Нуриянең аңламавына офтанып:

— Язмышыбыз шулайдыр инде, балам. Күрәчәк күмер ашата, диләр бит,— диде.

— Ник алайса без аларны куып чыгармыйбыз? Алар икесе яшәсен, без — икебез...

— И бәбкәм, синең бәхетең өчен тырышам бит. Син ятим үсмәсен, кагылып-сугылып йөрмәсен дим.

— Ә ник алайса аларның икесен калдырып, үзебез Габделхәлим абзыйларга күчеп китмибез? Ул бит мине ярата: алка алып килде, күлмәк...

— И кызым, күз нурым, яшь шул әле син, берни белмисең. Бай абзыйларга кунакка барганда гына кадерле буласың ул. Әгәр мохтаҗлык төшеп барсаң, алар синең белән мине асраулары торган кара бүлмәгә куарлар иде.

Шәмсениса абыстайга, аңардан да бигрәк Нуриягә әтисенең яшь хатынга өйләнүе көн саен тынгысызлык, күңелсезлек китереп торды. Сөйләшү-аңлашулар булганга бер атна тулды дигәндә, Нурия инде боегып йөрүдән туктап, янә дә үзенең шатлыклы, гамьсез-рәхәт тормышы белән яши башлаганда Барҗы авылыннан Габбас мулланың туганнан туган сеңлесе Зәйтүнә килеп төште.

Зәйтүнә бизәкле шәлъяулыгын салып агач караваг башына элде, шуннан соң юка иреннәрен кысып абыйсы Габбаска күз ташлады, эшләрнең юньлегә илтмәячәген аңлап алган Габбас мулла мәчеткә бару сылтавы белән өйдән чыгып тайгач, йорт эше эшләп йөргән ак алъяпкычлы, ал күлмәкле Хәнифәгә тилгән сыман очып кунды:

— И-и-и бәдбәхет, и-и-и җир убасы нәрсәкәй! Ни кыландың син, җә?! Ни йөзләрең белән үзеңнең остабикәң өстеннән кияүгә чыктың? Җә?! Үзеңне укыткан, сиңа гыйлем биргән кешегә карата шул начарлыкны ничек итеп эшли алдың син, җә?! Башка бер кешене дә таба алмадыңмыни, үзең ише хәерче беткәниемени?!

Зәйтүнә үтә дә чибәр йөзле, сары чәчле, усал-юка иренле кыз иде. Тиргәүне дә ул, авыл хатыннары кебек, авызын зур ачып тиргәми, борып-борып чеметкән кебек, сүзләрнең иң ачысын, иң зәһәрен энҗе кебек вак тешләре арасыннан кысып-кысып кына чыгара иде. Дөньяда иң сабыр, иң әүлия кеше табылса, Зәйтүнә аны да йөрәге тотар дәрәҗәгә, ни эшләгәнен белештермәс дәрәҗәгә китереп җиткерә алыр иде.

Хәнифә, ул тирги башлагач, үзсүзлеләнеп, ишек төбендәге урындыкка килеп утырды, юри артка кайшала төшеп, кулларын ташып торган күкрәкләре өстенә кушырып, каршы сүз әйтми тыңлады. Аның күңелендә — мине мулла, абыстай яклап чыгар әле, дигән уй бар иде. Тәҗ-

рибәсез яшь хатын, Шәмсениса абыстайның моннан бер атна гына элек әйткән сүзләрен исенә төшереп, үзен яклар вакыт җиткәнне көтеп утырды.

Ләкин ул аны көтеп бетерә алмады, Зәйтүнә сүзләреннән күңеле тулышып, елый ук башлаган абыстайга бер күз салып алды да, урыныннан торды Хәнифә. Аның боларга дөньяда булмаган усал сүзләр әйтәсе килә, тик әле ул, бер мәртәбә дә әйтеп караганы булмагач, усал сүзне ничегрәк итеп башлап җибәрергә кирәклеген белми иде.

Авыр кара толымнарын бугаз турысында чалыштырып, тетрәнгән иреннәрен көч-хәл белән сүз әйтерлек дәрәҗәгә китереп:

— Нигә сез... миңа каныгасыз... барыгыз да. Минем ни... гаебем бар? — диде. Бүтән сүз әйтергә көче җитмәде, авызы ямьсезләнеп кыйшайды, чырае көл кебек агарды.

Шәмсениса абыстай аның акырып елый-елый урамга чыгып барганын күрде, коты алынып: «Хәзер бөтен Зартугайны бер итеп акырып барачак», — дип уйлады.

— Кызым, бар, йөгер, алып кер түтәеңне! — диде.

Нурия урамга чыгып киткәч, каен сеңлесенә рәнҗешен белдерде.

— Шулай ярыймыни инде, Зәйтүнә... Тора торгач торҗагун дип кеше мыскыл итәргә тотыналармыни? — диде. — Мин бит аны үзем алып кайттым, үзем өйләндердем. Таминдар байларны, Габделхәлим абзыйларны күндереп йөрдем...

— Күндереп йөрсәң, авызыңны күтәреп елап торма, алайса! — диде Зәйтүнә усаллашып. — Рамазан хәерче кызын алып кайтмасаң, берәр бай кызы беткәндер шул!

— Күрәчәгемдер инде... — диде Шәмсениса абыстай юаш кына. Күңеленнән икенче төрле уйлады: «Гыйматдин хәзрәт хаҗга барган җиреннән үлеп калмаса, Рамазан хәерче кызы түгел, Җамалетдин хәерче малае Габбасның да минем йортыма аяк басасы югые. Күрәчәк күмер ашата...»

... Ишегалдына атылып чыгуга Нурия дөнья бетереп кычкырган Солтан тавышын ишетте.

— Нурия! Нөркәй, чык әле урамга! Нөркәй дим!

Нурия әнисенең йомышын шундук онытты, капка төбенә йөгереп чыкты да исе китеп карап калды. Капка төбендә үк Солтан басып тора: өстендә кара пинжәк, ак батис күлмәк, кара бәрхет түбәтәйне башка кыңгыр салган, аягына ялтыравыклы штиблет киеп җибәргән. Аны язын-көзен гел ялан аяктан, бөгәрләнеп беткән киндер күлмәк-ыштаннан күрергә гадәтләнгән Нурия, күзләрен йомып:

— Ай, син нинди чибәр бүген, Солтан! — дип әйтеп салганын сизми дә калды.

Солтан кызарынды, зәңгәр күзләренә мөлдерәп шатлык тулды һәм ул ашыгып:

— Әйдә, Нөркәй, су буена төшәбез! — диде.

— Нишлибез анда?

— Әйтәсе сүз бар.

— Әйт шуннан гына.

— Юк, моннан гына әйтеп булмый аны... — Солтан тагын комач кебек кызарды, кызарырга мәҗбүр иткән Нуриягә рәнҗеп, башын кискен генә чайкап алып китә үк башлады.

— Тукта, Солтан, көт мине, — диде.

Үзләренең мәчет урамын узгач, тар гына бер тыкрыкка борылдылар, кулларын җитәкләшеп, Иш буена таба йөгерделәр.

Иш буена алар Аксагыз тавы ягыннан килеп чыктылар. Елга инде ярларына кайтып төшкән, яр буе әрәмәләренең кара-кучкыл шәүләсе

су өстендә ята, өйлә турысына җитеп килгән кояш яшәреп килгән болын тугаен, еракгагы зәңгәр урманнарны юмарт нуры белән коендыра; офык читенә өелешкән аксыл болытларның чит-читләре төтен сыман җиңел булып, тузгып торалар, күк зәңгәрлеген тагын да җетерәк итеп күрсәтәләр иде.

Солтан, кеше-кара юкмы дип, як-ягына каранып алды. Аннары Нурияне кулыннан тотып, яр читенә үк алып килде.

Яр бик биек, яр астында комда үги ана яфрагы, бака үләне, әрсез әрекмән күтәрелеп килә иде.

Солтан кулын алгарак сузды:

— Ә-ә-әнә тегендә, тау астында, Таминдар байның аяклы амбарын күрәсеңме? — диде.

— Күрәм.

— Күрәсеңме, су ярты аршынга кимегән.

— Юк, анысын күрмим.

— Әнә бит инде, талларга сызык сызып калдырган.

— Нинди сызык?

— Су кичә кимегән төштә таллар әле кара сызыклы. Күрдеңме?

— Ә-ә-ә, күрдем, күрдем! — диде Нурия сөенеп.

— Су тагын шуның хәтле өч мәртәбә кимегәч, юлга чыгабыз.

— Нинди юлга?

— Сал агызырга. Чаллы белән Чистайга, белдеңме?

— Кем белән?

— Шәяхмәт абый белән.

— Ә саллар кайда соң?

— Таминдар байның аяклы амбары янында.

— Миңа күрсәтәсеңме соң салларны?

— Кешегә әйтмәсәң — күрсәтәм.

— Әйтмим.

— Шушы кояшның чыраен күрмим, диген. Ипидер, кояштыр, диген.

— И-и-и алай куркыныч бит.

Алар, кулларын кулга тотынган көе, аяклы амбар янына йөгерделәр.

Нурия яр өстеннән аска карады. Аста, чуер ташлар белән тулы яр читенә бүрәнә юанлыгы тимер казыклар кагылган, шул тимер казыкларга юан-юан чылбырлар килеп тоташкан, ә елга өстендә, саламнан бәйләгән мәтеләр төсле булып, бүрәнә җәемнәре ята иде. Су аларны әкрен генә чайкый, бүрәнәләр өстенә утыртып куйган сарылы-зәңгәрле ике өйне, түбәләре сумалаланган, йөзтүбән каплап куелган ике көймәне, мәтеләр белән бергә, селкетеп тора иде.

— Әнә шул умарта өйләре сал дип аталамыни? — диде Нурия.

— Җүләркәй! Йорт нишләп сал дип аталсын! Йорт карванка дип атала. Әнә шул җәелеп яткан бүрәнәләр сал дип атала. Су өч аршынга кимегәч, без аларны Чистайга аптөшеп китәбез. Белдеңме инде? — дип, Солтан кисәк кенә Нуриядән учын тартып алды, мәтәлли-мәтәлли яр астына очты. Аның шаулап, сөендекләнеп, кычкырып барган тавышы тирә-якка ишетелеп торды.

Тимер казыклар янына җиткәч, ул көч-хәл белән туктады, югарыга карап, Нуриягә кычкырды:

— Нөркә-ә-ә-әй! Курыкма-а-а-а! Төш мон-да-а-а!!!

Нурия биек үкчәле читеге белән яр астына йөгереп төшәргә курыкты, кәҗә бәтие кебек, көтү йөргән сукмакларны сайлап, кырын-кырын төште. Сал өстенә килеп кергәч, селкенешеп торган бүрәнәләрнең чайкалып китүеннән куркып, чатырдап Солтанга ябышты. Солтанга рәхәт, ул аның куркуыннан көлә, курыккан саен ныграк куркытасы килә иде.

Чайкалып торган бүрәнәләр өстеннән атлый-атлый, алар көймә янына килеп җиттеләр. Нурия көймә өстенә менде.

— Солтан, карале миңа, карале! — дип, кулларын канат кебек җәеп, егылып китмәс өчен чайкала-чайкала, көймә сыртыннан атлап, арты башка барып житте, сикерәм дигәндә аны Солтан күтәреп, кочаклап алды.

Алар бер салдан икенче салга күчәргә теләделәр. Ике сал арасы шактый киң, анда җанны өшетеп болганчык кызгылт су ага иде.

— Сикерә аласыңмы? — диде Солтан.

Бер мәртәбә язгы ташу вакытында хур булган Нурия Солтан алдында икенче мәртәбә хур булырга теләмәде. Ә дигәнче икенче салга сикереп, тибрәнешеп торган бүрәнәләр өстеннән йөгереп китеп барды.

Солтан аның артыннан элдертте.

Нуриянең күңелендә тыелгысыз бер ашкыну, дәрт, Солтаннан качасы, Солтаннан кудыртасы, Солтаннан тоттырасы килү теләге уянды. Сулышы кабып, егыла-мәтәлә язып, ул бүрәнәләр өстеннән чапты. Аяк астында язгы суның чупылдап калуын ишетте, артыннан куып килгән Солтанның сулыш алуын ишетте.

Куыша торгач, алар алгы салга ук барып життеләр. Солтан аны биленнән ике куллап тотып алды. Нурия рәхәт чыркылдап:

— Ай, җибәр! — дип кычкырды.

Алар — ялт! — бер-берсенә борылдылар. Кызарып алсуланган йөзләренә карап икесе берьюлы көлешә башладылар.

Аннары, кулларын кулга тотынып, кайту юлына киттеләр. Әкрен генә, сакланып баса-баса гына кайттылар. Әйтерсең алар әле генә шушы тибрәнешкән бүрәнәләр өстеннән йөгермәгәннәр, әйтерсең алар баш әйләнгеч хәвефтән рәхәтлек тойгысы кичермәгәннәр.

Зәңгәр буяулы йортның эченә керделәр. Рамнарын җете акка буяган бәләкәй тәрәзәдән кояш карый, кояш нурында җылынган сары нарат бүрәнәләрдән җанга ятышлы сагыз исе килә, йорт эче бик тын иде.

Солтан кинәт авыз эче кибеп киткәнне, чигә тамырлары сукылдап бәрә башлаганны тойды.

Нуриянең ике кулыннан берьюлы тотып, кызның шомырт кара күзләренә карады, Нурия оялып башын аска иде, керфекләре тетрәнде һәм ул, куркынып, кулы белән битен каплады.

Битен ачканда, Солтанның аяз күк йөзе кебек җете зәңгәр күзләрендә ул тәвәккәллек, ниндидер бер житди адым ясарга омтылу теләге күрде:

— Кирәкми, Солтан! Ай, кирәкми, — диде кайнар пышылдап.

## X

Көн болытлы, тынып житкән елга өсте шадралана башлаган, каршыдан җил исә. Садыйк абзый, чикмән җиңенә кулын тыгып, яр читендә таптана. Елгадан килгән су салкынымы, Аксагыз тавы ягыннан искән җилме аның күзеннән яшь бәреп чыгарган, шуны ул чикмән җиңе белән сөртә-сөртә, елгага аркасы белән борыла...

Унөч яшькә житеп, әле беркайчан да башыннан сыйпамаган, ягымлы сүзләр әйтә белмәгән кырыс табигатьле этисе Солтанга бу минутларда никтер үтә дә якын, хәтта ки кызганыч та кебек тоелып китә.

Солтан сукага чыккан көнне, этисе белән Шәяхмәт абыйсы басуда сөйләшкән сүзләрне исенә төшерә. Этисенең Солтанны җибәрмәс өчен теше-тырнагы белән каршы торуын, йорт житкезерлек бүрәнә бәрабәренә генә, тешен кысып кына ризалашуын уйлый — елга өстен шадралатып искән җил аңар салкынрак тоела башлый.

Нигә шул хәтле дә каршы тора соң этисе?

Әллә Солтанны авылдан ычкыныр дип куркамы икән?

Зартугайны бит Солтан бер генә авылга да алыштырмаячак.

Саллар әкрен генә, хәтта күзгә күренмәс дәрәҗәдә әкренлек белән кузгала; ак киез эшләпәле койрыкчы Мәхмүт, аның белән янәшә баскан Миргата, Сәфәргали, алар янына салның баш ягыннан килеп кушылган тагын өч-дүрт егет, киерелеп-киерелеп, көсмән кага башлыйлар. Ун аршыннан да ким булмаган нарат бүрәнә — көсмән ир-егетләрнең көчле беләкләренә буйсынып, Иш суын дулкын таулары итеп ишеп китерә.

Яр буена җыела башлаган халык, кулларын каш өстенә куеп, Шәяхмәт батырның куәтле-гайрәтле егетләрен сүзсез генә озатып калалар...

Төш вакытлары җиткәндә, кояш баш өстенә ук күтәрелеп елганы көмеш тәңкәле киң сукмак белән бизәгәч, идел өстенә килеп чыктылар. Кайчандыр болгар кызларының нәфис каекларын тирбәткән, үзенә бурлаклар ыңгылдавын, пароходларның моңсу тавышларын җыеп асраган Кама-Чулман иделе киң күкрәгенә аларның салларын кабул итте. Дөресрәге, Кама дәрьясы урам озынлыгы салны үзенеке итеп өлгергәнче Шаукымлы Шәяхмәт егетләренә беләк-күкрәкләренең көч-куәтен шактый күп җигәргә туры килде; җил-давыллар ком өстенә утыртып калдырмасын өчен якорь урынына тагылган йөзләгән пот иске тимернең — тишек чуен, иске балта, ташландык рельс кисәкләренең — сал астында суны ярып, чупылдатып барганы ишетелә. Ара-тирә Шәяхмәт абыйсының калын куе тавыш белән команда биргәне ишетелеп кала:

— Унгарак, туганнар! Койрыкны тигезлә!

Команда тавышы, су чупылдаулары белән кушылып, күңелдә янә дә Зартугайны тергезә. Аларның быел яңа өйләре булачак бит әле. Яңа өйдә тора башлагач, Айдар Садыйкларына Нурия-Нөркәйнең әтиәниләре дә кырын карамастыр бит инде... Ә нигә соң дөньяда берәүләр интекми-нитми генә рәхәт яши, икенче берәүләр гомер буе интегеп тә рәхәт яши алмый.

Элегрәк тә Чулман-Кама иделенә чыкканы бар иде Солтанның. Түбән очның Шәрифҗаннарга, Корбыйларга ияреп ул Кама аръягына, Минзәлә тарафына ук барып чыга, йомшак табигатьле паромчы Силантий карт аларны тавык оясыннан чәлдергән ике-өч йомырка яки сумалалаган сүс җеп бәрабәренә, олыларны төягән паромга утыртып, аръякка илтеп куя; тал араларында, болыннарда кош оясы эзләп, талдан сыбызгы ясап тамаклары ачып беткәнче йөриләр дә, яр буйларында пароходлардан ыргытып калдырган карбыз кабыкларын ашый-ашый кайтып китәләр. Ул чагында кемнең рәхәт, кемнең интегеп яшәве искә дә килеп карамый иде. Каян килде соң әле Солтанның күңеленә шундый сорау?

Җир өстенә эңгер иңә, күз бәйләнә, аннары төн килә. Караңгы күк йөзендә калтыранып кабынган беренче кыюсыз йолдызлар тора-бара зураялар, йөзекнең зөбәрҗәт кашы кебек яшел чаткыларын сибеп, балкып яналар, алар белән ярышырга теләгәндәй, су өстендә маяк утлары кабына, елга ярының ике ягыннан, кара офыктан томык сары утлары белән авыллар озата баралар. Туган-үскән авылыннан әле бер кая да чыкмаган үсмер малайның күңелендә яңа бер дөнья ачылып, хисләре өермәдәй бөтерелә, күкрәгенә сыймаслык булып давыллана башлый.

Солтан әле берәүгә дә әйтмәгән, әйтергә дә базмый торган яңа бер тойгы кичерә. Шәяхмәт абыйсының сал өстендәге өйләре, әйләндереп капланган көймәләре, зөбәрҗәт йолдызлар белән тулып килгән төн аның күңелен иләс-миләс итә, аңа нәрсәнеңдер җитмәвен сиздерә башлый. Әллә нишләп моңсу, ямансу. Җан сызлый, сыкрый. Бераздан ул үзенә нәрсәнеңдер түгел, кемнеңдер җитмәвен аңлый. Аның белән бергә тегермән буйларында уйнаган, аның белән бергә аяклы амбар үреннән йөгереп төшкән Нурия юк...

Аларның салы өстенә дулкын өемнәре җибәреп, көпчәкләрен шапылдатып, пароход узды. Солтанның пароходны кырыкмаса-кырык күргәне бар иде. Бу аның өчен авыл өйләре төсле, елга аша салынган күпер төсле, басу капкасы төсле, күреп-күнегеп беткән бер нәрсә иде, югыйсә. Ә менә бүген ике палубалы ак пароходның утларын күрүгә, бигрәк тә аның сузынкы итеп, мөгрәп кенә кычкыртып җибәрүен ишеткәндә, Солтанның йөрәк төпкелендә гүя бер тамыры өзелеп киткәндәй булды.

Гомерендә беренче тапкыр кичергән газаплы да, татлы да хисне бирәүгә дә, хәтта аның җырын тыңларга, аны җилкәсеннән кочып мактарга яраткан Шәяхмәт абыйсына да сиздерергә теләмәде, сал өйләренең берсенә кереп китте.

Үзе дә сизмәстән җыр сузып җибәрде.

Аптырап, сәерсенеп, туктап калды.

Бүтән чакта бик җиңел генә, гамьсез генә җырланыла торган җыр бүген аның керфек төпләрен дымландыра, тамак төбенә авыр бер җылы төен меңгерә иде...

... Сал бүрәнәләре бер-берсенә бәрелеп чупылдаган, күк йөзенә кара чаршау бөркәгән төсле караңгы, йолдызсыз бер төнне алар салы янына көймә килеп туктады, көймәдән өч кеше төште.

Абыйсы Шәяхмәт аларны каршы алды.

Килүчеләрнең икесе, көймәне чылбыр белән сал аратасына бәйләп, үзләре сал өстендә койрыкчы Мәхмүт белән сөйләшә калдылар. Өченчесе Шәяхмәт абыйсы белән бергә, карванканың тәбәнәк ишегеннән, бөгелә төшеп, эчкә узды.

Төнге кунакның башында ямьшәеп беткән соры киез эшләпә, өстендә брезент кәҗән, аягында озын кунычлы күн итек иде.

Мондый киемле кешеләр Шәяхмәт абыйсына яңа тоткан балык китерә торганнар иде.

«Тагын балык чистартасы була икән», — дип уйлады Солтан. Ике көн рәттән балык чистартып, ул инде тәмам туйган, тагын бер-ике көн рәттән чистартырга туры килсә, аның гомер буена балыктан күңеле бизүе мөмкин иде.

Тик бер нәрсә Солтанны сагаерга мәҗбүр итте. Теге көнне балык китерүчеләрнең битен кара төк баскан, алар бөтенләй кырынмаган килеш килгәннәр иде. Битләре дә кояштан, җилдән каралып беткән иде. Монын чырае ак, борыны туры, җирән төстәге матур мыегы, мәче мыегы төсле, тырпаеп тора.

Кунак, ишектән керүгә, тапчан буенда ялан аяк басып торган Солтанны күреп алды. Күрде дә, үз тиңенә дәшкәндәй: «Саумы, иптәш!» — дип, ягымлы итеп дәште, өстәвенә суыктан кызарып киткән кулын сузып, ныгытып күреште.

Әлбәттә, ул моның белән Солтанны бик уңайсыз хәлгә китереп куйды. Солтан ут кебек кызарды, тапчан буенда таптана-таптана, борынын тартып торырга мәҗбүр булды. Аннары ике кеше арасыннан елан балыгы сыман шуып чыгып, ишеккә таба атлады.

— Бу минем племяш, абыйның улы, Солтан атлы, — диде Шәяхмәт абыйсы. — Салчылар артилен ишәйтәм. Дөньяны таный торсын, диюем.

— Бик яхшы. Таный торуы бик әйбәт, — диде кунак, тыенкы гына елмаеп куйды. — Уку ягы ничегрәк?

— Әллә кем түгел. Мәдрәсәдә дүрт кыш аунады. Алабугага, учительский семинариягә бирергә исәп.

— Материаль ягын үзең карыйсынмы?

— Үзем, әлбәттә. Абыйдан ярдәм көтеп булмый. Уку турында сүз кузгатсаң, чәчләре үрә тора. Минем «зимагурлыкта» йөрүдән дә риза түгел.

Кунак, җирән мыегын дерелдәтеп, көлеп куйды.
Шәяхмәт абыйсы Солтанга таба борылды.
— Син, энем, болай ит: теге карванкага чыгып, самавыр куя тор. Кунак абыеңның чәй эчәсе килгәндер. Ә мин аңардан балык сатулаша торыйм. Бик кыйбат сатмыйсыңмы? — диде ул, Солтан ягына борылып, мутланып күз кысты: алдыйбыз, янәсе, кунакны! Чәй эчерткән булып, арзан хакка балыгын алып калабыз. Борын астында калдырылган шомырт кара мыекны сыпырып, кеткелдәп көлеп алды. — Кыйбат алырга акча юк минем, туган. Салларны бит әле Чаллыга илтеп җиткерәсе, Чаллы байларына сатасы, Таминдар Тураевка акчасын кайтарып бирәсе бар.
Боларны ул ниндидер уйнак, артык күтәренке, кыланчык тавыш белән әйтте. Солтанга ошамады абыйсының алай кыланып сөйләшүе. Өстәвенә, мәшәкать ясап, яңадан балык алып азаплана. Бик кирәге барые, көне буе балык исенә сасып, чалбардан балык тәңкәсе кубарып йөрергә...
Энесе чыгып китүгә Шәяхмәт җитдиләнде.
— Я, Мулланур абый, күрешик. Нинди җилләр ташлады? Күрешмәгәнгә бер елдан артып китте бугай. Сагынып беттем үзеңне!
— Күрешмәгәнгә күптән, — диде Вахитов, аның кулын үз учында тотып торды, болыт астыннан бик азга гына күренеп калган кояштай мыек астыннан ак тешләре балкып күренде. — Камага кайттым. Техник булып. Кама төбен чистартырга.
— Тормыш төбен чистартырга диген. Институтың бетмәгәндер бит әле?
— Юк. Экспедициягә язылдым. Студент-практикантлар белән. Сынykка сылтау инде анысы.
Карванкада бөркү иде, Вахитов кәҗәнен салырга ниятләп, төймәләрен чишеп җибәрде, ләкин өстендә көмеш погонлы техниклар тужуркасы икәнен абайлап, кәҗәнен салып тормады, сала башлаган киез эшләпәсен дә батырыбрак киде.
— Чемодан китердем сиңа. Өстә — балык, аста — китаплар...
— Петроград яңалыкларымы?
— Күбрәге шулар. Казан яңалыклары да бар. Татарча өндәмәләр. Чемоданны кире кайтарырга онытма. Утырыйк әле.
— И-и-и, мәнсезлекне кара инде, ә! — диде Шәяхмәт. — Кайчаннан бирле аяк өсте тотам бит, ә?! Сал әле өстеңнән, утыр әле, Мулланур абый. Очрашу шәрәфенә берәрне аударыйк әле. Салчылар да шикләнмәс, күңелгә дә рәхәтрәк булыр.
Шәяхмәт тапчан астыннан бер штоф аракы, стенага беркеткән «аптечка» шкафыннан ике стакан алды, аларны тотылмаган чиста тастымал белән озаклап сөртте; салкын ит белән суган турап куйды.
Әкрен генә чәкәшеп, күтәреп куйдылар.
— Мәркәздә ни хәлләр? Гөрлиме Петроград?
— Петроградта мин Казан хәбәрләрен укып ятам. Казан большевикларының җитәкче ядросы төрмәдә. «Правда» алар белән элемтәдә. Царизмга каршы, алпавытларга каршы көрәшергә крестьянны чакыра, эшчеләр сыйныфын җитәкче көч итеп танырга куша.
— Лозунгы кычкырып кына авыл агае кузгалырмы соң? Крәстиәннең акылы бит аның, Мулланур абый, мескен бүрке астында түгел, крәстиән акылы җир белән береккән акыл ул. Бик әкрен, бик сак кыймылдый торган акыл. Кайнаррак вакыйга, гыйбрәтлерәк берәр хәл кирәк.
— Гыйбрәтлесе дә бар, Шәяхмәт. «Правда» күптән түгел генә «Тормыш мәхшәрләре» дигән мәкалә бастырып чыгарды. Казан губернасы турында. Крестьянның коточкыч хәерчелеге, изелүе хакында. Спасс авылындагы Мынов фамилияле бер крестьян, байлар соңгы ки-

шәрлек җирен тартып алгач, дүрт баласын балта түтәсе белән бәреп үтергән.

— Нигә балалар?

— Хәер эстәргә чыгарырга теләмәгән.

Алар илдәге хәлләр турында, Столыпин галиҗәнабләренең Россияне һәлакәткә алып баруы турында, дар агачлары, сөргеннәр, татар буржуазиясенең явызлыгы, мөселман руханиларының икейөзле, сатлык җанлы булуы турында сөйләштеләр.

— Беләсеңме, туганым Шәяхмәт... завод-фабрикаларда булганың булса, күргәнсеңдер, пар казаннары бар анда. Казан кайный, кайный, кайный, пары күбәя бара, күбәя бара, ә пар бит ул хәтәр нәрсә, аны каядыр чыгарырга кирәк, чыгармасаң — ул бит казанны шартлатачак. Шуңа күрә пар казанына җыелган парны әледән-әле чыгара тору өчен, казанга клапан куялар. Рәчәй илендә царизм төзегән империя — ул пар казаны, шартламасын өчен аңар да клапан куйдылар. Патша Россиясенең клапаны — Себер рудниклары, Казан төрмәләре, Ырымбур сөргеннәре. Казанның клапаны никадәрле зур булмасын, Себер киңлекләре никадәрле очсыз-кырыйсыз булмасын, шаулап ташыган парны ул гына йотып бетермәячәк. Ул пар дигәнебез — эшчеләр хәрәкәте, пролетариатның албасты сыйныфларны үз өстеннән алып ташлауга булган омтылышы — отыры күбәя, отыры дәһшәтләнә, ташый, күр дә тор, бер дә бер көнне ул Россияне шартлатачак.

Күбрәк Вахитов сөйләде, Шәяхмәт Айдаров, нягеи бирчәйгән бармаклы зур кара кулы белән учлап, ара-тирә баш селеккәләп, игътибар белән тыңлап утырды.

Тыңлый торгач, ул ничектер икеләнебрәк әйтә куйды:

— Беләсеңме, Мулланур абый, бишенче елны күпме кан коелды, күпме кеше корбан булды. Давылны кузгатабыз кузгатуын, кешеләрнең гомере белән уйнамыйбызмы? Безгә моның өчен кайчан да булса бер җавап бирергә туры килмәгәе!

Вахитов киез эшләпәне башыннан йолкып алды: тоныкут яктысында аның кызгылт-җирән бөдрә чәчләре ялкын телләредәй дулкынланып күренде. Зыялыларга хас ак чырае күзгә күренеп бүртенә, тулыша барды, урт тешләре кысылды.

— Җитте, иптәш! Җитте, булды! Вак-төяк шөгыль белән чикләнеп, кул кушырып утырыр заман түгел. Судагы көймә кебек чайкалып, икеләнеп торыр заман да түгел. Патша охранкасы Тәтешне керәшчесез калдырды. Учитель Казаков, хатыны Нәфисә белән, Ырымбур даласында йөри — сөргендә. Икенче учителебез — Фатих Шәмсетдинов — Сембер төрмәсендә. Хөсәен Ямашев җир куенында. Шуннан соң да без икеләнеп торырга тиешме? Көрәш корбансыз булмый, Айдаров! Дөнья яңартуны рус пролетариаты башлады. Без, татарлар, гомер буе рус белән кулга-кул тотынып яшәгән халык, дөньяны яңарту давыннан читтә калсак, тарих безгә моны гафу итмәс.

Шәяхмәт, бөркүлектән тыны кысыла башлап, кыек якалы кара сатин күлмәгенең изүен чишеп җибәрде. Күкрәк тутырып сулыш алгач:

— Нишләргә соң? — диде.

— Нишләргәме? Яшьләрне күтәрергә кирәк. Яңа Ямашларны! Яшьләр күңеле сизгер, куркусыз. Камчылы, канлы кулларга каршы әйтер сүзләрен курыкмыйча әйтсеннәр. — Тавышын әкренәйтә төште, сер бүлешкәндәй кайнар пышылдап, сүзен дәвам иттерде: — Тукай җеназасында булдым... Нинди асыл затны югалттык! Гасырларга бер генә туа торган даһины. Менә кем иде халыкның үз җырчысы. Тукайны бөтен Казан озатты, Казан гына түгел, бөтен Россия, Урта Азия. Менә ничек бит ул... Урамнар тулык, ишек аллары, йорт түбәләре. Транспорт туктаган. Олаучылар туктаган. Халык, баш түбәсенә күтәреп,

Тукаен алып бара. Ишми ишаннарга, икейөзле сатлыкларга, имансызларга күрсәтеп алып бара. Ә бит ислам руханилары да Тукайны үзләренеке димәкчеләр! Беләсеңме, Шәяхмәт, Тукай җеназасына Россиядән өч йөз мулла килгән иде. Чалмалылар төркеме, тәгъбир әйтеп, урам тутырып барды. Ә бит Тукай аларны гомер буе иң усал, иң миһырбансыз сүзләр белән тиргәп, фаш итеп килгән иде. Татар буржуазиясенә, татар руханиларына да Тукай кирәк булды! Үлгәч, җеназасында булса да, алар шагыйрь яклы булып кыландылар. Ә син әйтәсең, кеше гомере белән уйнамыйбызмы? Таңның ничек атканын белмисеңмени син? Кара төнне куып, кояш килсә генә таң ата ала...

... Кунак киткән булгандырмы-юкмы, күпмедер вакыттан соң, Камада бик хәтәр дулап, дулкын өемнәрен саллар өстенә ыргыта-ыргыта, давыл башланды.

Солтан Шәяхмәт абыйсының салларны яр буена ышыкка алып барырга боерык биреп, рулевой Сәфәргали белән Миргатага, Мәхмүткә кычкырганын ишетте.

Ул мондый чакта карванка эчендә утырып тора алмый иде инде. Йөгереп саллар өстенә чыкты. Өстенә, чиләге белән су органдай, яңгыр китереп бәрде, ә дигәнче лачма су итеп ташлады. Карванка эченнән ул иске кәҗәнне бөркәнеп чыкты. Җил шундый көчле, яңгыр суы, җил агынтысы белән, куәтле дулкыннар белән бергә кушылып, аяктан егып салырдай итеп бәрә, тыннарны куырып китерә иде.

Солтан абыйсы Шәяхмәтнең озын кара гәүдәсен, кулына тоткан сары фонарь утын, салчы егетләрнең гаять зур көч белән көсмән кагуларын, Кама суын каерып-каерып ишүләрен, ут яктысында аларның битеннән, киез эшләпәләреннән, брезент кәҗәннәреннән елга булып су акканын күрде. Үзенең бөтен гәүдәсе суыктан дер-дер калтыраса да, яка эченә чиркандырып су акса да, шушындый давыллы төндә, салчыларның барысы бердәй җан-фәрманга эшләгән чакта, ничек итеп карванка эчендә бикләнеп утырасың! Оят булыр.

Ләкин күпме генә батырайсаң да, тоташ бәргән салкын яңгыр астында, төннең төн буена саллар өстендә басып торып булмый бит.

Саллар биек ярлы бер култыкка таба борыла башлагач, ул карванкага керде; абыйсы кушкан йомыш исенә төшеп, сүнеп утырган самавырын яңартырга булды. Чыннан да, нишләп әле ул бер эшсез яңгыр астында йөри, башкалар эшләгәндә, хөрәсән ялкавы кебек, башыннан кәҗән бөркәнеп, бөкшәеп басып тора. Менә, тиле!

Тырыша торгач, өрә торгач, самавыр эчендә ут дөрли башлады. Бераздан, самавырның җырлый-җырлый кайный башлавына сөенеп, үзе дә шуның янына килеп утырды, самавыр җыры белән бергә, үзенең дә күңеленә җыр килде. Шушы давыллы төндә, ике зур кара толымы белән, мөлдерәтеп карый торган зур кара күзләре белән, Нурия аның күз алдына басты. Ул күңеленнән аның белән болынга балтырган җыярга барды, үрдәк бәбкәләре саклады, Ләлек мамык чыбыркы белән бәргәләп көтү көтте, паромга утырып кояш җылысына иркәләнеп, Кама аръягына карлыганлыкка чыкты, кош оялары карады, яр буенда пароходлардан ташлап калдырган карбыз кабыкларын җыеп ашыйашый, көлә-көлә йөрде.

Тышта салчылар сални ышык урынга, текә яр астына алып бардылар.

Менә хәзер алар, өшеп-туңып, карванкага керерләр. Их, маладис, Солтан, самавыр кайнатып куйгансың, дип аны мактый-мактый чәй эчәрләр, аларның гына түгел, үзенең дә сал агызуда катнашлыгы барын тою Солтанга рәхәт булыр.

Салчылар турында, дулый-дулый дулкыннарын аткан, суык яңгыр-

ларын чиләкләп койган Кама турында уйлагач, Солтанның күз алдына төнге кунак килде. Абыйсы самавыр куярга кушып, юкка гына чыгарып җибәрде лә аны! Балык дигәне аның бөтенләй дә буш сүз булгандыр. Кап-караңгы төндә, давыл кузгалырга торганда, кем инде балык сатасым бар дип елга кичә? Юк, ул балыкчыга охшамаган. Мыегы да ул түгел, чыраеның аклыгы да ул түгел, чәченең җирәнлеге дә ул түгел. Теге көнне балык китергән кешеләр укмашып беткән сакаллы, күзләре белән тешләре генә елтырап калган кара-кучкыл чырайлылар иде.

Ә монын мыегын бөтереп куюы ук ни тора. Саумы, иптәш! Кайсы балыкчы сине шулай үз күреп сөйләшсен? Күпсенгән булды бит Солтанның абыйсы аңардан кунагын. Сөйләштереп утырмаган булды.

Бу көннен һәм Зартугайдан кузгалып киткәннән бирле узган бер атнаның вакыйгалары, хис-тойгылары шул хәтле дә күп иде, алар инде Солтанның җанын тутырып кына калмаганнар, басып ук тора башлаганнар иде, аннары суыкта чыланып кергәннән соң, җырлап кайнаган самавыр җылысында утыру шундый рәхәт, шундый талгын иде ки, Солтанның күз кабаклары авырая башлады, йокламаска күпме генә тырышса да, ул булдыра алмады, уянмаслык булып, оеп йоклап китте...

Ишектән бәреп кергән салкын, шаулап дөбердәшеп кергән салчылар уятты аны. Ул ялт кына сикереп торды, самавырына ташланды, шундук йөрәге өшеп китте: самавыр зәңгәрләнеп кыйшаеп төшкән иде.

Шәяхмәт абыйсы, кара мыеклы чибәр йөзен кулы белән каплап, эрегән самавырга моңсу гына карап торды да:

— Ярый, энем, маладис, эшкә ярый башладың! — диде.

## XI

1913 елның көзендә Шәяхмәт абыйсы Солтанны, Алабугага китереп, Земское училищега укырга урнаштырды.

Мондагы тормыш Кама дулкыннары өстендә тирбәлеп, төнге йолдызлар белән серләшү, сал йортында йоклау, хәтта давыллы яңгырларга чыланып йөрүгә караганда да кыенрак булып чыкты.

Стахиевларның көпчәкле йөк пароходына утырып, тозлы балык мичкәләре, он капчыклары, нинди-дер чыптага төргән авыр түкләр арасында көннен-көн буе азапланып килгәннән соң, алар Шәяхмәт абыйсы белән икәү, Алабуга пристанендә пароходтан төшеп калдылар.

Каршыда — Солтан беркайчан да күрмәгән текә тау, тауга исәпсез-сансыз басмачалары белән агач баскыч күтәрелә, Солтан, күрәсең, әнә шул баскычлар буйлап менәргә, менәргә, менәргә тиеш.

Безнең Зуртугай малае юньле-рәтле русча белми, ә бу хәлнең үз тормышында нинди күңелсезлекләр китереп чыгарасын башына да китерми иде әле.

Шәһәрнең Ерзовка бистәсендә яшәгән купец малайлары читтән берәр авыл «гыйбаты» килеп чыктымы, аңа капыгып, аның русча белмәвеннән көлеп, җаннарына рәхәт табалар иде. Башкисәр булу белән бөтен Алабугада дан тоткан Вадим Шарашкин шәһәр урамында пәйда булган һәрбер яңа малайга йодрыгын танытмый тынычланмый иде.

Солтан беренче көнне, училищеда күргәннәрен күңеленнән барлап, русча өйрәнә алмасам, ничекләр укырмын дип, хафага калып, башын түбән иеп кайтып килә иде, кинәт колак төбендә үк:

— Дорогу, деревенщина! — дип кычкырып җибәрделәр.

Солтан туктады, үз янында басып торган затлы киемле өч малайны күрде. Аларның елмаешып басып торуларыннан, болар миннән тартырга тәмәке сорыйлар бугай дип, уң кулын авызына китерде, ике бармак арасына тәмәке кысып тоткан сыман иттереп:

—Ниту, ниту! — диде.

Малайларның озын буйлы, кызыл чырайлысы бер адым алга атлады, ике кулын йодрыклап янәшә куйды да, һаман да елмайган килеш, Солтанның аяк астына китереп орды. Солтан, «аһ» итәргә дә өлгермичә, якындагы канауга чалкан әйләнеп төште.

Өч малайның өчесенең берьюлы шаркылдап көлгән тавышына исен җыеп, канаудан торды, канаган борынын җиңе белән сөртә-сөртә, җан ачысы белән елый-елый, үзен нахакка рәнҗеткән олы малайга — Шарашкинга килеп ябышты. Шул чакны малайларның икенчесе, күзенә үк батырып кара фуражка кигәне, Солтанның яңак төбенә шундый да чалтыратып салып җибәрде, малайның күзеннән утлы-яшелле очкыннар очты. Ул да түгел, өченче малай аны аяк чалып екты, һәм алар, өчесе берьюлы аның артына тибеп, көлешә-көлешә китеп бардылар.

Гарьлектән, бер гаепсезгә кыйналудан, йөрәге тоташ нәфрәт уты белән тулып, хәтта инде кычкырып елый да алмыйча, эт кебек шыңшып, җиргә йөзтүбән капланып ята иде.

«Тикай! Тикай!» — дигән тавышка башын күтәрде.

Караса — Шарашкин үзе дә, аның куштаннары да төрлесе төрле якка чабышалар. Солтаннар белән бергә укырга кергән Салагыш малае Мәрдән тегеләрне куып бара.

Солтанның йөрәге тасырдап тибә башлады.

Куа чыгарга!

Йөгерү турысына килгәндә, аны Зартугайда беркем дә уза алмый иде. Солтан сикереп торды да, шешкән яңагын, канаган борынын онытып, җан-фәрманга Шарашкин артыннан чапты. Бер мәртәбә канауга очып төшү аны саграк кыланырга өйрәткән иде. Шарашкинны куып җитү белән ул аңа тота-каба барып асыланмады, җиргә егылып, тегенең ботыннан кочаклап алды. Шарашкин гөрселдәп җиргә ауды.

Ул арада Мәрдән дә килеп җитте.

Купец малаен ул якасыннан умырып тотып, аягүрә бастырды, кизәнми-нитми генә, бала башы хәтле йодрыгы белән тегенең аяк астына китереп орды.

Шарашкин егылмады, а-а-а дип, ике кулы белән битен каплады.

— Ә-ә-ә, рәхәтме? Рәхәтме? — диде Солтан, аның әле бер, әле икенче ягына йөгереп чыкты.

Купец малае бәлки Солтанның татарча әйткән сүзләрен аңлап та бетермәгәндер, әмма Мәрдәннең йодрыгын аңлады бугай, сугышырга теләмәде, арырак бер читтә куркышып карап торган куштаннары янына китеп барды...

Русча белмәү. Һай, ул русча белмәүләр... Нинди генә күңелсезлекләр алып килмәделәр алар Солтанга.

Әгерҗе ягы малае булганлыктан, Солтан беркайчан да «д»ны чиста итеп әйтә белми. Аның ничектер башкортлар әйтеменә тартым «з» килеп чыга. Укытучы Елизавета Сергеевна Солтанга бер көнне китаптан кычкырып укырга кушты. Солтан, аны-моны уйлап тормастан, «Я могу свобозу заровать!» — дип укып китмәсенме!

Елизавета Сергеевна әйтә:

— Свободу даровать.

— Свобозу заровать, — дип кабатлый Солтан.

— Да-ровать,— дип иҗекләргә бүлә укытучы.

— Заровать, — дип кабатлый Солтан.

Класста хәзер ачулы «даровать» белән юаш тавышлы «заровать» кабатланып тора башлады.

Елизавета Сергеевна түзмәде, китабын кулына тоткан килеш Солтан янына килде дә, үсмернең башын кулы белән үзенә таба борды.

— Скажи, Айдаров, «де»,— диде.

— «Де», — диде Солтан.

— Вот так, скажи: даровать, — диде укытучы сөенеп.

Солтан каушавыннан тагын онытып җибәрде. Әүвәлгечә үк:

— Заровать, — диде.

Моңарчы көч-хәл белән түзеп торган малайлар шаркылдап көлеп җибәрделәр.

Елизавета Сергеевна, юри үчеклиләр дип белде, ахрысы, ике кулы белән башына тотынып, елап җибәрде. Чәчләре тузгып, тарагы, шпилькалары идәнгә чәчелде һәм ул, озын итәкләрен җилфердәтеп, бүлмәдән чыгып китте.

Шомлы тынлык.

Кап-кара ряса кигән поп килеп керде.

— Кто Айдаров?

Солтан аяк өсте басты.

Поп, күкрәк турысына сәгать чылбыры белән аскан зур алтын тәресен кулы белән басып, ашыкмый гына Солтан янына килде, үсмерне колагыннан тартып парта арасыннан чыгарды, кара такта янына китереп бастырды. Башта кул аркасы белән Солтанның битен чабаклады, аннан соң йодрыклары белән башын төйде, ахырдан чәченнән учлап тоткан көе башын стенага бәрергә тотынды.

Бу гамәлне кылган чакта попның битендәге бер генә төге дә селкенмәде, биленә җиткән кара сакалы гына селкенгәләп торды, алтын тәресе атынгалады.

Солтан өч көн рәттән дәрескә бара алмыйча, саташып авырып ятты.

Терелеп аякка басуга ул Зартугайга кайтып китәргә, Алабугага бүтән беркайчан да аяк басмаска дип күңеленнән ант итте. Әнә Шәяхмәт абыйсы Земское училищеда укымаган әле, нинди итеп сал куа, нинди көймәләр ясый, сарылы-зәңгәрле йортлар сала белә. Солтан үзен, Шәяхмәт абыйсы кебек, шомырт кара мыеклы, биек сәхтиян итекле, буйдан-буйга ак сәдәп тезеп чыккан кара сатин күлмәкле гайрәтле егет итеп күз алдына китерде. Иртәгә үк абыйсына: «Ал мине моннан, минем монда түзеп торыр хәлләрем калмады, алмасаң, мин качып кайтып китәм»,— дип хат язып салырга булды.

Иртәгесен ул курка-курка гына училищега барды, курка-курка гына эчкә керде. Документларын сорап алырга кирәк иде аңа. Кан калтырап, кара рясалы поп белән очрашудан коты алынып укытучылар бүлмәсе янына якынлашты. Якынлашты һәм... кинәт телсез калды.

Анда кулына кәрзин тоткан, башына ак шәл бөркәнгән Нурия басып тора иде.

— Син каян килеп чыктың? — диде ул бөтен кайгысын берьюлы онытып. Йөгереп аның каршысына килде.

Нуриянең зур кара күзләре тагын да зуррак булып ачылдылар.

— Солтан... ни булды сиңа?

— Ә... миңа? Берни дә булмады...

— Ә нигә күз төпләрең күгәргән? Әллә кыйнадылармы? — Нурия кәрзинен идәнгә куйды, Солтан белән ике куллап күреште, аның кулы җылы иде, күзләрендә Солтанны кызганудан моң саркып чыккан иде, ул елар чиккә җитеп: — Чыннан да... кем тиде сиңа? — дип сорады.

Солтан башын иеп беркавым дәшми торды, аннары өзелеп киткән тавыш белән, карлыгып:

— Әй, китәм лә мин моннан... — дип әйтеп куйды.

Укытучылар бүлмәсендә кемнәрнеңдер русчалатып дәгъвалашканнары ишетелде.

Нурия кемнәрнеңдер аннан чыгып килүләреннән шикләнеп, Солтанның кулын ике куллап тотып алды да:

— Ә мин тагын... сине эзләп... килеп йөргән булам...— диде. Әнә шул сүз Солтанны Алабугада алып калды.

... Тормыш тора-бара үз дигәнен итте, әкренләп Солтанның юашлыгын куып чыгарды. Җирән чәчле, дәү йодрыклы Мәрдәннәр, тиктормас Зарифлар, моңсу күзле Шәрифҗаннар белән дуслашу аңа ялгыз түгеллеген, бу дөньяда иптәшләре барлыгын аңлатты. Ул туп сугарга, тәрәзә ватса качарга, купец малайлары сугышырга тотынса, аларга «сдача» бирергә өйрәнде.

Тик бай малайлары белән уртак тел табарга гына өйрәнә алмады.

Алабугада уку йортлары күп; урамнарда епархиальное, реальное, городское, ремесленное, земское училищеларында укучы купец малайлары йөри, мещан кызлары йөри, алар инәдән-җептән генә чыккан елтыр киемнәре, тимер аякта, тимер чаналарда шуулары, урамнан күкрәк киереп атлаулары белән Солтанны кызыктыралар. Солтаннарга дин сабагы укытучы, бармаклар тигез булмаган кебек, адәм балаларының да тигезсезлеге аллаһы тәгаләдән килә дип аңлатучы Мисбах ахунның бер кызы гимназиядә, улы Реальныйда, зурысы кайдадыр (Петербурның үзендә үк диме!) авыл хуҗалыгы институтында укый икән. Болар кайчан карама шат күңелле, тук чырайлы. Болар урамнардан узган чакта купец Стахиевларның Россия күләмендәге байлыклары, бөтен Кама буена атаклы сыра заводлары, әчен чынаяк тәти төсле кафель белән тышлаган су коену бассейны турында сөйләшәләр, Ерзовка бистәсендә бер үзе әллә кайлардан ук күренеп торган дүрт катлы кызыл кирпеч бинаны — тоташ карадан киенеп йөри торган кызлар укыта торган Епархиальное училищены мактыйлар. Имеш, аны купец Стахиев салдыра башлаган да, бетереп җиткерә алмыйча, үлеп киткән. Стахиевның хатыны ирен бик яраткан, аны оныта алмый икән, иренең истәлеге итеп, бинаны салдырып бетергән. Инде менә хәзер Епархиальноеның кызлары карадан бөркәнеп, Стахиевның үлем хәсрәтен чигеп йөриләр. Траур дип атала русча.

Солтанга кинәт кызык булып китте: бер Стахиев үлгән, ике йөздән артык кыз аның хәсрәтенә хәсрәтләнеп кара көеп йөри. Тагын өч ел буе йөриячәк. Аннары алар попларның, дьяконнарның хатыннары булып китәчәкләр. Стахиев хатыны руханиларга затлы кызлар укытып бирә!

Солтан Габбас мулланың яшь хатынга өйләнүен күз алдына китерә. Ул исәптән Хәнифә түтине дә менә шундый таш биналарда укытырга кирәк булып чыга түгелме? Аны да мулла хатыны итәр өчен аерым киемнәргә киендереп йөртергә кирәк түгелме соң?

Габбас мулла турында уйлый башлагач, Солтан үзеннән-үзе күңел җепләре белән Нуриягә барып тоташа. Томыраеп торган зур кара күзле, биленә җиткән калын кара толымлы Нурия ул югында тагын да буйчанрак булып киткән, училищега йөрү өчен аерым форма да киеп алгач, әллә ничек үзгәргән иде.

Беренче көннәрне Солтан аңар бер дә карамаска, күзен дә салмаска тырышты. Кама буйлап сал куган чакта аны уйлап, аның өчен сагышланып йөрүләренә уңайсызланды. Ул аның уйларын, тойгыларын белгәндер кебек тоелып, тәне чымырдап киткән чаклары булды. Дәрестә ул я укытучысына, я дәфтәре өстенә генә иелеп утырды. Сабак бетүгә иң алдан чыгып фатирларына йөгерде.

Кичен өйгә биргән шигырьләрне ятлап утырган чакта аның күз алдына томыраеп торган зур кара күзле, аңа бик якын да, буй җитмәс ерак та булган кыз килеп баса иде. Баса да аны шигырь ятлаудан туктата. Китапның хәрефләре әлҗе-мөлҗе килә башлый, юллары саташа, Солтанның башына берни керми.

Дәресне өйрәнми килгәне өчен ул укытучысыннан шелтә алды. Бөтен класс алдында кызарынып басып торды.

Аның оялуы класстан түгел, барыннан да элек Нуриядән иде. Нурия аны, әлбәттә, булдыксыз малайга, бер тиенгә торгысыз, сәләтсез

укучыга санады инде. Аның белән бер училищеда, бер класста укып йөрүенә хурлангандыр да әле...

Солтан кара такта яныннан китеп, урынына барып утырган чакта, ихтыярсыз Нуриягә күз сирпеп алды. Ни хикмәттер, кызый ана кимсетеп карамый, мыскылламый, хурламый да, әллә ничек үз итеп, малайларча бер кызыксыну белән, авызын ачып карап тора иде.

Солтанның күңеле тынычлана төште, ул кыюланыбрак китте. Зартугайдагы гадәте буенча, кызга төртеп, я булмаса, чәчен тартып китү теләге уянды.

Әмма Нурия күзгә күренеп үзгәрде.

Аның зур кара күзләре шундый да ягымлы-ихлас итеп, үз итеп, томыраеп бер карады — Солтанның күңеле тетрәп китте.

Өйгә бергә кайттылар.

— Син кайда торасың? — диде Нурия, училище капкасыннан чыккач.

— Казанский урамда, ә син?

— Мин дә шунда торам бит...

— Китче! Әйдә алайса бергә кайтабыз.

— Соң әйдә...

Бер кварталны сөйләшми генә кайттылар. Алабуганың иң зур чиркәве турысына җиткәч, Нурия башын артка ташлап югары карады.

— Ай-йай биек! Түбәсенә менеп җитеп буламы икән моның, Солтан?

— Була. Минем анда менгәнем бар. Узган атнаны Мәрдән белән бергә менеп карадык.

— Булмас. Алдашасыңдыр...

— Менеп күрсәтимме?

— Яле!

— Ә син?

— Нәрсә мин?

— Син менсәң — менәм.

— Менмәсәм — менмисеңме?

— Юк. Беләсеңме, анда нәрсә бар?

— Нәрсә?

— Мунча түбәсе чаклы кулыкыл.

— Кит аннан, мунча түбәсе чаклы кулыкыл буламыни? Ат башы чаклы диген, ичмасам.

— Ышамыйсыңмы? Әйдә, бәхәс!

— Нәрсәдән?

— Әгәр мин әйткән дөрескә чыкса... мин сине көн саен озата барам... Өегезгә тикле.

Нурия кып-кызыл булып кызарды, шулай да ризалашты.

Чиркәүнең кеше йөрми торган аулак ягыннан, сәрби куаклары арасыннан, сыдырыла-сыдырыла әчкә уздылар. Рәшәткәнең тимере киңәйтелгән бер төшеннән баскыч янына килеп туктагач, Нуриянең йөрәге сикереп чыгардай булып тибә башлады.

— Солтан... мин куркам...

— Курыкма. Анда беркем дә юк. Иөгереп менәбез дә йөгереп төшәбез. Бүген әле урысларның бәйрәме түгел, анда беркем дә йөрми.

— Әйем, куркам.

Солтан башка бер сүз дә әйтмәде, читкә китте. Урамны аркылы чыктылар. Чатка басып чиркәүгә карап тордылар.

— Кулыкыл, атлы арба сыярлык, — диде Солтан үпкәләгән тавыш белән. — Юкка менмәдең. Беләсең килсә, аны биш ат та тартып алып бара алмый.

— Алмас инде бар. Безнең кара айгыр да тарта алмыймыни?

— Алмый дидем бит инде. Аның бит авырлыгы биш йөз пот. Бер ат егерме биш поттан да артыгын тарта алмый.

— Биш йөз пот? Әнекәем! Булмас... — диде Нурия әле һаман ышанып җитәргә теләмичә. — Ә нигә соң аны шулай зур итеп койганнар? — диде.

Солтан чиркәү түбәсеннән аста, ерак булып күренеп яткан уйсу үзәнлеккә, күз күреме җитмәс болыннар, әрәмәләр арасыннан кояш нурын балкытып агып яткан Кама елгасына карап тора иде, ерак урманнар, офык өстендә җыелып торган күгелҗем болыт өемнәре аның игътибарын биләп алган иде.

— Нәрсә дисең? Ник зур итеп койганнар дисеңме?

Ул кыңгырауны нигә шул тамаша зур итеп коюларының сәбәбен белми иде. Ләкин Нурия алдында авыз күтәреп белмим дип тору уңайсыз тоелды. Шуңа күрә ул үзе уйлап тапкан беренче уйны әйтте:

— Бәхетсезлек килсә хәбәр итәр өчен, — диде ул әкрен генә.

Әчке бер сизенү белән әйтелгән бу сүзләр тагын бер елдан соң дөрескә чыктылар.

... Кич. Караңгы төшеп килә.

Солтан белән Нурия Ерзовка бистәсеннән кайталар.

Урам уртасына җигүле атлар килеп бөялгән, коймаларга орына-орына, урам тутырып халык ташкыны килә.

Ташкын үзенең зурлыгы белән, кеше авазларын, эреле-ваклы чиркәү чаңнарын, баш өстенә тәре күтәреп барган попларның дога укыган тавышларын йота.

Кинәт тонык гүләүне, нәзек чаң тавышларын барысын күмеп, биш йөз потлы гигант чаң суга башлады. Бу аваздан җир селкенә, йортлар калтырана; атлар ярсып аягүрә басалар да, сискәнеп, җиргә чүгәләр иде.

Чиркәү каршысына мәйданга җыелган халык, күмәк ташкын булып, пристаньга таба кузгалды. Дәһшәтле чаң тавышы тынган араларда, кайдандыр билгесез бер яктан муллаларның моңлы тавыш белән коръән укулары ишетелеп куя, ул моңлы тавышка катыннарның ачыргаланып улап елаган тавышлары килеп кушыла иде.

Солтанның күзенә чалынып калды: Шәяхмәт абыйсының хатыны Сара җиңгине кемнәрдер култыклап алып киләләр, ул татар хатыннарына хас сабырлыгын җуйган, өчкелләп бәйләгән бизәкле яулыгыннан бүселеп чыккан чәчләре җилдә тузгый; йөзе аның тораташ кебек каткан, күгәргән иреннәре: «Йа, алла, йа, раббем...» — дип туктаусыз бер үк сүзләрне кабатлый.

Аның янынннан атлаган олы яшьтәге, сарафанлы бер әби:

— На кого ты нас оставляешь, кормилец? — дип такмаклап елый.

Пристаньга таба агылган халык төркеме өстеннән, урамнарны иңләп, елау-сыкрау авазларын бергә туплап, рәхимсез бер сүз калка:

— Сугыш!

Кичке җил ул сүзне йөзләгән чабаталы аяклар күтәргән тончыктыргыч соры тузан белән бергә кушып, бөтереп, күккә алып менә, ачы хәсрәт сөреме итеп кешеләрнең йөзләренә китереп сылый.

Солтан белән Нурия үзләрен камап алган догалардан, улап елау, ачынып кычкырып җибәрүләрдән качарга теләп, ләкин беркая да кача алмыйча, халык төркеме эчендә, шул төркемнең аерылгысыз бер кисәге булып, баралар да баралар...

*Дәвамы бар*

## Хәсән Туфан

### Иртәләрнең берсе

Әйләнә Җир тавыш-тынсыз гына
Иртәге көн янына табан —
Айлы төн үтәли үтеп бара
Кояшчыгыш ягына Казан.

Янып, балкып Җиргә төшеп китте
Метеор үзенең орбитасыннан,
Бөек һөҗүм вакыты җиткәнлекне
Хәбәр иткән ракета сыман.

Горизонтта — яңа таң калыкты
Тантаналы капка шикелле!
Киләчәккә табан аккан Ыкны,
Актанышны, Ыкны, Мөслимне

Таң капкасы аша яңа көнгә
Алып килеп керде Җир шары.
Сабан туйга барган кебек итеп
Эшкә чыга безнең Ил тагы.

Табигатьне гүя атакалап,
Һөҗүм башлап кырый төбәктә,
Районнарны кыю секретарьлар
Алып кереп китте көрәшкә.

Алып керде алар Актанышны,
Бөгелмәне, Әлмәт, Шөгерне,
Генераллар дивизияләрне
Җиңешләргә илткән шикелле!

---

Төрле елларда язылган шигырьләремнең бер кадәресе ике томлык сайланма әсәрләр күләменә сыймаган иде. Шуларның кайберләрен укучыларыбызга журналыбыз аша тапшырасы килә. Х. Т.

## Эштән кайтышлый

Син уйланып бераз туктап алдың
Киләчәккә үтеп барышлый...
Кояш инде шактый артта калды,
Казан инде
Кичне каршылый.

Кучмә байрак нурларында балкып
Үтеп китте бүген дә көнең;
Ә урамда шундый күңелле кич,
Болытлы да, бөркү дә түгел.

Зур җаныңның барлык иҗат көчен
Биреп тагын илең эшенә,
Байрак тотып кереп бара төсле
Бу көнең дә
Гасыр эченә.

Моннан ара якын кебек ничек,
Сыйныфларсыз тормыш чорына.
Байрагыңны килер көннәр җиле
Җилфердәтә төсле тоела...

## Ә печәнне...

Бу ягын да Илнең күримче дип,
Атта гына килдең Кырлайга...
Һәм мине дә шулай атта гына
Алып чыктың безнең кырларга.

Каеннар да, әйе, баланнар да,
Бар да монда — синең илдәшләр!—
Безне дә лә үзеңнеке ит дип,
Баш ияләр сиңа миләшләр.

Бәхетле син: һичбер гамь юк синдә,
Һәр ягында — Ил дә, җир дә бар,
Ул диңгездән теге диңгезгәчә
Кайда киңлек — анда син дә бар...

Һәм... тугармый гына бәйләп куйган
Ат та бар бит, абзый, дөньяда! —
Син дә шагыйрь, әйтик, мин дә шагыйрь,
Ә печәнне атка кем сала?!

•

...Байтак көнең юлда үтә, ир-ат,
Илдән-өйдән ерак җирләрдә.
Гаиләнең ,өйнең иминлеге,
И хатын-кыз, синең иңнәрдә.

Бураннарда искә төшәсез дә,
Җылынып китә безнең күңелләр!—
Сагындырган өчен рәхмәт сезгә,
Юксындырган өчен, сеңелләр.

Яздан хәбәр булып алтын нурлар
Тәрәзләрдән түргә кергәндә,
Үбеп-кочып сезне, и җаныйлар,
Сәлам әйтеп чыксын бездән дә.

•

...Ә кем белә аны — алдагыны,—
Ниләр булыр... шушы ел узгач:
Килеп җитәр тагын — туган көннәр...
Кем булыр да анда, кем булмас...

Моңсыз әле, тыныч безнең күңел.
Гөлләр генә әнә... уйчаннар:
Тынычгыз да хәтерләгез әле —
Дигән сыман уйга чумганнар.

«Әйтмәсәләр» истә түгелмени
Безнең өчен газиз исемнәр?!
Сип әле, сип, су сип шул гөлләргә! —
Күңеллерәк гомер итсеннәр...

## Юлдан гына

«Безнең юл»дан [1]
Чыккан идек юлга.
Күбәү идек...
Борылып карасак,
Азайганбыз:
Киләчәккә инде
Күчкән күпләр безнең арадан...

Сәлам бирә йөрәк
Юлдан сиңа,
Истәлеге итеп
Бу көннең: [2]
Тик яртысы гына булсын иде
Бу Иллесе
Синең гомернең!

---

[1] «Безнең юл» — хәзерге «Казан утлары» журналының Галимҗан ага Ибраһимов чорындагы исеме.
[2] Гази Кашшафның 50 еллыгы бәйрәмендә укылган шигырь.

## Кына

*«Төшләреңә кереп йөдәтермен».*
*Р. Алка*

Ак болытлы Әлтәм төннәрендә,
Алтын таллар күләгәсендә
Җаннарыма яллар бирим дисәм,
Искә төшеп йөдәтәсең лә,
Искә төшеп...

Утлар дөрли көзге куе җилдә,
Төн таулары түбәләрендә.
Сүним әле, тыныйм бераз дисәм,
Искә төшеп йөдәтәсең лә,
Искә төшеп...

Синнән калган кына кайсы икән?
Кайсы чарлак тәрәзәсендә?
Тәрәзләрдә гөлләр күргән саен
Искә төшеп йөдәтәсең лә,
Искә төшеп...

## Җиделәр

Ал байрагын, гүя җан байрагын
Җилфердәтеп Заман җилендә,
Ноябрьның соңгы җидесендә [1]
Килеп керәм җитмеш җидемә.

Синең, Илем, җырдай гүзәл телнең
Чәчкәләре микән җиделәр?—
Шулар, никтер, гомер буе миңа
Шигъри серле җылы бирделәр.

Көйләрдәге, төсләрдәге җырың [2]
Яңрый, Галәм, һәрбер җидеңдә:
Бу халәтең ишарәдер бәлки
Мәңгелекнең бер сыр серенә...

...Җиде төндә, җиде юл чатыннан
Баксам әгәр Җидегәнеңә,
«Җиде үлчә — бер кис!» дигәннәрең
Иңде минем күңелләремә.

...Чүлләрен дә кичтем дәверләрнең,
Гөлләрен дә өздем аларның...
Гасыр аша үтмәкчедер бәлки
Синең, Хәсән, гомер кәрваның?..

---

[1] Иске стиль белән исәпләгәндә 1900 ел ноябренең 27 се шагыйрьнең туган көне.
[2] Спектр һәм музыкадагы гамма һ. б. җиделәр.

Сиксәненче еллар ягындагы
Капкаларның җиделесенә
Җитәрсең дә, кәрван, үтәрсеңдер
Ул капканы тик минсез генә...

●

Шигъриятнең лирик милләтеннән,
Бер каннандыр безнең бу җаннар.
Белмим нидән, нигә шулай икән,
Сагындыра Сезне бу айлар?

Әйткән иде инде Дөнья миңа,
Әйткән иде әллә ничә кат.—
Дөрес икән: бары — фикри, шигъри,
Рухи дуслык балкый ич фәкать!

Милләтләргә бүлгәләсәләр дә
Лирикларны кайбер гасырда,
Төп милләте һәрбер чын чәчәннең
Шигърият бит, дуслар, асылда.

«Шигъри» кәсеп мәрәкәйчеләре
Тәрәздән дә — түргә узса да,
Алар «җаны» җиде ят бит безгә!—
Гәрчә каны «кардәш» булса да.

Кагылмасын шигъри кардәшлеккә
Фани дәртләр, фани өметләр:
Теге дөньяда да — я «яшисе»,
Я «үләсе» бар бит, егетләр.

Шигъриятнең лирик милләтеннән,
Бер каннандыр безнең бу җаннар...
Менә шулай сагына бу айларда
Хәсәнегез сезне, туганнар.

●

...Җил дә йоклый,
Төн дә тып-тыныч.
Сәбәп юк та дулкынланырга,
Нишләп, Диңгез,
Уф та уф килеп
Зарланасың Гагра ярында...

Син әйтәсең:
— Минем гомерем
Нинди кызык, нинди чиксез ул!
Әйдә, дисең,
Алмашабызмы?—
Мин — син булыйм, ә син — Диңгез бул!

Юк, кирәкми,
Синең — мәңгенең
Озынлыгы чиксез дә шиксез,
Ә мәңгегә хөкем ителү...
Беләм аны,
Ул бик күңелсез.

♦

...Кашлар — кыйгач, йөзләр — көләч.
Кояш болар!— диярлек.
Аяк баскан эзләренә
Асыл гөлләр сибәрлек.

Кайгы килсә, илермиләр.
Халык исмен сатмыйлар:
Тешне кысып, яшьне йотып,
Илдән әдәп саклыйлар...

Ул чактагы заманалар
Драмага бай иде,
Югалганнар, убылганнар,
Җуелганнар бар иде.

Ялгыз калды... Нишләсә дә
Иле исмен сатмады.
Тешен кысып, яшен йотып,
Йөрәгендә саклады.

Күргән-белгән сөйли һаман:
«Көтте, түзде, бизмәде,
Гомерләре өзелсә дә,
Өметләрен өзмәде...»

Ишетә алса әйтер идек:
— Үзеңне дә сөяргә
Кирәк иде!.. Соңга калдык
Менә шулай дияргә...

...И сез— безнең сеңелкәйләр!—
Кашларыгыз кыйгачлар,
Илнең гомер юлларына
Нур сибүче кояшлар,

Әнә шулай сөя сезнең
Йөздән туксан җидегез!
Әй, егетләр!
Шундыйларның
Кадерләрен белегез...

## Әле дә хәтердә

...Сорады Тары нараты:
«Исемкәй ничек синең?»
— Әптел дә, Гаптел дә түгел,
Тимерхан!— минем исем.

Сискәнеп куйды Нараткай —
Кайгырта, чамалаша:
«Индеге чорда, энем,— ди,—
Бу исем «янар» ласа?!»

Кайгырма, Нарат агай, дим,
Бу исем — хәйран исем:
«Хан»ымны төшерсәләр дә,
«Тимер»ем кала минем!..

...Сорады Карел каены:
«Кайларда туган ягың?»
Илемнең кайда икәнен
Белмәкче була, җаным.

— Кайларда булса да, димен,
Дөньяга килгән җирем,
Мең елдан бирле, сеңелкәй,
Туган тел минем илем...

...Ә миләш, Минзәл миләше,
Бик чибәр гибрид миләш:
— Минемчә яшә, Тимур!— дип
Бирмәкче миңа киңәш...

Тукай да — «И тел...» дигән ич.
Күрәсең, шуңа күрә,
Исәң дә, җаным, башыңны,
Йөрәк бит аягүрә.

## Мин тере бит әле

Була, кордаш, шундый читен кичләр...
Җанга терәк кирәк чагында,
Такташ та юк инде, Кутуй да юк,
Барып чыгып ишек шакырга.

Әйтә торган иде безгә Такташ,
Ярым җитди, ярым шаярып:
«Бу дөньяда бәндә күп тә күбен,
Таяныч аз, кәбәм, таяныч.

Гомер юлы тигез асфальт түгел,
Базлар да бар кайбер урында...
Абынырбыз да әле, егылырбыз да,
Торырбыз да, алла боерса...

Яшь талантлар башы аша үтеп,
«Шабашниклар» үрли шигырьгә.
Кул бирергә түгел, сүз кушарга
Чирканасың шулар ишенә...»

Шулай дия иде безгә һади,
Ярым җитди, ярым шаярып...
Такташлы чор ерагайган саен,
Кими бара интим таяныч.

Була шундый авыр, читен төннәр...
Җанга терәк кирәк чагында,
Мин тере бит,
Миңа килеп чыгып
Мөмкин әле ишек шакырга.

## Сандугачлар эзлиләр каенны

Бетерделәр аны...
Бәлки аның
Без белмәгән гаебе булгандыр...
Сандугачлар белән дус иде ул,
Бәлки аны... бары шуңадыр...
Үтерделәр...

Кем уйлаган... шундый яманлыкны
Кем дә булса тагын башлар дип:
Шундый гүзәл затны
Балта белән
Дүрт кисәккә турап ташлар дип,
Кем уйлаган...

Ул яшәүне җирдә сөя иде,
Кочаклардай булып, үз күреп!—
Әле генә менә унынчыдан,
Имтиханнан чыккан кыз кебек...

Зифа иде, сылу гүзәл иде,
Күрми калдык, саклый алмадык...
Безне бит ул
Кешегә саный иде...
Ә без?
Юк, без моны аклый алмадык!..

Уйлый иде:
«Болар — яшәү дусы.
Алдынгылар болар, аңлылар.
Җырларында минем исемне дә
Ничә тапкыр телгә алдылар...»
Ди иде ул.

Үтерделәр аны... Бәлки аның
Без белмәгән гаебе булгандыр....
Сандугачлар белән дус иде ул,
Бәлки аны... бары шуңадыр...

Турап ташлап ап-ак тәнкәйләрен,
Сирень төбенә яшереп киткәннәр.
Ерткаланган яшькелт шәлкәйләрен,
Яфракларын «кәфен» иткәннәр...

Ә тормышны ничек сөя иде!
Кочаклардай булып, үз күреп,
Әле генә менә унынчыдан,
Имтиханнан чыккан кыз кебек...

## Ташлардагы язулардан

●

Үтәр чорлар, дәвер, гасыр үтәр...
Син дә үтә, китә барырсың.
Сискәнер дә бәлки нәсел хисе,
Уяныр да — уйга калырсың...

●

Давыллардан — Чыңгызлардан соң да,
Үз көненә кайткан илләр бар.
Ташларына бак та Тарихларның,
Гыйбрәтләр ал — син дә, легендар.

●

Ни күрсәң дә берәм-берәм түгел,
Бергә күтәр, бергә чыда син,
Сыкратса да матәм килгән көннәр,
Бергә сыкра, бергә ела син.

●

Иләс нәфес киңәшләрен түгел,
Җаның-бәгърең әмерен искә ал:
Китмә, купма, бер карыш та күчмә,
Тукай калган җирдә — Илдә кал.

●

Еллар бераз суытса да җанны,
Данын сатма туганнарыңның:
Каралганы, каргалганы булма,
Чәчкәсе бул асыл тамырның!

## Фатих Хөсни

# КҮП БАЛАЛЫ... БАБАЙ

ХИКӘЯ



Аларның үз балалары булмады. Кайсының нинди кимчелеге аркасындадыр, аны тикшереп тормадылар. Хәер, моңа вакытлары да юк, чөнки тормыш корырга, юкны бар итәргә кирәк иде. Бәлки иң әһәмиятлесе шул булгандыр, алар бер-берсен үтә нык яратышалар, бала булмаслыгын сизенгән һәм моның өчен эчтән генә пошынган хәлдә, бу турыда бер-берсенә нинди дә булса ишарә ясарга телләре әйләнмәде. Әле без яшь, әле бөтенесе алда, быел булмаса — киләсе елга, анда да булмаса — аның киләсенә, дип, самими өмет белән яши бирделәр.

Дөресен генә әйткәндә, кәләше Зөмәрә, еракта-билгесезлектә ялтырап яткан «өмет»кә бик үк ышанып җитмичә, бер-ике мәртәбә медицинага да мөрәҗәгать итте — элек район больницасына, бераз тора төшкәч, түләүле поликлиникага. Янәсе, акча түләп күренгәч, андагыларның файдасы күбрәк тимәсме? Әмма тегеләре дә, боларь да, читләтеп булса да аңлаешлы итеп, бер хакыйкатьне әйттеләр: юк, Зөмәрә ханымга ерактан ялтырап күренгән бала табу бәхетенә ышанып ятарга нигез юк, табигать бирмәгәнне тартып алып булмый, бала иркәләүне язмаган икән, димәк, язмаган. Боларыннан юанычлы сүз ишетмәгәч, исеме яшертен рәвештә телдә йөргән карчыкларга мөрәҗәгать итеп бакты — әллә ни ышанудан түгел, «ятып калганчы, атып кал» дип. Түләгән акчалары, биргән садакалары китте, «атып калганы» тимәде. Әлбәттә, боларны ул ире Сәләхкә сиздермичә эшләде, теге сизә калса, аз дигәндә дә тынычлыгын югалтыр һәм, ихтимал, хатынына карата суына төшүе дә мөмкин дип фикер йөртте. Бу чаклысында ул, ай-һай ла, һич кенә дә хаклы түгел, ире Сәләхнең берниндн хәвеф алдында да хатыны Зөмәрәгә булган мәхәббәте какшамаячак, ул бары тик Зөмәрә белән генә һәм Зөмәрә өчен генә яши иде.

Шулай узды сугышка хәтле ун ел. Кем әйтә ала, бәлки сугыш афәтләрен исән-сау узып чыгуы, алган авыр яраларын җиңүе дә шушы зур ышаныч аркасында булгандыр? Физик яки рухи тетрәнү вакытларында безне екмыйча тотып кала торган нинди дә булса таяныч ноктасы юк икән, калса да безнең күбебездән салкын көл генә калыр иде. Дөньяның кырга сыймаслык кыланышларыннан, ял-

тыраулы бизәкләреннән бозылмаган рухи сәламәт кешеләрне исә мондый нык ышаныч аеруча саклый.

Өстәвенә, авыр сугыш елларында Зөмәрәсе үтә көчле бирелгәнлек белән көтте Сәләхны, хат арты хат язып туктамады һәм һәр хаты саен үзенчә иң кадерле дип тапкан сүзләре агыла торды. Бу бик аңлаешлы, чөнки үзенең кимчелекле икәнен белгәне хәлдә, сугышка хәтле узган ун елда Сәләхының авыз ачып бернинди үпкә яки читләтеп әйткән киная сүзен хәтерләми иде. Бусы бер яктан истән чыкмаса, икенче яктан, җиләк кебек кызлар егет таба алмыйча аптырашкан яки алма кебек толлар ирсез моңайган кытлык бер заманда, инде төс сала башлаган һәм мәктәптә җыештыручы булып кына эшләгән Зөмәрәнең бүтән бернинди таянычы да юк һәм ихлас күңелдән ничек көтәргә мөмкин — Сәләхын шулай көтә иде.

Теләгән теләкләре кабул булдымы, хатынының йөрәгеннән сыгып чыгарган сагыну хатлары калкан булып сакладымы, бик ватылып, чәчләре яртылаш агарып булса да Сәләхы кайтты Зөмәрәнең. Сәләхка күпмедер инвалидлык пособиесы чыга, Зөмәрә эшләгән җирендә эшләп тора, тормышлары, әлбәттә, күккә сикерерлек түгел, шулай да Зөмәрә бичараның башы җиденче кат күктә иде. Иренең исән-сау кайтып егылуы бер яктан сөендерсә, икенче яктан, моңарчы гел яшереп, гел күңелен тырнап йөрткән сернең җиңеләя төшүенә бер сәбәп булды. Шулай да көтмәгәндә бер ачылып куйды солдат:

— Яшьрәк чакта, көчле-җегәрле чакта күрергә насыйп булмаганны, — дип башлады ул, Зөмәрәсе алдында ни өчендер гафу үтенгән сымак итеп, — хәзер, ватылып-җимерелеп кайткан инвалидыңнан әллә ни рәт көтмә инде син, Зөмәрә җаным. Без, ахры, бәбкәсез казлар кебек шулай икәүдән-икәү генә картаербыздыр.

Йөзен иренең күкрәгенә каплап үкереп җылап җибәрүдән үзен көчкә-көчкә генә тыеп калды Зөмәрә. Белеп тора бит, чәнчелеп киткере: «Ватылып-җимерелеп кайткан» инвалидның монда тамчы да гаебе юк. Сугышка хәтле дә юк иде, хәзер дә юк, монда бөтен гаеп Зөмәрәнең үзендә.

Белеп тора, күңелендә күпме еллар саклап йөрткән серен ачыктан-ачык әйтеп, ирен тынычландырасы да килә. Ләкин шул ук вакытта эчке шайтаны да үзе белән: «Моңарчы әйтмәгәнне ник хәзер генә әйтергә? Әйтү белән кемгә файда? Аңамы, синең үзеңәме? Болай әле, ичмасам, уртак күтәрәсез», ди эчке шайтаны.

— Балалы кешеләр дә шушы без йөргән үк юлдан йөриләр, хәзерге балалардан игелек күргән кешеләр сирәк,— ди Зөмәрә, тоныкһәм төссез тавыш белән кемгәдер үпкәләгәндәй. Ләкин эшнең чын дөресе кайда, гаепнең кемдә икәнлеген танырга ашыкмый. Яшерелгән сер шул яшерелгән килеш кала килде.

Мәктәптә җыештыручы булып эшләүдән килгән акчага һәм картының инвалидлык пособиесына гына салынып яту ансат түгел, ипи белән сөттән, чәй белән шикәрдән артмый, кайчагында ит тә ашыйсы килә, җитмәсә тагы, Зөмәрәнең күзләре бар, күршеләр алган өс-баш, өй әйберләрен дә күрә, гел бер-береңә сырышып яту еллары узган, кай араларда читләтеп-читләтеп кенә булса да әйткәли иде.

— Анау Ртия заводында эшләүче Хәмит абзый телевизор апкайткан, гел бер әкәмәт инде. Кинога барып торасы да юк, кино өйләреңдә хәзер, иртәдән кичкә тиклем гөжләп утыра, ди.

— Сүнми торган самавар кебек икән, алайса, исе-мазары чыкмый диме соң аның? — дип, шаяртып уздырмакчы булды Сәләхы. Әмма шул ук вакытта җитдирәк итеп уйланмыйча да кала алмады: Зөмәрә дә кеше бит, кешедә булганны күреп кызыга, күрәсең. Һәм, гому-

мән, бала-чага шау-шуы да ишетелми торган алар өендә иртәдән-кичкә хәтле гөжләп утыра торган шундый берәр әкәмәт булса, бер дә эчне тишмәс иде. Югыйсә, кичләрен бик тын, Зөмәрәсе көнозын себеренеп, юып йөреп бик арып кайта, ашагач-эчкәч тә яту ягын карый, ө элеккеге солдат, азмы-күпме дөнья күреп кайткан Сәләхка тын өйдә кичләрен ялгыз уздыру ифрат та күңелсез, өйләренә яздырган бердәнбер газетаны ничәмә-ничә тапкыр кулга алып карама, гел бер: центнер да сөт, йон...

Әнә ул китек колак Хәмит алган «Тилевәзир»не Сәләх та бик алыр иде дә, әлеге шул кесә ягы... «Җәннәткә бик керәсе ие дә, гөнаһларым җибәрми», дип әйткән ди җор телле бер урыс карты.

Эчтән шулай уйланып, көндезләрен чыгып киткәләп йөргән Сәләх көннәрнең берендә кош тоткан кебек кайтты.

— Кара әле, карчык, сөйләшеп кайттым, эшкә керәм мин. Син анда, эшеңнән бушап торган араларда кибеткә чыгып, теге «Тилевәзир» дигәнеңнең өр-яңа маркаласын караштыргалый йөр әле. Нигә безгә китек колак Хәмиттән калышып торырга ди?

— Кырырсың инде син эшкә кереп, аягың-кулың як-якка таралырга торган инвалид,— дип каршы төште Зөмәрәсе, һәрвакыт уеның-чынын бергә бутап сөйли торган инвалидының сүзләренә ышанып җитмичә.

Ләкин бу очракта Сәләхның уйнап сөйләшкәне сизелми иде:

— Кырырмынмы-юкмы, иртәгә мин синнән элек торып чыгып китәчәкмен.

Бераз икеләнү катнаш уйланып йөргәннән соң, шулай да сорыйсы итте Зөмәрәсе:

— Ичмасам, әйтеп сөйләш: кайсы башсызы нинди эшкә алмакчы сине?

— Башсызы түгел, нәкъ менә башлысы. Күреп тора Сәләх инвалидның иң гадел патша булачак адәм икәнлеген.

— Патша итеп үк куярга булдылармыни? — бу юлы инде Зөмәрәсе көләргә булды.

— Патша булмый кем буласың. Урының бакчада чәчәкләр-гөлләр арасында булсын, үзеңне шунда эшләүче өч хатынга башлык-бригадир итеп билгеләсеннәр. Дөресен генә әйткәндә, эше бөтенләй юк аның, Зөмәрәм-җанкисәгем. Әлеге шул өч хатынга команда биреп кенә утырасы. Ә айлыгы ярыйсы гына: түп-түгәрәк алтмыш сум. Пособиең өстенә бит бу, тиле. Эчеңне тишәр дип уйлыйсың мәллә?

Бермәлгә бөтенләй телсез калды Зөмәрәсе. Калырсың телсез. Бер яктан куаныч: йортка алтмыш сум өстәмә акча килә диген сүз. Икенче яктан баш чуалткыч: бакча дигәне ярый, берәр каравылчымазар итептер инде, тик менә кул астында берьюлы өч хатын йөрүе генә әллә ничегрәк. Белмәссең ирләрнекен, инвалид дигәч тә, теге ни...

Һәм курт кына сорау куйды:

— Ул хатыннарны... синең кул астында эшләргә тиешле хатыннарны әйтәм. Нindirәк нәрсәләр соң алар? Өсләре-башлары, эшләреяшьләре дигән сүзем.

Сәләх иң элек рәхәтләнеп бер көлде — кара әле син аның Зөмәрәсен, моңа чаклы тамчы да сиздергәне юк иде, чак-чак кына көнләшә дә түгелме соң, рәхмәт яугыры. Шушы үзенең «аягы аякча, куллары кулча таралырга торган» инвалидыннан, әкәмәт.

Аннары тагы бер шаяртасы итте:

— Нindirәк дип әйтим, әлегә күргән нәрсәләрем түгел, горзеленхозда ишеткәнемне әйтәм. Ничек тә, мәйтәм, кашлы-күзле, аяклыкуллы адәм балаларыдыр инде. Өсләрендә-башларында да ни дә булса бардыр. Хур кызлары түгел, бөтенләй үк ялангач түгелләрдер.

Шаяртырга тырышып әйткән бу соңгы сүзләре көткән нәтиҗәне бөтенләй бирмәде.

— Тапкансың син дә эш, — дип, әллә мыскыллау, әллә үртәнү белән картын бөтереп алды Зөмәрә,— чыгып-чыгып киткәли идең аны, әлеге шул хур кызлары эзләп йөрүең булган икән, агара башлаган чәчең белән чит-ят хатыннар арасында буталып йөрмәсәң...

— Бергә эшли башлагач чит-ят булмый ул, сиңайтәм, — дип тә ычкындырды инвалиды, хатынын юри үчекләргә тырышып. Кызыклы яклары була кешенең, нәкъ әнә шулай маңгайга бәреп котырта башлаганнан соң, акылын җыйды Зөмәрә. Нишләсен, ул да адәм баласы, аның да телевизорлы өйдә торасы килә иде шул.

— Айлыгы алтмыш сум дисеңме? Пособиең дә сакланамы? Әгәр шул үзең әйтә торган бакча да булса, менә дигән эш бу, карт. Китәкайта йөргән иең аны, «алма пеш, авызыма төш»не эзләп йөргән икәнсең, төлке. Аның әле үз тирәбездән ерак булмавы ни тора. Үтәсүтә шул бакча аша йөрим, әйтеп куюым шушы: алай-болай берәр кырын эшеңне сизә башласам, хур кызларыңны күрсәтермен мин сиңа.

Кая ул «кырын эш»! «Башлык», «бригадир» дигән сүзләре дә сабын куыгы булып кына чыкты, бөтен эшне бергә җигелеп эшлиләр. Себерәләр өлешләп-өлешләп, берсенә артык, берсенә ким түгел. Себерүне әлеге өч хатын үз өсләренә алса, алар өеп калдырган чүп өемнәрен бер тәгәрмәчле тачка белән читтәге чокырга ташу — Сәләх бабаңа. Агач-куак төпләрен йомшартуга килгәндә, Сәләх бабаңа — шулай ук калҗаның майлысы: үз өлешенә тигәнне дә казый, теге өч хатын тырнап үткән урыннарга күз салмыйча да булдыра алмый.

— Эшегезне җиренә җиткереп эшләгез, йөрәк майларым, зеленхоз кешеләреннән замечание ясатырлык булмасын.

Гел зеленхоз исеменнән сөйләгәч, аннары тагы арада олы яшьтәге ир кеше дә булгач, җитмәсә тагы, буш араларда солдатта күргән әкәмәтләрен дә кызык итеп кыстыргалагач (нишләптер, аның күңелендә сугышның авыр, газаплы яклары түгел, кызыклы яклары гына сакланып калган), аның уйный-көлә әйткән «башлык», «бригадир» дигән сүзләре чынга әйләнә язды. Теге өч хатын, әле берсе, әле икенчесе аның янына йөгереп килеп, «Сәләх абзый, болай итсәк ничек булыр икән?», «Сәләх абзый, бик сай тырнамыйммы мин, карап кит әле», дип, гел аның киңәшен сорап торалар иде. Шуның өстенә тагы агачкуакларга су сиптергәндә, «син ир кеше, безгә караганда көчлерәк», дигән булып, йөз метрлы юан шлангны да аңардан өстерәтә башладылар. Иң читене балалар белән сугышу. Җәйге кояшлы көннәрдә алар карый торган бу шәһәр бакчасына, каз бәбкәләре кебек, оясыоясы белән тезелешеп, балалар бакчаларын китереп чәчәләр. Гөлҗимеш, роза, ясмин куакларының шау чәчәктә утырган чагы, бакча балаларының, әлбәттә, күзләре төшә, күзләре төшеп кенә калса икән әле! Чәчәк өзүчеләргә карата, олы кеше буларак, Сәләхнең тагы җаны түзми. Әле теге почмактан, әле бу куаклыктан аның кычкырганы яки кайдандыр табып алган свистогын чырылдатканы гел ишетелеп тора. Әгәр, алла сакласын, берәр чәчәк өзгән «нәни разбойник»ны тотса, юк инде, ул аны болай гына ычкындырмас, кулыннан әйбәт кенә җитәкләр, өзгән чәчәген икенче кулына тоттырып һәм шулай тантаналы марш белән мөрәббиясе каршына китереп бастырып һәм солдатта чакта йогып калган кырыслык белән кисәтер:

— Кара аны, бу сиңа ата-бабаң бакчасы түгел, бу — хөкүмәт бакчасы. Мин моны хөкүмәт кешесе буларак әйтәм, пацаннарыгызны күздән ычкындырмагыз. Югыйсә, хуже булыр.

Югыйсә, нәрсә булачагын ул үзе белми, әмма «хөкүмәт кешесе» буларак төшендереп бирергә тиеш таба.

Шундый-шундый эшләрнең барысын үз җилкәсенә алсын да, имеш, шул кеше башлык булмасын. Хатынына әйтергә генә ансат булган икән: имештер, «өч хатынга команда биреп кенә утырасы».

Әле аның иң читене шунда: эшеннән бушап торган араларда бакчага искәртмәстән генә хатыны Зөмәрә килеп чыга. Килеп чыга да, читтәге бер эскәмиягә утырып, тавышсыз-тынсыз гына күзәтә башлый. Эшләрен түгел, Сәләхын һәм аның тирәсендәге өч хатынны. Аның үз аршыны: «Белмәссең ирләрнекен. Иргә ышанма, Иделгә таянма!» Бигрәк тә башлык та булып алган кешенекен. Югыйсә, «башлык»ның ничек биегәнлеген күреп китә, шулай да үтешли-барышлый бакчага сугыла йөрүне кирәк саный.

Кызык бит бу дөнья: көне туа, планы тула, шул арада әкәмәт хәлләр дә була тора. Мәсәлән, ничек әкәмәт димәссең инде: Зөмәрәнең, әлеге теге бакчада эшләүче өч хатыннан шикләнеп (минем инвалидыма сырышмыйлармы?) килә-килә йөрүләре, әйтергә дә сәер, соңга таба бакча балаларыннан көнләшү сымак бер хис белән алышынды. Читтән күзәтеп торамы Зөмәрә, тормыймы Зөмәрә, менә алары, ичмасам, сырышалар. Әле йөгереп килеп, Сәләх башлыкның ботын кысып кочаклыйлар, әле суы агып ята торган шлангысын күтәреп, Сәләх башлыкның өстенә сиптерә башлыйлар, әле Сәләх башлыкка кесәләрендә аунап йөргән конфетны китереп тоттыралар. Ала башлык. Алмыйча карасын, теге шундук мөрәббиясе янына әләкләргә йөгерә: янәсе, бакчачы бабай аны яратмый, бакчачы бабай ул биргән конфетны алмады... Кыскасы, Сәләх карт белән бакча балалары арасында берничек тә әйтеп, аңлатып булмый торган дуслык мөнәсәбәте урнашты. Өйгә кайткач та, хатыны Зөмәрә белән тәмләп чәй эчеп утырганда әйтеп куйгалый кайчак:

— Арада бер Вова атлысы бар, мәгәр дә энә күзеннән үтеп чыккан кычыткан чыпчыгы инде. Чәчәк өзгәнен үз күзләрем белән күреп торам кай мәлне, тотасы да ыштанын төшереп чәбәклисе, юкса, кулым бармый. Мало што кулым бармый, апалары күргәнче дип, өзгән чәчәге белән тизрәк куак арасына яшерәм малайны. Ник дисәң, законы коры безнең. Мин аны өзгән чәчәген тоттырып апалары каршына китереп бастырырга, матьлап тормыйча гына әйтәсе сүземне әйтергә тиешмен. Ә миңа андый чакта матьлап тормыйча сүз әйтү читен, солдат кешенең теле шундыйга күнеккән. Икенчеләп, тәрбияче апасы аннары ул чебешне бик шәпләп кыздырырга — акылга утыртырга тиеш. Ә минем, карт ябалакның, күрә торып чебешне тилгәннән чукыттырасым килми. Бигрәк шук, үтә дә тере хәзерге балалар. Әллә анадан туганда ук җиде класс бетереп туалар инде.

Бу хәтлесен тыңлап утырырга чыдамлыгы да җитәр иде Зөмәрәнең. Шунда шул, уйлап җиткермичәрәк булса кирәк, картның теленнән мондый сүз дә ычкынды:

— Әллә үзебезнеке булмаганга... картайгач шулай азынам инде.

— Тач дөресе... «Азынам» дигәнең.

Зөмәрә артык чыдый алмады, утырган урыныннан ыргылып торды да, эчә торган чынаягын ук калдырып, кече якка шылды, берничә минут чамасы мышкылдап алды.

Бусы инде авырткан җиренә кагылудан иде. Ә эссе җәйге көннәрнең берсендә, гадәттәгечә карты эшли торган бакчага килеп, читтән генә күзәтеп утырганда, йа хода, түземлек бир, менә ниткән күренешнең шаһиты булды Зөмәрә.

...Үтә янган-тирләгән дүрт-биш почык борынны сафка тезде карт, солдатча җиренә җиткереп «Смирно!» командасы бирде һәм, теге-

ләрне рәтләп чишендереп тә тормыйча, шлангтан су коендырырга тотынды.

Бу, әлбәттә, карт бакчачының хәттән ашып тилерүе иде. Ләкин бу картинаны үз күзләре белән бер читтән күреп торган Зөмәрә тиләрә алмады, балаларны бу чаклы бирелеп ярата белүче картына — Сәләхына, ичмасам, берне генә булса да үз баласын табып бирә алмаудан өзгәләнеп, төштән соңгы җыештыру эшенә бармыйча, ялгыз өенә бикләнеп һәм мендәргә капланып үксеп-үксеп җылады.

Янә бер көнне менә мондый хәл булды. Көнне түгел, кара төн уртасында. Карты үзе йоклый, үзе төшендә әлеге шул бакча ташбашлары белән булыша. Берсен янына чакыра, болай гына түгел, исемен атап чакыра — ахрысы, ул бакча балаларының бөтенесен дә исеме белән ятлап өлгергән иде инде. Икенчесен, өченчесен чакыра, киләләр тагы тегеләре. Килми карасыннар, бабай белән ара өзелде диган сүз. Өзелмәсә дә, суына. Аннары аңардан ничә фашистны «тел» итеп һәм ниткән чәнечкеле киртәләр аша алып кайтканлыгын сөйләтеп кара син.

Юк, бу кара төндә фашистны «тел» итеп алып кайтышы түгел иде, карчыгын уятам дип тә тормады, шыр акырып команда бирде малайларга:

— Янгансыз ич, чутрый-кутрыйлар. Живо өсләрегездән салыгыз, шлангтан су коендырам, штобы солдатларча таза-нык булып үсегез.

Әмма Зөмәрәне уята дип куркырга урын калмаган, Зөмәрә инде әллә кайчан уянып, карт солдатның хәтта төнге йокы арасында да әлеге шул чит кеше балалары белән мәш килүен сәерсенү катнаш көнчелек хисе белән тыңлап ята иде. «Бичаракай гынам, инвалидкай гынам, үзеңнеке булса, нишләмәс иең син? Булмады шул, булмады... Ичмасам, берне генә булса да бүләк итә аладым» дип, кимсенеп, үйланып-газапланып ятты-ятты да, үзен-үзе тыя алмастан, үксеп җылап җибәрде. Аның үксүенә карты уянды, кайда монда, янында карчыгың үксеп ятканда, бакча ташбашлары белән булышып тору, «шабаш, бөтенегез берьюлы күз алдымнан югалыгыз!»

Һәм шундый ук катгыйлык белән карчыгыннан сорау алырга тотынды Сәләх:

— Нәрсә син төн уртасында балавыз сыгып ятасың, корт чаккырысы? Әллә инвалидың аркаңны җылытмый башладымы?

— Башлар да шул менә... син диванаңың әллә кемнәрнең чит-ят балалары белән йокы арасында да саташуын ишетеп ят та...

— Таптың син дә сүз... шуның өчен мышкылдап ятмасаң... йокы бүлеп.

— Тор әле, Сәләх... Әйтәсе сүзем бар сиңа. Караңгыда әйтә торган сүз түгел, ачуланма, утны яндырам.

Торды, утны кабызды, күреп калды Сәләхы, хатыны озак кына мышкылдаган иде булса кирәк, күз кабаклары шешенке, күзләре кызарган иде.

— Берәр чынаяк куе гына итеп чәй эчеп алыйк, — шулай сөйләнә-сөйләнә, кухня ягында газны тоташтырганы, плитәгә чәйник утыртканы ишетелде.

— Менә тиле... төн уртасында чәй эчеп алыйк, имеш, — дип, сукрана-шыгырдана, Сәләх та җылы урыныннан сыдырылып төшәргә мәҗбүр булды.— «Мәй» дип әйтсәң, хет колакка керер ие...

Ирен ишетергә дә теләмәде Зөмәрә, аның үз уйлары көчле, утыз биш ел буена саклап эчендә йөрткән, ниһаять, ташка әйләнгән серен менә-менә ачарга җыйнала, кайда монда чит кеше балалары белән саташкан гамьсез инвалидының авыз эченнән мыгырдануларын тыңлап тору.

Иренә һәм үзенә куе гына итеп чәй ясап куйды Зөмәрә һәм бер тын бернинди сүзсез тегенең күзенә карап калды.

— Беләсеңме, Сәләх җаным, — дип башлады аннары. Тагы тукталып калды, күренеп тора: ничек башласа да аңарга уңайсыз, утыз биш ел әйтмичә эчендә йөрткән бу сүз өчен ул үзен әйтеп бетергесез гаепле саный иде, — ...Синең үзеңнеке... үз балаң булырга тиеш иде бит... әгәр син бүтән бер кеше белән торган булсаң. Безнең үз балабыз булмавы өчен мин гаепле... мин! Миңа духтырлар әллә кайчан ук әйттеләр, ә мин сиңа әйтмәдем... Син ташлап китәрсең, минем белән тормассың дип куркып әйтмәдем. Синең бу хәтле саташкан, бала җанлы кеше икәнлегеңне белгән булсам соң... Бәлки хәзер дә соң түгелдер, ә? Син минем нәрсә әйтергә теләгәнемне аңлыйсыңмы? Юк, яшереп кала торган сүз түгел бу, әйт, аңлыйсыңмы син минем нәрсә әйтергә теләгәнемне?

Зөмәрә, тыелгысыз үксеп, картының күкрәгенә авып төште, терсәге белән чәйне түкте.

— Чүсәнә... ясаган чәйне түктең әрәм итеп, — Сәләх карчыгының муеныннан кочып алды, алар яшендә бу бик килешеп тә бетми иде, югыйсә, ләкин нишләтәсең, яшь белән исәпләшергә теләми иде ич Зөмәрәсе...

— Аңарга китсәме? — бергә яшәгән утыз биш ел эчендә һич күрсәтмәгән җитдилек, кызулык, самимилек белән бер тын кочагында кысып торды ир Зөмәрәсен. — Алайга китсә әгәр, әйтсәм әйтим инде алайса, хатын, алар... әнә ул минем аяк арасында чуала торган ул бакча балалары... ул Вовалар, Серbeginжалар, Фаялар — бөтенесе минекеләр... синең белән безнекеләр ич, карчык... Я әле, тынычлан, эчеп җибәр әнә минем суынган чәйне... төн уртасында чәйгә бик көеп тормыйм.

1975

## Госман Садә

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

И илаһи кышкы урман юлы!
Менә кайда таңнар балкышы.
Юл читендә бии каен кызы,
Кыңгыраулы карлар алкышы.

Карт наратлар тирән уйга чумган,
Тыңлап кышкы моңнар агышын.
Халкым минем шул моңнардан алган
Карурманның йөрәк кагышын.

Якын миңа аның һәр шырлыгы,
Тирән күле, аулак аланы.
Җыелмыйча калган кышка хәтле —
Ах, каршымда яна баланы!

Җәй җылысын җыйган ут-баланнар
Бураннарда җиргә коелыр.
... Көне буе йөреп арган аучы
Шул аланда туктап җылыныр.

●

Сыймый хыял тарлыкка,
Сорый киңлек, хөррият.
...Җирнең түбән катында,
Таулар-ташлар астында
Чишмә туплый көч-куәт.

Хыял җәя канатын,
Очар өчен җыр булып.
...Җир кабыгын җимереп,
Таулар көчен чигереп,
Чишмә чыга ургылып.

Сыймый хыял тарлыкка,
Киңлеккә әйди һаман.
...Җир куәтен туплаган,
Ага-ага туймаган
Чишмәдән илһам алам.

•

Как кыяда үсә каен,
Ялгызы яфрак яра.
Ә яныннан ак болытта,
Гүя юртак акбүз атта
Яшеннәр үтеп бара.

Ап-ак болыт куенында
Йокыга чумган алар.
Көннәр буе илләр буйлап,
Ут-кылычлар белән уйнап
Шаярып туйган алар.

Үрелә каен болытка —
Шундый да якын ара.
Ә болытта арып йоклап,
Яңа көнгә гайрәт туплап
Яшеннәр үтеп бара.

Яшеннәр үтеп бара...

## Сандугач

Мөлдерәмә нурлы таң тугач,
Чык тамчысы гөлгә сарылгач,
Сайрамасын ничек сандугач!—
Күңеле тулы ялкын, моң булгач.

Җыры оча иңләп тугайны,
Җыр канаты — алтын бүяулы.
Моңнан гына торган шул таңны
Кинәт кызым елап уянды.

«Ник елыйсың болай, чү, кызым,
Йом күзеңне, йокла, йолдызым.
Сайрасын ла, кызым, сандугач,
Җырны шулай өзелеп сагынгач».

Бишегенә кулым кагылгач,
Ни ишетәм: «Әт-тә, сан-ду-гач!»
Сабый тынды, елау басылды,—
«Сандугач» дип теле ачылды.

## Елмаясың

Иртән күрәм — елмаясың,
Кичен күрәм — елмаясың.
Ничәнче көн күзләреңне
Төштә күрәм — елмаясың.

Күргән саен бер үк сүзем:
«Исәнмесез!» — елмаясың.
Шуннан башка берни белмим,
Калам сүзсез — елмаясың.

Әлләниләр әйтер булып
Килгән идем — елмаясың.
«Башкаларга елмайма һич»,—
Дигән идем — елмаясың.

Нигә һаман елмаясың?

## Ялганган ботак монологы

Яфракларым җил иркендә...
Туфрагымнан ерак мин.
Бүтән агач кәүсәсенә
Ялганган бер ботак мин.

Шул агачның сутын эчеп,
Яз белән яфрак ярам.
Еллар үткән саен аңа
Ныграк кушыла барам.

Аның белән каршы алам
Елларымның иртәсен.
Тоя һәрбер күзәнәгем
Аның назлы иркәсен.

Тик яңгырлы көннәр була,
Йөзә кургаш болытлар.
Үткәннәргә кайта хәтер...
Тып-тын ага минутлар.

Тетрәнәм мин — бик таныш моң,
Көй, авазлар ишетәм...
... Үз агачым — үз әнием
Чакыргандай хис итәм.

Мәхмүт Хөсәен

# КОЯШ ҖАЙДАК БУ ЯКЛАРДА...

## Кунак та мин һәм хуҗа да

... Кунак та мин үз җиремдә,
Хуҗа да мин үз илемдә.
Диңгез — ял бишегем минем,
Ә кояш-җайдак иңемдә.

Шул кояш арыган тәнне
Ныгыта, кап-кара итә.
Саулык тамчылары бөркеп,
Йөрәк кылларыма чиртә.

Кояш һәм саф һава эчеп
И яшәрәм, и яңарам!
Хезмәттә тау күтәрергә
Әзер инде мин яңадан.

## Ак болытлар

Кызыл җайдак кебек калка кояш,
Кыя җилкәсенә атланып.
Ак болытлар — гүя тоныкк күлдә
Алкаланып йөзгән ак мамык.

Утлап йөргән куйлар көтүедәй
Ак болытлар белән тау тулы...
Кояш көлсә әгәр, көн дә аяз,
Су да җылы, яр да шау-шулы.

Ак болытлар хезмәт кешесенең
Шат йөзедәй ачык чырайлы.
Юк, куркытмый алар зәңгәр күктә
Ихлас сайрап очкан тургайны.

Алкаланып аккан ак болытлар —
Тау иңендә гүя ак бөҗра.
Күкрәгеннән кыя әйтерсең лә
Оя-оя аккош очыра!..

## Диңгездә — җыр!

Әкрен генә атлап төшәм ярга.
Шаула, диңгез!
Курай уйна, таң!
Йөзеп уятам мин дулкыннарны,
Ә тауларны җырлап уятам.

Зәңгәр үзән! Җырлап синдә йөзәм —
Чәчри тамчы төрле якларга.
Ләкин минем җырлап йөзүләрем
Ошап бетми кайбер затларга.

Ошамый дип тормыйм, мин гел җырлыйм,—
Ныграк чыңлый күңел тальяным!
Җыр кайтаваз булып ярлар иңли,
Чоңгылларын кичә дәрьяның.

Җырлыйм җирнең тиңсез матурлыгын,
Бәхет теләп тыныч көннәргә.
Тынгы белмәс йөрәкләрнең җырлыйм
Ашкынуын яңа үрләргә.

## Идел кызы

Кырым гына, Кавказ гына түгел,
Казаным да бар бит дөньяда.
Офык аша әнә әйтерсең лә
Идел кызы миңа елмая.

Тюльпан булып керә хисемә,
Чулпан булып керә төшемә,
Вулкан булып айкый йөрәгемне —
Бергә чакны искә төшерә.

## Куктүбә

Куктүбәдә күп түбә!
Бар таш түбә —
Баш түбә —
Мәшһүр Карадаг.
Бар ком түбә —
Тын түбә,
Астан карасак.

Өскә менсәк,
Куба анда җилләр туе —
Әйтерсең лә җеннәр туе!

Бар изге тау —
Көзге тау:
Төренеп ул комачка,
Үрелә гел кояшка.

Өч як та — тау,
Алда — диңгез...
Диңгездә — шау:
Җилләр туе —
Әйтерсең лә җеннәр туе!
Калка-чүгә тау-тау дулкын.
Дулкын асты — кара упкын...

Су узына,
Пыр тузына,
Охшап тол пәри кызына!..
Аннан тына...
Тау-тау дулкын юкка чыга...
Котырынган дәрья есте
Тынып кала дала төсле.
Диңгез тына.

Җилләр генә тынмый һаман —
Улый!..
Дулый!!.
Шундый аларның килбәте.
Бу — күп түбәле Күктүбә —
Тынмас җилләр җөмһүрияте.

Кырым, 1975.

Рәкыя Рөстәмова

# ИКЕ НӘСЕР

## Мәхәббәтем



Бүген синең туган көнең. Ничәнче тапкыр инде мин шушы көнне дулкынланып көтеп алам. Көтә-көтә хыяллар диңгезендә йөзәм, әллә нинди планнар корам, безгә хәтле бер кеше дә әйтмәгән сихри сүзләр эзлим.

Тик бүгенгә кадәр безгә ул көнне бергә үткәрергә туры килмәде. Күңелем түрендә сакланган җылы сүзләрем әйтелми, бүләкләрем бирелми калды.

Шулай да ел саен, син туган көндә, бер китап арасына күзнең явын алырлык чәчкәләр төшерелгән бер открытка өстәлде: бәйрәм өстәленә, бер караганда әллә ни күзгә бәрелеп тормаган, әмма кыш уртасында да күпереп чәчкәләргә күмелгән бер гөл куелды.

Тик син үзең генә булмадың...

Менә бүген алгы бүлмәдә мин ничәмә еллар нәкъ шушы көндә чылтыравын көткән кыңгырау тавышы ишетелде. Бары син генә шулай, артык бер минут та тышта, ишек төбендә торасың килмичә, берчә таләпчән, берчә түземсезләнеп, шалтыратасың. Бу — Син! Бөтен булмышың белән син.

Ишеккә йөгерәм. Син икәнне белсәм дә: «Кем бар!» дип сорыйм.

— Без...— дисең син.

Кайчандыр, кемнедер шаяртыпмы, әллә үзен-үзе артык олылаучы берәүдән усал көлепме әйткән шул сүзне син еш кына кабатлыйсың. «Без-з-з-з». Бу — Син!

Өйгә керәсең. Куе кашларың, керфекләрең бәсләнгән. Салкыннан бит алмаларың кызарган. Перчаткаларыңны тиз генә саласың — кулларың да өшегән икән. Кил әле, җылыныйк. Менә шулай: сине озак-озак көтүдән һәм әле килүең шатлыгыннан янган чигәләрем кулларыңны җылытсын. Битләреңне син очраган саен: «Җылы һәм йомшак куллар...», дип мактаган кулларыма алам. Әллә маңгайларны-маңгайга, чәчләрне-чәчкә куеп җылынасың киләме? Синеңчә булсын. Бүген — синең туган көнең бит.

Нигә әле басып торабыз? Әйдә, түргә уз. Бәйрәм табыны кәтә сине. Син менә монда, үз урыныңа — минем каршыма утыр.

— Туган көнең белән котлыйм...

Күңелең нечкәреп китте, күрәсең. «Рәхмәт сиңа!» дигән сүзеңне дә үтә дулкынланып әйттең. Хисләр ярсып ташудан без бермәлгә сүзсез калдык. Юк, юк, сүзсез калмадык — күңелләргә сүз бирдек.

Мин сиңа карап сокланам. Кырык өстендә инде, ә күңелең балаларча саф. Әчкерле түгелсең: көләсең килсә — көләсең, күңелең тулса — елыйсың. Бернинди тормыш шаукымы сине тупаслындыра алмаган, күрәсең. Күзләреңнән элеккечә нур бөркелә. Тик маңгаеңа тагы бер буразна өстәлгән, чигәңә көмеш тузаны кунган.

Тукта! Нигә уйланып калдың? Ни борчый сине: үткәндәге күңелсез хатирәләрме, әллә башка берәр шикле уймы?

— Мин сине яратам... Рәхмәт сиңа... Дөньяда яшәвең белән миңа ярдәм итүең өчен рәхмәт!— дисең син.

Йөрәгең миңа күптән бер сер сөйләгән иде. Шуны телдән әйтергә җыенгансың, шуңа дулкынлангансың икән.

Мин дә үземә олы бәхет килүгә шатмын, синең өчен дә, минем өчен дә озак еллар сер булып йөргән хиснең бүген килеп яңадан ургылып чыгуына куанам.

...Кайсыберәүләр безне: «Сез тиң түгелсез», диләр. Ялган сүз ул. Ышанма син аңа. Нигә тиң булмасын, ди. Кайбер кешеләр гомер буйларына бер түбә астында көн итеп тә, уртак тел таба алмый, уртак язмышка тиешә алмый, читләр булып калалар. Шул ачудан я берберсенең җанын кыйнап, я шәхси уңышсызлыкларыннан дөнья фаҗигасе ясап, үз-үзләрен кимсетүгә, берсен-берсе юкка чыгаруга барып җитәләр.

Ә без синең белән көтмәгәндә очраштык та җан дуслар булып киттек. Безнең бөтен нәрсәбез, бар булмышыбыз уртак иде. Әйтерсең лә без гомер буе бергә яшәгәнбез: бер үк ана сөтен имгәнбез, бер үк тугай печәнендә аунаганбыз, бер үк кыр икмәген ашаганбыз, бер үк чишмә суын эчкәнбез.

Тиң түгел, имеш. Ялган сүз ул. Иртәрәк булса да, чигә чәчләренә кырау төшә башлаган икәүнең хәтта уртак танышларга карашлары да бер үк төрле икән, ни эшләп алар тиң булмасыннар ди?

Нигә без соңлап очрашыйк ди? Без бит бер-беребезне гомеребез буе беләбез. Хәтерлисеңме сугыш елларын? Дүрт елга сузылган каһәрле, авыр көннәр сине дә, мине дә балалыктан мәхрүм итте. Сугыш, куркыныч әкиятләрдәге сихерле карчык сыман, безне олыгайтып җибәрде. Буыннарыбыз катмас борын авыр тормыш камытын кидерде. Үгез җиктереп җир сөрдерде. Кечкенә генә кулларыбызга өлкәннәр көче җитмәслек чалгы тоттырып печән чаптырды. Тире белән сөяккә калган беләкләребезне талдырып, үсәр-үсмәс игеннең көлтәсен бәйләтте, агач әзерләтте, торф кистерде, хәтта домна мичләре каршына бастырды.

Безнең буынга да зур сынау килде.

Туйлар да булмады ул елларда. Сугышка кадәр безнең Так елгасы топольләре, Дим буе тирәкләре күпме кеше серен саклыйлар иде. Ял көннәре алар, үзара, шыбыр-шыбыр килеп, серләшеп, яшьләр мәхәббәтен ышанычлырак яшерү өчен, үзләренең куе ботакларын ярга якынрак сузарлар иде. Көзен кемгә туй булачагын алдан белеп торалар иде алар. Ә көзен пар атларның дугаларына тагылган эрелеваклы кыңгыраулар, зың-зың килеп, туй шатлыкларын хәбәр иткәч, топольле һәм тирәкле яр буйлары сарылы-кызыллы яфракларга күмелер иде. Әйтерсең лә шушы мәңгелек сердәшләр, ак бәхет теләп, яшьләр юлына чәчкә сибәләр.

Туйлар булмады шул ул чакта.
Шул дүрт елга сузылган сугыш сине дә, мине дә үз вакытында белем баскычлары буйлап үрләтмәде. Без озак, ун-унбиш елга соңлап кына ныклы һөнәр ияләре булдык. Шулай да шушы, безнең өчен олы сынау елларына әверелгән тормыш безне авырлыкларны ничек кичерергә, шатлыкларны ничек сакларга өйрәтте: салкын кыштан соң чыклы җәй киләсенә нык ышанырга, ил язмышын тоеп яшәргә, сафлыкны җуймаска өйрәтте. Тик ул еллар бөреләре тулган чәчкәләрне вакытында аттырмый калдырды. «Сөям» сүзен соңлап ишеттерде.
Аннан соң без «кешечә» яшәргә ашыктык. Кинәт кенә барысын да аңлап та җиткермәдек, тик югалтканны тизрәк эзләп табарга, арттa калганны тизрәк куып җитәргә теләдек. Соңлап ашыгуыбыз безне шәхси тормышта абындырды да...
Әйе, үз йолдызыбызны озак таба алмый йөдәдек без. Бакырны алтын дип кабул иттең дә, соңыннан шул хаталану борчуы сине еллар буе буып торды.
Мин дә хаталандым. Хатам йөрәгемдә җуелмас яра калдырды.
— Син бәхетлеме? — дисең син.
Әлбәттә, бәхетлемен. Соңлап булса да, сине табуым белән бәхетлемен. Син — минем яшьнәргә өлгерми калган яшенем. Югалтмыйк шушы бәхетне. Югалтмыйк.



## Анам кулы

Олыгаясың, ахры, анам, олыгаясың. Алтмыш биш яшең тулганчы: «Арыдым, кызым»,— дип әйткәнең юк иде. Быел: «Картаям бит, балам», дидең. «Дим дә ераклашкан кебек... Кулларым да әйбер авырлыгын тоя башлады...» дип тә өстәдең әле.
Шул сүзләрне ишеткәч, үткән җәй Кыпчакка кайтканда авылдашларның:
— Анаң су сөлеге шикелле сылу гәүдәле, билдән түбән төшкән калын толымлы иде. Аның кайчан ятып, кайчан торганын һичкем белмәс — ничә күрсәң дә кулыннан эш төшермәс бик егәрле килен иде дип, «иде» сүзенә аерым мәгънә биребрәк әйткән сүзләре кылт итеп исемә төште.
Чынлап та олыгаясыңдыр шул, анам. Әнә бит, озын толымнарың да, көмеш җепләргә уралып, кыска гына үремгә калган. Тау-Күл чишмәсенең таң нурларына коенган тәүге тамчылары белән генә юынган, ап-ак чибәр йөзеңә дә вакыт үзенең буразналарын салып узган. Ә кулларың... Әче әрем исе, зәһәр билчән яшеле сеңгән, сәнәккөрәк, юкә дилбегә белән юкә чыбыркының сөян сабы бирчәйткән кулларыңны кулыма алам.
Олыгаясыңдыр шул, анам, олыгаясыңдыр. Шигырь белән язган хатларыңның берсендә юкка гына:

Мин картаям, җир яшәрә,
Шул минем сөенечем,

— дип язмагансыңдыр.
Тик мин бүген, әнием, еллар шулай бераз катылаткан, тик минем өчен һаман да аккош мамыгыннан да йомшаграк, беренче кырпак кардан да сафрак, аграк тоелган кулларыңнан җитәкләп, сине

яшьлегеңә алып кайтасым, туган авылыңдагы чишмәле тауның иң биек кыясына алып менәсем, хатирәләр диңгезенә чумдырасым килә.

— Хәтерлисеңме?

Сине, урманлы як кызын, кыйблага караган ягын кырыс җилләр ялангачландырган таулы, бөдрә таллар бизәгән иркен тугайлы як килен итеп төшергән.

Иренчәк килен булмагансың син. Ерак булса да, такта чәйне дә куян канндай куе итеп чыгара торган югары оч «Кәлимулла» коесына көн дә суга баргансың. Юл уңаенда, көянтәңне иңеңә күтәргән көенә, үзең салган сукмактан Акбаш тавына күтәрелгәнсең. Күтәрелгәнсең дә, кулларыңны маңгаеңа куеп, Дим буйларына карый-карый, үзең туып-үскән якларга охшаш билгеләр эзләгәнсең.

Тау-Күлеңне сагынгансыңдыр инде.

Син, кечкенә генә Так елга буе кызы, мин туасы авылга үзең белән бергә күпләрне таң калдырырлык егәрлек, уңган киленнәргә генә хас сыйфатлар алып килгәнсең. Таң кошыдай, таң сарысы югалмастан элек үк йокың туйдырып, килен өлешенә төшкән һәммә йорт эшләрен эшләп куйгансың. Самаварың кайнатып, ашың пешереп, кайнанаң урыныннан торганчы табын әзерләргә дә өлгергәнсең. Кыйблага каратып салынган кабык башлы өйнең идәннәрен, болдырларын көн дә кырып, комлап юып, сары балавызга әйләндергәнсең. Кайнанаң тирләп-пешеп бер самавар чәй эчкән арада я атаемның, я кайненеңнең сатин күлмәкләре якасына, җиң очларына күзнең явын алырлык чәчкәләр чигәргә дә өлгергәнсең.

— Алтын икән хатыныңның куллары,— дигәннәр әтиемә.

Күрше карчыклары син кояш яктысында күз чагылдырырлык итеп шоп-шома акшарлаган мичне кытыршы куллары белән сыпырып-сыпырып карар да, мактау сүзе таба алмагандай, тел шартлатып, баш селкеп куяр булганнар. Чатыр тауның акбурын, күрәсең, сиңа чаклы бер килен дә әле шулай, синең кебек итеп җиренә җиткереп яндырмаган да, шулай, биткә пудра итеп сөртерлек хәлгә китереп төймәгән дә, җиз иләктән генә иләп, сөткә генә изеп мич акламаган да.

Бервакыт кием-салым тегәргә осталыгың да ачылган. Бизәкле чаршау артында «Зингер» машинада зеңгер-зеңгер килеп кием тегүеңне ишеткәч, югары очтан да, түбән очтан да апайлар, җиңгәйләр килгәннәр. Ә берничә көннән соң эре парчалы ситса-сатиннардан өреләп торган бәбитәкле күлмәкләр киеп кайтып киткәннәр. Аяк-кулларың сызлаусыз булсын, — дип теләк теләгәннәр сиңа. Син чүпрәләп күпертеп пешергән икмәкнең, тары беленнәреңнең тәмлелеге үзе ни торган!

— Киленең салган икмәк уңган була, шуның бер сыныгын гына ашасам да савыгырмын кебек,— диючеләр дә булган.

Килгәннәр. Син, мул куллы килен, бер телем дә, бер кисәк тә түгел, ә күз нурларыңны кушып биш көреләп суккан шакмаклы ашъяулыгыңа бер бөтен икмәк төргәнсең дә: «Кирәк булса, тагы килегез»,— дип озаткансың аларны.

— Кулыңнан килә, килен, — дип киткәннәр алар.

Синең ал-ял белмәс кулларыңа еллар исәпсез-хисапсыз эз салган, күп көч төшергән. Минем балалык хәтерем сине бер караңгыдан икенче караңгыга басуда утау утаучы итеп тә, көлтә бәйләүче итеп тә күз алдына китерә. Унбишәр-унсигезәр сыерны да саудың. Курсларда укып кайткач, бригадир да булдың. Сугышка хәтле чорда һәм иң авыр сугыш елларында хуҗалыкның барлык малларын берләштергән ферма мөдире дә идең син. Аннан соң әле сине, намуслы булганың өчен, эшли алуыңа ышанып, сельпо председателе итеп тә

күтәрделәр. Кирәк булгач, авыл Советына җитәкче итеп тә куйдылар. Син һәр җирдә тырышып эшләдең. Әмма син безнең өчен һәр чак иң изге күңелле, балаларыңа җил-яңгыр тидермәс өчен барын да эшләргә әзер торган иң олы йөрәкле ана булып калдың.

Күңелеңнең киңлегенә, зиһененнең камиллегенә, акылыңа таң калырлык. Синең өлешкә ике-өч бала анасы булгач кына «ликбез»гә йөреп хәреф тану бәхете тигән. Каләм тотарга күнекмәгән кулларың белән «Без я-ң-а т-о-р-мыш т ө з и б е з» дип язарга өйрәнгән кичләрдә: «Балаларымны ничек тә белемле итәрмен», дип ант иткәнсеңме, әллә шулчакта ук яңа тормыш төзү өчен яңа тормышка яңача караучы, укымышлы кешеләр кирәклеген нечкә күңелең белән тойгансыңмы, белмим. Тик үзеңә авырга килсә килде, әмма балаларыңның барысын да укыттың, кеше иттең. Әгәр биш улың да Совет власте елларында гөрләп чәчкә аткан республикабыз өчен иң кирәкле һөнәр алганнар, офицер, агроном, механизатор, нефтьче, юрист булганнар икән — бу синең ана йөрәге, изге ана күңеле генә күтәрә алырлык тырышлыгың җимеше.

Алты балаң, алты йөрәк итең,
Алды синең сөю ялкының,

— дип язган шагыйрә сине һәм синең балаларыңны — безне дә күздә тоткандыр, күрәсең.

...Чишмәле таудан төшеп киләбез. Син кулларыңны минем иңбашыма куйгансың һәм... бәләкәй чактагыча, туп-туп китереп аркамнан сөя башлыйсың... Һаман мине яратасың, анам. Миңа шундый рәхәт. Мин дөньяга килгән сәгатьтән бирле синең кулларыңның җылысын тоеп яшим. Мин синең олы балаң булып тууым өчен дә шатланам. Икеләтә-өчләтә шатланам, чөнки мин синең кулларың изгелеген башка балаларыңа караганда күбрәк тойдым, күбрәк алдым. Рәхмәт сиңа. Мин синең алдыңда чиксез бурычлымын, газиз анам!

Әхмәт Рәшитов

# МАЯКЛАР

Батырларга шундый
таулар кирәк

Сапун-тауда музей карап йөрим.
Юк, онытмый икән Кырым җире —
Давыл кебек урап уйны-хисне,
Заман җилләреме шаулап исте,
Кинәт бар да күз алдымнан кичте.

Артта — Балаклава. Алда — таулар.
Оя корган анда дошман яулар.
Тик үзәннәр — һөҗүм өчен терәк,
Батырларга һәрчак таулар кирәк.
Тырнак батырырга туган җиргә
Мәлгунь юлбасарга ирек бирмә!
Сугыш кызган... Дөрләп янган ташлар –
Таш өстенә ауган газиз башлар,
Ватан ләкин баштан кадерлерәк —
Һәр карышы бәхет өчен кирәк.
Ә Сапун-тау җәһәннәмгә охшаш:
Актарылган тимер, яуган кургаш...
Тарих язган тимер белән кургаш.

Юк, батырлык язган ул тарихны,
Горурларның мәңге сүнмәс рухы...
Язган коммунистик иман белән,
Йөрәкләрдән тамган ал кан белән,
Еллар таң калырдай зур дан белән!
Әнә шуңа, фашистларга янап,
Өскә таба үрли кызыл байрак.
Үлемнәрдән көлеп йөри солдат...
Дот авызына күкрәк тери солдат.

Юк, ул белми әле, еллар кичеп,
Бу якларның үзгәрәсен ничек,
Җиңү таңы кайчан атачагын,
Тыныч җилләр назлап яз чәчәген,
Бу тауларга яшәү кайтачагын.

Сапун-тауда музей карап йөрим.
Мәңгелек ут... һәйкәл... Матәм җыры...
Тетрәнеп һәм ярсып тибә йөрәк...
Батырларга шундый таулар кирәк!

●

Илаһи сын, кайнар кочак эзләп
Килмәдем мин зәңгәр ярларга:
Дары кирәк иде хисләремә,
Дәва кирәк иде ярама.

Язмыш шаяруы гына дисәң,
Болай туры килү икеле...
Очраштык без бер-беребезне инде
Күптән сагынып көткән шикелле.

Җитәкләшеп йөрдек сабыйлар күк,
Онытып җирдә гамьне, ваемны.
Кавыштырдык кипарислар белән
Иделдәге горур каенны.

Чагыштырдык күңелдәге йөкне,
Озынлыгын үткән юлларның...
Һәм, мөгаен, гади мантыйк моны
Беркатлылык диеп юрардыр.

Сәер аңлашу бу дигән сыман,
Дулкын ярдан үрелеп тыңлады:
Әйтерсең лә серләшәләр иде
Спиноза белән Колгали.

Тукай телендә мин шигырь әйттем,
Син яһүдчә моңлы җыр суздың.
Мәңгелек бер чынлык чыңлап торды
Күкрәгендә зәңгәр диңгезнең.

...Без барыбыз да бер җир балалары —
Меридианнар бүлми йөрәкне.
Бергә каршыларга таңнар булса,
Бәхет өчен берни кирәкми.

## Чуфут-кала

Ышанмагыз тарих хәтеренә —
Һәр битендә аның күп нокта...
Чуфут-кала [1], әнә, үз башыннан
Ни кичкәнен инде оныткан.

Заманы да көйсез кияү кебек
Гел үзгәреп торган ул чакны;
Я юнаннар куган скифларны,
Я хазарлар буган кыпчакны...

[1] Чуфут-кала — Бакчасарайдан ерак түгел урнашкан буш мәгарә-шәһәрчек.

Мәгарәдән мәгарәгә йөрим,
Сәер бер хис буа бугаздан:
Якты бу җиһанга кабер сыман
Авыз ачып карый таш базлар.

Ә кайчандыр... Ә кайчандыр монда
Тормыш кайнап торган һәр җирдә.
Кемдер кемнәрнедер сагынып көткән...
Елаулар да булган... һәм җыр да...

Һәм баш имәс өчен җиде ятка,
Крепость булып баскан бу таулар,
Хисләр хискә бәрелеп чыңлаганнар,
Сөңгеләрдә сөңге уйнаган.

Бары да үткән. Аппий юлы сыман
Хәзер ул тик шомнар тарата.
Кайтавазлар гына йөри бугай
Өрәк булып ерак тарафта.

Мең язмышның моңын суза сыман
Җилдә тирбәлүче кылганнар.
Һәм билгесез батыр каберендә
Сырт җылыта кәлтә еланнар.

Һәм битараф кына кояш яна,
Үткәннәрнең исә тик җиле,
Байтак күрдем мондый гыйбрәтләрне,
Исем китми, дигән шикелле.

Миңа инде барыбер дигән сыман,
Чуфут-кала — чорлар чатында
Башын кыңгыр салып уйлап ята
Мәңгелек һәм мизгел хакында.

## Төнге манзара

Төнге тынлык сарган тау сукмагын
Тыныч күңел белән кем узар?!
Баш түбәмә тияр-тимәс булып,
Чекерәеп яна йолдызлар.

Күк гөмбәзе ишелеп, кыя таулар
Сытылмасын берүк, дигәндәй,
Ябалдашын җәеп үрә баскан
Сакчы сыман уяу имәннәр.

Ә түбәндә — диңгез... Аңа тагын
Сәлам бирә икән кай яклар?!
Җилкәннәргә җилләр тулуын көтеп
Йокымсырап утыра маяклар.

## Нәҗип Мадьяров

### Ашкынам болыннарга

●

Безнең яшьлек үткәрмәде гомерен
Хәзергедәй матур киенеп.
Киндер чалбар, сатин күлмәкне дә
Кабул итә идек сөенеп.

Сугыш чоры булгангадыр бәлки,
Юк-бар өчен һич тә көймәдек,
Сынмады рух, заман безне түгел,
Без заманның үзен көйләдек.

●

Үсмер чакта шактый көтү көттем,
Башка эшләр өелеп торса да.
Хезмәт хакы югарырак иде,
Дәрәҗәсе түбән булса да.

Хәзер аңлыйм. Зур хак болыннарны
Өйрәнүем белән түләнгән.
Табигатьне аңлар дәрәҗәгә
Күтәреләм шуңа түбәннән.

●

Ашкынамын болыннарга —
Чәчәкләр ватанына.
Киләчәгемә юлларым
Тик шулар аша гына.

Кабына борчу катыш уй
Никадәр чикләнеп тә.
Җир «оҗмахы»на үтәргә
Куямын шикләнеп тә:

Андагы рәхәтлеккә бит
Түзә белү дә кирәк.
Ул гүзәллек дәрьясында
Йөзә белү дә кирәк.

•

Күтәрелдем таш тау түбәсенә,
Корып беткән аның бар ягы.
Анда фәкать ялгыз үлән күрдем,
Ул да булса — шайтан таягы.

Үзәнлектә бәлки нәфрәт белән
Сыйлар идем аны, тукталып.
Ә биредә, белмим, нилектәндер,
Карап тордым аңа сокланып.

•

Чын күңелдән сөйде мине берәү,
Чын күңелдән аны сөймәдем.
Теләмәдем хәтерен калдырырга,
Гүя изге иде теләгем.

Искә алып ул шук минутларны
Үз-үземне тотып тиргәдем.
Төшендем мин: сыкратмаска уйлап
Сыкратканмын аның йөрәген.

•

Мәкерле җан. Кара уйлы күңелендә
Гел явызлык, саф хис тәмам-тәмам беткән.
Бер уйласаң, кызганыч, бик кызганыч ул,
Андый кеше корган агач төсле икән.

Шул кешегә, кызгансаң да, уйлансаң да,
Берничек тә шәп игътибар туплап булмый.
Сирәк-мирәк кунып кайчак сайраса да,
Корган агачка кош та бит оя кормый.

•

Бер-берсенә ялгап ясыйм менә
Сүзләрдән мин фикер чылбыры.
Бәйләү өчен дуслар игътибарын,
Эх, дим, алар ныграк булгыры.

## Александр Блок

### Тилгән

Йоклап яткан буш болынны урап
Очып йөри өстә бер тилгән, —
Ә бер өйдә, сагышлардан сыкрап,
Баласына ана иелгән:
«Мә ипи, мә, я им дә йокла,
Зур үс, буйсын, тәңрең онытма».

Шаулый сугыш, куба көчле гыйсъян,
Яна йортлар, үтә ни заман!.. —
Искечә син, илем, борынгыңнан
Күз яшеңнән купшы манзараң, —

Кайчангача ана кайгырыр?
Кайчангача тилгән каңгырыр?

1916

●

Тормыш көймәсе
Терәлде комга...
Эшчеләр тавышы
Яңгырады шунда.

Тын суда — җыр да
Һәм борчу гына...
Менә җиләнле
Бер көчле чыга.

Җилкәнне төшереп,
Рульне кузгата,
Күкрәге белән
Багорга ята.

Ул әкрен бора
Кызыл көймәне, —
Йөгерә яр буйлап,
Кала өйләре.

Юнәлде көймә,
Юлчылар бик шат...
Тик алар безне
Утыртмаячак!

1904

## Ялгыз хатын

*Август Стриндберг хатирәсе*

Газапларны татыдым, хыялландым
Шашып үлем көтеп үземә...
Тик юк! Хәятемә кул салмадым,
Яшим менә — кайгы йөземдә.

Язын зират буйлап гизә идем,
Очраттым бер нәни курганны,
Таныш түгел кабер белсен дидем
Башларымнан ниләр узганны!

Мин чәчәкләр китереп салдым аңа,
Кояш баеп барган чагында...
Кемдер йөри, йөри һаман янда,
Карап куя минем ягыма.

Көтмәгәндә тоткан карашыннан
Игътибарын миңа аңладым,
Юк, ялгыз мин, ялгыз! Карауычыдан
Йөз чөердем, читкә атладым.

Әллә борчый иде ялгызлыгы?
Әллә инде күреп ошатты
Талган йөземдәге тирән моңны?
Ник карады икән бу чаклы?

Юк, мин йомдым тизрәк күзләремне:
Буйга зифа, моңсу йөзләре.
Арабызда, тоташтырып безне,
Сузылмасын сагыш эзләре...

Ләкин тоям: җилкәм аша гына
Карап тора, тәмам янымда...
Кире кагар өчен, тизрәк моңа
Авыр сүзләр эзлим җанымда.

Ул пышылдап көчкә әйтә шунда,
Азапланып, сыкрап күңелдән:
«Курыкмагыз миннән. Бу урында
Нәни балам минем күмелгән».

Гаепледәй, кичерү сорадым да,
Башым идем кайгы белдереп.
Ә ул сузды чәчәкләрне миңа,
Онытып бара икән дип белеп.

«Алар калсын, дидем, сабыегызда,
Очрашудан безнең бер ядкарь...»
Ул иңбашын тартты салкын гына:
«Алар бигрәк Сезгә кирәкләр».

Мин гаепле, әйе, хатам да хак,
Тик үлгәнгә кадәр кичермәм! —
Минем арттан кызгангандай карап
Елмаюы чыкмый исемнән.

1914

•

Гүзәлем, ник алай гашыйклар ауларга,
Күзеңдә нинди ул сихерләр?
Мин дә бит түзәлмәм бу кадәр арбауга,
Ләкин, юк,— башкалар сөйсеннәр.

Бу хәтәр уеның, яздырып акылдан,
Кол итәр күпләрне арада,
Әйләнерсең аннан яшь, матур хатыннан
Акыллы, рәхимле анага.

Син инде язмышың уенына күнеккән, —
Күпме ул наз, бәла китерде! —
Яңадан туарсың саф алсу күбектән,
Нәкъ шулай, бүгенге шикелле.

1915

•

Мин — Һамлетмын. Каным туңа минем
Мәкер җәтмә коруын күргә.
Җанда яши иң беренче сөюем
Дөньядагы бердәнберемә.

Зәмһәрирле тоомыш алып китте
Сине — Офелиямне еракка.
Агуланган кылыч һәлак итте
Мин-принцны туган туфракта.

1914

•

Гел яшәдең ялгыз! Эзләмәдең
Имандаш та, дус та, терәк тә.
Син чәнечтең хәнҗәр, кызганмадың,
Бәхет өчен ачык йөрәккә.

«Бәхет табар идең син дә, шашкан!..»
«Нигә! барыбер саклап калырга
Мөмкин түгел аны дулап ташкан
Бураннарның салкын карында!»

1914

## Газазил

Атла, атла, минем арттан калма,
Тугры колым булып, иеп баш.
Очып менәр өчен якты тауга
Уңай булыр янда син булгач.

Ашырырмын өскә, упкыннарның
Үртәп төпсез-тирән ярларын.
Файдасызга булыр куркуларың,
Илһам гына булыр зарларың.

Эфирлардан, башың әйләнүдән
Химаяләп бөтен көчемнән
Саклармын мин канатларым белән,
Бер күтәргәч кулдан төшермәм.

Таш тауларның ап-ак балкышында,
Тапталмаган саф бер болында,
Мин илаһи тәнем белән шунда
Көйдерермен гаҗәп нурымда.

Син кыргый дәрт дип атаган әйбер –
Бик кечкенә нәрсә, алдану,
Моңсу сагыш кына җирдәге бер...
Сыймыйдыр шул синең аңга бу? —

Кечке дөнья бераз тына төшкәч,
Сихерем көче җаның упканда,
Очыйк диярсең син тагын өскә,
Күк даласы яккан утларга.

Әйе, алып сине мин асманга,
Ашырырмын гаршең-күгеңә,
Җир күренә йолдыз булып анда,
Ә йолдыз җир булып күренә.

Оерсың син тәмам хәйран калып,
Синең алда яңа дөньялар —
Ышанмаслык күренеш торыр балкып, —
Мин тудырган уен тик алар...

Син куркудан хәлсезләнеп, тетрәп
Пышылдарсың: җибәр!..— дип шунда.
Мин җәермен канатларым кинәт,
Елмаермын: оч, бул юлыңда!

Шул илаһи елмаюдан эреп —
Гел әверелә барып юклыкка,
Син очарсың, таштай бөтерелеп,
Балкып торган чиксез бушлыкка.

1916

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре.

# КАМАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## ЯНВАРЬ, 1976

Җыю заводының зур корпусында мең-мең төрле авазлар яңгырый. Кырык гектар мәйданны биләгән түбә астында 150 автомат линия эшләячәк... Җыю заводы — комплексның төп заводларыннан берсе. Иң элек ремонт-инструменталь заводы эшли башлады. Хәзер ул производствоның башка төр тармакларын стандарт булмаган җиһазлар, технологик кирәк-яраклар һәм инструментлар белән тәэмин итү буенча зур булышлык күрсәтә.

Узган ел планнан тыш 110 мең квадрат метр производство мәйданы хәзерләнгән һәм 2500 берәмлек җиһаз урнаштырылган. Җибәрү-көйләү процессында биш йөздән артык исемдәге деталь һәм булачак машинаның алтмыш узелы үзләштерелгән, КамАЗның беренче моторлары җыелган.

Яңа автомобильне барлык кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итү һәм аны юлга тиешенчә әзерләү эше Чаллының бер үзендә генә алып барылмый. Кама автомобиль төзелешенең үзәген тәшкил иткән алты заводтан тыш тагын җиде завод: Тольяттида генераторлар һәм стартерлар, Зәйдә — тәгәрмәчләр һәм дистанцион аппаратлар, Октябрьскида — автомобиль приборлары, Нефтекамскида — үзбушаткычлар, Ярославльдә — дизель, Рославльдә — тормоз аппаратлары, Красноярскида прицеп заводлары төзелә. Егермегә якын предприятие өр-яңадан реконструкцияләнә. Автомобиль комплексын төзүгә билгеләнгән капиталь салымның өчтән бере чамасы КамАЗ «юлдашлары»на туры килә.

Генераторлар һәм стартерлар заводы удар темплар белән төзелә. Аның корпуслары ВАЗ янәшәсендә күтәрелә... Бәләбәйдәге автонормальләр, Паневежистагы автокомпрессорлар, Димитровградтагы кузов арматурлары, Ставровдагы автотракторлар заводларында, илебезнең башка предприятиеләрендә эшләр яхшы бара.

КамАЗ йөк машинасына кирәкле сигез мең ярым детальнең ике меңләбе читтән китереләчәк. Союз күләмендәге унсигез министрлыкның 300 ләп предприятиесе КамАЗ өчен эшләячәк. Тәэминат картотекасында биш меңнән артык позиция исәпләнә. Болар — корычның махсус маркалары һәм прокат профильләре, электротехник резин әйберләр, яңа полимерлар, майлау материаллары, тукымалар...

Планлаштыруның программа-максат логикасы әнә шундый. Менә шуңа күрә дә автомобильләрне билгеләнгән срокта чыгара башлау өчен арадаш предприятиеләрнең заводны барлык кирәкле нәрсәләр белән һичбер нинди тоткарлыксыз тәэмин итеп торулары сорала. Әмма күзгә күренеп торган тоткарлыклар шактый әле. Менә аларның кайберләре: камазлылар алдында, беренче чиратта, Кара металлургия министрлыгы бик зур бурычлы. Металлурглар аларга елына, барысын бергә кушып исәпләгәндә, миллион ярым тонна прокат, торба һәм чимал бирергә тиеш иде. Эшләр кирәгенчә бармый. Шул ук вакытта Кара металлургия министрлыгының кайбер предприятиеләре һаман да бирергә тиешле продукцияне җитештермәгәннәр. Биредә ике яклы килешүнең барлык пунктлары да үтәлә дип әйтеп булмый. Хәзерге көнгәчә 3,6 миллиметр калынлыгындагы салкын юл белән коелган табаклы калай җитештерү башланмаган. Ә аннан башка кардан валы торбаларын ясау мөмкин түгел... Кама автомобиль комплексын төзүчеләрнең Электротехника промышленносте министрлыгына да үпкәләре бар. Бу министрлык эшләп чыгара торган яңа продукция — «Родник» аккумуляторлары үзләре бик җиңел һәм алар зур энергия куәтенә ия. Моторны салкын һава шартларында кабызганда моның әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Әлеге продукция Подольскида үзләштерелгән. Ләкин биредә электр энергиясенең куәте җитәрлек түгел. Шуңа күрә ул башка шәһәрләрдәге предприятиеләр ярдәменә мохтаҗ. Автомобиль промышленносте министрлыгы буенча комплектлаштыру әйберләре производствосы технологик

кирәк-яраклар белән әле тулысынча тәэмин ителмәгән. Ул кирәк-яраклар җыелмасын ашыгыч рәвештә сынап карау һәм аны тиешле параметрларына җиткерү — бүгенге көндә иң мөһим һәм ашыгыч бурычларның берсе әнә шул...

«Известия», Мәскәү.

Дулап югарыга үрләгән ялкын телләре... Ерак-еракка чыңлаган металл тавышы. Очкыннар әченнән кулына авыр чүкеч тоткан тимерченең алга иелә төшкән гәүдәсе күренә. Бөтен җирдә бары тик ике төс — кара һәм коңгырт-көрән төс хакимлек итә. «Тимерчелек» дигән сүзне әйтүгә, безнең күз алдыбызга әнә шундый күренеш килеп баса.

Заманнар узу белән сүзләрнең мәгънәләре дә үзгәрә. КамАЗның тимерчелек заводы бөтенләй башка. Ул зур-зур биш корпустан тора. Эчтә дә, тышкы якта да күзләрнең явын алырлык йомшак, рәхәт яктылык. Кая карама — өр-яңа җиһазлар, төрле-төрле төстәге күп санлы кнопкалар.

1975 елның 10 сентябрендә беренче номерлы пресслар цехында беренче кайнар чүкелмә штампланды. Беренче корпусның үзәгендәге зәңгәр өстәл монда әйтерсең лә КамАЗның киләчәктә ачылачак музееннан китерелгән иде. Табличкага ачык һәм төгәл итеп: «Термик цехта эшләнгән поковкалар» дип язылган сүзләрне укыйбыз. Аның янәшәсендә төрле конфигурациядәге вак һәм эре-эре детальләр. Аларның кайберләренең авырлыгы 250 грамм, ә кайберләренеке 18 килограммга житә. Бүгенге штамповкалаучы-тимерчеләр әнә шундый әзер детальләр белән эш итәләр. Аларга хәзерге заманның иң яңа техникасы хезмәт күрсәтә.

«Комсомолец Татарии», Казан.

Чаллы автомеханика техникумында кышкы имтиханнар сессиясе башланды. Билгеле булганча, Чаллыда автомобиль комплексын төзү белән бәррәттән югары квалификацияле эшчеләр хәзерләү буенча зур эш алып барыла. Яшьләр профессиональ-техник училищеларда, техникумнарда һәм Казан институты филиалында укыйлар. Бу уку йортларын тәмамлап чыгучылар Мәскәү, Минск, Тольятти, Горький һәм илебезнең башка шәһәрләре предприятиеләрендә белем алучы тәҗрибәле белгечләр белән бергә КамАЗ заводларында эшләячәкләр.

«Правда», Мәскәү.

КамАЗ автомобиль заводының барлык коллективлары партия съезды хөрмәтенә илле көнлек удар вахтага бастылар. Завод эшчеләре «КПССның XXV съездына — Кама автомобиле!» дигән девиз астында эшлиләр.

Партиябез съезды хөрмәтенә кабул ителгән социалистик йөкләмәләренең уңышлы үтәлүе турында беренче булып картерлар цехы коллективы рапорт бирде. Биредә көйләү-җибәрү эшләре барышында тәҗрибә узу өчен чыгарылачак 200 йөк машинасына җитәрлек детальләр һәм узелларның тулы номенклатурасы хәзерләнде.


Артта — искиткеч зур һәм авыр хезмәт. 1975 елның башында цехта әле бер генә квадрат метр да производство мәйданы юк иде. Тимер-бетон конструкцияләрне монтажлау эше алып барылды, кирәкле тоннельләр һәм чокырлар казылды. Төзүчеләргә ярдәм итү өчен завод эшчеләре бригадалары оештырылды. Ә инде февраль азакларында җиһазларны монтажлау өчен кирәкле производство мәйданының беренче квадрат метрлары әзер иде. 5 мартта цехта беренче станокны монтажлауга багышланган митинг уздырылды. Аны монтажлау хокукын ярышта җиңеп чыгучылар яулап алды.

Автомобиль заводы төзелеше тарихында картерлар цехы коллективы ифрат зур роль уйнады: автомат линия өчен беренче рам шушы цехта коелды, заводта беренче автомат линия шушы цехта монтажланды. Цехтагы алты автомат линиянең иң зурысы «КУКА» дип атала. Ул 42 технологик берәмлектән тора. Аны төзүдә 10 чит ил фирмасы катнашты. Технологик эшләрнең беренче чираты — механик эшкәртү, күмер әчелеге газында эретеп ябыштыру, ышкып ябыштыру, вакуумда сынау, автомат контроль системасы шушында һәм бу катлаулы эшләрнең бөтенесе дә иң кыска срокларда башкарылды. Эш процессында цехта таза һәм сугышчан коллектив формалашты. Бу коллектив баш конвейерны эшләтә башлауга хәзерлеккә бәйле булган барлык бурычларны уңышлы үти.

«Советская Татария», Казан.

## Альберт Хәсәнов

# БУРОВОЙ ЮЛЛАРЫНДА



Бер уйласаң, гаҗәп, бик тә гаҗәп инде бу тормыш дигәнең! Менә кичәге тамашаны гына әйт инде син. Андагы тантананы, андагы котлау сүзләрен әйтеп бетерешле генәме соң? Залның бер башында эстрада оркестры, икенче башында — тынлысы. Берсе чүт кенә ялга туктауга, икенчесе уйнап җибәрә. Җиз быргыларын кычкыртып, барабаннар сугып, залга мәктәп балалары килеп керде. Кулларында — байраклар, муеннарында — кызыл галстук...

Бу алкышның барысы да аларга — Камилгә һәм аның иптәшләренә. Бүген алар — рекордчылар, буровой вышкаларын Татарстанда гына түгел, бөтен илдә иң кыска срокларда һәм иң арзанлы ысуллар белән куючылар. Инде йөз туксан ике буровой төзеп, бишьеллык заданиеләрен алар өч айга алдан үтәп чыктылар. Бу чыннан да зур җиңү. Тугызынчы бишьеллыкта илебездә вышка төзүче бригадаларның берсе дә мондый күрсәткечкә ирешә алмаган.

Хезмәтенә күрә хөрмәте: Камилне һәм аның иптәшләрен чәчәкләр белән күмделәр. Һәркайсын аерым-аерым да, аннары барысын бергә утыртып та фоторәсемгә төшереп алдылар. Мәскәү телевидениесенең «Вакыт» программасында күрсәтү өчен киногә төшерделәр. Шәһәрнең культура сараенда үткәрелгән бу кичәдә аларга сүз белән аңлатып бирә алмаслык ихтирам күрсәтелде.

Ә менә бүген инде бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләре белән килгән гадәти эш көне. Бригадир һәм аның егетләре, картлар әйтмешли, иң изге сәгатькә туры китереп, хезмәт исәбен ике ай ярымга алдан ачып җибәрергә җыеналар. Анысы шулай. Әмма буровой юллары тайгак юл. Әйе, ничек инде шулай димәссең! Кичәге оркестр авазлары, алкышлау сүзләре әле тынып та бетмәгән иртәдә бригадир Нуруллин үзе өчен авыр истәлекле Куакбаш мәйданына, бораулаучылар арасында яманаты белән дан алган Чүте тавына эләкте. Сорап алсаң да шулай туры килмәс...

Ромашкино ятмасы яңалардан түгел, бередәге күпчелек мәйданнарны кабаттан әйләнеп кайтып бораулау инде күптәннән бара. Камилгә дә үзенең бригадасы белән бер тапкыр булып киткән җирләрендә яңадан буровойлар корып йөрергә күп туры килде. Ләкин ул нәкъ менә бүгенге иртәдә, нәкъ шушы пеләш баш Чүте тавына эләгермен дип башына да китермәгән иде. Күрәсең, язмыш дигән нәрсә аны тагын бер тапкыр сынарга тели. Буровойны бүген дә, теге чактагы кебек үк, Чүте чишмәсенең бу як ярыннан сүтеп алып, каршы якка күчереп куярга кирәк. Ике араны сазлыклы тирән чокыр бүлеп тора. Бригадир алдында ике юл бар. Беренчесе — тигез, чокыр-чакырсыз юлдан елга үзәнен әйләнеп узу. Сигез чакрым өскә, сигез чакрым аска... Бер уйлаганда, күп ара да түгел. Анысы шулай. Юлның әйләнечтән туры булуын Камил дә яхшы белә. Әмма уналты чакрым җир уналты адым гына түгел шул. Алтмыш тоннадан артык йөк тарткан кәрван өчен бу кимендә ике-өч көнлек юл. Өстәвенә тагын ничәмә дистә гектарлы ямь-яшел уҗым басуын таптап узарга кирәк булачак. Ызанда туып, бураэнада аунап үскән Камилнең күңелен менә шул тырный. Ә икенче юлны сайлап, турыдан бәрдерсәң исә, текә таудан төшеп, шундый ук текә ярга үрмәләргә туры киләчәк. Абайлап өлгермәсәң буровоең-ниең белән бергә мәтәлеп, муеның аска килүе дә бик ихтимал. Әмма Камил тәвәккәлләргә, турыдан таш ярырга ярата. Теге вакытта да икенче вариантны сайлаган иде.

Рингта авыр нокаут алган боксер бокс белән шөгыльләнүен бәтенләй ташлый, я озак вакытлар рингка чыкмый тора. Теге чакта Камил дә нокаут алды. Аның да ниндиен генә әле! Шуннан соң ул буровой юллары белән чак кына хушлашмады...

Егетләр инде буровойны сүтеп бетереп тә киләләр. Ә ул күңеленә дулкын-дулкын булып ишелгән истәлекләрдән һаман арына алмый. Ул вакытта Камил гади бригадир гына иде. Бүген ул — даны илгә таралган атаклы вышкалар төзү остасы. Әйе, еллар уза, кешеләр үсә. Кеше кырыкка кадәр генә торам дип яшәр, ди. Камил абзагыз инде биш дистәне тутырып килә. Ләкин аның әле бирешергә исәбе юк, һаман да корам дип яши. Җитмеш өченче елны алар вышка төзү остасы, Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй Баһманов белән бил алыштылар. Камил, аннан ике буровойга уздырып, 139 вышка төзеде. Илебездә моңарчы ирешелмәгән яңа рекорд иде бу. Җитмеш дүртнең социалистик ярышында да аның бригадасы яңадан җиңүче булып чыкты. Алар ел әйләнәсенә 141 буровой кордылар. Тугызынчы бишьеллыкның соңгы елында Камил Нуруллин үзенең монтажчы егетләре белән 145 буровой төзергә йөкләмә алган иде. Елны бригада яңа бөтенсоюз рекорды белән — инде 184 буровой корып тәмамлады. Менә шушылардан соң хурлыкка калсаң нишләрсең? Кеше күзенә ни йөзең белән күренерсең?..

Юк, Камил бүген дә чигенмәскә булды. Менә аның янына беренче звено башлыгы Наил Шәмгунов килеп туктады.

— Сүтеп бетердек, тракторларны тоташтырдык, кузгалсак та була торгандыр,— диде ул Камилгә. Әллә бригадирга шулай тоелды гына, әллә чыннан да сынау өчен: — Каян бәрдерәбез? — дип өстәде.

— Турыдан! — диде Камил. Аннары үзен-үзе аклагандай әйтеп куйды.— Өстән китсәк хәвефсезрәк инде хәвефсезрәген, әмма күпме уҗымны харап итәчәкбез.

— Турыдан икән, турыдан,— диде Наил.— Тракторлар куәтле, маршрут таныш. Бер дә шикләнмә, шапылдатып илтеп куябыз аны.

Наил Шәмгуновка бригадир үзенә караганда да ныграк ышана. Алар унбиш ел инде гел бергә эшлиләр. Наил — ике ел Алжирда булып, татар егетләренең кемлекләрен күрсәтеп кайткан оста. Брюссельдә үткәрелгән Бөтендөнья күргәзмәсендә Совет павильонында куелган бораулау установкасын да Наил Шәмгунов звеносы төзеп кайтты.

Ә шулай да күңелен төрле буталчык уйлар биләгән бригадирга болар аз кебек тоелды. Вышканың ничек утыруын, арканнарның ныклыгын, ничек беркетелүен, кайсы тракторның кая куелуын тагын бер кат үзе барлап, үзе тикшереп чыкты.

Юл өстендә яткан тимер-томыр кисәкләрен бер читкә алып ыргыттылар. Шуннан соң гына ул үз урынына басты, уң кулын югары күтәрде:

— Кузгалдык!

Әйләнә-тирә куәтле тракторлар гөрелтесенә күмелде. Очы болытларга ашып утырган пәһлевандай биек вышка, шушы кечкенә гәүдәле кешегә буйсынуын белдергәндәй, җиңелчә генә чайкалып куйды һәм үзенең алтмыш тоннадан артык авырлыгын өстерәп, бригадир артыннан атлады.

Юкка гына борчылды, юкка гына дулкынланды бугай бригадир. Таудан да җиңел генә төштеләр, сазлыклы үзәнне дә артык азапланмыйча уздылар, каршы як тау битендә дә хәвеф-хәтәрсез генә үрмәләделәр. Үрмәләмәскә соң! Камил абзагыз буровойлар кору эшендә инде чирек гасырдан артык эшли. Шул дәвер эчендә мондый гына таулардан төшәргә, мондый гына кыя башларына менәргә туры килдеме соң аңа! Вышкалар хәзер чын сәяхәтчеләргә әйләнде бит. Бүген алар Чүте тавында, иртәгә Елховой болынында. Аннары исә буровой — Карабаш диңгезе ярында. Элек унике-унөч «ДТ-54»ләр көч-хәл белән өстерәгән шул ук вышканы бүгенге «С-80», «С-100» тракторлары җилтерәтеп кенә йөртәләр.

Ә кешеләр — янәшәңдә ничәшәр ел кулга-кул тотынышып эшләгән егетләр — ничек үзгәрде! Дмитрий Николаев, Виктор Яковлев, Галимҗан Шәрипов, Мөхәммәтнасыйх Гәрәев, Әсхәт Нәбиев, Сафуан Галимов, Шәйхеразый Низамовлар вышканы бер урыннан икенче урынга, кирәксә, уч төбенә утыртып күчереп куя алырлардыр төсле.

Тау кашына күтәрелгәч тә, вышка бригадир артыннан күндәм атлады. Тракторлар аны яңа скважина бораулаyачак урынга хәвеф-хәтәрсез китереп бастырдылар.

Монтажчылар шунда ук аңа центровка ясарга да кереште. Монысы аның вышка коруда иң җаваплы эшләрнең берсе. Вышканы кыек утыртсаң, скважина кыек бораулана. Ә кыек бораулаunion, боравың, девонга төшәсе урынга, Чүте тавы итәгенә килеп чыгып, адәм көлкесенә калуың бар. Бригадир хәзер зур симфоник оркестрның дирижерын хәтерләтә. Аның чак кына кул изәве белән беләк юанлыгы арканнарның беришләре бушый, икенчеләре скрипка кылыдай тартыла. Вышка, бригадир әмеренә буйсынып, әле бер якка, әле икенче якка кыйшая. Шул чак монтажчылар аны, астына махсус бүкәннәр куеп, кирәгенчә тигезлиләр. Әйтерсең вышка бирегә гомерлеккә утыртыла.

Әллә инде шулай кыен һәм җаваплы булганга, центровка ясауны Камил башка эшләргә караганда ныграк ярата. Ә мәшәкать, җаваплылык биредә чыннан да җитәрлек. Блоклар аша арканнарны хәрәкәткә китерүче, тартучы тракторларның берсе буровойның бер ягында, икенчесе икенче якта. Аралары кимендә ике-өч йөз метр. Алар белән кычкырып хәбәрләшә алмыйсың, моторлар гөрелтесе комачаулый...

Озак еллар буе бергә эшләү нәтиҗәседер инде, кайчан кайсы арканны бушатырга, кайсын тартырга икәнен тракторчылар да, монтажчылар да бригадирның чак кына кул изәвеннән үк белеп торалар. Менә бүген дә буровойны утырту алдан ук репетиция ясалган кебек көйле бара.

Әмма берараны ул шулай да ничектер шикле чайкалып киткән төсле булды. Ә бәлки бригадирга гына шулай тоелгандыр, бәлки аны күк йөзе буйлап каядыр агылган болытлар шулай ялгыштыргандыр. Шулай да ул эсселе-суыклы булып китте, маңгаеннан салкын тир бәреп чыкты. Камилнең күз алдына моннан элек булып узган бер вакыйга килеп басты. Ул чакта да вышканы нәкъ менә тигезләгән, утырткан чакта...

Камил шунда ук центровканы туктатты:

— Егетләр, бер төтәтеп алыйк булмаса...— диде ул, бер як читкәрәк китеп, каен төбенә барып утырды. Әлеге вакыйга аңа һич кенә дә тынгылык бирми иде.

...Көннең көнендә, нәкъ сәгать алтыда елмаеп кайтып керә торган Камил ул кичне җиде тулып та, сигезенче киткәч тә күренмәде. Хатыны Хәят аның кайтышына һәр вакыт су җылытып куя иде. Буровойдан тузанга батып кайткан Камил капкадан керә-керешкә билдән чишенеп ташлый да, бар дөньясын онытып, рәхәтләнеп юына. Ул арада Хәяты аңа дөнья яңалыкларын, балаларның көне буе ни кылануларын сөйләп өлгерә. Бригада хәлләрен, бүген аларның кайда һәм ничек эшләүләрен сораштыра. Аннары өйгә керәләр. Үсеп, инде кул арасына кереп барган ике малай урамда көтү каршылап кала, ә кечкенәләре Венера әтисе алдына менеп утыра. Иркенләп, тәмләп чәй эчәргә комачауласа да, Камил аны алдыннан төшерми.

Ә менә ул кичне казандагы су берничә тапкыр кайнап чыгарга өлгерде, Камил һаман күренмәде. Иренең шулай соңгаруына борчыла башлаган Хәят капка төбенә чыкты. Тыкрык башында аңа иңенә көянтә-чиләк аскан күрше килене очрады. Аның да ире буровойда шофер булып эшли иде.

— Камил абыйны әйтәм, һаман юкмы әле?— диде ул.

— Юк шул, нишләптер озаклады.

— Безнең Касыйм күптән кайтты инде,— диде күрше килене. Аннары уңайсызланып кына әйтә куйды:

— Анда бит бүген авария булган, Хәят апа. Камил абыйларның буровое ауган.

Хәятның күз аллары караңгыланып китте.

— Ә үзләре?.. Үзләре исән-саулар диме соң?

— Үзләренә ул-бу булмаган.

— Я ходаем, бар икән күрәселәр, бар икән...

Камил төннең икенче яртысында гына кайтты. Ашамады, эчмәде. Дәшми-тынмый гына юынды да чоланга кереп караватына ауды. Буровойда булган хәлнең үзе өчен сер түгеллеген белдереп берничә тапкыр сүз башласа да, Хәят аның авызын ачтыра алмады.

Мондый чакта күзгә йокы керәме соң? Хәят он иләп, камыр изгәнче яктыра, таң беленә башлады. Коймак пешереп, чәй өлгертте. Инде Камилне уятыйм дип чоланга керсә, тегесе күптән аяк өстендә: ишегалдына чыгып, бүрәнәләр таратып маташа иде. Хәят чолан тәрәзәсеннән башын гына тыгып аңа дәште:

— Әтисе, керәсеңме, чәй өлгерде.

Камил аны әллә ишетмәде, әллә инде ишетеп тә җавап кайтармады.

— Әтисе, дим, сиңа әйтәм. Аннары эшкә соңгарасың!

— Соңгарыр урын юк хәзер безгә,— диде Камил теш арасыннан гына.— Буровой юллары ябык. Мәңгегә ябык алар миңа.

— Ничек инде ябык?

— Бригадирлыктан кичә үк алдылар. Ә калганын комиссия әйтер. Суд эскәмиясенә утыртырлармы, йортны сатып түләргә кушарлармы...

Бу сүзләрне ишетүгә Хәят алъяпкыч итәге белән йөзен каплады да тын гына еларга кереште.

Камил кичә буровойдан арып-алҗып кайтса да, тиз генә йоклап китә алмады. Әйләнде, тулганды, әмма күзенә йокы эленмәде. Әз генә яктыра башлау белән торып ишегалдына чыкты. Абзар кырында өелеп яткан бүрәнәләрне таратып ташлады. Бүген аның ашыгыр җире юк, вакытны бушка уздырганчы мунча бурый тора, янәсе. Менә ул балтасын бер генә чаба да бүрәнә өстенә утырып тагын үзен тиргәргә тотына. Егетлек күрсәтәм, булдырам, имеш. Әйе, булдырды, шәм кебек утырган буровойны мәтәлдерде, чәлпәрәмә китерде. Яңалык ача, янәсе, новатор була...

Юк, юк, мондый уйлар аның башына да килмәде ул вакытта. Боларны ул тик менә хәзер, үз-үзен орышу өчен генә уйлап чыгарды. Сәбәп шунда: унбиш-уналты километр араны әйләнеп йөрисе килмәде аның. Вышканы турыдан гына күчереп куярга теләде. Буровойларны яңача ысул, индустриаль алымнар белән күчерүгә керешкән генә көннәр иде әле бу. Кырык ике метр биеклегендәге вышка, кара исәп белән исәпләгәндә дә, унике-унөч катлы йорт биеклеге дигән сүз бит ул. Менә шул пәһлеванны, бер генә кисәген дә сүтми-нитми, икенче җиргә күчереп кара әле син. Ә Камилгә болар гына да аз тоелды. Бораулау установкаларын, Татарстанда беренчеләрдән булып, тигез юллардан гына түгел, чокыр-чакырлы юллардан, сазлыклы үзәннәрдән күчереп йөртү мөмкинлеген расларга, шуны практикада күрсәтергә теләде ул. Чоры шундый иде. Республикабызда нефть промышленностеның күкрәп, җәелеп килгән чагы. Һәркайда яңалык, һәркайда прогрессив эш алымнары куллану кирәк... Әнә буровойларда токым бораулау тизлеген моңарчы күрелмәгән-ишетелмәгән темп белән башкаралар ич. Я булмаса, промыселчыларга күз сал. «Кара алтын» чишмәләрен автомат җайланмаларга көйләп, берьюлы ун-унбишәр, хәтта егермешәр скважина эшен күзәтә башладылар. Индустриаль методларга күчү белән вышкалар монтажлау өлкәсендә дә зур гына үзгәрешләр булды. Югыйсә, әле кайчан гына бер буровойны ким дигәндә ике-өч ай төзиләр иде. Бораулаучылар аларның теңкәләренә тиеп бетә — чөнки бер скважинаны унбиш-егерме көн эчендә шапылдатып бораулап чыгалар да, яңа буровой өлгергәнне көтеп, ике-өч атна эшсез утыралар. Әйе, буровойларны бөтен блоклары белән берьюлы күчерә башлау монтаж эшләрен уннарча тапкыр тизләтте. Ләкин шушында тукталырга, алга инде бер адым да атламаска дигән сүз түгел иде бит әле бу. Буровойларны тагын да кыскарак вакыт эчендә төзү юлларын эзләргә кирәк иде. Камил моны йөрәге белән сизә. Вышкаларны, тасма тарткандай, тигез юллардан гына түгел, чокырлы-чакырлы сукмаклардан да күчереп йөртергә мөмкин икәнен эштә расласаң — бу яңа җиңү булыр иде. Камил нәкъ әнә шуны исбатларга теләде. Буровойны, унике тракторга җигеп, кыр кәҗәсенең башы әйләнерлек таудан да алып төште, сазлыклы үзәнне дә уздылар, каршы як тау битенә дә нәкъ менә бүгенге кебек җиңел генә үрмәләделәр. Ләкин тиешле урынга китереп утырткач, корыч арканнарны бушатуга — вышка ауды.

Бүгенге «БУ-75» тибындагы бораулау установкаларының аву-түнүгә каршы запаслары бергә — өч. Ә ул чактагы «Уралмаш-6Э» установкаларыныкы бергә — бер генә иде. Алай да, вышка тикмәгә аумый. Гаеп Камилнең үзендә булды.

Моның исә үз сәбәпләре бар. Яшьли, әле мыек та чыкмаган килеш, кырык өченче елны ул фронтка китте. Ике тапкыр яраланды да яңадан сафка кайтты. Дивизия командиры аны мактап туймас иде:

— Синең бу кулларны җимерүгә түгел, ә төзү эшенә җиксәң иде менә!

Камил сугыштан үзе дә тыныч төзелешкә сусап кайтты. Кайтып атна да ял итмәде, буровойга эшкә урнашты. Тиз арада вышкалар кору һөнәрен үзләштерде. Озак та үтмәде, аны бригадир итеп күтәрделәр.

Аву-түнүгә каршы запасы бергә — бер генә булса да, ул чакта вышка бәлкем аумаган да булыр иде. Әлеге дә баягы шул чуар йөрәкле булуы харап итте. Установканы шундый катлаулы, кыен маршрут белән күчерү җиңел булмады. Кешеләр талчыкты. Монтаж эшләрен бәлкем шушының белән туктатырга, кешеләргә ял бирергә кирәк булгандыр аңа. Ләкин... Камил ул турыда уйламады. Вышканы урынына китереп бастыру белән, шунда ук центровка да ясарга керештеләр. Камил үзе дә чиктән тыш арыган иде. Әллә үзе команданы дөрес бирмәде, әллә дөрес биреп тә аны ялгыш аңладылар. Вышканың уң аягын күтәртергә, аскуйманы шул якка куярга тиешләр иде. Әмма установка һичкем көтмәгәндә сул якка, тау астына таба янтая башлады. Башта бер градуска хәтле арканнарның тартуы буенча янтайды. Аннары, бәйдән ычкынган айгыр төсле, үз авырлыгы белән арканнарны өзеп, тау астына, чокыр төбенә очты. Ярый әле, монтажчыларның үзләрен харап итмәде. Камил, аларны кисәтеп, як-якка сибелергә боерып өлгерде.

Шул ук сәгатьтә участокка төрле комиссияләр килеп җитте. Үлчәделәр, исәпләделәр, озын-озын беркетмәләр яздылар. Бригадирның үзеннән дә ниләрдер сораштырдылар. Ул вакытта каушап, югалып калган Камил аларга ниләр сөйләгәнен үзе дә хәтерләми. Бары тик шунысы истә: аны бригадирлыктан алдылар. Үзләренең баш инженерлары аңа:

— Мальчишка, кулыңнан килерлек булмагач, маташмыйлар аны,— диде.

Хәер, аңа да үпкәләп булмый. Баш инженер дип тормаганнардыр, буровой хәтле буровой аугач, аңа да эләкмичә калмады, әлбәттә.

Мунча бураган булып, Камил өч көн азапланды. Әмма өч көнгә бер буй да чыга алмады. Ә дүртенче көнне иртүк юл капчыгын хәстәрли башлады. Бу көннәрдә ире шикелле үк йокы күрмәгән, ризык капмаган Хәят:

— Аталары, монысы тагын кая җыенуың? — дип, аның кулыннан юл капчыгын тартып алды.

— Буровойдан кудылар дип, һаман өйдә ятып булмас. Әнә Тимәштә бераүгә түбә ябарга кирәк икән...

— Юк инде! — диде хатыны үзенә хас бер кызулык белән.— «Мальчишка» дип әйткәннәр икән, имеш, аңа. Шул сүзне серкәсе күтәрә алмаганга, ничә көн инде эшкә чыкмый ята. Ярар, ди менә. Шәмдәй утырган буровойны ташка төшкән пыяладай чәлпәрәмә китер дә, сүз дә әйтмәсеннәр аңа... Молодец, дисеннәр, башыңннан сыйпасыннар... Җыен, киттек кантурыгызга, барабыз директорыгыз янына. Судка бирәләр икән, судка бирсеннәр, түләргә ясыйлар икән, аз-азлап булса да түләрбез.

— Үзем чакыртырга җыенып тора идем әле,— дип каршылады Камилне контора директоры.— Син нәрсә, дускай, үзең шундый ЧП ясадың, ә үзең ничә көн эшкә чыкмый ятасың. Вышканы аударганың һәм өч көн прогул ясаганың өчен сиңа каты шелтә белдерәм. Монысы миннән. Ә комиссия членнары вышканың авуына түгел, ә синең аны шундый текә тау башына ничек алып менүеңә гаҗәпләнгәннәр. Кыскасы, иртәгәдән үк бригадага!

Шул көннән Камил кабат коллективка, вышка төзүчеләр арасына кайтты. Дөрес, аны гади монтажчы гына итеп калдырдылар. Күпмедер күләмдә вышка бәясен дә түләде. Әмма аны новатор итеп таныдылар. Вышкаларны тигез булмаган җирдән текә таулар аша елга үзәннәренә күчерү мөмкин икәнлеген «Татнефть» берләшмәсендә беренчеләрдән булып ул күрсәтте. Аны төрле семинарларга, киңәшмәләргә чакырдылар, бу яңа метод турында газеталарга язып чыктылар.

...Әйе, кеше эштә сынала. Моннан берничә ел элек Камил эшләгән участокның бригадиры пенсиягә китте. Участокта бригадир булырдай алдынгы эшчеләр күп иде күбен. Ләкин контора җитәкчеләре дә, монтажчы егетләр үзләре дә бригаданы Камил Нуруллин җитәкләвен теләделәр. Шулай итеп, ул яңадан кырыклап кешедән торган комплекслы зур бригада белән җитәкчелек итә башлады. Ә бер тынгысыз кеше гел тынгысыз инде ул. Егетләр белән ныклап киңәште, булган мөмкинлекләрен кат-кат исәпкә алдылар. Һәм атаклы вышка төзү остасы, Социалистик Хезмәт Герое Гәрәй Баһманов бригадасын социалистик ярышка чакырдылар.

Гәрәй Баһманов Азнакай вышкалар монтажлау конторасында эшли. Бу районда нефть ятмалары чагыштырмача яңа, аларны әле күптән түгел генә үзләштерә башладылар. Үзеннән-үзе аңлашыла: монда вышкаларны күчереп йөртү дә җиңелрәк. Камил бригадасы эшләгән нефть мәйданнары исә иске, аларның өсте төрле промысел объектлары, тимер һәм асфальт юллар, электр, телефон линияләре челтәре белән капланган. Буровойларны бер урыннан икенче урынга күчергән вакытта болар барысы да өстәмә кыенлыклар тудыра. Әйтик, әле яңа гына бушаган буровойны геологларның соравы буенча башка урынга күчерергә кирәк. Ә вышка күчерәсе юлны югары вольтлы электр линиясе кисеп үтә. Буровой узган чакта аны ике-өч сәгатькә өзеп торырга кирәк. Бу линия исә йөзләрчә станок-качалкаларга энергия бирә, группалы уннарча установкаларны көч белән тукландыра. Аңлашканчы, уртак тел тапканчы, ике-өч буровой монтажларлык вакытың үтә дә китә. Әмма Камил, Гәрәй Баһманов бригадасы белән ярышка чыкканда, боларның берсеннән дә курыкмады. Алар тугызынчы бишьеллыкның соңгы ел йөкләмәләрендә каралган 145 урынына 184 буровой кордылар. Моңа хәтле әле беркем дә ирешә алмаган рекорд иде бу!

Менә бригаданың вахта журналы.

Егерме бишенче май.

Бу көнне бригадир Камил Нуруллин үзенең егетләре белән берьюлы өч буровойда демонтаж эшләре башлап җибәрә. Шул ук көнне 15503 нче буровойны алар иске урыныннан сүтеп алып, нибары биш сәгать тә егерме минут эчендә яңа урынга китереп монтажлыйлар, 15534 нче буровойны сүтеп, яңа урынга күчереп куялар, ә 1064 нче буровойны сүтеп, икенче көнне күчерү өчен хәстәрлиләр. Бер уйлаганда, гап-гади бер эш кебе. Ә моның нигезендә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү, буровойлар төзү срогын тагын да кыскарту буенча нәтиҗәле кыю эзләнү ята. Ә бит бер буровойны ике-өч ай буена төзегән чаклар әле кайчан гына иде! Коммунист Камил Нуруллин

җитәкләгән коллективның башлангычын «Татнефть» берләшмәсендәге башка бригадаларга да өйрәнергә, үзләштерергә тәкъдим ителде. Бу хакта СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең махсус бюллетенендә язып чыктылар.

...Күп булса, тәмәке тартып алырлык ара узгандыр. Ә шушы минутлар эчендә Камилнең күңеленнән күпме вакыйгалар, күпме истәлекләр узды. Шунда кемдер аның иңбашына кулын салды. Караса, әлеге Наил Шәмгунов икән.

— Ярыйсы гына ял да итеп алдык, төгәллик булмаса,— диде ул, каршыда басып торган вышкага ымлап.

— Төгәллик, егетләр, әнә бораулаучылар да килеп җиткән, көттермик,— диде бригадир, урыныннан җәһәт кенә күтәрелеп.

Яңа бишьеллыкның хезмәт исәбен ачарга тиешле беренче буровой иде бу. Центровка да уңышлы гына төгәлләнде, Манифольд линиясен дә тоташтырып өлгерттеләр һәм смена ахырына буровойны бораулаучыларга тапшырдылар.

Автобуска утырып, кайтыр юлга чыккач, монтажчылар арасыннан кайсыдыр ярым шаяру катыш:

— Ай-һай, уйландың бүген Камил,— дип куйды.

— Сөйлисе дә юк. Тәмам аптырадым. Башка килмәгән бер генә уй да калмады.

— Бер сиңа гына түгел, туган, безгә дә тынгылык бирмәде бу буровой,— диде икенчесе, аның сүзен куәтләп.— Теге чактагы кебек хурлыкка калмагаек дип, кайсыбыз гына борчылмады икән?!

Вахта автобусы тигез юлдан шәһәргә таба чаба. Анда вакытны узып эшләүче, унынчы бишьеллыкны ике ай ярымга алдан башлап җибәрүче, республикабызның данын күтәрүче егетләр кайта.

# ТАЛАНТЛАР ЮЛЫ



Менә ничә көннәр инде кулга каләм алырга куркып йөрим — Мирсәй Әмир иҗатының зурлыгы куркыта. Күпме мактасаң да аз булыр төсле.

«Авыл яшьләре» журналының 1926 елгы ноябрь санында әдипнең «Дуслар һәм дошманнар» исемле беренче хикәясе басыла. Аннан бирле узган ярты гасыр вакыт эчендә ул язган хикәяләрнең һәм роман-повестьларның, фельетоннарның һәм сәхнә әсәрләренең, публицистик мәкаләләрнең һәм тәнкыйть хезмәтләренең һәммәсен бергә җыйсаң, аларның гомуми күләме берничә йөз табакка җитәр иде. Әмма язучы иҗатының зурлыгын ул язган әсәрләрнең саны һәм күләме белән генә билгеләп булмый.

Әдәбият, сәнгать дөньясында иң соңгы судья — вакыт үзе. Вакыт сынавын узарлык бер әсәр язган кеше — бәхетле язучы. Мирсәй Әмирнең андый әсәрләре әллә ничәү: «Агыйдел», «Миңлекамал», «Мөстәкыйм карт йокысы», «Балыкчы ялганнары»... Шуларның берсе белән дә ул әдәбият тарихына зур язучы булып керер иде. Ләкин сүз биредә тагын да киңрәк, тагын да тирәнрәк мәгънәдәге зурлык хакында бара.

Бөек Октябрь халык арасыннан чыккан талантларның үсүе өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудыра. Мирсәй Әмир — әнә шундый талантларның, чор үзе тудырган талантларның берсе. Ярты гасыр вакыт эчендә ул газаплы эзләнүләр, куанычлы табышлар белән тулы зур иҗат юлы уза: бөтен көчен һәм талантын биреп, яңа әдәбиятны — социалистик реализм әдәбиятын тудыруда катнаша; әдәбиятыбызның алтын фондына керерлек әсәрләр язып, яңа методның көчен раслый, абруен күтәрә. Бер тамчы суда чагылган кояш нурыдай, аның иҗатында татар совет әдәбиятының ярты гасырлык үсеш юлы чагыла, аның әсәрләрендә героик халкыбыз узган данлы юл чагыла. Мирсәй Әмир иҗатының зурлыгы әнә шунда, минемчә: әсәрләренең халык тормышының елъязмасы булуында, иҗатының чорыбызга лаек иҗат булуында...

Чын Мирсәй Әмир «Безнең авыл кешесе» белән «Агыйдел» повестеннан башлана диләр. Бу — берьяклы караш. Безнең уебызча, чын Мирсәй Әмир, художник Мирсәй Әмир шактый иртә башлана. «Хафиз бармагы», «Җанлы бүкән», «Бәхет порошогы» кебек хикәяләрен, «Пар күгәрчен», «Хикмәтуллинның маневрда күргәннәре», «Карамалы егете» («Командир») исемле повестьларын язган чорлардан ук башлана.

Ихтимал, язучының беренче чор әсәрләрендә очеркка хас алымнар шактыйдыр. Ихтимал, аның ул әсәрләренә сюжет-композиция бөтенлеге җитеп бетмидер. Аның каравы, аларның һәркайсыннан егерменче еллар тормышының кайнар сулышын сизеп

була, аларның һәркайсында көчле тасвир куәтенә ия художник кулы ярылып ята. Ул әсәрләрне укыганда, без шул чорга хас кызыклы вакыйгалар һәм ситуацияләр, үзенчәлекле характерлар белән очрашабыз. Ул әсәрләрдә ифрат җанлы һәм табигый чыккан, тормышчанлык көче белән укучыны тетрәтерлек күренешләр күп.

Язучының беренче чор иҗатына караган әсәрләрнең һәркайсы диярлек табигый, халыкчан юмор белән сугарылган. Аның иҗатында юморның җылы, мөлаем көлүдән алып ачы сатирага кадәр булган барлык төсмерләрен очратырга мөмкин. Юмор-сатира алымнары язучының беренче чор әсәрләренә үзгә бер ямь һәм матурлык өсти, аларны кызыклы һәм үзенчәлекле итә.

Шул рәвешчә, беренче чор иҗаты буенча, Мирсәй Әмир безнең алга тормыштагы үзгәреш-яңарышларны җентекләп күзәтеп баручы оста хикәяче, чәчрәп торган көлү сәләтенә ия юморист булып килеп баса.

Алга таба язучының иҗат палитрасы тагын да байый һәм төрләнә төшә. «Безнең авыл кешесе» әнә шул хакта сөйли. Бер үк вакытта ул 30 нчы еллар әдәбиятында барган үзгәрешләр хакында да сөйли.

«Кайда өзеклек, кайда эш бармый — шунда сыйнфый дошман кулы тыгылган була...» Бу сүзләрне повестьның төп герое коммунист Бикташев әйтә. Аның шул сүзләрендә әлеге повестьның да һәм гомумән ул чор әдәбиятының да төп рухы, төп пафосы чагыла. Матур әдәбият йөз белән сыйнфый көрәш мәсьәләләренә борыла.

«Безнең авыл кешесе», чорның үзе кебек үк, кырыс, киеренке әсәр. Корыч пружина кебек, соң чиккәчә кысылган повесть. Кискен драматизм, кырыс буяулар, гүя ки, сыйнфый көрәшнең дә рәхимсезлеген раслап торалар. «Безнең авыл кешесе» — кыска һәм җыйнак әсәр, укучыга булган тәэсир көченең зурлыгы, активлыгы белән аерылып торган әсәр.

Автор сыйнфый көрәш мәсьәләләрен гадиләштереп сурәтләүдән ерак тора. Әсәрдә без реаль көрәш күренешләре, тормышчан итеп эшләнгән кызыклы образлар белән очрашабыз. Әсәрнең төп герое — җаны-тәне белән яңа тормыш төзү эшенә бирелгән коммунист, егерме биш меңче колхоз председателе Бикташев, революция мәнфәгатьләрен барыннан да өстен куйган максималист кеше, халык интереслары, социализм интереслары өчен шәхси бәхеттән баш тартырга әзер торган аскет кеше. Язучы аның шәхси тормышына, индивидуаль сыйфатларына һәм эчке дөньясына аз туктала. Шуңа да ул безнең алга, сөя, кайгыра һәм шатлана белүче җир кешесе булудан бигрәк, кырыс һәм нык ихтыярлы революция солдаты булып килеп баса. Без күбрәк аның яңа тормыш төзү өчен барган кискен көрәш юлында йөргән чагын күрәбез, аның белән күбрәк сыйнфый көрәш мәйданында очрашабыз.

Бикташев ярлы халыкны — үз көче белән яшәргә омтылучы чын кешеләрне бәхетле итү өчен көрәшә. Сыйнфый дошманнар, Миргали кебек, йомшак сөйләп, каты утырта торган мәкерле кулаклар яшәгәндә, ул бу максатка җиңел генә ирешеп булмаячагын яхшы аңлый. Кулак Миргалинең көче чын максатын яшерә белүдә, үз дигәненә ирешү өчен мәкерле планнар кора белүдә күренсә, коммунист Бикташевның көче — халык массаларына таянуда. Шуңа да ахыр чиктә ул сыйнфый дошманнарның барлык хәйләләрен җиңеп чыга. Кайчандыр Миргали йогынтысында булган ярлы Сабирлар, яңа тормыш төзү юлына баскан бик күп башка колхозчылар кулак Миргалине түгел, ә читтән килгән Бикташевны, каты куллы, әмма гадел коммунистны якын итәләр, **безнең авыл кешесе** дип атыйлар.

Каты куллы җитәкче диюгә, хәтергә, кылт итеп, «Чит кеше» пьесасындагы Чешков образы килеп төшә. Асылда Чешков та М. Әмирнең Бикташевы кебегрәк бер кеше бит. Күпме сүз булды бу образ турында, күпме мактадылар бу әсәрне... Ә бит шул ук нәрсәләрне (дөрес, башка материал җирлегендә) үз язучыбыз моннан 40 ел элек үк күтәргән булган! Мәсьәләгә әнә шул ноктадан карап якын килсәк, «Безнең авыл кешесе» повестеның әһәмияте тагын да арта төшәр.

Әдәбият тарихында барлык кешеләр тарафыннан бер дәрәҗәдә сөеп укыла торган әсәрләр була. «Агыйдел» — шундый повесть, бер тын алуда язылган, бер сулыш белән язылган әсәр. «Акчарлаклар», «Кара йөзләр» кебек үк, бәхетле язмышка очраган әсәр. «Агыйдел»не укып ничә буын укучы картайган. Гаязлар, Артыкбикәләр һаман картаймый. Алар кичергән хисләр һаман искерми. Повестьның сихри көче нәрсәдә?.. Мин еш кына шул хакта уйланам.

Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестен укыганда, чын күңелдән Гарифларны, Газизәләрне бәхетле итәсе килә, эчтән генә булса да: «Балык күбрәк керсә ярар иде», — дип теләп торасың. «Кара йөзләр»не укыганда бәхетсез Галимәне кызганасың, аның югалган матурлыгы өчен әрнисең. Әнә шул нәрсә әлеге әсәрләрне бөтен итә, камил һәм матур итә. «Агыйдел»нең сере нәрсәдә? Аны нинди көч яшәтә, нинди хис гүзәл һәм бөтен итә?..

Беренче карашка, «Агыйдел» повестеның укучыны шаккатырырлык бер җире дә юк кебек, ул — бик гади әсәр.

Ямьле Агыйдел буена урнашкан авылларның берсенә, җәйге ялларын үткәрергә дип, ике студент кайта. Әсәрнең нигезенә шул ике егетнең язмышы салынган. Авылда уздырган берничә ай вакыт эчендә аларга төрле кешеләр белән аралашырга, кызыклы һәм гыйбрәтле күп кенә вакыйгаларда катнашырга туры килә. Әсәрне уку дәвамында без алар башкарган эшләр, алар башыннан узган хәлләр белән танышабыз. Бер уйлаганда, гадәти хәлләр, колхозлашу чорындагы авыл тормышы өчен табигый вакыйгалар...

Әмма бөтен хикмәт шунда, ул вакыйгаларның һәммәсе ифрат зур кызыксыну һәм мавыгу белән укыла. Беренче битләрдән үк әсәр безнең игътибарыбызны биләп ала, автор безне үз артыннан ияртеп алып китә. Ник дип сорасагыз, ул үзе сурәтли торган геройларга һәм вакыйгаларга карата бездә кызыксыну уята белә. Повестьның башыннан ахырына кадәр күңелләрне үзенә тартып, сихерләп торган Артыкбикә турында сөйләп тормыйм. Мондый образ тагын Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә генә очрарга мөмкин. Күчәрбайларны һәм Тешсез Ибрайларны, Тәкъвә Сәхәүләрне һәм Низамиларны искә төшерегез. Һәркайсы — искиткеч тормышчан, истә калырлык геройлар. Әсәрнең Агыйдел табигатен сурәтләүгә багышланган урыннары, Гаязларның, җыелышып Урал тауларына күтәрелүләрен тасвирлаган бүлекләре турында шулай ук сөйләп тормыйм. Ямен җибәрермен дип куркам. Низамилардагы аш мәҗлесен, я булмаса гает көне алдыннан уздырылган кичәне алып карыйк. Никадәр җанлы һәм мавыктыргыч булып чыккан алар!

«Агыйдел» повесте гел контраст буяулардан тора. Шатлыклы вакыйгалар драматик вакыйгалар, матур күренешләр ямьсез күренешләр белән чиратлаша, яшьлек, мәхәббәт хисләрен сыйнфый көрәш картиналары алмаштыра, яхшы кешеләр яман кешеләр кармагына килеп каба... Шуңа да карамастан, әсәр ифрат якты, күтәренке тәэсир калдыра. Бусының хикмәте нәрсәдә икән?.. Безнеңчә, автор әсәрдә сурәтләнгән барлык вакыйгаларга тормышка гашыйк егетләр күзе белән, Гаязлар, Ильяслар күзе белән карый алган. Шуңа да повестьтан яшьлек хисе, яшәү көче ташып тора. Шул хис әсәрнең бөтен рухына, яңгырашына үз эзен салган. Яктылык, лирик җылылык шуннан килә.

Яшьлек хисе, яшәү көче... Мәхәббәткә сусаган, гүзәллеккә гашыйк яшьләр... «Агыйдел» повестеның сихри көче дә әнә шунда — яшьлекне символик мәгънәгә ия көч итеп күрсәтә алуда булса кирәк. Яшьләр — матурлык һәм гүзәллек сакчылары, алар — матур һәм гүзәл тормыш өчен көрәшчеләр. Яшьлек һәм яңа тормыш. Укучы аңында яңа тормыш үзеннән-үзе гүзәл һәм матур яшьлеккә тиңләштерелә. Хәзер инде Тәкъвә Сәхәүләрнең Гаязларга каршы көрәше тагын да зуррак һәм тирәнрәк мәгънә ала. Алар, ахыр чиктә, яңа тормышны, димәк ки, яшьлекне, гүзәллекне җимерергә маташучылар икән... Билгеле, укучы җаны-тәне белән Гаязлар, Ильяслар ягына күчә, искелек тарафдарларын күрәлмый башлый. Әнә шул хис әсәрдәге барлык вакыйгаларны бер үзәк тирәсенә җыйный, повестьның эмоциональ тәэсир көчен арттыра, аны төзек һәм бөтен итә.

Язучы бик зур һәм файдалы идеяләрне укучы аңына бернинди көчләүсез, чын сәнгать чаралары, тормышчан геройларның тормышчан хисләрен сурәтләү аша җиткерә алган. «Агыйдел» повестеның төп кыйммәте шунда.

Күп санлы хикәяләрдән, роман-повестьлардан тыш, Мирсәй Әмир — уннан артык пьеса язган кеше. Аларның һәммәсенә тукталып тормастан, «Миңлекамал» белән «Тормыш җыры» турында гына берничә сүз әйтәсе килә.

Чор сулышын, заманның төп рухын чагылдыру ягыннан «Миңлекамал» драмасы бер Мирсәй Әмир иҗатында гына түгел, ә бөтен татар драматургиясендә зур һәм мактаулы урын тота. «Безнең авыл кешесе» повесте кебек үк, «Миңлекамал» да шул

чорга хас кырыс буяулар ярдәмендә язылган. Язучы сугыш елларындагы колхоз тормышына хас авырлыкларны һәм кыенлыкларны яшерми. Шул ук вакытта ул авыл кешеләренең фидакарьлеген, совет кешеләренә хас патриотизмны да ифрат калку һәм тәэсирле итеп күрсәтә алган. Бу яктан драманың III пәрдәсе аеруча оста эшләнгән.

... Үз теләге белән колхоз председателе булып эшли башлаган Миңлекамал бер вакыт бик авыр хәлдә кала. Бәла арты бәла, күңелсезлек арты күңелсезлек чыгып тора. Язгы чәчү вакыты килеп җиткән. Ә колхозның ни чәчәргә орлыгы, ни җир сөрергә юньле атлары, ни эшләргә кешеләре җитми. Шундый бер чорда колхоздагы соңгы ирләрне, җигәргә яраклы тагын биш атны армиягә алалар. Район орлык лабораториясеннән бодай орлыгыгыз чәчәргә ярамый дигән күңелсез хәбәр килә. Карак Хәлимнәр, ялкау Мәймүнәләр колхоз эшенә таяк тыгып җанга тияләр. Шуларның һәммәсе өстенә авылга коточкыч авыр хәбәр килеп төшә: немец-фашист илбасарларына каршы көрәштә Миңлекамалның ире Шиһап һәлак булган...

Кинәт килеп төшкән бу кадәр авырлыкка адәм баласы түзмәс, никадәр генә түзем булмасын, сынар, сыгылып төшәр, дип уйлыйсың. Юк, Миңлекамал сыгылып төшми — иң кыен шул минутта җан ачысы белән: **«Җенемне кузгаттың, Гитлер, инде чыдап кара!»** — дип кычкыра. Аның бу сүзләре заманында тамашачыларга ничек тәэсир итте икән?! Бомба шартлаганнан ким булмагандыр, мөгаен. Аның бу сүзләре күпме кешене фидакарь хезмәткә күтәргәндер, күпме кеше күңелендә дошманга ачу һәм каһәрле нәфрәт уяткандыр! Чын сәнгать әсәренең көче кайчак бомбалар, снарядлар шартлавыннан куәтлерәк булып чыга. Шикләнми әйтергә була: М. Әмир шундый көчкә ия әсәр иҗат иткән. Миңлекамал кебек кешеләре булган стройны, Миңлекамал кебек гүзәл кешеләрне тәрбияләп үстергән стройны беркем дә, бер дошман да җиңә алмаячак! Драма укучы һәм тамашачы күңелендә әнә шундый ышаныч уята.

Характеры, яңгырашы белән «Тормыш җыры» «Миңлекамал»дан нык аерыла. «Миңлекамал» җитди һәм кырыс буяулар белән язылган булса, бусында якты төсләр, романтик буяулар өстенлек итә. Беренче драмада колхоз тормышындагы авырлыкларга һәм кыенлыкларга басым ясалса, «Тормыш җыры» мәхәббәткә дан җырлый, саф мәхәббәтне, мәхәббәткә тугрылыкны романтик биеклеккә күтәрә. Тормыш сугыштагы ирен көтүче хатыннардан, тылдагы хатынын сагынучы солдатлардан торган ул чор өчен һәм бер ул чор өчен генә дә түгел, бу мәсьәләнең никадәр мөһим, никадәр актуаль булуы һәркемгә аңлашыладыр. «Тормыш җыры»ның тамашачылар арасында зур популярлык казануы үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

«Миңлекамал» һәм «Тормыш җыры»нда күтәрелгән тема-проблемаларны язучы «Саф күңел» романында тагын да үстерә, ачыклый һәм тирәнәйтә төшә. «Саф күңел» безнең прозада зур мәсьәләләргә багышланган, зур иҗтимагый конфликтларга корылган романнар күбәйгән, чорның актуаль мәсьәләләрен күтәргән повестьлар активлашкан елларда, татар совет проза әдәбияты бик бай чорда, бер-бер артлы кызыклы әсәрләр чыгып торганда дөнья күрә. Шуңадыр, ахры, ул тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк кала.

Дөрес, әдәби тәнкыйть әсәрне бөтенләй күрми узды, дип булмый. Аерым мәкаләләрдә һәм рецензияләрдә романның көчле яклары да, кимчелекләре дә беркадәр ачыла. Тәнкыйтьчеләр, мәсәлән, авторның эпик хикәяләү остасы булуын, әсәрдәге төп геройның шактый уңышлы һәм тулы эшләнгәнлеген билгеләп үтәләр. Шуның белән бергә, роман артык озынга сузылган һәм таркау чыккан, диләр. Фронт тормышы, сугыш эпизодлары ясалмарак һәм төссез тоела, диләр. Нигездә бу фикерләрнең күбесе белән килешергә мөмкин.

Шулай да, соңгы басмасын укып чыккач, «Саф күңел»нең җитдирәк игътибарга һәм югарырак бәягә лаек әсәр булуына ышанасың. Иң элек ул гаять киң колачлы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Бер мәктәп, бер укытучы гаиләсенең тормышын сурәтләүдән башланып киткән роман бүлектән-бүлеккә гел киңәя, тармаклана бара. Язучы мәктәп тормышыннан шәһәр тормышына күчә, аннан республика һәм бөтен ил тормышын иңли. Әсәргә берөзлексез яңа геройлар, яңа вакыйгалар өстәлеп тора. Тора-бара «Саф күңел» Бөек Ватан сугышы елларындагы тормышның барлык якларын иңләгән монументаль әсәргә әйләнә. Романда истә кала торган образлар күп. Бүлек саен диярлек без анда оста сурәтләнгән эпизодлар белән очрашабыз. Язучы, җитәкче

һәм массаларның үзара мөнәсәбәте, җитәкченең мораль һәм күңел сафлыгы кебек, актуальлеген беркайчан да җуймый торган зур проблемалар күтәрә.

Ахыр чиктә, «Саф күңел» — безнең әдәбияттагы иң калын роман. Сәнгатьчә көче ягыннан дип әйтмим, ә менә күтәргән мәсьәләләренең күплеге һәм зурлыгы ягыннан, киң колачлы булуы ягыннан аны бары бер генә әсәр — «Сугыш һәм тынычлык» романы белән генә янәшә куеп була. Мин моны күзгә төтен җибәрү яки укучыны шаккаттыру өчен генә әйтмим. «Саф күңел»не язганда, Лев Толстой әсәре авторга бөек өлгө булып хезмәт иткән. Мирсәй Әмир «Сугыш һәм тынычлык» колачындагы, «Сугыш һәм тынычлык» кебек яңгырарлык роман язарга омтылган. «Саф күңел» романы үзе шундый фикергә этәрә. Игътибар белән укысагыз, сизми калмассыз...

Мирсәй Әмирнең беренче әсәрләре табигый, тормышчан юмор белән сугарылган диган идек. Иҗат юлын көлке хикәяләрдән башлаган язучыбыз, «Балыкчы ялганнары»н һәм «Мыжык карт язмалары»н чыгарып, соңгы елларда бу өлкәдә тагын бер ут уйнатып алды.

«Балыкчы ялганнары» — ифрат кызыклы һәм үзенчәлекле әсәр, әдәбиятыбызны баета, аның жанр чикләрен киңәйтә торган әсәр. Повестьта кызыклы ситуацияләр, көлкеле хәлләр күп. Анда бер тын алуда укыла торган, бөтен дөньяңны оныттыра торган бүлекчәләр бар: «Такыр башлы кеше», «Мөхәммәтша», «Иртәгә балыкка чыгасы көннең киче», «Иртәгә балыкка чыгасы кичнең төне», «Чистай сәгате һәм Тула самавары», «Хәтер төзәтү тарихы...» Нихәтле шаянлык, күпме мәгънә аларда!

Әсәрдә көлә һәм көлдерә белә торган мәзәкчел кешеләр байтак. Үтә заманча киенеп йөрергә ярата торган Латыйп карт үзе генә ни тора! Повестьның иң матур, иң шаян урыннары шул карт белән бәйләнгән.

Хәтердә калырлык, кызыклы образларның тагы берсе — «пошляк» Мөхәммәтша. Латыйп карт кебек үк, ул да ифрат кызыклы һәм колоритлы шәхес. Билгеле, әсәрдәге кызыклы образлар болар белән генә чикләнми. Оптимист Мәхмүтне алыгыз, аның янына ата балыкчы Таҗины китереп куегыз. Андрюшкиннарны, башка образларны искә төшерегез. Шулай да Мөхәммәтша белән Латыйп картка җиткәне юк. Әсәрнең уңышын нигездә шул ике образ билгели.

Кыска бер мәкаләдә М. Әмир кебек үз мәктәбе, үз шәкертләре булган язучының иҗатына тулы һәм төпле бәя бирү, ярты гасыр вакыт дәвамында язган барлык әсәрләренә туктапу мөмкин түгел. Телисеңме-юкмы, иҗат юлының төп этапларына туктапып, әдипнең иң характерлы әсәрләрен санап чыгу белән чикләнергә туры килде. Без әле аның балалар өчен язган әсәрләрен, әдәби тәнкыйть хезмәтләрен, җәмәгать эшләрен телгә дә алмадык. Алар үзләре мөстәкыйль хезмәт язуны сорый. Аның барлык әсәрләренә хас уртак яклар, М. Әмирнең аерым әсәрләрен үзара якынайта торган сыйфатлар хакында да язып тормыйбыз.

Ләкин, кабатлап булса да, бер фикергә басым ясыйсы килә: Мирсәй Әмир — гомер-гомергә заман, чор сулышын тоеп яшәгән, ил һәм халык ихтыяҗларын тоеп яшәгән әдип, аннан да бигрәк ил, халык ихтыяҗларын тоеп **иҗат иткән** әдип. Менә шуңа күрә дә колхозлашу хәрәкәте көчәеп кенә килгән бер чорда ул «Безнең авыл кешесе»н, Ватан сугышы елларында «Миңлекамал»ны, партиянең XX съездыннан соң «Хөррият»не яза. Чор, заман ихтыяҗларына сизгер булу — язучы иҗатының иң характерлы һәм иң матур сыйфаты, аның иҗатының зурлыгын билгели торган сыйфат.

Аннан соң, әдипнең барлык күренекле әсәрләре тормышның кайнар вакыйгалары эзеннән, нәкъ үз вакытында, нәкъ кирәк чагында языла. Игътибар итегез: «Безнең авыл кешесе» 1933 елда, «Агыйдел» 1935 елда, «Миңлекамал» 1944 елда басылып чыга. Бу да — бик гыйбрәтле хәл. Чын сәнгать әсәре язу өчен, тормыш вакыйгаларының утырып, эзгә төшеп беткәнен көтеп яту, «дистанция» саклау мәҗбүри түгел икән. Мирсәй Әмирнең иҗат практикасы тагын шул хакта сөйли.

Өлкән яшьтә булуына карамастан, Мирсәй Әмир бүген дә тулы канлы иҗат тормышы белән яши. Матбугатта әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре белән катнаша. «Казан утлары» журналының редколлегия члены буларак, каләмдәш дусларының һәм яшь язучыларның яңа әсәрләрен укый. һәм бер өзлексез яңа әсәрләр яза. Күренекле язучыбыз 70 яшьлек бәйрәмен «Без бәләкәй чакларда» исемле зур күләмле яңа әсәр тәмамлап каршылый.

**Ф. МИҢНУЛЛИН.**

# МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ КӨНДӘЛЕКЛӘРЕННӘН

*XIX гасыр ахырларындагы татар интеллигенциясе вәкиле Харис Фәйзуллин үз заманының укымышлылары, язучылары, артистлары белән якыннан аралашып яшәгән. Атаклы драматург Мирхәйдәр Фәйзи, тәрҗемәче Сәгыйть Фәйзуллиннар шушы нәсел кешесе, халкыбызның сөекле композиторы Җәүдәт Фәйзи — Харис аганың улы.*

*Җәүдәт Фәйзинең бертуганы РСФСР һәм ТАССРның атказанган фән эшлеклесе Мидхәт Фәйзуллин үзләренең гаиләләре турында истәлекләр яза. Укучыларыбыз игътибарына шул истәлекнең бер бүлеген тәкъдим итәбез.*

Аның турында башлап әниебездән ишеттек. Ничектер берзакыт ул Мирхәйдәр исемле шагыйрь туганыбызның Орск шәһәрендә яшәвен әйтте.

Бернечә елдан Мирхәйдәр абыйның үзе белән дә очраштык. Ул вакытта миңа әле сигез яшь кенә булганга, бу очрашу хәтердә яхшы сакланмаган. Ә менә икенче тапкыр — 1922 елның 18 сентябрендә күрешүебез бүгенгедәй күз алдымда.

Звонок тавышын ишеткәч, ишекне ачып җибәрсәм, озынча йөзле, ябык кешене күрдем. Утыз яшьләр чамасындагы бу кешенең кем икәнен белергә теләп, зур соры күзләренә карап торган арада әнием дә килеп җитте.

— Мирхәйдәр, әйдүк, түрдән уз, — дип, кунакны бүлмәгә чакырды, чишенергә кушты.

Аның өстендә куе кызыл төстәге күн пальто, башында кепка, аягында тупый борынлы ботинкалар иде. Өстен салгач, толстовкадан калды.

Әнием өстәл әзерләп йөргән арада, Мирхәйдәр абый белән якыннан танышып өлгердек. Ул җан җылымны, ягымлы кеше иде. Укуымны, киләчәк планнарымны сораштырып утырды.

Оренбургка ул Уфага узышлый туктаган икән. Юлдашлары белән шәһәр үзегеннән читтә булган кунак йортына төшүләрен белгәч, әнием аңа безнең үзебездә генә калырга кушты.

Без Мирхәйдәр абый белән икәүләп шәһәрне карап йөрдек, ә кичтәсе кичендә ул безгә «Ак калфак» пьесасын укыды. Сәхнәдәге кебек, рольләргә кереп укый иде ул. Хатын-кызларның сүзләрен әйткәндә, хәтта тавышын үзгәртеп, нечкәләп укый иде.

Мирхәйдәр Фәйзидә актерлык сәләте бар иде, ахры. Көндәлегендәге: «Орскида беренче тапкыр татар спектаклен 1911 елда «Сәйяр» труппасы куйды. Ләкин сәхнәдән беренче сүзне әйтү бәхете миңа эләкте», — дигән юллар да аның театр сәнгате белән чынлап кызыксынуын күрсәтә.

Оренбургтагы очрашудан соң без аның белән әле Уфада, әле Казанда әледәнәле күрешкәләп тордык.

Уфага ул, мәшәкатьле юл үтеп, 1922 елның 24 сентябрендә килеп җитә. Килгән көннәрендә көндәлегенә болай дип язып куя: «Кая барырга? Беркемне белмим, мине



дә беркем белми». Чынында исә ул ялгыша: биредә аның әсәрләрен белүчеләр күп була. Ул үзе дә 27 октябрьда язган хатында китап кибете яныннан үткәндә витринага куелган китаплары арасында «Галиябану»ын күрүе, кибеткә кереп, миллион сумлап акчага шушы китапны сатып алуы турында яза. Коймаларга ябыштырылган театр афишаларыннан үзенең «Тәкъдир шаяруы» дигән пьесасы куелуын белә.

Шулай да аңа Уфада яшәве кыен була, язучы авылны сагына. Ул, 1923 елның җәен Чепия районы Шода авылында үткәреп, сентябрьдә Казанга килә.

Гомеренең күп өлешен авылда яшәгән, авыл тормышын яхшы белгән драматург, Казанга килгәч, эшчеләр тормышын өйрәнергә тели: шул ният белән бер завод китапханәсенә эшкә керә. Озакламый аны шәһәр китапханәсенең балалар бүлегенә күчерәләр. Гаиләсез, баласыз Мирхәйдәр үтә бала җанлы кеше була һәм ул бөтен күңеле белән бирелеп эшкә керешә. Ят шәһәргә килеп төшкән драматургка тормышын җайлап җибәрү кыен була, әлбәттә. Беренче татар математикларыннан берсе, профессор Һарун Салиховның әтисе Сәмигулла ага Салихов һәм аның әнисе Зөһрә ханым бу көннәрдә Мирхәйдәр Фәйзигә зур ярдәм күрсәтәләр. Заманының укымышлыларыннан булган, «Бала тәрбиясе» дигән китап язган Зөһрә ханым драматургка торак урынын биреп кенә калмый, бераз материал ярдәм дә күрсәтеп тора. Шулай булса да, Мирхәйдәр, бу кунакчыл гаиләгә артык мәшәкать тудырудан уңайсызланып, «Француз» номерларына күчә. Ләкин анда да озак яши алмый — бүлмә өчен түләү бәясе артык зур була. Мирхәйдәргә эш урынында яшәргә рөхсәт итәләр һәм ул кеше аз йөри торган гарәп китаплары бүлегендә шкафлар белән үзенә бер почмак бүлеп ала. Аш-суны җыештыручы хатын әзерли. Тукай урамы белән Печән базары чатындагы Үзәк китапханә тормышын ул шулай җайлап җибәрә.

Мирхәйдәр Фәйзи көннәрдән бер көнне урамда Зыя Буби белән очраша. Шатланып күрешәләр, сөйләшәләр, Зыя аны үзләренә, Кабан буендагы Икенче фермага кунакка чакыра.

Берникадәр вакыттан соң Мирхәйдәр Бубиларга килә дә, Вахитов заводына хәтле трамвайда барып, ары таба җәяү китә. Пычрак ерып атлый торгач, «Аркадий» бакчасын, Воскресенск авылын үтә. Сагынылган авыл табигатен, печән кибәннәрен күреп шатлана һәм, шаярып, көндәлегенә: «Көзге табигатькә сокланып бардым. Килеп җиткәнче бер кадак алма белән клиндер кимереп бетердем», — дип язып куя.

Икенче ферма — ул чакта авыл хуҗалыгы техникумының уку базасы — бер-берсенә тоташтырылган өчәр катлы ике бинага урнашкан. Зыяның әтисе Гобәйдулла Буби шунда уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли, гаиләсе белән шунда, берничә бүлмәле таш йортта яши торган була. Мирхәйдәрне шатланып каршы алалар, сыйлыйлар, җиде чакрымны җәяүләп үткән кеше бит син дип шаяртып, йомшак урынга ял итәргә яткыралар.

Ул чакны мин шушы техникумда укыйм һәм, йомышым булса да, булмаса да, Гобәйдулла абзыйларга кереп йөри торган идем.

Мирхәйдәр абый белән Казанда беренче күрешүем дә Бубилар өендә булды. Миннән ул тормышым, хәлем турында сорашты. Ә мин, туганнарым булса да, өйдәгеләрдән оялып, теләр-теләмәс кенә җавап биреп утыра идем. Ул, хәлемне аңлап, мине урамга алып чыкты. Тышта җил иде, урман шаулый, караңгы төшеп килә, ләкин

яңгыры юк. Ул бик арыган иде булса кирәк, әз генә бардык та часовня янындагы эскәмиягә утырдык. Мин күңелемдәген сөйләп биргәндә ул бүлдермичә генә тыңлап торды да аталарча киңәш бирә башлады. «Кыенлыкларны җиңә белергә кирәк, юкса, үз-үзеңне хөрмәт итми башлыйсың ул»,— диде Мирхәйдәр абый. Ялгыз түгеллегемне, янымда туганнарым булуын искә төшерде. Әйбәт кенә дусларың да бардыр әле, дип әйтте. Шушы сөйләшүдән соң үземне тынычрак тота башладым.

Мирхәйдәр Фәйзи балаларны ярата дип әйткән идем. Балалар китапханәсендә ул китап биреп, китап алып кына утырмады. Еш кына балалар өчен кичәләр оештыра, кычкырып китаплар укый, «Сихерле фонарь» аша төрле темаларга диапозитивлар күрсәтә, балалар катнашы белән спектакльләр куя иде. Алар Октябрь һәм Беренче Май бәйрәмнәренә аеруча яхшы әзерләнәләр. Йомшак күңелле бу кешене балалар үзләре дә ярата, аның янына барам дип кенә торалар иде. 1923 елның 13 октябрендә Мирхәйдәр Фәйзи үз көндәлегенә: «Балалар белән җыелыш үткәрдек. Октябрь бәйрәменә кичә ясарга уйлыйбыз. Балаларга үзем турында, кайларда булуым, ниләр эшләвем турында сөйләдем. Кызыксынып тыңладылар», — дип язып куя. 16 октябрьдагы язмада: «Көн саен балалар белән репетиция үткәрәм. Бик сәләтле, әйбәт балалар бар», — дигән юлларны укырга була. 19 октябрьда: «Бүген миңа 33 яшь тулды. Күп инде. Чәчләрем коелып, чалара башласам да, үземне карт дип уйламыйм әле»,— диелә.

Егерме алтынчы октябрьда мин аның янына килдем. Мирхәйдәр аганы почмак ягындагы залда дип әйттеләр. Мин кергәндә ул ишеккә арты белән утырып балаларга нидер сөйли иде. Октябрь бәйрәменә әзерләнәләр икән. Булачак кичәнең авторы да, режиссеры да — ул үзе. Мине күргәч, сүзен бүлеп:

— Мидхәт, бер ярты сәгать кенә утырып тор инде. Булдыра алабызмы икән, карап торырсың, — диде. Ә балаларга: «Бу минем энем Мидхәт була, аннан уңайсызланмагыз. Ул безнең тамашачыбыз дип уйлагыз», — дип аңлатты. Балалар аның «Коммунага» дигән әсәрен өйрәнәләр икән.

Мирхәйдәр абый яхшы режиссер иде. Балаларны сәхнәгә чыгарга, халык алдында үзеңне ничек тотарга, кайсы сүзне нинди тавыш белән әйтергә кирәген өйрәтте. Мин спектакльдә катнашучылар арасында муеннарына кызыл бәйләгән бер малай белән кызны күргәч аптырап, соңыннан шул турыда Мирхәйдәр абыйдан сорадым. Ул миңа кызыл галстук һәм пионерлар турында сөйләде. Моннан бер ел элек пионер оешмасы төзелүен әйтте. Ул — политик оешманың беренче баскычы, аннан соң комсомоллар, коммунистлар китә, пионерлар яхшы укырга, тәртипле булырга, авырлыкларны җиңә белергә тиеш, диде. Пионер галстугы балаларның шушы оешмада торуларын белдергәнен аңлатты.

— Балаларны яратасыңмы син, Мидхәт? — дип сорады ул.

Мин аңа:

— Юк, — дип җавап бирдем.

— Балаларны яратырга, аларга ярдәм итәргә кирәк. Алар — безнең киләчәгебез. Балалар булмаса, тормыш күңелсез булыр иде, — диде ул.

Икенче килүемдә ул «Чаян» журналының 1924 елда чыккан тугызынчы санын күрсәтте. Анда өч язучыга карикатура басылган иде.



— Ничек, ошаганмы миңа? — диде ул шуларның берсенә күрсәтеп, — аңламыйм, ни өчен миңа халат киерттеләр икән? Ярый әле, Таһиров кебек итеп, сыерга атландырмаганнар, ни әйтсәң дә атта чабам.

Карикатура астына шундый сүзләр язылган иде: «Гыйльми мәркәз театр китапларына «ярыш» ясап, беренчелекне алган әсәрләргә 300 сум, икенчегә — 150 сум, өченчегә — 100 сум мәкамәт бирергә дип игълан ителгән иде. Ләкин 300 сумны алырга кызыгучы булмады. Әмири, Фәйзи, Таһиров 100 сумлык мәкамәт белән канәгатьләнделәр».

Конкурска Мирхәйдәр Фәйзи «Адашкан күңел» һәм «Кызыл йолдыз» пьесаларын биргән булган. Бүләкне ул үзе «Кызыл йолдыз» алыр дип уйлаган булса да, «Адашкан күңел» өчен биргәннәр. Икенче турда «Кызыл йолдыз» да кызыксындыру бүләге алган.

Берничә көннән соң тагын китапханәгә килдем. Мирхәйдәр абый альбомыма ике шигырь язды. «Куаныч хәбәр» дигән шигыренең астына: «Мидхәт энем! Былтыр «Яшь юксыл» газетасында басылган бу нәрсәм синең альбомыңа керергә хаклы булса кирәк. Сельхозтехникум укучылары кадәр күңелем тарафыннан ардакланган яшьләр юк. Мин аларны артыграк яратам, укуларыннан куанычлы нәтиҗәләр көтәм. Син дә монда үзеңә уңыш табарсың. 26 январь, 1924 ел, Мирхәйдәр Фәйзи».

Шигырьләрнең икенчесе беркайда да басылмаган иде, ахры. Үкенечкә каршы, аның күп юллары хәзер инде тоныкланып, танып булмаслык хәлгә килгән. Ә сакланып калган өлеше менә шундый:

### МИДХӘТКӘ ЯДКАРЬ

Гөлләр өздем,
Альбомыңа тездем...
— Каян тездең!— дисеңме!
Күңелемдән!
Уз... гөлләр... бар
Ал чәчәкләр үсә
Тегеннән...
[Аллаларның изге, ал канатлы
...белә кылган күңелдән дип
Уйлама тагы].
Кызыл йолдыздан
Күңелемә
Нурлар тегелгән...
Альбомыңны мин матурларга,
Иясенең күңелен нурларга
Яздым моны.
Кушылып...
Марксизм җырын җырларга.
Исчә
Кызыл чәчәкләрне!
Исен ярат,
Исмен тарат.

26 январь, 1924 ел, Казан.

**МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ.**

Ул кичне минем кәефем юк иде. Мирхәйдәр абый, шуны сизеп алды да, хәлемне сораша башлады. Мин тагын укудан, тормыш шартларының авырлыгыннан зарланып куйдым.

— Мирхәйдәр абый, Сез дә бит укуыгызны ташлагансыз, шулай да күренекле урын тотасыз, — дип әйттем.

— Кадерлем Мидхәт, минем сәбәпләрем башка. Сәламәтлегем әйбәт түгел иде. Аннан соң «Хөсәения» мәдрәсәсендәге уку тәртипләреннән канәгать булмадым. Укытучыларының белеме түбән, күп вакыт буш бәхәсләр белән үтә иде. Белем җитмәгәнлеген мин һәр вакыт тоеп яшим, борчылам. Шуңа күрә туктаусыз укып, белемемне арттырырга тырышам. Син бәхетле заманда укыйсың. Юләрләнүеңне ташла, егет. Миннән үрнәк алма. Һәркемнең үз юлы, җәмгыять алдында үз бурычы булырга тиеш, — диде ул миңа шул кичне.

Бу сөйләшү турында мин соңыннан да кат-кат уйладым һәм Мирхәйдәр Фәйзинең үз хәле, халкы өчен никадәр янып яшәвен торган саен ныграк аңлый бардым.

Менә аның 1923 елда язган көндәлеге. 11 ноябрьда шундый сүзләр язып куйган: «Колхозчы әлифбасы»н укыдым. Шуннан соң үземне чын колхозчы итеп сизә башладым. Хәзер мин үземне дин һәм мещанлык сөременнән бөтенләе белән азат булган чын ирекле гражданин дип саныйм. Сәламәтлегем ярыйсы булса, партиягә керүне үземә бурыч итеп куям».

Партия сафларында булу аның ихтыяҗына әйләнә, ул инде үзен күптән партиясез коммунист дип саный торган була. Партия сафларында торганда коммунистик идеалларны әсәрләрендә тирәнрәк итеп чагылдырырга мөмкин дип карый, ләкин коммунист дигән бөек исемгә лаек түгелмендер әле дип шикләнә дә.

«Мин аллага да, муллага да ышанмыйм, — дип яза ул 1924 елның 7 январенда. — Дарвин теориясенә табынам, марксизм-ленинизмга ышанам. Шулай да мин мещанлык даирәсендә тәрбия алган, хәлле крестьян гаиләсендә үскән кешемен. Вакыйгаларга политик бәя биргәндә мин бәлки вакыты белән ялгыша да торганмындыр. Әмма сыйнфый каршылыкны яхшы аңлыйм. Лаек дип тапсалар, партиягә керәм».

Мирхәйдәр Фәйзи егерменче еллардагы әдәбият һәм сәнгать вәкилләренең күпчелеге белән аралашмый, әмма Г. Ибраһимов, К. Нәҗми, Һ. Такташ, Г. Кутуйлар белән озын-озак әңгәмәләр аңа күңел байлыгы бирә. Гомумән ул оялчан кеше иде. Бервакыт шулай Ленин бакчасыннан үтеп барганда, җиңел тәгәрмәчле кул арбасында утырган Фатих Әмирханны күрә. Мирхәйдәр Фәйзинең күренекле язучы белән күрешеп, сөйләшеп аласы килә, тик янына барырга кыюлыгы җитми. Ә күрешкән булса, үзенең иҗаты турында Фатих Әмирханнан шактый файдалы сүзләр ишетер иде. Ул елларда әле, хәле бик авыр булса да, Фатих Әмирхан әдәбият белән якыннан кызыксына, иҗади эшен дә дәвам итә иде. Мәсәлән, 1923 елның 7 декабренда ул Мирхәйдәр Фәйзинең «Кызыл йолдыз» пьесасына рецензия язып, пьесаның өченче дәрәҗәдәге бүләккә лаек икәнен кире какмыйча, җитди генә бер кимчелегенә тукталаː әсәрнең төп герое Хәй яхшылык теләүче кеше генә булып сурәтләнә, актив эш күрсәтүче түгел, дигән фикерне әйтә.

1922—24 елларда Мирхәйдәр Фәйзи үз әсәрләрен М. Хәйдәр Фәйзи дигән имза белән бастыра башлый. 1927 елның көзендә әле генә басылып чыккан китабын күрдем. Китап тышында Мирхәйдәр Фәйз дип язылган иде.

— Хата җибәргәннәр бит, — дидем мин авторга.

— Бернинди хата юк, хәзер мин үземне шулай дип йөртәчәкмен.

— Ә ни өчен?

— Фәйзиләр күбәеп китте. Санап бетерерлек түгел. Фәйз булып калыйм әле. Буталмаска әйбәт була ул.

1925 елны Мәскәүнең СССР халыклары үзәк нәшриятында басылып чыккан соңгы китабы — «Коммунага» пьесасын да ул Мирхәйдәр Фәйз исеме белән чыгарды.

...Үзенә язган некрологны беркемнең дә укып караганы юк. Ә Мирхәйдәр Фәйзи укыды. Китапханәгә килгән бер кичемдә ул миңа шундый вакыйганы сөйләде.

Бу хәл 1921 елны булган. Мирхәйдәр Фәйзи тиф белән авырып саташып ята икән. Врачлар бу йогышлы каты чиргә Мирхәйдәр абыйның йөрәге түзә алмас дип уйлаганнар. Кемдер «драматург үлде» дигән хәбәр таратырга ашыккан. «Оренбург тормышы» газетасында некролог басылып чыга. Хәле яхшыра төшкәч, соңгы хәбәрләр белән танышырга теләгән Мирхәйдәр Фәйзигә газета-журналлар китергәннәр.

Шунда ул үзенә язылган әлеге некрологны күрә. Башта күзләренә ышанмый, кат-кат укып карый, төшем түгелме бу дип, тәннәрен чеметә, палатага кергән хатыннан: «Апа, мин исәнме, әллә үлдемме?» дип сорый. Ә хатын, бу бичара тагын саташа башлады дип уйлап, аның башына сулы чүпрәк куя. Мирхәйдәр, кулларын сорткәч: «Әнә мине газетада үлгән дип язалар», — ди.

Ә соңыннан көндәлегенә: «Мине беләләр икән әле, иҗатыма әһәмият бирәләр икән», — дип язып куя.

Ул чактагы тормыш җайсызлыклары Мирхәйдәрнең сәламәтлеген нык какшата. 1924 елның языннан ул үзен бик начар сизә, врачларга еш күренә башлый. Аңа авылда яшәргә киңәш бирәләр. Мирхәйдәр авылга китәргә җыена, эшләрен тапшыра, ләкин Казан белән аерылуны бик авыр кичерә. Дәфтәренә ул:

**Татарстан илләрендә**
**Татарлар арасында,**
**Баллары бар гөлләрендә.**
**Күңелемнең ярасына,**
**Җаннарыма ямь бирәдер,**
**Казан шәһәре күренеше,**
**Йөрәгемә ял буладыр,**
**Татар авылы тормышы,**

— дип рифмалы юллар язып куя. Шәһәр белән саубуллашып, соң мәртәбә урамнарны әйләнеп чыга, Ташаякка хәтле килә, ләкин беркемгә дә керми, китәсен берәүгә дә әйтми.

Унынчы июнь иртәсендә ул шәһәрдән чыгып китә. «Ике кулым, дүрт кисәк багажым да авыру йөрәгем бар — ничек барып җитәрмен... кесәм такыр булса да «Раскольников» теплоходының III классына билет алдым», — дип яза ул.

Юлда сөйләшеп барырлык кешеләр очрамый. Аның янына спекулянтлар утырган була. Язучы палубага чыга һәм шунда тәбәнәк буйлы, нык бәдәнле яшь егетнең дә пароходка утыруына игътибар итә.

Менә пароход кузгалып китә. Палубага баскан Мирхәйдәр Казанның һәм, шуның белән бергә, бу борынгы шәһәргә бәйле хыялларының да әкрен-әкрен чигенә баруын күзәтә. Казанда ул иҗат планнарының барын да тормышка ашырып бетерә алмады шул.

«Хуш, Казан. Үзем китсәм дә, йөрәгем калды. Бүләгем булсын ул сиңа. Әлегә хәтле мин бары тик алга таба гына атладым. Сине ташлап китәргә мәҗбүр булуым — артка таба бер адымым ул», — дип яза Мирхәйдәр.

Йөрәктә нидер таш булып ята, күңелдә моңсулык, янда уйларын бүлешер кеше юк... Иркен Идел ярларына тагын бер әйләнеп кайтырмы әле ул, Казан урамнарын таптап йөри алырмы?

Шулай күңелсезләнеп барганда, бер-ике кеше аша гына басып торган әлеге егетне күрә. Ул да уйланып кына шәһәр силуэтына карап тора икән. Мирхәйдәр аның янына килә, сөйләшеп китәләр, танышалар. Берсенең драматург Мирхәйдәр Фәйзи, икенчесенең шагыйрь Муса Җәлил икәнен белгәч шатланышалар. Икесенең дә Оренбургка барышы икән. Муса өлкән каләмдәше белән барырга туры килүенә чын күңелдән шатлана.

Бу ике язучы Оренбургка кадәр ниләр турында гына сөйләшеп бармаганнардыр?! Үкенечкә каршы, Мусага багышланган берничә юлдан соң көндәлектәге язулар өзелә...

1924 елның 7 сентябрендә, бик күңелсезләнгән бер вакытында, Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләренең кайберләрен юкка чыгара. Бер дәфтәренә: «Бүген күп язмаларымны яндырдым, җырларымны Абдулла Палатовка бирдем — әйдә, гармунда уйнап, минем җырларымны җырласын», — дип язып куя.

Яндырылган биш дәфтәр белән бергә Казаннан Орскига барган вакыттагы тәэсоратлары, шул җөмләдән, Муса белән әңгәмәләре дә эзсез югала. Ләкин аларның беренче һәм соңгы очрашулары булмый ул.

Казаннан киткәч, Мирхәйдәр Фәйзи Тубинский рудникта китапханәче булып эшли, аннан соң Баймакка килә. 1925—26 елларда Орскида да еш була. Ул елларда Муса Җәлил комсомолның Орск өяз комитеты инструкторы булып эшли, Мирхәйдәрнең туганы Хәдичә Фәйзуллинада фатирда тора. Хәдичә апаның кызы Сөмбел Фәйзуллинаның әйтүенә караганда, Мирхәйдәр Фәйзи аларда еш булган, Муса белән күп очрашкан.

1926 елны драматург Казанга тагын бер тапкыр килә. Сентябрь башларында Мәскәүгә барышлый Казанның «Гранд Отель» (хәзерге Качалов исемендәге театрның актерлар тулай торагы) гостиницасына тукталган Мирхәйдәр янына күп кеше килә. Барыннан да ешрак Гадел Кутуй, Гомәр Бәширов, Җәүдәт Фәйзи кереп йөри.

Ул вакытны Фәйзинең кәефе яхшы була, дусларын ачык йөз белән каршы ала, озаклап сөйләшеп утыралар. Соңыннан Кутуй турында ул: «Мин аны аерата якын итәм», — дип язып куя. Мирхәйдәр Фәйзи янына берничә мәртәбә Мансур Мозаффаров керә. Казанда яшәгән чагында Мирхәйдәр нотага салу өчен үзенең ун җырын Мансур Мозаффаровка биргән булган икән. Композитор шуларны китерә килгән.

Җиденче сентябрьдә Мирхәйдәр Фәйзи Казаннан китә. Көннәре тыгыз һәм мәшәкатьле үтсә дә, бу аерылу аңа кыен була. Чөнки ул биредә күп дусларын очрата, күп эшләрен башкара, китапханә өчен китаплар ала. Каләмдәш дусларыннан Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов, Сәгыйть Фәйзи, Кави Нәҗми белән дә күрешеп сөйләшә.

...Мәскәүдә ул егерме көнләп тора. Баймак китапханәсе өчен китаплар җыйный. Тагын какшап киткән сәламәтлегенә өстенә сукыр эчәк авыруы кузгала, аны больницага салалар, хәле яхшыра башлагач, янына 60 кеше килүе, шуларның 32 се рус, 28 татар һәм башкорт дуслары булуы турында яза. Эшчән һәм тыйнак драматургның шул кадәр күп дуслары булу бер дә гаҗәп түгел. 37 яшьлек кыска гына гомерендә ул 16 пьеса, берничә хикәя, 200 гә якын шигырь язып өлгерә, рус теленнән 7 пьесаны татарчалаштыра, күп кенә фольклор материаллары җыя. Боларның барысын да халык карый, укый һәм җырлый.

# ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТ ҺӘМ ЦЕНЗУРА

1905-1907 елгы Беренче рус революциясе тәэсирендә барлыкка килгән вакытлы татар матбугаты үзенең беренче адымнарыннан ук полиция һәм цензураның өзлексез эзәрлекләвенә юлыга. Дөрес, революциянең яңа күтәрелешеннән курыккан патша хөкүмәте, хәлиткеч көрәштә вакыт оту нияте белән, халыкка ташламалар да ясарга мәҗбүр була. Ул ялган вәгъдәләр белән тулы 17 октябрь манифестын игълан итә. Әмма царизмның матбугат ирекe хакындагы вәгъдәләре кәгазьдә генә кала. Демократик матбугат органнарына каршы көрәш милли окраиналарда аеруча кискен төс ала.

Демократик татар матбугатының көннән-көн киңрәк колач ала баруын күздә тотып, җирле властьлар 1906 елда матбугат эшләре буенча Казанда вакытлы комитет төзү хәстәренә керешәләр. Бу комитет 1907 елның 1 гыйнвареннан үзенең эшчәнлеген җәелдереп җибәрә[1]. Вакытлы татар матбугатын күзәтү һәм аның юнәлеше турында Эчке эшләр министрына ай саен отчет биреп бару комитетның төп бурычларыннан берсе була. Моннан тыш, ул татар газеталарының һәр санын 6 данәдә Петербургка җибәреп тора. «Казан цензура комитеты,— дип яза Р. Нәфиков,— патша хөкүмәте кушкан эшләрне пөхтә итеп үтәүче, еш кына инициативалы һәм оператив рәвештә эш итүче орган була»[2].

Революция дулкыннары чигенә башлагач, царизм татар матбугатына каршы көрәшне тагын да көчәйтә төшә. Бу хәл татар интеллигенциясенең алдынгы вәкилләре арасында тирән ризасызлык уята. «Агызны ничә сантиметр кадәр ачып сөйләргә «сүз иркенчелеге» бирелгән, шул кадәр итеп сөйли бирәмез»[3],— дип яза, әлеге мәсьәләгә тукталып, «Азат» газетасы.

Билгеле ки, «Азат»ның рәсми нашире һәм мөхәррире Казан мулласы Габдулла Апанаев була. Ләкин газета редакциясендә, Апанаев һәм аның үзе кебек либераль журналистлар белән бергә, демократик рухтагы интеллигенция вәкилләре дә эшли. Алар арасында өзлексез көрәш бара[4]. Демократик лагерьны Г. Камал белән Г. Коләхметов җитәкли, алар үз тирәләренә М. Гафури, Н. Думавый, М. Укмасый кебек прогрессив язучыларны тарталар. «Азат» газетасының демократик юнәлеше шул әдипләрнең эшчәнлегенә бәйле.

Цензура йодрыгын да башлап нәкъ менә «Азат» газетасына татырга туры килә. Газетаның 9 нчы санында басылган хәбәрләрнең берничәсен цензура эчтәлекләре ягыннан «хөкүмәткә каршы» юнәлдерелгән дип таба. Ул хәбәрләрнең беренчесендә сүз Саратов губернасы крестьяннарының чуалышын рәхимсез рәвештә бастырган генерал-лейтенант Сахаровның үтерелүе хакында бара. Икенчесендә Казан полицмейстерының коралсыз халыкның демонстрациясен кан белән бастырырга хәзерләнүе турында языла. Казан округ суды прокуроры суд палатасы прокурорыннан «Азат» газетасына каршы кичекмәстән кискен чара күрүен таләп итә. Эш юстиция министрына кадәр барып җитә. «Азат»ның 10 нчы санында «сизгер» чиновникларның дикъ-

---

[1] А. Г. Каримуллин. Татарская книга начала XX века. Рус телендә, Казан, 1974 ел. 206 бит.
[2] Р. И. Нафигов. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли. Рус телендә, Казан, 1964 ел, 60—61 битләр.
[3] «Азат» газетасы, 1906 ел, 19 февраль.
[4] М. Гайнуллин. Татарская литература и публицистика начала XX века. Рус телендә, Казан, 1966 ел, 39 бит.

катен җәлеп итәрлек тагын бер мәкалә басыла. «Гаепсез сүзләр» бүлегендә газета крестьяннарның помещик җирләрен көч белән тартып алырга җыенулары хакында хәбәр итә. Казан цензоры бу хәбәрне яшәп килгән дәүләт строен бәреп төшерергә өндәү дип бәяли һәм редакцияне яңадан суд җаваплылыгына тарту турында эш кузгата[1]. «Азат»ның 11 нче саныннан соң цензура газетаны бөтенләй туктатуны таләп итә. Суд карары чыгып өлгермәүдән файдаланып, Г. Камал белән Г. Коләхметов аның 12 нче санын да бастыралар. Мондый «башбаштаклык» патша администрациясенең күпме генә «җенен» чыгармасын, революция шартларында цензура газетаның 10 нчы санын конфискацияләү һәм «Азат»ның чыгуын бер атна чамасы туктатып тору белән чикләнергә мәҗбүр була[2].

1906 елның 5 маенда «Азат»ның 44 нче санына тагын арест салына. Габдулла Апанаевка бу җитә кала. Цензура эзәрлекләвеннән куркып калган редактор газета битләрендә актуаль политик мәкаләләр бастыруга төрле чаралар белән каршы килә башлый[3]. Ләкин редакция хезмәткәрләренең Г. Камал җитәкчелегендәге демократик өлеше үз позициясендә нык тора. Газета редакциясендәге либераль буржуаз һәм демократик көчләрнең үзара көрәше анда басылган материалларның эчтәлегендә дә чагылмый калмый, әлбәттә. Җирле властьлар белән яңа низаглар килеп чыгудан шүрләгән Апанаев 30 майда «Азат»ны яба...

Казан большевикларының көчле йогынтысында чыккан «Азат халык» газетасының гомере тагын да кыскарак була. Аның нибары 15 саны чыгып кала. Нашире һәм мөхәррире Г. Камал булган бу газетада социал-демократик характердагы күп кенә мәкаләләр, хәтта партия съезды материаллары басылып килә. Шуңа күрә «Азат халык»ның җирле властьлар, аерым алганда, Казан цензура комитеты белән мөнәсәбәтләре аеруча киеренке була. Газетаның аерым саннары, цензура тыкшынуы аркасында, берничә көн буе таратылмый тора. «Азат халык» битләрендә басылган социал-демократик рухтагы мәкаләләрне даими рәвештә күзәтеп барган цензорлар, аның 15 нче санында царизмның золымы һәм милли культураларны кысрыклавы хакында мәкалә басылгач, ныклап «эшкә» керешәләр. Уңай очрак чыгудан файдаланып, цензура самодержавиегә каршы тавыш күтәрергә җөрьәт иткән газетаны ябу чараларын күрә: 15 нче сан шунда ук конфискацияләнә, Г. Камал суд җаваплылыгына тартыла — бер айга гражданская гауптвахтага ябарга хөкем ителә[4]. Г. Камал югары суд органнарына апелляция бирә һәм адвокат ярдәмендә суд карарын үзгәртүгә ирешә. Бер айлык төрмә урынына аңа 100 сум күләмендә штраф салына[5]. «Азат халык» яшәүдән туктый.

Татар социалист-революционерлары органы булган «Таң йолдызы» газетасы да каты эзәрлекләүләргә дучар ителә. Газета битләрендә эсерларның лидерлары шактый актив басылса да, аның рухи җитәкчесе Сәгыйть Рәмиев була. 10 нчы саннан алып соңгы 65 нче санына кадәр ул «Таң йолдызы»ның җаваплы редакторы вазифасын үти. Нәкъ шул чорда редакциянең цензура органнары белән мөнәсәбәте көннән-көн кискенләшә бара. 17 октябрь манифестының чын асылын үз җилкәсендә башлап шушы газета татый дияргә була. «Шул хөррияте матбугат хакында, — дип яза «Таң йолдызы», — гәзитәмез әллә никадәр үзенең төсен югалтты... кызыл төсе әллә никадәр уңды»[6]. Ул үз укучыларын «тагы бер мәртәбә юл араларыннан чынлабрак укырга, чынлабрак уйларга чакыра»[7]. Кыска гына вакыт эчендә газетаның 15, 25 һәм 62 нче саннарына арест салына, редактор Сәгыйть Рәмиев берничә мәртәбә суд җаваплылыгына тартыла. Аңа күпмедер вакыт Казан төрмәсенең бер кешелек камерасында утырып чыгарга туры килә[8]. «Таң йолдызы»нда басылган материаллардан коты очкан губернатор, ахыр килеп, газета басыла торган Ермолаева типографиясен ябарга мәҗбүр була. Газетаның язмышы шуның белән хәл ителә. Ләкин реакция елларында, жандарм идарәсенең инициативасы белән, соңга калып булса да, «Таң йолдызы»ның 1, 4, 5, 7, 8, 12, 13, 16, 22, 23, 25, 28, 47, 49, 50, 51, 59 һәм 62 нче саннарына да яңа-

---

[1] ЦГИА СССР, 1405 фонд, 530 тасвирлама, 320 эш, 42 бит.
[2] «Азат», 1906 ел, 18 март.
[3] М. Гайнуллин. Күрсәтелгән хезмәт, 39 бит.
[4] Г. Камал. Альбом. Казан, 1941 ел, 9—10 битләр.
[5] Шунда ук, 10 бит.
[6] «Таң йолдызы» газетасы, 1906 ел, 20 сентябрь.
[7] Шунда ук.
[8] Ш. Садретдинов. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Казан, 1973 ел, 22 бит.

дан арест салына. Газетаны уку һәм кулдан-кулга йөртү катгый рәвештә тыела. «Таң йолдызы»ның дәвамы булып чыккан «Таң мәҗмугасы» ике, «Тавыш» газетасы исә алты саны чыкканнан соң туктап калалар.

1907 елның март-апрель айларында Әстерхан шәһәрендә чыккан «Туп» журналының гомере бигрәк тә кыска була. Столыпин галиҗәнабләреннән килгән өчен, өлкәнең вице-губернаторы тарафыннан аның беренче санына ук арест салына. Әчке эшләр министрының «эче авырта» дип яза журнал, мөфти хәзрәтенең язып алып барган догасын изеп эчсә дә, аңа моның да файдасы тимәде. Шул ук санда Әстерхан ахуны Мохтар Салиховның «Казан губернасындагы ачлардан кыз сатып алырга» китүе хәбәр ителә. Бу да игътибарга алына. Әстерхан округ суды журнал редакторы Хәбибулла Гомәровка каршы эш кузгата һәм аны ике айга төрмәгә ябу, ә «Туп»ны туктату турында карар чыгара[1]. Ләкин бу карар көченә кергәнче, редакция хезмәткәрләре аның яңадан ике санын чыгарып өлгерәләр. Тиздән өлкән советник «хөкүмәткә каршы» чыгышлары һәм «дәүләт хезмәтендә торган чиновникларга тел тидергән өчен», журналның 3 нче санына яңадан арест сала. «Туп»ның гомере бөтенләйгә киселә.

II Дәүләт думасы әгъзасы, трудовик Кәлимулла Хәсәнов редакторлыгында 1907 елның апрель-май айларында Петербургта чыккан «Дума» газетасы да патша хөкүмәтенә шактый мәшәкать тудырган. Казан губернаторына җибәргән яшерен донесениедә матбугат комитеты газетаны «революцион партия» органы дип атый, «Дума» эшчеләрне стачка һәм забастовкаларга, ә крестьяннарны помещик җирләрен тартып алырга өнди, ди[2]. «Дума»ны ябарга кирәклеген искәртеп, комитет губернаторга анда басылган мәкаләләрне тәрҗемә итеп җибәрә. «Дума» газетасы Петербургның үзендә дә һәртөрле кысулардан җәфа чигә һәм еш кына билгеләнгән срокка чыгып җитә алмый[3]. II Дума таратылганнан соң күп тә үтми, бу газета яшәүдән бөтенләй туктый, аны Петербургның шәһәр башлыгы яптыра.

1906—1907 елларда Оренбургта чыгып килгән «Карчыга» журналының гомере шулай ук озын булмый. 1907 елның июль аенда 9 нчы саны чыгуга ул туктап кала. «Гәрчә моңарчы архивларда журналның ябылу сәбәпләрен ачыклардык документлар табылмаса да,— дип яза М. Гайнуллин,— аның үз ихтыяры белән тукталмавы ачык»[4]. «Карчыга»ның нашире һәм мөхәррире Шакир Мөхәммәдовка бик еш «жандармерия тарафыннан... салына торган» штрафлар түләргә туры килә[5].

Революция чигенүгә йөз тоткан шартларда матбугат чыгару эшен дәвам итү, редакторлык вазифасын үтәү көннән-көн кыенлаша бара. Цензура, полиция агентларының эзәрлекләвенә дин башлыкларының, сәүдәгәрләрнең корткычлыклары, аяк чалулары, яла ягулары өстәлә. Бу һөҗүмне бигрәк тә Уральскида чыккан прогрессив газета-журнал җитәкчеләренә күп татырга туры килә. «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» һәм «Уклар» исемле газета-журналларның рәсми редакторы Камил Мотыйгыйның мәсәлман динчеләренә һәм искелеккә каршы көрәше карагруһчыларда тирән ачу уята. Мотыйгыйның үзенә һәм гаиләсенә кыйнау белән янаулар әледән-әле кабатланып тора. Типографиягә берничә мәртәбә һөҗүм оештырыла. Шундый һөҗүмнәрнең берсе турында Г. Тукай үзенең «Погром» дигән мәкаләсендә язып чыга[6]. Үзләренең мәкерле планнарын тулысынча тормышка ашыра алмаган карагруһчылар «дини хисләрне мәсхәрәләгән», хатын-кызлар хокукын яклаган, реакционерларны фаш иткән һәм башка шундый «җинаятьләре» өчен К. Мотыйгыйны берничә тапкыр суд хөкеменә тарталар. Шундый «мәсхәрәләнгәннәрнең» берсе — танылган карагруһчы, Казан сәүдәгәре Әхмәтҗан Сәйдәшев була. Аны «Фикер» битләрендә «Казанда бөлгән Әхмәтҗан бабай кыйссасы» исемле имзасыз басылган мәкалә[7] чыгырыннан чыгара. Сәйдәшев белән Мотыйгыйның ярты елга сузылган «мөнәсәбәт ачыклашулары» «Бәянелхак» белән «Фикер» газеталары битләренә дә күчә. 1907 елның февралендә «Фикер» Мотыйгыйга Казан округ судыннан повестка килүе турында хәбәр итә. Суд 12 мартка билгеләнә[8]. Г. Тукай шушы авыр көннәрдә Мотыйгыйга ярдәмгә килә:

---

[1] «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 6 сан, 151 бит.
[2] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 420 фонд, 1 тасвирлама, 90 эш, 44 бит.
[3] «Дума» газетасы, 1907 ел, 1 май.
[4] М. Гайнуллин. Татарская литература и публицистика начала XX века, 75—76 битләр.
[5] «Совет әдәбияты» журналы, 1965 ел, 5 сан, 151 бит.
[6] «Фикер» газетасы, 1906 ел, 10 июль.
[7] «Фикер» газетасы, 1906 ел, 3 июль.
[8] «Фикер» газетасы, 1907 ел, 18 февраль.

Һәр заман хакны сәвәннәр сез кеби мәкъһур улыр,
Кустәрер бер көн кәлер дә милләтең миһре саңа...

Дугры сөйлә, дугры яз, хәвеф итмә һичбер кемсәдән,
Сабир ул, чын дәшмәмештер эшләрең сәһле саңа [1].

1907 елның 22 февралендә җирле властьлар тарафыннан К. Мотыйгыйның наширлек һәм мөхәррирлек хокуклары алына [2]. Ә 24 февральдә Уральск өлкәсенең хәрби губернаторы «Фикер», «Әлгасрел-җәдит» һәм «Уклар» газета-журналларын бай сәүдәгәр Гобәйдуллин карамагына тапшыра. Ләкин яңа хуҗа тиздән «Фикер» һәм «Әлгасрел-җәдит»не үзе яба. Ә «Уклар» инде 1906 елның ноябренда ук чыгудан туктаган була.

1907 нче елның октябреннан, бу өч органның дәвамы сымак булып, «Яңа тормыш» газетасы чыга башлый. Ләкин ул беренче адымнарыннан ук цензура эзәрлекләвенә очрый. Аның икенче санында басылган «хөкүмәткә каршы юнәлештәге» мәкаләсе өчен редактор Мөхәммәтгали Мусинга 250 сум штраф салына. 20 нче санда «Инсаннар тормышы» дигән мәкалә урнаштырган өчен, Мусинга 300 сум штраф түләргә туры килә. Ул да түгел, редакторга 2 айлык төрмә яный. Уральск өлкәсенең хәрби губернаторы, газета «мондый мәкаләләре белән бер катлау кешеләрен (ярлыларны) икенче катлау кешеләренә (байларга) каршы куеп кына калмый, бәлки хөкүмәткә каршы да дошманлык тәрбияли», дип күрсәтә [3]. Губернаторның бу ишарәсе газетаны ябуга сигнал була. 1908 елның мартында «Яңа тормыш» чыгудан туктый.

Китерелгән фактлардан күренгәнчә, татар демократик вакытлы матбугатының тууы, аякка басуы һәм үсүе туктаусыз полиция һәм цензура эзәрлекләве шартларында барган. Хөкүмәт органнары демократик матбугатның һәр адымын туктаусыз күзәтәләр һәм, газета-журналлар цензура рамкаларыннан аз гына читкә тайпылса да, редакторларга кичекмәстән каты җәза бирергә ашыгалар. Революция чигенүгә барган чорда һәм реакция елларында цензура аеруча нык котырына. Ул наширләр һәм мөхәррирләрне, демократик журналларны туктаусыз эзәрлекли. Цензураның демократик матбугатка, аның сотрудникларына ябырылуы нәтиҗәсендә газета-журнал битләрендә көн кадагына суга торган әһәмиятле материаллар басылмый кала. Азатлык идеяләрен буу өчен, патша администрациясе һәм цензура кулга алулар үткәрә, конфискацияләү кулланыла, газета-журналларның таралуын тоткарлый, типографияләрне яба, мөхәррирләрне суд хөкеменә тарта, аларны сак астына ала һәм штрафлар сала. Мондый адымнарга барганда җирле властьлар Петербургның цензура органнары белән киңәшеп, алардан күрсәтмәләр алып эш итәләр һәм үзләре күргән чаралары турында хәтта Эчке эшләр министрлына мәгълүмат биреп баралар. Әлеге чаралар матбугат аша алдынгы идеяләрне пропагандалауны нык тоткарлый. Матбугат битләренә чыкканчы ук революцион характердагы материалларны цензор кайчысы һәлак итә. Ак баганалар, күп нокталар, тәмамланмаган фикерләр, имзасыз басылган мәкаләләр — полиция һәм цензура эзәрлекләвенең ачык мисаллары. Бер генә демократик матбугат та жандарм һәм суд органнарының катнашыннан башка ябылмый диярлек. Беренче рус революциясе елларында дөньяга килгән демократик татар матбугаты фактта рәсми властьлар тарафыннан буыла.

Ләкин барлык киртәләр һәм тоткарлыкларга карамастан, вакытлы матбугат тараткан демократик һәм социалистик идеяләр акрынлап кешеләрнең зиһененә үтеп керә, татар халкының аңына революцион йогынты ясый. Хәтта киң күләмле җәза ысуллары белән дә самодержавие изелгән милләтнең ирек сөючән омтылышларын буа алмый. Чөнки халыкның азатлыкка, мәдәниятка, прогресска, белемгә омтылышы искиткеч көчле була. Татар телендәге газета һәм журналлар хәтта иң ерак авылларга һәм караңгы почмакларга үтеп керәләр. Алар татар халкының рухи азыгына әйләнә, аны демократик ирек, якты киләчәк өчен көрәшкә рухландыра. Үзенең массалар арасында алдынгы идеяләр таратуы, аларны царизмга каршы көрәшкә өндәгән фидакарь эшчәнлеге белән демократик татар матбугаты татар халкының гына түгел, бәлки бөтен төрки халыкларның тормышында якты эз калдыра.

**Равил ӘМИРХАНОВ.**

[1] «Әлгасрел-җәдит», 1906 ел, 8 сан.
[2] «Фикер», 1907 ел, 22 февраль.
[3] ЦГИА СССР, 776 фонд, 21 тасвирлама, 11 бүлек, 270 эш, 7 бит.

# МӨСЕЛМАН СОЦИАЛИСТЛАР КОМИТЕТЫ ҺӘМ БУРЖУАЗ ТАРИХЧЫЛАР

1917 елның апрелендә Мулланур Вахитов инициативасы белән Мөселман социалистлар комитеты төзелә. Идел буе һәм Урал тирәләрендә социалистик революциянең җиңеп чыгуында, татар хезмәт ияләрен буржуаз милләтчеләр йогынтысыннан арындыруда бу комитетның роле гаять зур. Башлыча Мөселман социалистлар комитеты эшчәнлеге нәтиҗәсендә татар хезмәт ияләренең күп өлеше 1917 елның көзендә социалистик революция байрагы астына баса.

Мөселман социалистлар комитетының эшчәнлеге И. Рәхмәтуллин, Л. Рубинштейн, Е. Медведев, А. Григорьев, М. Булатов, А. Тарасов, М. Мөхәррәмов, Р. Нәфиков, Г. Сәйфуллин, И. Ионенко, И. Таһиров, Р. Вәлиев һәм башка галимнәрнең хезмәтләрендә шактый киң яктыртылган. Мөселман социалистлар комитетына багышланган беренче хезмәтләр егерменче еллар башында ук языла. Аларда Мөселман социалистлар комитетының һәм Мулланур Вахитовның 1917 елда эшчәнлегенә карата төрле, урыны белән капма-каршы фикерләр әйтелә. Бары тик КПССның XX съездыннан соң гына тарихчылар Октябрь революциясе алдыннан халык массаларын әзерләүдә һәм мобилизацияләүдә Мөселман социалистлар комитетының ролен, аның эшчәнлегенең чын-чынлап революцион характерын күрсәтә алдылар.

Шулай да Мөселман социалистлар комитеты эшчәнлеге тулысынча ачылып беткән дип уйларга иртәрәк әле. Аның тарихының кайбер яклары тагы да төгәлрәк, тирәнрәк тикшеренүне таләп итә. Буржуаз тарихчыларның Мөселман социалистлар комитеты эшчәнлеген бозып, фальсификацияләп күрсәтергә маташуларын да истән чыгарырга ярамый.

Үзләрен советологлар дип атап йөрткән чит ил тарихчылары совет галимнәренең бу мәсьәләгә карата моңа кадәр яшәп килгән карашларының төрле булуын үз максатлары өчен файдаланалар. Алар, бер яктан, совет авторларының кайбер хезмәтләрендәге аерым өзекләргә ишарә ясаган булып, үзләренчә «объектив» икәнлекләрен расларга тырышсалар, икенче яктан, ялгыш концепцияләрне идеологик диверсия максатларына җигәләр.

Социалистик революциядә Мөселман социалистлар комитетының*ролен 1917 елда татар хезмәт ияләренең милли азатлык хәрәкәтенә бәйләп кенә аңлатырга мөмкин. Бары тик шушы хәрәкәтнең характерын һәм төп тенденцияләрен анализлау гына аның оештырылу сәбәпләрен һәм максатларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Ә буржуаз тарихчылар, бу мәсьәләнең асылын дорфа бозып, татарлар арасында милли азатлык хәрәкәтенең характерын һәм тенденцияләрен ялган бәялиләр.

Яманаты белән танылган милләтче Г. Исхакый 1917 елда татарлар арасындагы милли азатлык хәрәкәтен антагонистик каршылыклары булмаган, гомуми идеологиягә, бердәм максатка юнәлдерелгән хәрәкәт итеп күрсәтергә тырыша. Аныңча, Беренче рус революциясе чорында «төрле төркемнәргә, партияләргә таркалган» татарлар 1917 елда, янәсе, «үзләренең бердәмлеген аңлыйлар һәм берләшеп хәрәкәт итәләр...» [1].

Америка «советологы» Р. Пайпс та, милли-азатлык хәрәкәтенә «бердәм идеология» тамгасы ябыштырып, шундый ук карашны яклый.

---

[1] Г. Исхакый. Идел-Урал (рус телендә), Париж, 1933 ел, 39 бит.

Совет тарихчылары 1917 елгы милли-азатлык хәрәкәтенең төрле сыйнфый максатларны һәм интересларны чагылдырган төрле агымнар үрелмәсеннән гыйбарәт булуын күптән инде ачык күрсәттеләр. С. Мөхәммәтов белән М. Мөхәррәмов «Советская Татария» газетасында чыккан мәкаләләрендә (1957 ел, 2 ноябрь) милли хәрәкәттә өч агым — пролетар, революцион-демократик һәм буржуаз агымнар булганлыгын бик хаклы рәвештә билгеләп үтәләр.

Пролетар агым — иң революцион һәм иң эзлекле агым. Ул интернационализм һәм барлык милләт хезмәт ияләренең туганлык идеологиясенә нигезләнгән. Буржуаз агым — киресенчә, контрреволюцион агым. Аның нигезендә татар буржуазиясенең, рус буржуазиясе белән җитди конфликтка кереп тормастан, «барлык мөселманнарның бердәмлеге» кебек икейөзле фразаларга төренеп, үзенең политик позициясен ныгытырга тырышуы, хезмәт ияләрен тагын да бөлгенлеккә төшерергә омтылуы ята. Революцион-демократик агым — әлеге ике капма-каршы агымның уртасында. Ул бер яктан, милли мәсьәләне демократик нигездә хәл итәргә омтыла, икенче яктан, иҗтимагый хәле буенча урталыкта булу сәбәпле, әледән-әле икеләнә һәм аңа пролетариатның җитәкчелек итүе зарур.

Пролетариат белән буржуазия арасында халык массаларының урта катламын — крестьяннарны һәм шәһәр ярлыларын үз якларына тарту өчен көрәш бара. Һәм бу көрәш милли-азатлык хәрәкәте эчендә сыйнфый мөнәсәбәтләрнең үзеген тәшкил итә. Ул көрәшнең нәтиҗәсе объектив факторларга да, субъектив факторларга да бәйле була.

Объектив факторларга бәя биргәндә, буржуаз тарихчылар, егерменче йөз башында татарлар арасында иҗтимагый мөнәсәбәтләр социалистик революция өчен түгел, хәтта буржуаз-демократик революция өчен дә өлгереп җитмәгән, дип ышандырмакчы булалар. Көнчыгыш халыклары буенча немец «белгече» Г. Менде карашынча, имеш, Февраль буржуаз-демократик революциясе «Россиядәге барлык төрки халыклар өчен берничә дистә елга вакытыннан элек килә...»[1]

Татарларга карата бу тезис тулысы белән дөрес түгел. Билгеле булганча, XX йөз башында ук инде татар пролетариаты һәм татар буржуазиясе бер-берсенә капма-каршы сыйныфлар булып әверелә. Капитализм үсешенә бәйле рәвештә татарның сәүдә һәм промышленность буржуазиясе дә үсә. Татар эшчеләре үз интересларының һәр төрле Хөсәеновлар, Яушевлар, Акчуриннар h. б. капкорсакларның интересларына капма-каршы булуын яхшы аңлыйлар. Татарлар арасындагы сыйнфый антагонизмны чагылдырып, демократик рухтагы «Аваз» газетасы 1917 елның 22 апрель санында татар хезмәт ияләренең комсыз татар байлары өчен тир түгүләрен бик дөрес билгеләп үтә.

Татар авылларында да кискен сыйнфый каршылыклар хөкем сөрә. Революция чорындагы күп санлы документлардан күренгәнчә, крестьяннар алпавыт һәм кулак җирләрен тартып алалар, урманнарын кисәләр, утарларын яндыралар. Ул документлар татарлар арасында иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең буржуаз-демократик революция өчен генә түгел, социалистик революциягә кучу өчен дә җитлеккән булуын ачык күрсәтә.

Вак буржуа массаларының политик аңына йогынты ясаган субъектив факторларга килгәндә дә, чынбарлыктагы хәл татар буржуазиясе файдасына булмый. Эш монда, Менде раслаганча, 1917 ел алдыннан үз позицияләрен ныгыту өчен татар буржуазиясенең җитәрлек вакыты булмавында түгел. Бөтенләй киресенчә. Февраль революциясе башлану моментына татар буржуазиясенең экономик һәм политик позицияләре шактый нык иде. Әмма ул халыкны үз ягына аудару өчен көрәштә җиңеп чыга алмады. Күп санлы матбугат органнарының, руханилар пропагандасының һәм буржуаз интеллигенциянең тырышлыкларына да карамастан, төп халык массалары революцион-демократик идеяләр ягында кала.

Кайбер «советолог»лар, тарихи фактларны бозып, төрки халыклар, шул исәптән татарлар да, большевикларга тискәре карашта булды, дип ышандырырга маташалар. Француз тарихчылары А. Беннигсен белән Ш. Келькеже дә, Казан большевиклар оеш-

[1] G. v. Mende. «Der nationale Kampf der Russlandtürken. Ein Beitrag zur Nationalen Frage in der Sowjetunion». Berlin, 1936, S 125.

масында татар хезмәт ияләре вәкилләренең аз санлы булуын нигез итеп алып, шул ук фикерне алга сөрәләр.

Казан большевиклар оешмасында татарларның русларга караганда чагыштырмача азрак булуын татар хезмәт ияләренең большевикларга тискәре карашы белән түгел, ә бәлки аларның самодержавие табаны астында икеләтә изелеп яшәве белән аңлатырга кирәк. Милли һәм социаль изү, һичшиксез, татар хезмәт ияләренең политик һәм культура дәрәҗәсенә йогынты ясамый калмады. Ләкин, шуңа да карамастан, татар хезмәт ияләре, рус иптәшләре булышлыгында, марксизмның асылына төшенәләр һәм большевиклар партиясе сафларына киләләр. Партиягә беренче чиратта Казандагы зур заводлардан Алафузов, Крестовников, Казна заводлары эшчеләре керә. 1917 елның язында Алафузов заводында, мәсәлән, 47 коммунистның 13е татар була [1].

Бу чорда Мөселман социалистлар комитеты хезмәт ияләре арасында революцион идеяләрне таратуда гаять зур роль уйный. Хезмәт ияләре массалары өчен көрәш интереслары пролетар һәм революцион-демократик карашлы кешеләрне бер оешмага берләштерү бурычын алга куя.

Мөселман социалистлар комитетының 1917 елның 21 апрелендә кабул ителгән уставында социализмны үзенең идеалы итеп санаучы барлык гражданнарның комитетка член итеп кабул ителүе турында турыдан-туры әйтелә.

Большевикларны һәм сул социалистик агым вәкилләрен берләштергән бу оешманың политик платформасы «Кызыл байрак» газетасының 1917 елның 15 нче июнь санында игълан ителә. Ул түбәндәге таләпләрне үз эченә ала:

1) властьны Эшче, крестьян һәм солдат депутатлары советы кулына тапшыру;

2) җирне һич кичекмәстән крестьяннарга бүлеп бирү;

3) контрреволюцион учреждениеләрне — Дәүләт думасын һәм Дәүләт советын тарату;

4) патша хөкүмәтенең һәм Вакытлы буржуаз хөкүмәтнең яшерен килешүләрен матбугатта игълан итү;

5) империалистик сугышны тизрәк бетерү;

6) киләчәктә заводларны һәм фабрикаларны эшчеләр карамагына тапшыру [2].

Болар һәммәсе революцион таләпләр була, чөнки аларны тормышка ашыру җәмгыятьтә иң мөһим социаль-экономик һәм политик үзгәртүләрне алга сөрә. Бу таләпләр В. И. Ленинның «Апрель тезислары»нда һәм партиянең VII (Апрель) конференциясе карарларында күтәрелгән лозунгларның чагылышы булып тора.

Мөселман социалистлар комитеты органы булган «Кызыл байрак» газетасы, комитет каршында оештырылган эшчеләр клубы һәм социаль фәннәр курслары да үзләренең эшчәнлекләрен массаларны политик тәрбияләүгә, киң катлам хезмәт ияләре арасында марксистик-ленинчыл идеяләрне җәелдерүгә юнәлдерәләр.

Шушы фактларга да карамастан, буржуаз «советолог»лар Мөселман социалистлар комитетын... милләтчеләр интересын яклаучы оешма итеп күрсәтергә маташалар. Үзләренең тезисларын нигезләү өчен алар турыдан-туры ялганлаудан да тайчынмыйлар. Беннигсен һәм Келькеже, мәсәлән, Л. Рубинштейнның «Ленинчыл милли политика өчен көрәшкә» дигән китабыннан Мөселман социалистлар комитеты эшчәнлегендәге кайбер ялгышларны һәм кимчелекләрне күрсәткән урыннарны контексттан аерып китерәләр һәм цитаталарның мәгънәсен бозалар.

Мөселман социалистлар комитетының һәм Мулланур Вахитовның эшчәнлеге татар милләтчеләрендә көчле нәфрәт кузгата. Алар Мулланур Вахитов турында төрле гайбәтләр, ялган хәбәрләр тараталар.

Шундый сорау туа: буржуаз «советолог»лар әйткәнчә, Мулланур Вахитов милләтчелек рухындагы оешма белән җитәкчелек иткән булгач, 1918 елның августында, ак чехлар Казанны алганнан соң, татар милләтчеләре (Г. Исхакый, Ф. Туктаров, Г. Терегулов һ. б. лар) ни өчен соң аңа бертавыштан үлем карары чыгаралар? Бу сорауга җавап бер генә: Мулланур Вахитов татар буржуазиясенең һәм аның череп таркалган идеологиясенең килешмәс дошманы була.

Әлеге «советолог»ларның Мөселман социалистлар комитетын «милләтчелек мәктәбе» итеп күрсәтергә тырышулары ахыр чиктә аерым бер максатка юнәлдерелгән.

[1] Очерки истории партийной организации Татарии. 183 бит.
[2] Партия в борьбе за победу пролетарской революции. 171—172 битләр.

Алар вакытында шушы комитетның члены булган татар милләтчесе М. Солтангалиевның коммунизмга һәм Советка каршы эшчәнлеген акларга тырышмакчылар, Мөселман социалистлар комитетының Галимҗан Сәйфетдинов, Әминә Мөхетдинова, Каюм Саттаров, Якуб Чанышев, Хәсият Гайнуллин, Шәһит Әхмәдиев, Камил Якуб, Вәли Шәфигуллин, Миңнулла Вахитов, Абдулла Измайлов кебек һәм башка интернационалист членнарын милләтчеләр белән бер рәткә куймакчылар. Әмма фактлар аларның маташуларын кире кага.

Буржуаз тарихчылар Мөселман социалистлар комитетын марксизмга түгел, бәлки милләтчелеккә якын торган оешма итеп исбатлар өчен көчләрен кызганмыйлар. Янәсе, «Мөселман социалистлар комитеты большевиклар белән органик бәйләнештә булмаган, алар белән бары тик очраклы рәвештә генә контактка кергән» [1].

Билгеле булганча, Мөселман социалистлар комитетының үзендә үк большевиклар фракциясе була һәм аның членнары комитетның көндәлек эшенә актив катнашалар. Мулланур Вахитов үзе дә, аның көрәштәшләре дә большевикларның Казан комитеты җитәкчеләре белән Мөселман социалистлар комитетында да, җыелышларда һәм митингларда да даими очрашып, киңәшеп эш итәләр [2]. Шунысы да билгеле, большевиклар оешмасы җитәкчеләре (аерым алганда Я. С. Шейнкман) комитет каршындагы клубта лекцияләр укыйлар. Алай гына да түгел, Мөселман социалистлар комитеты РСДРП(б) Үзәк Комитеты белән турыдан-туры бәйләнештә була. МСК председателе Мулланур Вахитов партия Үзәк Комитеты белән даими хәбәрләшеп тора, ә «Кызыл байрак» газетасы большевистик «Правда» газетасында басылган мөһим материалларны тәрҗемә итеп бастыра. Мөселман социалистлар комитеты вәкиле, большевик А. Измайлов партиянең кораллы восстаниегә хәзерлек курсын билгеләгән VI съезды эшендә катнаша. Съезддан соң МСК, большевиклар белән берлектә, Вакытлы буржуаз хөкүмәтне бәреп төшерү өчен актив көрәшкә керешә [3].

Шулай итеп, тарихи материаллар МСК җитәкчеләре һәм большевиклар арасындагы бәйләнешнең «очраклы» булуы турындагы уйдырмаларны юкка чыгара. Нәкъ менә большевиклар белән тыгыз бәйләнештә булганга күрә дә Мөселман социалистлар комитеты үзенең эшчәнлегендә матур нәтиҗәләргә ирешә: татар хезмәт ияләренең күпчелеге буржуаз милләтчелек йогынтысыннан арына һәм Совет власте урнаштыру өчен көрәшкә актив катнаша.

Казанда Октябрь көннәрендәге күтәрелешкә татар солдатларының актив катнашуын характерлап, баш күтәргән гарнизонның штаб начальнигы Массальский: «Татарлар үзләрен менә дигән итеп тоттылар», — дип яза. Бу бәя солдатларга гына түгел, эксплуататорларга каршы кискен көрәшкә күтәрелгән эшче һәм крестьяннарга да карый.

Мөселман социалистлар комитетының, югарыда әйтелгәнчә, Идел буенда һәм Уралда Совет властен ныгыту өчен халыкны көрәшкә оештыруда роле гаять зур. Совет власте өчен иң кыен вакытта МСК большевиклар ягында була. 1918 елның мартында ул татар буржуаз милләтчеләр оештырган «Болак арты республикасы»н тар-мар итүдә мөһим роль уйный. Ә гражданнар сугышы башлангач, татар хезмәт ияләрен, кулларына корал алып, Совет дәүләтен сакларга чакыра.

**МИДХӘТ АБДУЛЛИН,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

IIIIIIIIIIIII

[1] A. Bennigsen et Ch. Quelquejay, «Les mouvements nationaux chez les musulmans de Russie. Le «Sultangalivisme» au Tatarstan». Paris, Mouton, p. 72.
[2] Р. Нәфиков. Мулланур Вахитов. Казан, 1960, 73—74 битләр.
[3] М. Вахитов. Сайланма әсәрләр. Тарих фәннәре докторы Р. Нәфиковның сүз башы, 8 бит.

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘГЕ ОБРАЗЛАРНЫҢ ПРОТОТИПЛАРЫ

Рус галимнәре аерым әсәрләрдәге әдәби образларның прототипларын өйрәнү эше белән күптән шөгыльләнеп киләләр. Һәм алар А. Пушкин, М. Лермонтов, Н. Гоголь, Л. Толстой, И. Тургенев һәм башка классикларның әсәрләрендәге бик күп образларның тормыштагы прототипларын ачыкладылар инде. Ихтимал, безгә дә Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек язучыларыбызның әсәрләрен шул юнәлештә тикшерә башларга вакыт җиткәндер. Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Яшь йөрәкләр» кебек киң полотнолы романнарында һәм «Кызыл чәчәкләр» повестенда, Ф. Әмирханның «Хәят» повестенда һәм «Тигезсезләр» драмасында, Ш. Камал новеллаларында һәм Г. Камал пьесаларында шул заман типларының бай галереясы бирелгән. Аларның үрнәкләре чынбарлыктан алынганлыгын берәү дә инкарь итә алмас кебек. Г. Ибраһимов, мәсәлән, Х. Кәримгә язган хатларының берсендә, шушы мәсьәләгә тукталып, болай ди: «Безнең көннәр»дә байтак яңа кешеләр чыгар кебек. Арада үзеңне күрсәң, гаҗәпләнмә! Ләкин шул бар, иптәш, татар тормышы, бигрәк тә яшьләр галәме тар, тәмам эшләнеп, булып җиткән характерлар юк диярлек аз»[1]. Филология фәннәре докторы М. Хәсәнов та, бу романдагы «Зариф Булатов образында Г. Ибраһимовның Х. Ямашев сыйфатларын гәүдәләндерүен аңлавы кыен түгел»[2], ди. Шулай икән, димәк, башка геройларның да прототиплары булуы бик мөмкин бит.

Бу мәкаләдә сүз Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» һәм «Безнең көннәр» әсәрләрендәге ике образның прототиплары хакында барачак. Башта «Кызыл чәчәкләр» повестендагы Фазыйл образына тукталыйк.

Фазыйл, мәгълүм булганча, катлаулы шәхес. Әгәр шулай әйтергә яраса, трагик шәхес. Әсәрнең буеннан-буена автор төп герой булган Солтанның аңа ихтирамын, соклануын белдереп бара. Повестьта күп тапкырлар Фазыйлның күркәм холкы, матур, акыллы күзләре, юаш карашы телгә алына. Солтан сыйнфый көрәш сынауларында Фазыйлның зур хаталар җибәрүенә ачына. Тора-бара алар арасында ерып чыкмаслык упкыннар хасил була...

«Фазыйл да Казанда иде. Авылда күренмәде, шунда каралып алынганмы, ничектер, Мәскәүгә барган да, лашманчыларга башлык сыман булып урынга кергән.

Үзбәкләрне, казакъларны солдатка алмыйлар икән... Шулай да... аларны бу якка хайван кебек көтү-көтү куып китерәләр икән дә, әллә нинди кара, пычрак эшкә кушалар икән, шуларга безнең укыганрак кешеләрне башлык ясап, патшага агент куялар икән.

---

[1] Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960 ел, 80 бит.
[2] М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1964 ел, 285 бит.

Безнең Фазыйл да үзенең Мәскәүдәге дуслары, байлары аркасында шунда барып сыенган, ди. Аның бу эше күңелемә бер дә, бер дә ошамады! Әллә кайдан китерелгән бичара колларны, чыбыркы тотып, кара, пычрак хезмәткә куып, шуңа башлык булып йөрү егетлекмени ул! Алай иткәнче үзең солдат бул, үзең сугышка кит тә үз язмышыңны үзең күр!

Әдрисен белсәм, берсеннән бик оста хат яздырып, бик нык шелтәлим әле Фазыйлны!

Әйтермен: без кара кеше, надан кеше, шулай булсак та бөтенләй җүләр түгел, яхшы-яманны аера беләбез, диярмен. Ул бичараларны изеп, кол кебек куып йөрергә ялланып, «лашманчы» булу — синең кебек зур укыган, тирә-якның йолдызы булган бер кешегә килешә торган эш түгел, диярмен...» [1].

Революция көннәрендә Фазыйл, аклар ягында торып, Советка каршы көрәшә. Ахырдан хатасын аңлый һәм кабат Совет ягына күчә.

Әсәрнең буеннан-буена автор Фазыйлны укымышлы кеше («тирә-якның йолдызы булган») дип әйтә бара. Ул гел яхшы киемнән йөри: «Беләгенә ак тасма таккан матур, әйбәт бер яшь офицер» (479 бит); «Күзем аның калын алтын сәгать бавына, аягындагы сары штиблетына, үтә ак якасына төште» (480 бит); «Аякта зур итек, солдат пуставыннан тегелгән галифе чалбар белән килешле френч; билдә, аркада каешлар, сары кобура, аның эченнән наган башын чыгарып карап тора» (492 бит).

Фазыйлның йөз-чыраен да Г. Ибраһимов берничә урында тасвирлап уза: «Гәүдә нык, таза күренә; элеккедән күп чыныкканга ошый. Сакал-мыекны әле дә кыра икән. Ләкин, озак юлда булудандыр, яңаклары, муеннары күгәреп, ярты каралып киләләр, иреннәр кейгән, карасуланып көеп, бераз кызу канлылык әсәре күрсәтәләр. Фазыйлда элек бу юк иде. Күзләре элекке кебек матур, акыллы тирән бер уй белән карыйлар. Күз төпләренә, маңгай урталарына таба сузылган тирән җыерчыклар, ике чигәдә ара-тирә ялтыраган ак чәчләр егетнең соңгы берничә елда күп нәрсә, бик күп җәфа кичергәнен күрсәтәләр. Чех, Колчак сабак биргән икән дип уйладым.

Күзләренә туры карадым да:

— Син дә шулай тиз картаясыңмы икәнни, Фазыйл?— дидем.

Начар махорканы китаптан ертып алган кәгазьгә төрә-төрә:

— Бардыр, Солтан, мин кичергән җәһәннәмнәр бер минутта адәмнең чәчләрен бөтенләй агартсалар да гаҗәп түгел!— диде» (493 бит).

Тышкы кыяфәте, йөз-чырае белән бик нык детальләштерелгән бу образның прототибы юкмы, булса кем? Мәгълүм булганча, прототип тормыштан әдәбиятка шул көенчә генә килеп керми, язучының иҗат фантазиясе белән баетыла, үзгәртелә. Әмма төп сыйфатлар нигезгә алына, саклана. Язучының яшьлек елларына, аның мөхитенә таба эчкәрәк кереп карыйк. Әдипнең Фазыйлга прототип булырлык берәр дусты булмаганмы? Әйтик, танышларыннан берәрсе лашманчылар армиясендә хезмәт итмәгәнме? Г. Ибраһимов тирәсендә укымышлылыгы белән Фазыйлга охшаган берәр яшьлек дусты булмаганмы?..

Башкортстанда яшәүче өлкән журналист Хәбиб Зәйнинең 1966 елда безгә язган истәлекләрендә моңа бер ачкыч бар кебек. Ул анда Златоуст белән Уфа арасындагы Дуван, Мәчетле авыллары тирәсеннән чыккан, чама белән 1885 елда туган Хәлим Искәндәрев дигән бер егетне искә ала. Х. Искәндәрев Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыган. Сабакташлары Мәҗит Гафури, Йосыф Шәркый [2], Мансур Халиковлар булган. Болар арасында М. Гафуриның авторитеты аеруча зур була. Й. Шәркый Троицк мәдрәсәсенә М. Гафуриның кайтып керүен болай искә ала: «Бер вакыт гаять иттифакый гына сукыр Гобәй Кинҗин, Хәлим Искәндәрнең үзара ниндидер «Мәҗит шәрикнең» кайтуы турында сөйләгән сүзләрен ишеттем. Ниндидер «Мәҗит шәрик» каяндыр кайткан, имеш... Ниһаять, кыш уртасы җитте. Әлеге Гобәйләр, Хәлимнәр сөйләгән Мәҗитне күрергә дә насыйп булды... Хәлим һәм Гобәй белән танышу авыр түгел, чөнки без алар белән тәмәкене бергә качып тартабыз» [3].

---

[1] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр, II том, 460—461 битләр. Алда барлык өзекләр шушы басма буенча китерелә.

[2] Й. Шәркый-Деликамов — 1910 елларда татар матбугатында басылган күп кенә педагогик мәкаләләрнең авторы. Октябрь революциясеннән соң Томскида педтехникум директоры була.

[3] Мәҗит Гафури турында замандаштары. Өфе, 1961 ел, 56 бит.

Х. Искәндәревне өлкән укытучы З. Тупиев та искә ала. «Бу елларда без, М. Гафури фикердәшләре, мөритләре әйтмешли, «жуликлар» күбәеп киттек. Гафуриның квартирасы безнең һәр көн җыела торган урыныбыз булды. Хәлим Искәндәрев, Мансур Халиков... Бәләбәйдән Шәрәфи, Йосыф Шәркый (Деликамов), Габделхәй Карабаев һәм башкалар җыела торган идек» [1].

«Рәсүлия» шәкертләренең алдынгылары, гадәттә, белемнәрен күтәрү өчен соңыннан Уфага — «Галия»гә килгәннәр. Х. Искәндәрев, М. Гафури, Г. Ибраһимов, З. Өмməти әнә шулай «Галия»дә бер чорда укыйлар. Бу егетләр русча өйрәнү буенча бер түгәрәк оештыралар. Х. Зәйнинең безгә язган истәлеге Башкортстанның өлкән укытучысы Гата Исхакыйның матбугатта чыккан истәлеге белән туры килә. Ул да «Галия» шәкертләре арасында М. Гафури белән Х. Искәндәревне телгә ала [2].

«Галия»гә килеп керүгә Х. Искәндәревне назыйр (шәкертләрнең тәртибен карап торучы) итеп билгелиләр... Назыйр булганлыктан аңа, гадәт буенча, аерым бүлмә бирәләр. Г. Ибраһимов, Х. Искәндәрев, М. Гафури, З. Өммәти, Х. Зәйни анда рус әдәбиятын укыйлар, рус грамматикасын өйрәнәләр.

Х. Искәндәрев 1911 елның җәендә, татар шәкертләренең бик күбесенә хас булганча, казакъ-кыргыз балаларын укытып йөргән булырга тиеш. Шәһит Әхмәдиевнең 1912 елның мартында «Бәянелхак»та бастырган «Хат һәм җаваплар»ында, безнең уебызча, бер хат Хәлим Искәндәревнеке. Хатында ул шул чорда Россиядәге политик атмосфераның кысанлыгыннан зарлана, идеалсызлыкны тәнкыйть итә, үзенең «Иртыш елгасы буенда караңгы гына бер авылда изелеп, кыргыз, татар балалары укытып» ятканын яза. Халык җилкәсендәге бай малайларының, «укыйм» исеме күтәреп тә, милләткә файдасыз кешеләр булып калуын әйтеп: «Безнең өчен кулын сызганып, тезләнеп бала тәгълим кылучы мөгаллимнәр, файдалы кешеләр кирәк», ди. Хәтта Грибоедовның «Горе от ума» әсәреннән өзек китерелә: «Бегу, оглянусь, пойду искать по свету, где оскорбленному есть чувству уголок» [3]. Моны цитата итеп китерерлек татар шәкертенең (хәтта аның инициаллары «Х. И.» дип бирелгән) русча хәзерлеге булганлыгы шиксез. Х. Искәндәрев түгелме ул?

1912—1914 елларда Х. Искәндәрев Троицкидагы дарелмөгаллиматта (хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты) татар теле һәм әдәбияты укыта. Шул чорда аның мәктәп балалары өчен «Белек йорты» дигән уку китабы басылып чыга. «Белек йорты»н Сәйфи Кудаш шул заманның «зәвык белән төзелгән зур хрестоматияләреннән» берсе дип бәяли [4].

Х. Искәндәревнең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеге дә шул чорда башлана. «Йолдыз» газетасының 1913 һәм 1914 елгы саннарында (1093, 1103, 1113 саннар) аның «Галимҗан Ибраһимов вә аның әсәрләре» дигән зур күләмле тәнкыйть мәкаләсе басыла. Тәнкыйтьче биредә Г. Ибраһимов иҗатының иң характерлы якларын билгеләргә омтыла. «Әдиптә, — ди ул, — дикъкатьне алырлык бер мәел, көчле вә муәффәкыятьле бер мәел бар: ул шөбһәви... вә гомумән куркынычлырак урыннарны куертырга ярата». Шул ук вакытта Х. Искәндәрев язучының стиль үзенчәлеген билгеләргә тырыша. Ул аның стилен «үзенә махсусрак, күз алдында чәчрәп тора торган бер стиль» дип атый [5]. Ләкин ул әдәбиятка иҗтимагый-социаль позициядән торып анализ ясый алмый әле. Г. Ибраһимов әсәрләрендә татар хатын-кызларының язмышы чагылу мәсьәләсенә тукталып, тәнкыйтьче авыр язмышның социаль сәбәпләрен ачуга кадәр күтәрелә алмый. Һәм шунлыктан тәнкыйть мәкаләсендә татар тормышын каргаудан, өзгәләнүдән узмый. Х. Искәндәрев татар хатын-кызларының авыр язмышына сыкрана, сызлана, ләкин идеалистик фәлсәфәгә кереп бутала...

Үз чиратында Г. Ибраһимов та тәнкыйтьченең журналистлык эшчәнлегенә югары бәя биргән. 1914 елда Сухумида вакытта ул Х. Искәндәревкә хат яза. Бу хат жандармерия кулына килеп керә һәм күчермәсе мөселманнар яшәгән барлык губерналарның жандарм идарәләренә җибәрелә. Г. Ибраһимов анда «Йолдыз»ның нашире һәм редакторы Һади Максудины редакторлыктан азат итү кирәклеге турында сүз алып

---

[1] Шунда ук, 42 бит.
[2] Шунда ук, 64 бит.
[3] Ш. Әхмәдиев. Сайланма әсәрләр. 1959 ел, Казан, 54—55 битләр.
[4] С. Кудаш. Яшьлек эзләре буйлап. Казан, 1964 ел, 44 бит.
[5] «Йолдыз» газетасы. 1914 ел, 1113 сан.

бара. Башкалар бит, ди ул, газеталарны үзләренеке иттеләр. Нигә безгә дә шулай эшләмәскә? «Безгә, шуңа күрә, күбрәк иптәшләр җыярга кирәк. Гомумән, мин сиңа Казанга күчәргә, шунда яшәргә киңәш бирер идем... Бу казанда һәрбер матбугат әһеле бер кат кайнап чыгарга тиеш... Бу кышны мин синең «Йолдыз»да эшләвеңне телим. Анда синең хыялыңны очырырга мәйдан зур. Әнә бит «Вакыт»та Җәләй күп яза. Синең әдәби багажың һич тә Җәләйнекеннән ким түгел... Мин һадины редакторлыктан азат итәргә тырышам. Һади бары тик нашир генә булып кала, чөнки ул анда бер роль дә уйнамый»[1].

«Йолдыз» идарәсе дә Х. Искәндәревнең каләменә югары бәя биргән: газетаның тарихын яктырткан бер мәкаләдә «Йолдыз» Х. Искәндәревне, Г. Ибраһимовлар белән беррәттән, «мәгъруф (танылган) каләм әһеле» дип атый (1913 ел, 1078 сан).

Беренче империалистик сугыш башлангач, Х. Искәндәрев хезмәт армиясенә элгә. Мәгълүм булганча, беренче империалистик сугыш вакытында патша хөкүмәте казакъкыргызларны тыл эшләренә ала. Бу вакыйга дини һәм милли изү астында җәфа чиккән казакъ халыклары арасында сыйнфый көрәш утын кабызып җибәрә. Казакъ-кыргызлар царизмга каршы баш күтәрәләр. Х. Искәндәрев исә әлеге казакъ-кыргызлар арасында меңбашы булып хезмәт итә. Патша төшерелгән көннәрдә Уфа урамнарында яхшы френч, затлы итекләр кигән, яссы каешлар белән уралган мәһабәт гәүдәле бер офицерны күрергә мөмкин була. Ул — меңбашы Хәлим Искәндәрев икән. Казакъкыргыз арасында йөргәндә Х. Искәндәрев бу восстаниенең патша хөкүмәте тарафыннан канга батырылуын күргән. Шул чагында ул үзе нинди позициядә торган? Моны әйтүе кыен. Һәрхәлдә, күргәннәрен яшьлек дусты М. Гафурига сөйләгән булуы бик мөмкин. Безнең уебызча, М. Гафуриның «Бер нәүхә» шигыре алар арасында булуы мөмкин дип фараз ителгән очрашу-сөйләшүдән соң язылган.

Еракта... Әллә кайда!.. Зар
Елыйлар, ишетелә нәүхә.
Йөрәк әрнеп күз алдымда
Хасил булды кара ләүхә...

Туганнар тилмереп, иңрәп,
Торалар шунда каршымда,
Тыныч тормыш югалган, гөж
Киләләр шунда каршымда...

Елыйлар, туктый алмыйлар...
Нигәдер, һәммәсе кызган!..
Кыямәт көн кебек булган:
Урамда чалмалар тузган...

Йөрәкләр әрнешә, күзләр
Елый дәһшәтле бу көннән,
Ирекле көннәр үткән, бар
Халык аерылган иркеннән...

Шулай торган вакытта күк
Күкрәгән төсле тавыш чыкты,
Аларның аһ-зарыннан
Да көчле бер тавыш чыкты...

Тавыш-тын бетте шунда ук,
Нә елау калды, нә сүз калды...
Фәкать бер әрнү берлән шул
Урында канлы эз калды...

---

[1] Оренбург үзәк дәүләт архивы, 21 фонд, 9 тасвирлама, 4 эш, 85 документ. Әдәбият фәнендә бер тәгәлсезлек киткән: кайбер чыганакларда бу хат Харис Фәйзигә адресланган дип күрсәтелә. Җәләй — Җ. Вәлидинең псевдонимы.

Шигырьгә искәрмәсендә М. Гафури бу әсәрнең казакъ-кыргызларның лашманчылыкка каршы күтәрелгән восстаниесенә мөнәсәбәт белән язылган икәнен әйтә.[1]

Хезмәт армиясеннән кайткач, Х. Искәндәрев Томск педагогия техникумында татар теле һәм әдәбияты укыта. Себернең күп кенә шәһәрләрендә мәгариф инспекторы булып йөри. 1927—28 елларда ул Мәскәүгә килә һәм элеккеге Әсәдуллаев мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бераздан аны бу мәктәпкә мөдир итеп билгелиләр. 1929—34 елларда ул КУТВның (Коммунистический университет трудящихся востока) татар бүлегендә татар теле укыта. Х. Искәндәрев Мәскәүдә 1941 елга кадәр эшләгәнме, әллә аңарчы ук Казанга кайткан булганмы — моны ачыклап булмады. Әмма сугыш вакытында ул Арча педагогия училищесында рус теле һәм әдәбияты укыта, укыту бүлеге мөдире булып эшли иде. Ул студентлар белән бер авыз сүз татарча сөйләшмәде. «Мин Мәскәү татары, татарча сөйләшмәгәнемә байтак, сез миннән русча өйрәнеп калырга тырышыгыз», — ди иде.

Х. Искәндәрев мәһабәт гәүдәле, яшел френчтән, сугыш елларындагы кышкы салкыннарда да затлы штиблетлардан, кепкадан, үтүкләнгән чалбардан йөри, бик еш һәм бик тәмләп тәмәке тарта иде. Ара-тирә аның гарәпчә белгәнлеге сизелеп куя иде. Рус әдәбиятына, рус теленә ул чын мәгънәсендә гашыйк кеше, берниндя акцентсыз сөйләшә иде. Үзенең югары культурасы белән ул күпләргә үрнәк булды. Аның тышкы кыяфәте — мәһабәт гәүдәсе, җыерчык узган маңгайлары, френч, штиблет киюләре нәкъ «Кызыл чәчәкләр»дәге Фазыйл иде. Х. Искәндәрев үзенең биографиясенә кагылышлы бер генә сүз дә сөйләми, бары тик «миңа алтмыш яшь (1944—45 уку елында), мин күпне күрдем» дип әйткәләп куя иде. Чәчен озын итеп үстерә, дәреско кергәч, чәч юлларын ачып кыеклап тарап куя, гадәттән тыш пөхтә иде. И. Рәминең 1926 елда чыккан «Татар вакытлы матбугаты» дигән альбомында Х. Искәндәревнең унсигезенче еллар тирәсендә булса кирәк төшкән рәсеме бар. Анда да ул френчтән, чәч юллары кыеклап ачылган, үткен карашлы, мәһабәт йөзле...

Йомгак ясап шуларны әйтергә мөмкин булыр иде: Г. Ибраһимов үзенең яшьлек дусты Х. Искәндәревнең укымышлылыгына, эрудициясенә ничек югары бәя бирсә («Йолдыз»га редактор итеп куярга тели), «Кызыл чәчәкләр»дәге Солтан да Фазыйлга башта шулай ихтирам белән карый. Х. Искәндәрев тә, Фазыйл да лашманчылар армиясендә офицер чинында хезмәт итәләр. Х. Искәндәревнең тышкы портреты, киенү манерасы белән Фазыйлның портреты, манерасы бер үк төрле, һ. б. һ. б. Ләкин болар әле аерым тышкы детальләр генә, аерым биографик охшашлыклар гына булды. Прототип исә социаль-политик карашлары буенча да әдәби герой белән охшаш булырга мөмкин һәм күп очракта ул шулай була да. Гражданнар сугышы елларында Солтан, Гыйлаҗи, Шаһбазлар, эшче-крестьян мәнфәгатьләрен яклап, кан коеп йөргәндә, чибәр егет Фазыйл кайда булган соң? Фазыйлның үзен тыңлыйк:

«Зур сүзләр бар иде... — ди ул. — Бераүләр бөек Русия, ди иде, ватан, ди иде. Без төрек-татар байрагы ди идек. **Милли азатлык намена чехка, милли идарәгә, Колчакка тагылдык...** Халыкны аларга чакырдык. Гыйлмебезне, талантыбызны шуларга корал иттек»... (494 бит. Курсив безнеке — М. М.)

Прототип дип уйланылган Х. Искәндәрев биографиясендә моңа охшаш момент шулай ук бар. Сыйнфый көрәшнең иң кискен бер вакытында — 1918 елның 25 ноябрендә — Уфада «Ил теле» дигән бер газета чыга башлый. Газета үзенең политик йөзе турында болай дип белдерә: «Учредительное собрание әгъзалары каумиятенең мәдәният вә мәгърифәт тарату шөгъбәсе нашир-әфкяре, сәяси, иҗтимагый, әдәби төрек-татар газетасы». Газетаның төп лозунгысы: «Бөтен хакимият Учредительное собрание кулында булсын! Милләт бөтен бер булып, барлык әфрады: сәүдәгәре, укытучысы, эшчесе, ярлысы, бае бергә барырга!» Лозунг газетаның йөзен ап-ачык билгели: татар-башкорт буржуаларының интересын күзәткән, «татарда сыйныф юк» дигән реакцион газета бу. Аны чыгаручы — Хәлим Искәндәрев[2].

---

[1] М. Гафури. Сайланма әсәрләр. 1939 ел, 78—79 битләр. Китапта М. Гафуриның бу шигыре 1915 елда язылган дип күрсәтелә. Бу — хата фикер. Казакълар восстаниесе 1916 елда була. Димәк, шигырь берничек тә 1915 елда языла алмый. Һәм шуннан соңгы чыганакларда уа 1916 ел белән билгеләнә.

[2] И. Рәми. Татар вакытлы матбугаты. Казан, 1926 ел, 107 бит.

Игътибар итик, «Галия» буенча яшьлек дуслары, әдәби-журналистлык эшчәнлекләрендә заманында мәсләктәш булган ике әдип — Г. Ибраһимов һәм Х. Искәндәрев— **политик көрәш аренасында икесе ике якта.** Г. Ибраһимов Үзәк мөселман комиссариатында татар-башкорт милләтчеләренә каршы көрәш алып бара, «учредилка»чыларны аяусыз тәнкыйтьли. Х. Искәндәрев исә нәкъ шул вакытта учредилканы яклап газета чыгара. «Кызыл чәчәкләр»дә сыйнфый көрәш кырларында Солтан кан коеп йөргәндә аның яшьлек дусты Фазыйл френч киеп, сары каешлар белән уралып, кобура тагып чехка, Колчакка тагылып йөри. Прототип белән әдәби герой арасындагы иң әһәмиятле охшашлыкларның берсе, әлбәттә, менә шунысы.

Алга таба күзәтик: әсәрдә Фазыйлның үз ялгышларын аңлап ахырдан Совет ягына чыгуы һәм үткәндәге хаталары өчен чын күңелдән үкенүе әйтелә. Солтан да аңа ышана, аны яңадан ярата башлаган сыман була, **әмма сыйнфый көрәш елларында эшче-крестьян азатлыгы өчен кан койган дуслары аның күз алдында укымышлы егет Фазыйлны каплыйлар, аны читкә этәрәләр.** Прототип белән дә шулай: 1918 елның 6 декабрендә Бишенче Армия каршында татарча «Кызыл яу» газетасы чыга башлый. Бөгелмәдә чыга башлаган бу газета, Уфа аклардан чистартылгач, Уфага күчә, аннан Чиләбегә һәм Колчакны куган саен эчкәрерәк керә... Бу чорда инде большевистик хәрби газета «Кызыл яу»да без, Галимҗан Нигъмәти, Самат Шәрәфетдиневләр белән бергә, **Хәлим Искәндәревне дә күрәбез.** Димәк, үзенең «чәч агартырлык» михнәт-җәфаларыннан соң Искәндәрев тә Колчакка ияреп китмәгән, ә дөрес юлны тапкан, большевиклар ягына чыккан. Х. Искәндәревнең язмышындагы хәлиткеч борылышта Г. Ибраһимовның роле булмаганмы? Һәрхәлдә, сыйнфый көрәш елларында ике сабакташ бер генә тапкыр очрашмаганнардыр. «Кызыл яу», мәсәлән, бервакытлар Чиләбедә чыга. Г. Ибраһимов Колчак тылыннан кайтышлый Бишенче Армиянең политидарәсенә — Чиләбегә туктала һәм информация ясый[1]. Х. Искәндәрев исә политотдел каршындагы газетада эшли. Димәк, алар арасында бик кызыклы очрашу, әһәмиятле сөйләшү, аңлашу булгандыр дип уйлый алабыз.

Югарыда китерелгән фактлар татар журналисты, совет власте елларында укытучы Хәлим Искәндәревне «Кызыл чәчәкләр хикәясе»ндәге Фазыйлның прототибы булган дип уйларга тулы мөмкинлек бирә.

Инде «Безнең көннәр» романындагы Баязит кариның прототибын эзләп карыйк. Романның ике вариантын да укыган кешеләр хәтерлидер: беренче вариантта провокатор Баязит карига урын аз бирелгән. Ул, гомумән, укучылар алдында ачылмый кала, аның провокаторлыгының социаль җирлеге, партиячел асылы аңлашылмый. Г. Ибраһимов революциядән соң «Безнең көннәр» романына кабат әйләнеп кайта. Икенче вариантка керешкәнче, ул охранканың яшерен документларын җентекләп өйрәнә. Документлар аны царизмга каршы көрәшеп йөргән ялкынлы яшьлегенә кире кайтаргандай булалар. Һәм романда, башка үзгәрешләр белән беррәттән, зур, катлаулы образ — эсер Баязит кари образы туа. Романның беренче вариантында Баязит кари штрихлар белән генә бирелгән. Аның әсәрдәге роле дә социаль-политик яңгыраш алмый, ул — бер эпизодик образ гына. Язучы нинди чыганаклар нигезендә баеткан соң бу образны? Архив документлары аңа берәр танышын яңа яктан ачмаганнармы? Шул вакыйгалар тасвирланган заманның матбугатына мөрәҗәгать итик. Башта, үзеннән-үзе, Баязит кариның яңа варианты белән татар журналисты Исхак Бикчурин арасында **биографик аналогия** туа.

Әдәбият фәнендә Бикчуринның биографиясенә кагылышлы бер төгәлсезлек киткән. М. Галәү «Г. Тукай турындагы истәлекләрдән бер кисәк» дигән мәкаләсендә («Совет әдәбияты» журналы, 1936 ел, 5 сан) И. Бикчурин асылынып үлгән көннәрдә Г. Тукайның бик кәефсез йөргәнен, шул вакыйгага багышлап «Катиле нәфескә» исемле шигырь язганын сөйли. М. Галәүнең бу мәкаләсе шул көенчә «Тукай турында замандашлары» дигән җыентыкка да кертелгән. Чыганаклар буенча тикшереп карыйк. «Катиле нәфескә» шигыре «Йолдыз» газетасының 1910 елгы 15 апрель санында басылган. Исхак Бикчурин исә **Тукай үлеп бернičә көннән соң** гына үзен-үзе үтергән. Шуның белән М. Галәүнең «Катиле нәфескә» шигырен ялгыш аңлатуы исбат ите-

---

[1] М. Хасанов. Галимджан Ибрагимов. Рус телендә. Казан, 1969 ел, 204 бит.

лә. Монысы «Тукай турында замандашлары»ның киләчәк басмаларында төзәтелер. Әдәбият фәне өчен бу зур хәл түгел. Әмма Исхак Бикчуринның биографиясендә безне кызыксындырган башка яклар байтак әле.

И. Бикчурин «Таң»чы булган. Октябрь революциясеннән соң Казан жандармерия идарәсенең «бик яшерен» фондларын караган Г. Ибраһимов бу кешенең провокатор булганлыгын ачыклый. Бу турыда язып та чыга[1]. Хәзер провокатор И. Бикчуринның биографиясе белән танышыйк. Ул 1881 елда Чистай ягында яшәүче Хәлил хәзрәт семьясында туган. Үзлегеннән русча укып, Татарская учительская школага кергән. 1906 елда студентлар хәрәкәтендә катнашкан өчен школадан чыгарылган. Байтак вакыт «Таң» газетасында, «Бәянелхак»та эшли. «Кояш» газетасына күп яза. И. Бикчурин күп мәкаләләрен имзасыз яза[2]. Аның жандармериягә кайчан ялланганы әлегә ачылмаган. Ләкин провокаторның биографиясендә бер закончалык бар: башта «Таң»чы эсер, үз газетасы ябылгач, начар дан алган «Бәянелхак»ка күчә, күп мәкаләләрен **имзасыз** бастыра, газетада язылганча, **«шәһрәткә кызыкмый»**[3], аның **рухи азыгы Ф. Ницше тәгълиматы** була. Ницшеның иseме аның «авызыннан төшми»[4]. И. Бикчуринның үлеме татар журналистларын тетрәтеп ала. Аның турында иң зур мәкаләләр язып чыгучылар кемнәр? «Таң»чы Ф. Туктаров, эре провокатор, татар язучыларын жандармериягә саткан Т. Мамлеев. Соңгысы үзенең имзасына «Исхакның иң якын дусларыннан»[5] дип өсти. Димәк, боларның дуслыгы провокаторлык хезмәте белән беркетелгән. Гыймад Нугайбәккә бервакыт Бикчурин болай дип сөйләгән: «Тукаевның Казандагы тормышын миннән яхшы белгән кеше юк, ул **бүтәннәрдән яшерә торган серләрен миннән яшерми иде.** Мин аның тормышын бик яхшы беләм» (курсив безнеке). Г. Тукай үлгәч тә И. Бикчурин, шагыйрьнең Казандагы тормышы турында китап язарга уйлап, шәһәр тирәсенә дачага җыена[6]. Ләкин 20 апрельдә, ягъни Г. Тукай үлеп 18 көн үткәч, үзен-үзе үтерә. Мамлеевлар аның веногына: «Аңлашылмаган халык каһарманына»[7] дип, лента куеп озаталар. Характерлы бер деталь: университетның анатомия театрыннан провокаторның гәүдәсен алып чыкканда процессия артына траур киеменнән бер хатын килеп баса да: «Бу кем? Исхак түгелме?» — дип сорый. Үзе елый, ләкин **мәет янына килми, үзен кешегә танытмый.** Ахырдан гына моның Исхакның әнисе икәнлеге беленә. Мондый «серлелек»ләрнең барысыннан да бер версия туа: «куркәм холыклы, дәрвиш табигатьле» бу егетнең Тукай Казанга килгәч ук аны күзәтү өчен беркетелеп куелган булуы мөмкин. Моны Т. Мамлеев кебек «үз ишләре» белгән һәм Бикчуринның әнисе дә сизенгәндер. Г. Тукай үлгәч, Бикчуринга охранка яңа задание биргән булырга тиеш. Әйтик, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Коләхметовлар артыннан күзәтергә. Ихтимал, сатлык җан үзенең табигый финалына ниндидер янаулар, куркытулардан соң килгәндер, чөнки ул шагыйрьнең Казандагы тормышы турында язарга вәгъдә биреп тә язып кала алмаган.

Шәхес буларак пычрак җанлы кеше әдәбиятта нәрсәләр эшләгән соң? Ул ориенталист Вамбери хезмәтләрен татарчага тәрҗемә итәргә тотынып караган — ахырына барып чыкмаган[8]. Г. Тукай турында язарга җыенган — язмаган. Ләкин аның өлгергән өлкәләре дә булган. Мәсәлән, ул русча әсәрләрнең кайбер урыннарын үзгәрткәләп үз исемен куеп чыгаргалаган. Үзе үлгәч, танышларыннан берәү (Шәриф Хөсәенов) аның турында «Сахтә әдәбияттан бер ләүхә» дигән мәкалә язып чыга. Бервакыт И. Бикчурин аңа диктовка белән бер пьеса яздырта. Ике утыруда бер пьеса язылып бетә. Бикчурин моны үз исеменнән каядыр сата[9]. Ш. Хөсәенов бераздан бу пьесаның асыл нөсхәсен таба: ул рус язучысы Г. Сибиряковның «Асрау кыз» дигән әсәре булып чыга. Плагиатор аны бераз гына татар дөньясына күчереп эшләгән икән[10].

Мәгълүм булганча, Г. Ибраһимов «Безнең көннәр» романының беренче вариантын 1914 елда яза. Ике табагы басылгач, патша властьлары әсәрнең тиражын конфис-

---

[1] Г. Ибраһимов. Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан. Казан, 1922 ел, 5 бит.
[2] «Кояш» газетасы, 1913 ел, 104 сан.
[3] Шунда ук.
[4] Шунда ук, 108 сан.
[5] Шунда ук.
[6] Шунда ук, 104 сан.
[7] Шунда ук, 105 сан.
[8] Бу турыда: «Идел» газетасы, 1913 ел, 585—586 саннар; «Мир ислама». Том II, СПб, 1913, вып. X, рус телендә, 707 бит.
[9] Китапханәләрдә аерым китап рәвешендә Бикчурин әсәрләре очрамады.
[10] «Кояш» газетасы, 1914 ел, 536 сан.

кациялиләр[1]. Әсәрнең революциядән соң чыккан басмасы да, авторның әйтүенчә, «шул 1914 елгы кульъязма тексты буенча» эшләнә[2]. Г. Ибраһимовка «революциядән соңгы 15—16 ел эчендә иске охранканың архивын күп тикшерергә» туры килә[3]. «Безнең көннәр» романының яңа басмасы нинди принциплардан чыгып яхшыртылуы, идея-эстетик яктан тирәнәйтелүе турында Г. Ибраһимов үзе дә һәм аның иҗатын тикшерүче М. Хәсәнов та күрсәтә[4]. М. Хәсәнов «Безнең көннәр» романындагы кайбер образларның, вакыйгаларның тарихи җирлеген беренче буларак тикшерә. Алда әйтелгәнчә, З. Булатовта ул большевик Х. Ямашевка хас булган сыйфатларны, автор белән аның герое Сәхип биографиясендә бик күп уртак моментлар булуны һ. б. ачыклый.

Прототипларга мөрәҗәгать итү — «Безнең көннәр» кебек ике вариантлы зур сәнгать әсәрен аңлау өчен искиткеч әһәмиятле момент. Әсәрнең яңа вариантын эшләгәндә Г. Ибраһимов, марксизм-ленинизмның революциядә пролетариат гегемонлыгы турындагы төп идеясен нигез итеп алудан тыш, «жандармерия, охранканың яшерен механизмын ачарга тиешле урыннарны тагын бик көчәйтергә кирәк» дип таба һәм «аеруча зинданнарны, тоткыннарны, палачларны» күңеле «туйганчы киңәйтә, тирәнәйтә баруны» үзенә бурыч дип саный[5].

Алда санап чыккан фактлар безне И. Бикчуриннан Баязит кари образына алып киләләр. Алар икесе дә «Таң»чы, иптәшләре арасында искиткеч әдәплеләр, самимиләр. Менә шундый бик күп уртак сыйфатлар Баязит кариның прототибы И. Бикчурин дип уйларга нигез бирә. Баязит — мәшһүр Җиһан ишан улы, Бикчурин — Чистай өязеннән «шөһрәтле Хәлил хәзрәт улы». Исхак Бикчурин провокатор Т. Мамлеев квартирасында сөлгегә асылынып үлә. Аның гәүдәсе янында «Төкерәм мин сезнең дөньягызга» дигән язу табалар. «Безнең көннәр»дә Баязит үз номерында асылынып үлә. Язу калдыра: «Туйдым, дөньяның, тормышның газабыннан, мәгънәсезлегеннән туйдым».

«Таң»чылар Бикчуринны ничек зур шөбһә астында, кызганып, аңлый алмыйча күмсәләр, Баязитны да иптәшләре шулай күмә. Бикчуринны күмгәндә дә туганнары катнашмый, Баязит та шулай күмелә. «Таң»чылар язган бик күп мәкаләләрдә Бикчуринның «гаҗәп әйбәт холкы» мактала. Баязитны да үлгәч әнә шулай искә алалар. Хәтта аларның укыган җирләре дә туры килә: әгәр романдагы «мәдрәсәи «Исламия»»не Казанның «Мөхәммәдия»се дип кабул итсәк һәм Бикчуринның «Мөхәммәдия»дә укыганлыгын искә алсак, Баязит биографиясе ул — провокатор Исхак Бикчурин биографиясе.

Без Г. Ибраһимовның ике әсәрендәге ике катлаулы образның прототиплары булмаганмы, булса, алар кемнәр? дигән сорауга җавап эзләп карадык. Һәм язучының замандашларыннан һәр ике образга байтак яклары белән туры килгән ике шәхеснең биографияләре белән таныштык. **Безнең гипотезабыз дөрес булган очракта да Г. Ибраһимов бу шәхесләрнең биографияләрен үзгәртмичә романга керткән дип уйларга ярамый.** Ул биографик материаллар, әлбәттә, язучының иҗат фантазиясе белән баетылганнар, үстерелгәннәр, гомумиләштерелгәннәр.

Прототип ул — теге яки бу образны тудыру өчен язучы тарафыннан **нигезгә** алынган реаль шәхес. Бу шәхесне баету, «сипләү», үстерү яки бераз «кырку» инде әсәрнең социаль-эстетик юнәлешеннән чыгып башкарыла. Г. Ибраһимовта да бу процесс әлеге очракта нәкъ шулай булгандыр дип уйларга нигез бар.

IIIIIIIIIIIIIII

---

[1] Бу турыда: М. Хәсәнов. Галимҗан Ибраһимов. 1964 ел, 87 бит.
[2] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 3 том, Казан, 1956 ел, 429 бит.
[3] Шунда ук, 432 бит.
[4] М. Хасанов. Галимджан Ибрагимов. Рус телендә, Казан, 1969 ел, 397—420 битләр.
[5] Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. 3 том, 431 бит.

Динә Вәлиева

# БОЛГАР СӘНГАТЕ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Бөек Болгар иле... Борынгы тарихчылар да, гарәп сәяхәтчеләре дә Европаның көнчыгыш тарафында яшәгән ул бай һәм шактый эре дәүләтнең тормыш-көнкүрешен бәйнә-бәйнә тасвир иткән язмалар калдырмаганнар диярлек. Ибн Фадлан сәяхәтнамәсе, төрле тарихи язмаларда сакланган берничә өзек, кыска-кыска хәбәрләр, археология табышлары ярдәмендә генә без болгар бабаларыбызның яшәеш рәвеше, гореф-гадәтләре, дәүләт төзелеше, материаль культурасы, һөнәрләре хакында фикер йөртә алабыз.

Идел буе болгарларының рухи культурасын, әдәбият һәм сәнгате казанышларын өйрәнү мөмкинлекләре исә тагын да чикләнгәнрәк. Тарихта кайбер болгар шагыйрьләренең һәм тарихчыларының исемнәре билгеле (әйтик, «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасының авторы Кол Гали, «Болгар тарихы»н язган Якуп бине Ногман һ. б.). Әмма болгар сәнгате хакында нинди дә булса фикерләр яисә болгар сәнгать осталарының тормыш-яшәешләреннән хәбәр биргән язмаларны очрату бик кыен. Ә сәнгать яшәгән, төрле һөнәрләр чәчәк ату чорын кичергән. Болгар сәнгате әйберләренең Мәскәү, Ленинград, Казан, Хельсинки шәһәрләрендә саклана торган коллекцияләре безгә әнә шул хакта сөйли. Музейларда без алтын яки көмештән, җиздән һәм бакырдан, сөяктән, күбесенчә җәнлек яки кош рәвешендә эшләнеп, үзенчәлекле орнамент белән бизәлгән йорт җиһазы, бизәнү әйберләрен очратабыз.

... Менә саф алтыннан эшләнгән кыңгыравыклы алка, бөҗрасына нечкә чылбыр белән асылмалы алтын «чикләвекләр» беркетелгән. Бөҗра эчендә — нәфис итеп эшләнгән үрдәк фигурасы (томшыклары ачылыр-ачылмас).

Бөртекләү техникасын гаять оста кулланып, нечкә зәвык белән ясалган бу затлы алкалар үзеннән-үзе соклану хисе уяталар, шул чак гүя болгар хатын-кызы тагып йөргән шул алкаларның чыңлавын ишеткәндәй буласың... Нинди останың кулы тудырды икән бу кечкенә могҗизаны?

Бармаклар алтын алканың кытыршы бөртекләре өстенә тиеп үтә, шул чак тәнеммнән кайнар дулкын йөгереп уза. Заман гүя кинәт артка чигә һәм мин бик ерактан ата-бабаларымның җандай якын туган җире Идел Болгарын бер мизгелгә күргәндәй булам...

«Болгарлар Итиль дип аталган һәм Хазар диңгезенә коя торган елга буенда яшиләр.... Болгарлар иген игүче халык һәм һәр төрле бөртекле ашлык үстерәләр. Аларның күпчелеге ислам динен тота, авылларында мәчетләр һәм башлангыч мәктәпләр бар...» (Ибн Дустә, X йөз.)

«Болгар — зур шәһәр, тирә-ягы имән бүрәнәләрдән диварлар белән әйләндереп алынган, ә йортлары нараттан салынган...» (Әбү Хәмид Әл-Гарнатый, XII йөз.)

«Бүләр — кеше яши торган җирнең иң төньяк читендә, Иделдән төньяк-көнчыгышка таба үзәнлектә урнашкан, таулардан аңа кадәр бер көнлек юл...» (Әбулфәда.)

Ул заманның эре шәһәрләре Бүләр, Болгар, Суварда һөнәрчеләр күп яши, аларның металл һәм сөяктән ясаган әйберләре арасында чын сәнгать әсәре югарылыгына күтәрелгәннәре дә аз булмый. Бизәнү әйберләренең бер өлеше читкә — Урта Азия, Иран, Гарәбстан илләренә китә, күршедәге рус җиренә дә тарала. Шуңа күрә дә кыңгыравыклы алкалар элекке Идел буеннан бик ерак җирләрдә дә очрый. Ә югарыда әйтелгән алка 1868 елда табылган Болгар-Спасс хәзинәсеннән алынган. А. П. Смирнов, Т. А. Хлебникова кебек археолог-галимнәр аны X—XI йөздә эшләнгән дип саныйлар. Шушындый ук алтын алкалар Бүләр шәһәре урынындагы казылмалардан да табылды. Алканың боҗрасына чикләвек рәвешендә өч бизәк ясалган, «чикләвек»ләр дә, үрдәкнең гәүдәсе дә бөртекле орнамент белән капланган. Бик борынгы заманнардан алып урта гасыр ахырларына кадәрге чорларда киң таралган «җәнлек стиле»нең үзенчәлекле бер чагылышы бу.

Фәндә исбат ителгәнчә, борынгы кешенең аңында җәнлек сурәте магик мәгънәгә ия булган, төрле җәнлек сурәтләрен ясау гадәте һәм йоласы аучылык белән бәйләнештә барлыкка килгән. Соңрак исә һәр кыргый җәнлек һәм аның сурәте символик мәгънә алган. Арыслан, барс, аю, бүре — көч-куәт, бөеклек, өстенлек, көчленең көчсезне яклавы символы; ат, поши, болан, эт — дуслык, тугрылык билгесе; елан, ябалак — гакыл, зирәклек, кайчагында мәкерлелек билгесе булып йөргәннәр.

Каз-үрдәк образы барлык су кошларын гәүдәләндерүче булып киткән, шуңа күрә борынгы болгарлар йорт җиһазына яки бизәнү әйберсенә ясалган үрдәк һәм каз сурәте барлык йорт кошларын авырудан һәм бәла-казадан саклый дип исәпләгәннәр.

Алай гына да түгел, борынгы болгарларда үрдәк дөньяның барлыкка килүен күзаллауда мөһим урын тоткан булса кирәк. Күп халыкларда үрдәк гомумән тормышяшәешне белдерә. Төрле халыкларның әкиятләрендә яшәеш символы булган үрдәк йомыркасын кулга төшерү өчен үрдәк ауларга йөрүче батыр турында хикәя ителә.

Шушы рәвешчә фикер йөрткәндә, чикләвеккә охшаш өч кыңгыраучыкның нәкъ менә шушындый йомырка символлары булуына төшенү кыен түгел. Болгарларда җан өч төрле мәгънәдә йөри дип әйтергә була: җан (гомуми төшенчә), өрәк (хатын-кыз җаны), кот (ир кеше җаны). Шулай итеп, әлеге ювелир әйберсен дөнья яратылуы турындагы бер сюжет итеп карарга мөмкин. Себер татарларында нәкъ менә шундый сөйләк сакланган. Имеш, кайчандыр бик борынгы заманнарда хәзерге коры җир урынында очсыз-кырыйсыз диңгез җәелеп яткан, җир бөтенләй күренмәгән. Җан иясреннән бары кошлар гына яшәгән. Бер заман суда йөзеп йөргән үрдәк диңгез төбеннән балчык алып чыгарга уйлаган. Бер чумган, ике чумган, өченчесендә томшыгы белән бер кисәк балчык алып чыккан. Әнә шул кисәктән коры җир барлыкка килгән.

Борынгы болгар остасының гаҗәеп нәфис һәм сокландыргыч иҗат үрнәге булган әлеге алтын алкага тагын бер тапкыр әйләнеп кайтыйк. Аны урта гасырлардагы декоратив һәм көнкүреш сәнгатенең иң югары үрнәкләре белән чагыштырып карау кызыклы. Мисал өчен Киев Русе осталарының XI—XII йөзләрдә ясаган алтын һәм көмеш әйберләрен — колак алкаларын, муенсаларын алып карарга мөмкин. Өч бөртек асыл ташлы колак алкалары анда да эшләнгән, ләкин болгар алкалары алардан асылмалы кыңгыраучыклары белән дә, боҗрадагы бизәкләренең чикләвек формасында булулары белән дә аерылып торалар. Бу хакта В. П. Левашованың кызыклы мәкаләсе бар[1]. Анда болай диелә: «Болгар колак алкаларының килеп чыгышын түбәндәгечә күз алдына китерергә мөмкин: өч бөртекле алка формасын алар рус күршеләреннән алганнар, болгар ювелирлары аны асылмалы чикләвек-кыңгыраулар һәм кош фигурасы белән баетканнар. Ләкин көнбатыш славян илләренең археология материаллары белән танышу болгар алкасының ниндидер башка прототиптан алынып, катлаулырак эволюция кичергәнлеген күрсәтә. Ул прототипны, күрәсең, Русьта түгел, башка җирдән эзләргә кирәктер».

Алайса, кайдан эзләргә? Чылбырлы болгар алкаларын хәтерләтүче колак алкалары, мәсәлән, Чехословакиядә дә табылган. Шулай да, В. П. Левашова әйтүенчә, бол-

---

[1] В. П. Левашова. О сходстве височных украшений волжских болгар с великоморавскими. «Древности Восточной Европы» дигән җыентыкта. «Наука» нәшрияты, Мәскәү, 1969 ел, 125—130 битләр.

гар алкаларының болгар җирендә эшләнгән булуына шикләнергә туры килми, ә Моравиядә табылган алкаларга килгәндә исә, алар шул төбәкнең үзендәге элекке бизәнү әйберләреннән аерылып торалар, һәм, өстәвенә, алар берничә данә генә.

Урта гасырларда төрле илләрнең, хәтта бер-берсеннән ерак яшәгән халыкларның да, сәнгать үсеше ниндидер уртак һәм охшаш юллар белән барган. Бу хәл, ахыр чиктә, феодализм чоры экономик мөнәсәбәтләренең чагыштырмача бердәм үсеше белән билгеләнә. Бер-берсенә охшаш билгеләрдә сәнгатьләр үсешенең төп сызыклары чагылыш таба. һәм ул охшашлык үзара йогынты нәтиҗәсе генә булмыйча, аның нигезендә, иң беренче чиратта, үсеш закончалыкларының бердәмлеге, төрле халыкларның көнкүрешендәге уртаклык, дөньяны күзаллауда мәҗүсилек карашларының уртаклыгы ята.

Мәҗүсилек чорында яшәгән халыкларның сәнгате үзенең мифологик характерда булуы белән аерыла. Аның серләренә төшенү борынгы кешеләрнең ышану-ырымнарын, мифларын өйрәнү аша гына мөмкин. Ул асылда символлар сәнгате булган, шуңа күрә теләсә нинди җәнлек сурәте, сызык һәм орнамент эчке үз мәгънәсен ачуны, бүгенге заман теленә күчерүне таләп итә. Ул фигураларга күп образлар яшеренгән, һәрберсе шартлы, һәркайсы нинди дә булса мәгънәне белдерә. Рус һәм чех җирендә охшаш билге-гәүдәләнешләрен тапкан болгар алтын алкасы да шуны раслый торган мисалларның берсе.

Борынгы болгар археологик табылдыкларының икенчесе — «Маклашеево җайдагы» дип йөртелә торган йозак.

Барс яки бүрегә охшаш ерткыч җәнлеккә атланган хатын-кыз рәвешендә ясалган бу йозак 1966 елда Татарстанның Куйбышев районында табып алынган. Профессор А. Х. Халиков аны VII—VIII йөздә эшләнгән дип саный[1]. Моннан ике төрле нәтиҗә ясарга мөмкин. Беренчедән, VII—VIII йөзләрдә Идел-Кама буйларына болгар кабиләләре утыра гына башлый. Аннан элгәрерәк биредә «ананьино культурасы»н тудырган кабиләләр һәм борынгы төрки кабиләләр яшәгән. «Маклашеево җайдагы» белән ананьино культурасы чорына карый торган әйберләрдәге кеше сурәтләре арасында охшашлык юк түгел. Мәсәлән, шлемны хәтерләткән баш киемнәре бер-берсенә шактый охшашлар. Бу хәл йозакның җирле ананьино культурасына нисбәтле булуы хакында сөйләмимени? Әмма, икенче яктан, бу фикергә каршы килә торган бер сорау туа. Ананьино культурасы фин-угор тибына карый, ә йозак исә композициясе буенча төрки халыкның килеп чыгуы турындагы борынгы төрки легенданы чагылдыра. Бу легенда буенча, төркиләрнең ата-бабалары кайчандыр дошманнар тарафыннан кырып бетерелә, бары тик, аяк-куллары чабылып, сазлык эченә ташланган ун яшьлек бер малай гына исән кала. Аны үлемнән ана бүре коткара. Төрки нәселе әнә шул ана бүре белән малайдан башланып китә. Икенче легенда исә төрки кабиләнең нәсел башын шундый ук хәлләрдә бүре тарафыннан коткарылган хун патшасының кызына бәйли.

Әлеге йозакның төрки легендага бәйле икәнлеге Үзбәкстан җирендә табылган борынгы әйберләр белән чагыштырганда аеруча ачык төсмерләнә. Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясенең тарих музеенда бронзадан чүкеп эшләнгән ике сугышчы сыны бар. Аларның башына шлем кидерелгән, һәм икесендә дә имгәтелгән кешеләр сурәтләнә: берсенең кулы һәм бер аягы чабылган, күзе чукып алынган, икенчесенең ике кулы өзелгән. Җамбул шәһәре музеенда да бүрегә атланган кулсыз-аяксыз сугышчыны сурәтләгән бронза статуэтка саклана. Сыннар VIII—IX йөзгә карый дип санала[2].

Урта Азия һәм Идел буенда табылган бу әйберләр арасындагы охшашлык очраклы хәлме? һәм VI—VII йөз ананьино сугышчысы, VII—VIII йөзгә карый торган «Маклашеево җайдагы», VIII—IX йөздә Урта Азиядә эшләнгән ир кеше сыннарының бер-берсенә охшашлыгын нәрсә белән аңлатырга? Бу сыннарның төп чыганагын Идел һәм Арал-Каспий тирәләрендә яшәгән борынгы төрки кабиләләргә илтеп тоташтыру дөресрәк булыр кебек. Ул чагында безнең алдыбызда борынгы төрки легенданың сәнгатьчә гәүдәләнеше басып тора...

---

[1] А. Х. Халиков. «Маклашеевская всадница». «Советская археология» журналы. I сан, 1971 ел.
[2] Г. А. Пугаченкова, Л. И. Ремпель. История искусств Узбекистана с древнейших времен до середины XIX в. «Исскусство» нәшрияты, Мәскәү, 1965 ел, 155 бит.

«Маклашеево җайдагы»нда халыкның зооморф һәм антропоморф карашлары аеруча калку чагылыш тапкан. Ата-бабаларга табыну, кабиләнең яклаучысы, сакчысы саналган җәнлек культы борынгы кешенең аң-карашларында гаять зур урын тота. Аның күзаллавынча, изге хайван сурәтендәге теләсә нинди әйбер үзенең хуҗасын төрле көтелмәгән бәла-казалардан, һәлакәттән йолып калучы бер тылсым иясе булып санала. Барс та, бүре дә борынгы төркиләр (һәм болгарлар) өчен иң хөрмәтле, иң олы җәнлек. Һәм бу карашлар, гасырлар буе сакланып килеп, халык ырымнарына кереп калган. (Мәсәлән, бүре очрату яхшыга юрала.)

Йозакта ерткыч җәнлекнең гәүдәсе ярыйсы ук реалистик сурәтләнә. Шул ук вакытта, аны ясаган останың ерткыч җәнлеккә карата булган хөрмәте, җылы мөнәсәбәте сизелеп тора. Җәнлекнең ерткычлык билгеләренә артык басым ясалмый, киресенчә, аның тышкы рәвешендә ниндидер юашлык бар. Җәнлекнең аркасында бер күзе чокылган, бер имчәге, куллары киселгән хатын-кыз утырып тора. Чыннан да, мондый хәлдә коткарса аны бары тик шушы изге күңелле ерткыч кына коткарып кала алуы үзеннән-үзе аңлашыла.

Борында, урта гасырларда да, кеше табигатьтән аерылгысыз булган. Табигатьтәге һәрнәрсә җанлы, һәрбер нәрсә уйлый, хисләнә белә... Шуңа күрә борынгы бабабыз каршында кеше белән табигатьнең, кеше белән хайванның бер бөтен тәшкил итүе ул кадәр гаҗәп тә түгел. Борынгы легендаларның бик күбесендә кеше, үсемлек, агач, болыт, кош һәм ерткыч җәнлек кебек үк, табигатьнең гадәти бер өлеше итеп сурәтләнә. Хәтта без «җансыз табигать» дип йөрткән барлык нәрсәләр дә аның аңында, күрәсең, рухи тормыш белән яшәргә сәләтле булып тоелган.

Хатын-кыз белән җәнлек рәвешендә ясалган гади ишек йозагында монголларга кадәрге чор болгар кешеләренең эчке дөньясы чагылып үтә кебек. Табигать һәм кеше бердәмлегенең гаҗәеп образын гәүдәләндерүе белән бу көнкүреш җиһазы безнең алда сәнгать әсәре югарылыгына күтәрелә дә.

VII—VIII йөзләрдә Идел буенда мөселман дине кабул ителүгә әле ерак була. Җан ияләренең сурәтен ясауны тыю әле беркемнең дә башына килмәгән ул чорларда җанлы табигатьне сурәтләгән, хайваннар дөньясы аша кешенең тормышка, тирәюньгә мөнәсәбәтен белдергән серле, гаҗәеп әсәрләр болгарлар тарафыннан бик күп санда иҗат ителә.

Шуларның тагын берсе — кабарынкы эллипс формасында сөяктән ясалган һәм кырыйлары болгар орнаменты белән чокып бизәлгән сәер бер карачкы башы сурәте. Ул ат дирбиясе бизәге булып хезмәт иткән. Карачкының башына зирәклек символы — мәче башлы ябалак утыртылган. Ләкин иң гаҗәпләндерә торганы шунда ки, ул кара-каршы баскан кәкре томшыклы ике кош гәүдәсеннән тора. Карчыгаларның башы — карачкының колагы, канатлары — аның күзләре, койрыклары — ияге булып күренә. Шунысы гаҗәп, карачкы кыяфәте белән һич тә куркыныч түгел. Нәрсә бу? Нинди дә булса изге рухмы? Яшәешнең төпсез серләре, табигатьнең хәтәр һәм аңлаешсыз күренешләре белән чолгап алынган борынгы заман һәм урта гасыр кешесе үзенә ярдәм итәрдәй, бәла килгәндә коткарырдай затка, изге бер даһига мохтаҗ булган ич. Атына атланып походка чыгамы, сунарга барамы, чит җирләргә сәяхәткә китәме, — кая барса да, ни эшләсә дә, аңа изге күңелле көчле бер таяныч, яклаучы һәм сакчы кирәк. Шулай булгач, ат дирбиясенә бер генә изге рух сурәте дә такмыйча йөрергә мөмкинме? Ә бәлки төрле җан ияләренең шушы рәвешчә бер сурәт итеп берләштерелүендә без урта гасыр кешеләренең (әлеге очракта болгар бабаларыбызның) үзенчәлекле тормыш фәлсәфәсен күрәбездер? Яхшы белән яманның мөнәсәбәтен, бу ике башлангычның тормыштагы үзара мәңгелек көрәшен алар шушы сурәт аша гәүдәләндергәннәрдер? Кешеләрнең тормышы, эчке дөньялары каршылыклардан һәм көрәштән һичкайчан азат булмаган ич.

Мәскәүнең А. С. Пушкин исемендәге сынлы сәнгать музеенда VII—VIII йөзгә караган кабер ташы саклана. Монда да без шул ук мотивны күрәбез. Орлык чүпләүче ике кошчык сурәте бергә кушылып, тешләрен ыржайткан коточкыч бер җанвар хасил итә.

Ә без тикшерә торган сюжетның чыганаклары кайда ята соң? Ул карачкыда барлык җан ияләренең башлангычы гәүдәләнмиме, кеше дә, барс һәм болан да, барлык кош-кортлар да, борынгылар фикеренчә, шулардан аерылып чыкмаганмы?..

Дөньяның барлыкка килүе, җир йөзендәге тормыш-яшәешнең башланып китүе турындагы легенда... Урта гасыр кешесе, ихтимал, шушы сурәт аша тормыш мәгънәсен, дөньядагы бар нәрсәнең бердәм булуын чагылдырырга тырышкандыр? Һәм, ихтимал, шушындый карачкылар, төрле җәнлек сурәтләнмешләре буенча элек яшәгән халыкларның (бу очракта, болгарларның) телдән сөйләнгән легендаларын, мифларын тергезергә мөмкин булыр. Ул сурәт-образларның үз теле бар, алар нинди дә булса бер билге — знак, гүя ки дөнья турында сөйләүче бер китап булып хезмәт итәләр. Минемчә, без аларны элеккеләр хакында соңгы буыннарга билгеле бер информация алып килүче үзенчәлекле кульъязмалар дип тә карый алабыз. Сурәт-образлар, әлбәттә, бик борынгы заманнарда туган. Ул дәверләрдә халыкның тормыш-көнкүреш рәвеше үзгәрү процессы гаять дәрәҗәдә акрын барган, һәм шуңа күрә дә, сәнгать-һөнәрчелек өлкәсендә төрле мотив һәм сюжетлар сайланып һәм сакланып килә-килә, даими төс алганнар. Мондый шартларда исә аерым бер остага үз эшендә новаторлык ысулы куллану, үзе ясаган әйберләргә нинди дә булса яңалык кертү, һәвәскәрлек белән шөгыльләнү мөмкин дә булмагандыр. Көнкүреш сәнгате халыкның үзара аңлашу чарасы, билгеләр системасы, аның үзенчәлекле «теле» булып әверелгән.

Нибарысы берничә сәнгать әсәрен — кыңгыравыклы колак алкасын, «Җайдак кыз» һәм ат дирбиясенә беркетелә торган сөяк эллипсны (накладка) бер-берсе белән чагыштырып карау да әнә нинди кызыклы сиземләнүләр, фикерләр уята. Аларның һәрберсе үзенчәлекле, һәркайсы төрле гасырда эшләнгән, башкарылу осталыгы ягыннан да бер дәрәҗәдә түгелләр. Әмма алар өчесе дә халык сәнгате җимешләре булуы, борынгы болгарларның тормышны, табигатьне ничек күзаллауларын гәүдәләндерүләре белән кыйммәт. Алар безнең ата-бабаларыбызның рухи дөньясы табигатькә бик нечкә, тыгыз җепләр белән бәйләнгән булуы турында сөйли.

Һәм бу күренешнең төбендә нинди дә булса очраклылык түгел, ә тирән закончалык ята. Сәнгатьтә берни дә очраклы рәвештә тумый. Аның теләсә кайсы чылбыры тегеләй дә, болай да түгел, ә билгеле бер тәртиптә, үз рәвешендә генә була ала. Урта гасыр болгар сәнгатенә халыкның эчке дөньясын сиземләү аша, аның мифлары, сөйләк һәм риваятьләре аша гына якын килергә мөмкин.

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре кандидаты.
**Әнвәр Хәйруллин,**
фәнни хезмәткәр.

# МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ХӘРӘКӘТЕ КАРЛЫГАЧЫ

*Г. Курсавиның тууына 200 ел тулу уңае белән*

Россиянең экономик һәм культура тормышындагы үзгәрешләр, иҗтимагый фикер үсеше һәм революцион омтылышлар XVIII гасыр азакларында ук татар халкы арасында үзенең тәэсирен күрсәтә башлый. Капиталистик мөнәсәбәтләрнең үтеп керүе гасырлар буена яшәп килгән традицияләрне какшата, акрынлап гамәлдәге социаль тәртипләргә һәм урта гасырчылык күренешләренә каршы протест тенденцияләре тарала, аерым даирәләр буржуаз-демократик ирек лозунглары күтәреп чыгалар. Бер төркем буржуалашкан ясаклы татарлар Екатерина II оештырган комиссиягә җибәргән наказларында, мәсәлән, болай дип язалар: «һәр кеше үзенең табигате белән нәрсәгә дә булса сәләтле булып туа; төрле катлаулардан чыккан кешеләрнең игенчелек хезмәтенә күнегүләре дә, үзләрен коммерция эшенә багышлаулары да мөмкин. Кеше рухына тынычлыкны бары тумыштан бирелгән ирекне сакланганда гына таба һәм ул иминлеген һичнинди көчләүсез, үз ихтыяры белән тәэмин итәргә хаклы. Рус дәүләтеннән читтә эш итәргә теләгән һәр кеше, әгәр үзенең кире әйләнеп кайтачагына ышанычлы дәлилләр китерсә, император җәнабләренең башка бәндәләре кебек ук, һичнинди тоткарлыксыз паспорт белән җибәрелсен: коммерциядә беркем дә үзенең кәсебеннән мәхрүм ителергә тиеш түгел». (Русское историческое общество, 115 том. СПб, 1903 ел, 375 бит.)

Шул ук вакытта халык массалары арасында социаль һәм милли изелүдән котылуга омтылыш та көчәя бара. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында татар хезмәт ияләренең актив катнашуы — моның ачык бер мисалы.

Халыкның иҗтимагый аңындагы бу үзгәрешләр идея-теоретик яктан мәгърифәтчелек хәрәкәтендә чагыла. Татарлар арасында бу хәрәкәт XVIII гасыр азагында һәм XIX гасыр башында формалаша башлый һәм аның нигезендә халыкны урта гасыр торгынлыгыннан фән һәм прогресс мәйданына, ислам идеологиясенең кысан рамкаларыннан мәгърифәт дөньясына чыгаруга омтылыш ята. Г. Курсави, И. Хәлфин һәм

Утыз Имәни (Әл-Болгари) шушы прогрессив хәрәкәтнең беренче карлыгачларыннан булдылар.

Күренекле галим, татар иҗтимагый фикерендә рационалистик агымга нигез салучыларның берсе Габденнасыйр Курсави (Әбүнасыйр Габденнасыйр бине Ибраһим бине Ярмөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави) 1776 елда[1] Казан губернасы Курса авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне ул Малмыж өязе, Мәчкәрә авылы мәдрәсәсендә ала. Гаять сәләтле һәм белемгә омтылучан бу баланы мәдрәсәдә биргән белем генә канәгатьләндерми. Ул үзлегеннән дә күп укый һәм кайбер мәсьәләләрдә остазларыннан өстенрәк фикер йөртә башлый. Мәдрәсәне тәмамлагач, Г. Курсави ул вакыттагы традиция буенча заманының гыйлем һәм мәгърифәт үзәге саналган Бохарага укырга китә. Андагы күренекле мөдәррисләрнең берсе — Мөхәммәт Нияз Колый әт-Төрекмәнидән дүрт ел буе дәресләр ала. Бохарада узган елларында ул һәръяклап дини тәгълиматны өйрәнә, бик тырышып көнчыгыш телләрен үзләштерү өстендә эшли, күренекле шагыйрьләрнең һәм урта гасырда яшәгән фикер ияләренең әсәрләре белән таныша. Укуын тәмамлап туган якларына кайткач, Курса авылында ул зур мәдрәсә ача һәм үз тирәсенә шәкертләр туплап, мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалый башлый. Кыска гына вакыт эчендә тирә-якта зур дан казанып өлгерә.

Мәгърифәтче галимнең көчле акылы, тирән укымышлылыгы бик күпләрне сокландыра. «Курсавиның гыйлемдә улан мәртәбәсе шул дәрәҗәдә иде ки,— дип искә ала аның фикердәше булган Әхмәд бин Сәгыйть әш-Шырданый,— һәр фән бабының дәлилләренә һич кемнең иганәтеннән (ярдәменнән) башка вә һичбер китабә мөрәҗәгать итмәй, күңеленнән баян идәргә мөкътәдир иде». (Р. Фәхретдинов. Асар, III ж., Оренбург, 1903 ел, 122 бит.) Курсавиның башка замандашлары да шуны ук куәтли. Аның турындагы истәлекләрнең берсендә: «Нәзары дәкыйк (карашы анык), китаб вә сөннәт гыйлемнәренә маһир, иҗтиһады (тырышлыгы) куәтле, истинбаты (нәтиҗә чыгару) тугры иде», диелә. (Шунда ук, 123 бит.) Курсави турында замандашларының фикерләрен бергә туплап, Риза Фәхретдинов аның «озын буйлы, киң маңгайлы, олуг күзле, үткен сүзле, арык вә риязый (ябык гәүдәле), табигате зәки (зирәк), фитънәте (үткенлеге) кямил, фәһме (аңлавы) дөрес, җавабы сәригъ (тиз), хитабы бәдигъ (сөйләшүе матур), зиһене мөстәкыйм (туры), вәкарьле (горур)» булганлыгын күрсәтеп үтә. (Шунда ук, 99 бит.)

Курсавидагы бу сыйфатлар дуслары һәм фикердәшләрендә соклану хисе уятса, дошманнарын, киресенчә, калтырарга мәҗбүр итә. Соңгылары, җае чыкканда, аның белән очрашудан кача торган булганнар. Чөнки һәр нәрсәдән мәгълүматлы, туры һәм үткен сүзле галим белән бәхәскә кереп кеше көлкесенә калганчы, аның күзенә чалынмауны мәгкульрәк күргәннәр. Шундый берничә фактны Ш. Мәрҗани үзенең «Мөстәфад әл-әхбар»ында күрсәтеп үтә. «Бер вакыт,— дип яза ул,— Муса бай мөлла Фазылны иртә белән чәйгә алмага җибәреп, кариб (якын) килүб җитдектә хадимдән (хезмәтчедән) кунак я мәҗлес бармы дип сорагач, юк, Курса мулласы гына бар дип җавап биргәч, гарәбәсендән (экипаж) төшеп би-ля тәвәккыф (туктап та тормыйча) җәяүләп Яңа бистәгә кайтуб китмеш, вә бер мәҗлесенә мөлла Ибраһим әфәнде вә Дәмади мөлла Таҗетдин әл-Иштирәки тәкрар дәгъват иделүб (кабатлап чакырылып тә) вармай калмышлар». (Ш. Мәрҗани. Мөстәфад әл-әхбар... II том, Казан, 1900 ел, 169—170 битләр.)

Курсави уннан артык фәнни хезмәт язып калдыра. Алар арасында иң мәшһүре — «Әл-иршад лил-гыйбад» (Кешеләрне туры юлга өндәү) исемле китап. Татар иҗтимагый фикер тарихында бу хезмәт күренекле роль уйный. Халкыбызның рухи тормышында аның урынын билгеләп Г. Сәгъди: «Әл-иршад лил-гыйбад» үзе тәнкыйди

---

[1] Г. Курсавиның туу һәм үлү еллары төрле чыганакларда төрлечә күрсәтелә. М. Гайнуллин «Татарская литература XIX века» (Казан, 1975 ел, 9 бит) дигән хезмәтендә 1776—1818 елларны атый. В. Гороховның «Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья» (Казан, 1941 ел, 151 бит) дигән хезмәтендә 1788—1814 еллар күрсәтелә. К. Насыйри аның тормышын 1765—1813 (календарь, 1877 ел, 43 бит), Җ. Вәлиди 1783—1814 (Очерк истории образованности и литературы волжских татар. Мәскәү-Петроград, 1923 ел, 33 бит), Г. Сәгъди 1776—1813 (Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926 ел, 21 бит), Х. Хисмәтуллин 1770—1813 (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 22 фонд, 1 теркәмә, 20 саклау берәмлеге, 3—4 битләр) еллар белән чикләләр. Ш. Мәрҗани белән Р. Фәхретдинов хезмәтләрендә 1776—1812 еллар әйтелә.

бер әсәр, ул (Курсави) моның белән гәрчә гарәп телендә булса да, татарда беренче мәртәбә тәнкыйть юлын ача. Аның тәнкыйде дә каты, ачы. Әлбәттә, әдәби тәнкыйть түгел, дини, фәлсәфи, бер тәнкыйть» (Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1926 ел, 22 бит.),— дип язды.

«Әл-иршад лил-гыйбад» әсәрендә, шулай ук башка китапларында һәм күп санлы чыгышларында Г. Курсави искелекне, туңлыкны ачы тәнкыйть уты астына ала, патриархаль йолаларны, урта гасырчылык тәртипләрен аклаучы идеологик өскормаларны фаш итә, схоластиканың һәм фанатизмның чын йөзен ачып бирә. «Курсави,— дип яза Ш. Мәрҗани аның эшчәнлегенә бәя биреп,— хәдисләр, борынгылар өйрәтүе белән күзләре томаланган галимнәр һәм надан руханилар янында үзенә урын тапмады. Алланың сыйфатлары һәм мәҗбүри үтәлергә тиеш булган дини кагыйдәләрнең күплеге, борынгы шәхесләргә табыну кирәклеге турында сөйләүчеләр юлыннан бармады. Аның өчен фәнни чыганаклар бар нәрсәдән дә өстен иде... Гомумән, ул дөреслек сөюче галим ир иде». (Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк очрый торган кульъязмалар бүлеге. Ш. Мәрҗани. Вафият-әл-әслаф вә тәхият-әл-әхлаф (Борынгыларның үлеме һәм аларның киләчәк буынга бүләге), 6 том, 146 бит. Авторлар тәрҗемәсе.)

Курсави халыкның киләчәге, аның прогресс һәм мәгърифәт юлына баса алуы фәнни белемнәр һәм мәдәният таратуга бәйләнгән дип карый һәм, шуннан чыгып, мәдрәсәләр салу, китаплар язу эшенә өнди, гасырлар буена яшәп килгән иске традицияләрне җимереп, хакыйкатьне эзләргә чакыра, фикергә ирек даулый, кеше акылын богаулап торган чылбырларны өзәргә омтыла.

Курсави, беренчеләрдән булып, руханилар кулында хөр фикергә каршы корал итеп файдаланылган бик күп догматик кагыйдәләрне фаш итә, дин һәм алла исеме белән халыкның аңын томалау өчен тырышкан консерватив муллаларның чын йөзләрен ачып бирә. Дөрес, аның хезмәтләрендә без әле турыдан-туры дини тәгълиматны тәнкыйтьләүне күрмибез һәм бу гаҗәп тә түгел. Мондый тәнкыйтькә Курсави яшәгән чорда объектив җирлек тә юк, моңа ул субъектив яктан да әзер түгел иде. Мәгърифәтче галим моны үзе дә аңлый һәм заманының кара көчләренә каршы көрәштә кулайрак юллар эзли. «Шуны белергә кирәк,— дип яза ул,— безнең гасырыбыздагы һәм үткән гасырдагы адәмнәр арасында шундыйлар бар: алар гыйлемнән бер төрле дә өлешләре булмаган хәлдә үзләрен гыйлем кешеләре рәтенә куялар. Менә шуларның тудырган сүзләрен хикәя кылу һәм сүзләренең бозыклыгын ачып бирү өчен алардан аерым битләр ачсам бик яхшы булыр иде. Шулай итеп, наданлыктан һәм наданнардан качу, алардан йөз дүндерү, наданлыкны үтерү, ул наданнарның исемнәрен үк югалту өчен бик яхшы эш эшләнгән булыр иде. Ләкин эшнең соңы начар булып чыгудан... аларның яңлыш булган бер игътикадка, галимнәр каршында ташланган сүзләргә ышанырга ашыгуларыннан куркып, бу юлны тотмадым. Хосусан, гыйлем әһеленең киеме белән киенеп тә, караңгылык ишекләренә ябышып ятучы кешеләрдән курыктым. Шуның өчен тик аларның сүзләренең бозыклыгын гына ачып бирүне, сүзләрен читкә кага баруны гына халык өчен муафыйграк һәм нәтиҗәсе яхшырак булыр дип таптым». (Г. Курсави. Әл-иршад лил-гыйбад. Казан, 1903 ел, 2 бит. Гарәпчәдән безнең тәрҗемә.— Авторлар.) Бу юллардан күренгәнчә, Курсави искелеккә каршы көрәшнең нәтиҗәлерәк чараларын табарга тырыша, искелек сагында торучы көчләрнең йомшаграк урыннарын эзли һәм, һөҗүмен шунда юнәлтеп, бу көчләрнең бердәм фронтын какшатырга, алар өчен изге саналган идеологик өскорманың заман таләпләренә җавап бирмәвен ачып салырга уйлый.

Дөньяга караш мәсьәләсендә Г. Курсави әле идеализм чикләреннән чыкмый, алланың барлыгын һәм берлеген таный. Шул ук вакытта ул дини бәхәсләрдә мөтәкәллимнәр (дини тәгълимат — кәлям вәкилләре) тарафыннан ифрат дәрәҗәдә куертылган алланың сыйфатлары турындагы өйрәтмәләрне кискен тәнкыйть итә. «Алланың күп төрле сыйфатларын, исемнәрен, дөньяны, табигатьне һәм барлык җан ияләрен барлыкка китерүен һәм башка төрле мөмкин булган сыйфатларын,— дип саный ул,— бары тик кешеләр үзләре генә уйлап чыгарганнар, сөбхане рәббикә рәббе-әл-гыйззәте гамма ясыйфунә, ягъни үзен ничек итеп сыйфатлауга алла мохтаҗ түгел, ул аннан ерак тора. Аны төрле кисәкләргә, саннарга бүлгәләргә һәм аерырга һич кирәк түгел. Алланың сыйфатлары: ишетүе, күрүе, бөек акылы, кулы һәм йөзе

юк... Ул күп төрле һәм күп санлы була алмый. Алланың сыйфаты бер генә һәм бары үзе өчен генә». (Р. Фәхретдинов. Асар. III ж., 99 бит.) Бу өземтәдән күренгәнчә, Г. Курсави, беренчедән, алланың сыйфатлары турындагы бәхәсне дә, аңа тагылган сыйфатларны да дин галимнәре уйлап чыгарган бер уйдырма гына итеп карый һәм, икенчедән, аны күрсәтелгән сыйфатлардан аерып, абстракт төшенчәгә әйләндереп калдыра. Бу иҗтимагый һәм философик фикернең ислам дине кысаларында гасырлар буе формалашкан төшенчәләрен какшату-җимерүдә мөһим бер адым иде һәм ул Г. Курсави эшен дәвам иттерүчеләргә дөньяга караш мәсьәләсендә тагы да кыюрак фикерләр күтәреп чыгу өчен җирлек булды. Моны без Ш. Мәрҗани мисалында ачык күрәбез. Мәрҗани мөтәкәллимнәр белән алла һәм аның сыйфатлары турында бәхәс алып барганда, алланы официаль дини тәгълимат вәкилләре тарафыннан тагылган сыйфатлардан арындырып, яшәешнең нигезендә ятучы абстракт бер принцип — мәңгелек (кыйдам) дип саный. Шул ук вакытта ул, алланың табигатькә мөнәсәбәтен турыдан-туры тасвирлауга кучкәч, пантеизм позициясенә баса һәм аны туктаусыз яңаручан һәм конкрет әйберләрнең барлыкка килүенә җирлек булган мәңгелек табигать белән тиңләштерә.

Курсави мөтәкәллимнәрнең философияне дини тәгълимат казанында эретүләре белән дә килешә алмый һәм бу аның кәлам турындагы фикерләрендә ачык чагыла. Билгеле булганча, кәлам, мөтәкәллимнәрнең күп гасырларга сузылган тырышлыгы белән, нигездә дини философия булып формалаша. Аның тарафдарлары дөнья һәм аның конкрет әйберләренең яратылышы мәсьәләсен шәригать кануннары нигезендә хәл итәргә тырышалар. Курсави фикеренчә, бу урынлы түгел һәм кәламне баштанаяк дини тәгълимат белән тәңгәлләштерергә ярамый. «Шуны белегез ки, и дөреслек юлыннан баручы барлык сәләфләребез,— дип яза ул. — Алланың берлеге һәм аның сыйфатлары турындагы өйрәтүләр фәкать мәҗбүри дини кагыйдәләрнең эчтәлеге һәм шәригать рөхсәт иткән эшләрнең нигезе генә... һәм ул өйрәтүләр генә кәлам фәнен тәшкил итмиләр. Кәлам фәне ул фәлсәфәгә керә торган фән». (Р. Фәхретдинов. Асар. III ж., Оренбург, 1903 ел, 26 бит.— Авторлар тәрҗемәсе.) Күренүенчә, кәлам — философик фән, ә философия коры дини өйрәтүләр белән генә чикләнми һәм аның проблемаларын шәригать кануннары нигезендә генә хәл итәргә ярамый. Фикерен раслау өчен ул борынгы грек философларына мөрәҗәгать итә, кәламнең ислам дөньясына алардан килеп кергәнлеген һәм аларда аның рамкаларында киң философик мәсьәләләр каралганлыгын күрсәтә.

Курсави яшәгән чорда искелекнең һәм фикри туңлыкның төп терәкләреннән берсе тәкълидчелек була. Һәр төрле фанатиклар, дини тәгълимат әһелләре һәр фикергә каршы көрәш алып барганда шуңа таяналар, борынгылар сүзенә турылыклы булырга өндиләр, патриархальлек традицияләреннән тайпылмаска һәм күптән яшәгән мөселман авторитетлары тәгълиматына сукырларча ышанырга чакыралар. Мәгърифәтче галим моңа кискен рәвештә каршы чыга һәм искелеккә яраклашып йөрүче надан тәкълидчеләрдән көлеп түбәндәге юлларны яза: тәкълидчеләр «безнең илебезнең яки теге илнең галимнәре фәләнчә фәтва биргәннәр. Без дә шушы фәтвадагыча гамәл итәргә тиешбез. Чөнки аларның фәтвасына каршы чыгу диннән йөз чөерү булыр иде,— диләр... Фәлән китап фәлән шәһәрдә фәлән вакытлардан бирле мәшһүр. Димәк, анда икътикад (дини инану) һәм гамәли мәсьәләләрдән булган барлык хөкемнәр хак, аңа каршы килү һич ярамый. Аңа каршы чыгучы — ул явыз, азгын кеше, ул кяфер булып санала, аны үтерү хәләл, хәтта тиеш, аны үтерүче савaплы булачак,— диләр. Бу сүзләрне сөйләүчеләр бидгатьчеләр (яңалык кертүчеләр) артыннан нясеннән һич аерылмый торган эт кебек ияреп йөрерләр. Син аларга меңләп ныклы дәлилләр китерсәң дә, хәтта алар аны үз күзләре белән күрсәләр дә, үзләренең кимчелекләрен танымаслар, күзебез ялгышты, без сихерләндек, диярләр». (Г. Курсави. Әл-иршад лил-гыйбад. Казан, 1903 ел, 40 бит.)

Кемнәрнең дә булса әйткән сүзләре яки кылган гамәлләре белән гамәл кылу, борынгы авторитетларның сүзләрен һәм эшләрен көндәлек практикада дәлил итеп алу, Г. Курсави фикеренчә, бары «караңгылык һәм наданлык әһелләре уйлап чыгарган бер нәрсә генә». (Шунда ук, 42 б.) Зур авторитет саналган борынгы дини галимнәр һәм закон чыгаручылар да — кешеләр. Алар замандашларыбыз табына торган дини кагыйдәләрне һәм законнарны эзләнү юлы белән иҗат иткәннәр. Һәм бу эзләнү

процессында аларның дәреслеккә тап булулары да, ялгышулары да мөмкин. Шулай булгач, алар әйтеп калдырганнарга сукырларча ышану зур ялгышлык. Аерым кешеләрнең әйткәннәре, алар нинди генә зур авторитет саналмасыннар, уйламыйча-нитмичә ышана торган дәлил түгел. Һәр кеше үзенең кылган гамәленә акылы белән ышанычлы дәлил эзләргә тиеш.

Бу уңайдан Г. Курсави «иҗтиһад мөнкарыйз» төшенчәсен дә читкә алып ташлый. «Кайберәүләр,— дип яза ул,— инде иҗтиһад белән шөгыльләнү заманнары күптән узып киткән, мөкаллиднең (иярүченең, хәзерге заман кешесенең) дәлиле бары мөҗтәһиднең сүзе генә булырга мөмкин, без үзебез уйлап эш итүдән гаҗизбез, аңа ихтыяҗыбыз калмады,— диләр». Болар, мәгърифәтче галим фикеренчә, «фахиш, гаять бозык сүзләр», алар «халык арасында җаһиллек — караңгылык тараталар». (Г. Курсави. Әл-иршад лил-гыйбад. 29, 30 битләр.) Юк, иҗтиһад гасыры узмаган. Һәр кеше, кайчан гына булмасын, үзенең көче җиткән кадәр уйлап, иҗтиһад белән эш итәргә тиеш.

Шулай итеп, Г. Курсави борынгы авторитетларга сукырларча ышанудан баш тарта һәм хакыйкатьне эзләп табуда һәр кешегә тулы хокук бирелүен таләп итә. Ул кешеләрне, гасырлар буена яшәп килгән традицияләрне җимереп, акыл үсешенә, аек фикергә турылыклы булырга, аңа ирек бирергә чакыра.

Курсави йөзендә без шулай ук ислам дөньясында киң таралган мистик агым — тәсауууфның (суфичылыкның) аяусыз бер дошманын күрәбез. Үзенең әсәрләрендә һәм чыгышларында ул тәсауууфка тирән күренешләрен, һәр төрле суфичылыкны һәм ишанлануларны фаш итә. «Безнең гасырыбызда һәм үткән гасырларда,— дип яза ул,— халык арасында тәсауууфка бирелү, «иршад» (изге юлга күндерү) һәм «истиршад» (изге юлга күнделү) ны дәгъва кылу таралып китте. Ләкин моны дәгъва кылучылар тәсауууфның чын мәгънәсен һәм максатын белмиләр. Нәтиҗәдә алар берсе өстендә икенчесе булган катлаулы караңгылык эчендә томаланалар; гүяки болар төпсез диңгезгә батканнар да, анда дулкын өстенә дулкын күтәрелеп, аларны һаман каплый, баса бара». (Г. Курсави. Әл-иршад лил-гыйбад. 51 бит.) Шулай итеп, мәгърифәтче галим үрмәкүч пәрәвезе кебек халыкның аңын томалаган суфичылыкны коточкыч караңгылык һәм төпсез диңгез белән тиңләп, аның мәкерле тозагына эләгүдән кисәтеп куя, ә эләксәң исән чыгуың шикле булыр дигән фикерне искәртә. Әгәр без Г. Тукайның әле Беренче рус революциясеннән соң язган шигырьләрендә дә суфиларны һәм ишаннарны сүгеп чыгуын, Ф. Әмирханның да аяусыз көрәш алып баруын искә төшерсәк, аларга кадәр 100 ел элек яшәгән Курсавиның суфичылыкка каршы чыгышы ни дәрәҗәдә әһәмиятле булганлыгын ачык күз алдына китерә алырбыз.

Курсавиның бу кыю фикерләре искелек сагында торучы бөтен кара көчләрнең, шул исәптән, үзләрен галим санап йөргән фанатикларның, әлбәттә, ачуын китерми калмый. Алар аны диннән язуда гаепләләр, «кяфер», «зиндикъ», «даһри» дип каргыйлар. Дини фанатизм хакимлек иткән ул заманда мондый хәтәр сүзләр үзләре үк үлем җәзасына хөкем итү белән бер булган. Ахыр чиктә эш шуңа барып җитә дә. Бу вакыйга Бохарада, Ш. Мәрҗани китергән мәгълүматларга караганда, 1808 елда була. Бирегә Курсави үзенең иске таныш-белешләре белән очрашу, андагы галимнәр белән үзен борчыган мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен килә. Очрашулар вакытында аның белән Бохара голәмасы арасында дини-философик бәхәсләр чыга һәм үзенең туры сүзе, көчле дәлилләре, ачык фикере белән ул бу бәхәсләрдә өстенлек ала. Ачудан ярсыган голәма «үзсүзле» бу татарның көфер сүзләре турында Бохара әмире Хәйдәргә җиткерә. Әмир Хәйдәр Г. Курсавиның үзен тыңлап карарга теләк белдерә һәм, зур голәма мәҗлесе чакырып, аның катнашы белән мөназара (дини-схоластик диспут) оештырырга боера. Р. Фәхретдинов җыеп калдырган мәгълүматларга караганда, гадәттәге голәма мәҗлесләрендә тәртипсез һәм мәгънәсез шау-шулардан туеп беткән Г. Курсави, моны ишетеп, хәтта шатлана да. Ул әмир Хәйдәрнең үзе катнашында узачак мондый зур мәҗлестә сорауларга иркенләп җавап бирергә һәм үзенә дә сорау куярга мөмкин булыр, фикерләр ачыкланыр, ә соңыннан зур белгечләр тарафыннан һәр яклап анализ ясалыр һәм төпле йомгаклау сүзе әйтелер дип уйлый. Шуңа ышанып, үзенең фикерләрен мәҗлестә ачыктан-ачык бәян итә. «Солтанәтле улан бу мәҗлестә,— дип яза Р. Фәхретдинов,— Г. Курсави максадын сабыр вә

вәкарь үзрендә изах әйләмеш (аңлатмыш); ничә сәнәләрдән бирле низам (тәртип) үзрендә сөйләмәя хәсрәт чигүб йөрмеш улан морадыны да зә әл-мәҗаз (күчерелмә мәгънәдә сөйләшүчеләр) вә яки гакяз (таякка таянып йөрүчеләр) мәйданында таяк тотып сөйләмәктә улан гарәп хатибы мисалында (вәгазь сөйләүче кебек) тәкърир (аңлатып сөйләү) идәрәк, хәзари хәйран (аптырап калган шәһәр халкын) вә хәсымларының (дошманнарының) шөбһәләрене әсасыннан (тамырыннан) вәйран итмештер (җимерде)». (Р. Фәхретдинов. Асар. III җ., 120 бит.)

Г. Курсави үзенең фикерләрен шул кадәр дәлилләп сөйли ки, аның белән бәхәскә ярсып килгән голәма ни дип җавап бирүдән дә гаҗиз кала. Соңыннан бу вакыйга турында мөлла әбүән-Нәгыйм мәхдүм дигән берәү: «Мөлла әбү ән-Насыр Бохара голәмаларыны һәммәсене бер тишеккә тыгып китте»,— дип искә ала. (Ш. Мәрҗани. Мөстәфад әл-әхбар... II кисәк, Казан, 1900 ел, 169 бит.)

Ләкин иске кануннарга ябышып ятучы әмир Хәйдәр дә, Бохара голәмасы да Г. Курсави күтәргән мәсьәләләрне аңлаудан ерак торалар. Алар аның фикерләрендә бары диннән язуны гына күрәләр. «Аның сүзене фәһем итәрлек куәт,— дип яза соңыннан Бохара голәмасыннан берәү,— безем галимләрдә булмады». (Р. Фәхретдинов. Асар, III җ., 120 бит.) Ә әмир Хәйдәр «диннән язган» бу татарның башбаштаклыгына чик куярга була һәм аны ислам кануннарын бозган өчен үлем җәзасына хөкем итә. Хөкем карары әмир Хәйдәрдән тыш реакцион руханилардан 16 кешенең имзасы белән беркетелә. Җәзалау көне килеп җитә. Әмир Хәйдәр сәясәт мәйданына[1] килеп үзенә билгеләнгән урынга урнаша. Тоткынны крепостьтан алып чыгып көчле сак астында мәйданга китерәләр. Аның ике ягына ялангач кылычларын өскә күтәреп ике җәллад баса. Курсавиның гомерен саклап калу теләге белән, дуслары аңа «акылга килергә» һәм эшләгән гөнаһысы өчен «тәүбә кылырга» киңәш итәләр. Дусларының киңәшен тыңлап, ул үлем җәзасыннан котылып кала. Ләкин Курсави үзенең фикерләреннән баш тартырга уйлап та карамый һәм яңадан да әмир Хәйдәр хөкеменә дучар булмас өчен Бохарадан качып китә. Ватанына әйләнеп кайткач, ул элеккечә үк, мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалавын дәвам иттерә, дини-философик бәхәсләрдә үзенең мәгълүм позициясен яклый. Ш. Мәрҗани күрсәткәнчә, әмир Хәйдәр соңыннан үзенең өч хатасы турында бик үкенеп сөйли торган була. Бу өч «хата»ның берсе Курсавины җәзаламыйча калдыруы була. «Ул һаман да Курсавига үч тотып йөрде һәм «бозык караш»ы өчен аны бетәрләүдән туктамады. Үзенең үчен бастыру өчен ул аны үзенең ватанында да үтерергә әзер иде». (Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең сирәк очрый торган кульязмалар бүлеге, № 614 (г). Ш. Мәрҗани. Вафият әл-әсләф... 6 том, 146 бит.)

Әмир Хәйдәргә артык борчылырлык урын юк иде. Чөнки аның фикердәшләре биредә дә мәгърифәтче галимгә тынгылык бирмиләр. «Казанга килгәч,— дип яза шагыйрь Гали Чокрый бу турыда ачынып,— мөлла Габденнасыйр әл-Курсави хәзрәтләренә дә бәдәхаһлар (яманлык теләүчеләр) булгандыр вә нәчә кемсәнәләр аңа тәгъян (кысрыклау) кыйлгандыр». (Н. К. Крупская исемендәге Башкортстан республика китапханәсе, крайны өйрәнү бүлеге. Гали Чокрый фонды, № 4013, 5 дәфтәр, 3—5 битләр.) Чыннан да Г. Курсавины ватанында да диннең нигезләрен тәшкил иткән кагыйдәләргә тискәре карашта булуда, дәрестә үзенең зарарлы фикерләрен сөйләп яшьләрне бозуда гаепләүләр. Курсави өстеннән Диния назаратына доноснар яудырыла. Мисал итеп, Казаннан ерак булмаган Өре авылының указлы имамы, ахун Фәтхулла Хөсәен улының мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәеновка 1810 ел, 11 ноябрьдә язган хатын китерергә мөмкин. «... Шул хосусда ки,— дип яза бу хатның авторы,— Казан округында, Югары Курсада Габденнасыйр Ибраһим углы мөҗтәһидлек дәрәҗәсен дәгъва кылып, Гомәрән-Нәсифигә (X гасырда яшәгән Урта Азия галиме.— Авторлар) комментарий бирел, нигездә асылы бозык булган үзенең карашын үз теләге буенча билгеләп, алланың тиешле булган (мәҗбүри) сыйфатлары һәм бөек үзенчәлекләре фәкать үзе өчен генә (ә безнең өчен түгел, ягъни алланың барлыгы, аның сыйфатлары безнең аңыбызга бәйле түгел), дип сөйләп һәм алланың сыйфатларын күплеген инкарь итеп, борынгы

[1] Сәясәт мәйданы — политик тоткыннарны җәзалау урыны.

традицияләрнең үсүе, дәвам итүе белән бергә аек фикергә дә турылыклы булырга кирәк дип сөйли. Һәм шундый сүзләре белән, дини мәсьәләләр буенча дүрт йөз елдан алып бу заманга кадәр, артык тырыш мөҗтәһидләр һәм күренекле галимнәрнең алмашчысы булган — галимнәр галиме Тәфтазани, хаклык эзләүче галим Дәвани һәм Сәед Ширази һәм аларга охшашларны хурлап, аларга каршы чыгып, дөрес юлдан читкә тайпылып, ялган һәм начар юлга басты. Һәм менә шул дүрт йөз елдан бирле көнчыгышта булсын, көнбатышта булсын, тулы нигездә яратып укылган һәм кулланылышта булган дини тәгълиматны өйрәнү буенча китаплар укыган мәдрәсәләрне чынбарлыктан читкә тайпылдырып (?!) һәм ул китапларга иярүне, ышануны тыеп, кайбер авылларга барганда хак юлдан җитәкләүче җәмәгать намазына бармый. Ислам диненең байрагы булган җомга һәм гаедләрне нигездә ташлый, яңача яшәргә кирәк, — дип, үзенең эшен галим затлар арасында булган йокымсыраган муллалар белән дәвам иттерүне мәгъкуль күрә. Тәкәбберләнеп, горурланып имтихан бирергә бармыйча (указ алу өчен Диния назаратына барып имтихан бирү турында сүз бара.— Авторлар), мәдрәсәләр салдырып әле өлгереп җитмәгән, башлангыч сыйныф укучыларын үз тирәсенә туплап һәм янына җыйналган наданнарны эшкәртеп, «дәрес бирәм», —дип, мөселман диненә ышануны боздырып, ялган һәм бозык юлга тарта. Аның мәдрәсәсен тәмамлап чыккан ничәмә-ничә укучылары, электә җомга һәм гаедне калдырмаган авылларга имам булып баргач, мөселманнарны изге гыйбадәт кылу урыннары булган җомга һәм гаедләрдән мәхрүм иттеләр. Сез бөек җәнабыбызга мәгълүм булсын: дингә ышануны яңача уйлап табучы (реформатор) һәм динсезлеккә илтүче буларак, бу реформаторның эше кяфер эше булып, аны (Курсавины) хурлап кына, аңа йомшаклык күрсәтергә ярамый. Динсезлеккә илтүче сәбәпнең иң зурысы тагын шул: Бохарадагы вакыйгаларга кадәр үк, ул алланың барлык тереклекне барлыкка китерүен бутады, аңа ышанмады, инкарь итте. Ул реформаторга кяфергә караганда да катырак җәза бирергә кирәк...» (Р. Фәхретдинов. Асар. III җ., Оренбург, 1903 ел, 109 бит.)

Мондый донослар мөфти исеменә бер тапкыр гына язылмаган. Күбәүләр аның якты дөньяда исән-сау йөрүенә, Бохара әмире тарафыннан җәзаланмый калуына борчылганнар. «Мөлла Җәмалетдин бин Шәмсетдин әс-Сабави, — дип яза Ш. Мәрҗани, — үзенең остазы мөлла Сәйфетдин бин Әбүбәкер әс-Сабавиның «Һай шул нәрсәне Бохарада алуб кына куймадылар ләбаса» дидекене нәкыль кыйлур иде». (Ш. Мәрҗани. Мөстәфад әл-әхбар... II т., Казан, 1900 ел, 169—170 битләр.) Мөфти дә Г. Курсави өстеннән килгән доносларны илтифатсыз калдырмаган булыр. Аның үзенә дә Бохара атмосферасы шул кадәр сеңгән булган ки, ул хәтта үзенең муллаларга булган рәсми мөрәҗәгатьләрен дә фарсы телендә төзүне артык күргән. Шуңа күрә Бохара тәртипләрен куралмаучы Курсавига аның мөнәсәбәте ничек булганлыгын күзаллау авыр түгел.

Туктаусыз эзәрлекләүләргә түзә алмыйча, дошманнарының күзеннән бераз югалып тору нияте белән, Г. Курсави туган якларын ташлап китәргә мәҗбүр була. Һиҗри белән 1227, милади белән 1812 елда ул хаҗ сәфәренә юнәлә. Юлда чума белән авырып, Төркиянең Стамбул шәһәрендә вафат була.

Шулай итеп, әле яңа гына 37 яшь тулган галим иҗатының һәм гомеренең чәчәк аткан чорында дөньядан китеп барды. Шулай да ул татар иҗтимагый фикер тарихында якты эз калдырды. «Заманында вә гасырында назыйре юк иде димиюрем,— дип яза Ш. Мәрҗани үзенең бер язмасында.— Буйлә димәк, аны дәрәҗәсеннән төшерү булыр иде. Голүм гакълия (акылга нигезләнгән фәннәр), голүм нәкълиядә (традицион фәннәрдә), мәһарәтдә (сәләтлектә), әдәб вә мөназарада (бәхәстә) мәзһәбләрне (доктриналарны) белмәктә, ... куәтле иҗтиһад, дөрес инстинбатда аның кеби кямил затны бу заман күзе биш йөз елдан бирле күрмәмеш иде. Заманасында улан адәм баласына тиңдәше юк иде». (Р. Фәхретдинов. Асар. III җ., 122 бит).

Шулай да ул вакытта Г. Курсави эшчәнлегенең әле ныклы социаль нигезе юк иде. Дөрес, Урта Азиядә дә, үз ватанында да аның тарафдарлары һәм аңа теләктәшлек күрсәтүчеләр була. Әмма алар әле аз санлы, ә искелек сагында торучы көчләрнең хакимлеге нык иде. Соңгылары тарафыннан Г. Курсави үзе генә түгел, хәтта аңа азмы-күпме теләктәшлек күрсәткән яки аның юлын дәвам иттерергә омтылган фи-

кердәшләре дә зур эзәрлекләүләргә дучар булдылар. С. Айни, мәсәлән, Г. Курсави тарафдарларыннан Хоҗанд мулласы Хаҗибатның мөселман мәктәпләрендәге укыту тәртипләре белән килешә алмаганы өчен укытучылык эше алып барудан тыелуын, ә Сәмарканд казые әбү-Сәгыйтьнең милке конфискацияләнүен күрсәтә. Ислам диненең консерватив тарафдарлары яшәп килүче тәртипләргә канәгатьсезлек белдерүләре, Коръәннең кайбер урыннарын шик астына алулары һәм аңа үзләренчә аңлатма бирүгә җөрьәт итүләре өчен Һиҗуванлы Фазылны, Вабкенттан Мөэмин Хуҗаны, Байсуннан Ходайбирдене каты хөкем җәзасына тарталар. (Кара: А. М. Богоутдинов. Очерки по истории таджикской литературы. Душанбе, 1961 ел, 261 бит.)

Бу шартларда Г. Курсави эшчәнлегенең нәтиҗәсе үз заманында зур була алмады. Монда аның дошманнарының көчле һәм күп санлы булуы белән берррәттән, рухи тонлык һәм халыкны каплап алган караңгылык та үзенең ролен уйный. Торгынлык һәм караңгылык үзенең хакимиятен дәвам иттерә иде әле. Шуңа күрә дә Г. Ибраһимов Г. Курсавиның эшчәнлеген калын кар катламы астыннан тишелеп чыккан һәм бик тиз шиңгән чәчәккә тиңләде. Ләкин аның яктылык һәм яңарыш турындагы хыяллары, караңгылык дөньясына каршы юнәлдерелгән ачы тәнкыйте халык күңелендә тирән эз калдырды. Г. Ибраһимов, Г. Курсавиның тарихтагы урынын бәяләп, аны «алгы көн йолдызы» дип атый. (Каюм Насыйри мәҗмугасы. Казан, 1922 ел, 17 бит.) Чыннан да, аның иҗаты татар халкының уяну чорында якты нур чәчеп, прогресс һәм мәгърифәт дөньясына аяк басу турында хыялланган яшь көчләрнең юлын яктыртып торды. Татарларда рационализм карашларын һәм тәнкыйть фикерләрен беренче буларак күтәреп чыккан Г. Курсавиның эшчәнлеген соңрак Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри кебек күренекле галимнәр дәвам иттерде һәм үстерде.

**Гайса Хөсәенов,**
филология фәннәре докторы

# УТЫЗ ИМӘНИ БАШКОРТСТАНДА

Күренекле татар шагыйре Габдерәхим Утыз Иманинең (1754—1834) тормышы һәм иҗаты чагыштырмача яхшы өйрәнелгән. Аның турында заманында Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани кебек атаклы галимнәр язып чыккан. Совет чорында Утыз Имәнигә багышлап Л. Җәләй, М. Гайнуллин, Ү. Беляева, Ә. Шәриповлар күп кенә мәкаләләр, хәтта диссертацияләр яздылар.

Шулай да шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты тулы өйрәнелеп җиткән, барлык кулъязмалары табылып беткән дип әйтүе кыен әле. Утыз Имәнинең тормыш һәм иҗат юлын киңрәк һәм тирәнрәк тикшерү ниятеннән чыгып, бу мәкаләдә аның Башкортстанда булуы, башкорт халкы белән аралашуы, татар шагыйренең кулъязмалары һәм аерым әсәрләре хакындагы кайбер фикерләр белән уртаклашасы килә.

Мәгълүм булуынча, Габдерәхим Утыз Имәни тынгысыз җанлы илгизәр бер кеше булган. Чистай өязенең үзе туып үскән Утыз Имән авылы мәдрәсәсендә күпмедер сабак алганнан соң, ата-анасы үлеп, үксез-ятим калгач, ул читкә чыгып киткән. Бераз вакыт Оренбург Каргалысында укыган, шуннан Урта Азиягә юл тоткан. Бохара мәдрәсәләрендә укып йөргән. Азак Сәмәрканд, Бәлех, Һират, Кабул калаларына барып чыккан. Гыйлем өстәү юлында күп галимнәр, әдипләр белән очрашкан, күп илләр күргән.

Урта Азиядә Утыз Имәни үзе дә укыту эшенә тотынган, шунда өйләнгән, байтак гомер дөнья көткән. Анда ике улы үлеп, ниһаять, хатыны Хәмидә дә дөнья куйгач, ул туган ягына кайтырга була. Кайтышлый Башкортстанга килеп юлыга.

Риза Фәхретдинов бу хакта түбәндәгечә яза: Габдерәхим Госман улы Утыз Имәни «Бохарадан кайтышлый Стәрлетамак өязе Мерәс авылында башкортлар түрәсе Локман кантон Госман улы Ибраһимовның Габдрәхим исемле югалган улы урынына ул булырга ризалык биргән. Уллыкка алу хөкүмәт органнары тарафыннан рәсмиләштерелгән»[1].

Р. Фәхретдинов анык кына әйтмәсә дә, тол калган Утыз Имәни Мерәстә өйләнеп, шунда күпмедер дөнья көткән булса кирәк. «Аның балалары да башкорт җиренә һәм туфрагына береккән, — ди галим. — Уллары исә бу көндә Уфа өязе, Өршәк елгасы буенда Мерәс авылында яшиләр. Җамалетдин исемле улы югарыда әйтелгән Мерәс авылында яшәп 1304 тарихында (1889 елда) вафат булды. Нәселе күп һәм киң таралган. Аны һәм Гыймалетдин улы Котлыбайны шәкертлек көннәрендә күргәнем бар иде»[2].

---

[1] Р. Фәхретдинов. Асар. 1 том, 6 кисәк, Оренбург, 1908 ел, 301 нче бит.
[2] Шунда ук, 300—301 битләр.

Мерәс авылында яшәгәндә Утыз Имәни шул замандагы атаклы мәдрәсәләрнең берсе булган Стәрлебашка еш килгән булса кирәк. Аның хәтта Стәрлебаш мәдрәсәсендә сабак укытып, шунда күпмедер торуы да бик ихтимал. Стәрлебаш мәдрәсәсенең мөдәррисе Харис Биктимеров (1810—1870) хакында язганда Риза Фәхретдинов остазы Габделфатих Габделкаюм улының шундый истәлеген китерә: «Шәкерт чагында Стәрлебаш авылына бардым, — ди ул. — Җәй көне иде. Харис хәзрәтләре бер урында тегермән буасын будыра иде. Хәзрәт көндез эшләүчеләр янына барган чагында арбасына мине дә утыртты. Ул миннән төрле нәрсәләр сораштыра торган иде. Ни мөнәсәбәт беләндер Габдерәхим Госман улы Утыз Имәнинең чәй хакында бер әсәр язып, шунда чәй эчүне хупламаганлыгын сөйләп ташладым. Моңа карата ул: ул зат (ягъни Утыз Имәни — Г. Х.) исә һәр вакыт атабыз хәзрәтләренә килер иде. «Сезгә ике нәрсә өчен киләм, дир иде: берсе — сездә «Тәгъриф» китабы бар. Шуңа гашыйкмын; икенчесе — чәйне күп һәм куе итеп эчерәсез. Мин исә хосусан куе чәйне ярата торган кеше» дип сөйләде»[1].

Димәк, Утыз Имәни Стәрлебашта Харис Биктимеровның атасы Нигъмәтулла ишан өендә еш була торган булган (Нигъмәтулла Биктимеров 1812 елдан 1844 елга кадәр мәдрәсәнең мөдәррисе була).

Заманында атаклы Өчбүлә (Башкортстанда) мәдрәсәсендә укыган, хәзер Уфада яшәүче карт пенсионер Барый ага Ганиев үзенең истәлекләрендә, Утыз Имәнинең Стәрлебашта Нигъмәтулла ишан белән бер дини-фәнни бәхәскә кереп, ул бәхәс шәкертләр арасына да таралуы, аларны капма-каршы ике төркемгә аеруы, ишан яклы шәкертләрнең Утыз Имәнине мәдрәсәдән китәргә мәҗбүр итүләре хакында ишеткәнем бар, ди[2].

Чыннан да, алдынгы карашлы шагыйрьнең схоластик дини мәдрәсә башлыгы белән кискен бәрелешкә керүе табигый хәл. Габдерәхим Утыз Имәнинең прогрессив карашлы кеше булуы, мәсәлән, рус халкы белән дуслыкны ныгытуны һәм рус телен белүнең мөһимлеген кыю яклавында бик ачык күренә. «Россиядә яшәүче мөселманнарга кырык бер нәрсә фарыз, аның кырык беренчесе — рус телен белү»[3], — дигән ул.

Утыз Имәнигә зур ихтирам белән караган мөдәррис Харис Биктимеров, бәлки аның йогынтысы беләндер, «Россия мөселманнары өчен дәүләт телен (ягъни рус телен — Г. Х.) белү мотлак лязим» дип исәпләгән. Алай гына түгел, атасы Нигъмәтулла ишан үлеп Стәрлебашта үзе мөдәррис булып калгач, мәдрәсәдә рус телен укытуны керткән, аның өчен махсус мөгаллим китерткән, китапханәсенә рус телендәге «Голос» газетасын яздырып, андагы хәбәрләрне тәрҗемә иттереп, шәкертләренә таныштыра барган[4].

Утыз Имәнинең Өршәк буе Мерәс авылыннан табылган бер кульязмасында китап укуның төрле намаз-мазар укудан йөз тапкырга хәерлерәк, саваплырак эш булуы турында язганнары да мәгълүм. Риза Фәхретдинов шагыйрьнең күп яратып укыган китаплары арасында XI гасыр гарәп философы Мөхәммәт Газалиның «Ихъя әл-гөлүм», Якуб Бохариның «Тәгъриф» китапларын аерып атап китә (Асар, 1 том, 302 бит). Алда телгә алынган истәлектә дә Утыз Имәнинең Нигъмәтулла ишан өенә үзе гашыйк «Тәгъриф» китабын укыр өчен килгәнлеге әйтелә.

Шунысы да характерлы, Стәрлебаш мәдрәсәсе китапханәсеннән сакланып калган кульязма китаплар арасында Сәгъди, Газали, Якуб Бохари, Шәмсетдин Мөхәммәт әл-Хорасани кебек әдип һәм философларның Утыз Имәни яратып укыган зур-зур томнарын күрергә мөмкин. Мәсәлән, Башкортстан республика китапханәсенең кульязма китаплар фондында Газалиның «Ихъя әл-гөлүм» дигән әсәренең 1630 елда күчерелгән томнары, Шәмсетдин Мөхәммәт әл-Хорасаниның «Җәмәгъ-эр-ромуз» әсәренең ике томлыгы да бар. Мәгълүм булуынча, Утыз Имәни соңгы авторның томнарындагы авыр аңлашылган сүзләргә гарәпчә-фарсыча сүзлек тә төзегән булган.

Көнчыгыш галимнәренә, шулай ук урта гасырларда Европа философиясенә көчле йогынты ясаган Газалиның (1058—1111) Р. Фәхретдинов философ янында философ, суфи янында суфи, шагыйрь янында шагыйрь булып, киң эрудицияле, төрле

[1] Р. Фәхретдинов. Асар. 2 том, 15 кисәк, Оренбург, 1909 ел, 506 бит.
[2] Уфадагы тарих, тел һәм әдәбият институты архивыннан.
[3] Р. Фәхретдинов. Асар. 2 том, 15 кисәк, 505 бит.
[4] Шунда ук, 505—506 битләр.

фәнгә маһир икәнлеген күрсәтә. Шул ук вакытта ул бу хакимнән өйрәнүче Утыз Имәнинең дә философ янында философ, суфи янында суфи, шагыйрь янында шагыйрь булырга омтылышын, төрле өлкәдәге эшчәнлеген билгеләп үтә.

Габдерәхим Утыз Имәнинең әнә шундый киң иҗади эшчәнлеген күрсәткән әсәрләре, күчереп язган кульязма китаплары, шигырь һәм проза җыентыклары Башкортстанда да элек киң таралган булган. Рус музыка белгече һәм фольклорчысы С. Рыбаков XIX гасырның ахырында Уралда башкортлар һәм татарлар арасыннан бик күп җырлар белән бергә, бәет һәм мөнәҗәтләр дә язып алган. Шул мөнәҗәтләрнең берсен «Музыка и песни Уральских мусульман» (1897) дигән китабында бастырып чыгарган.

**Илаһи, әйләмә мохтаҗ шу дүрт адәм капусына**
**Бере вәли[1], бере казый, бере мөфти, бере солтан.**
**Шу дүрт адәмнәрнең шәррен[2] безгә күстәрмә, йә раббым:**
**Бере нәммә[3], бере замйон[4], бере гаммаз[5], бере шайтан.**
**Ачыглардан[6] имин әйлә шу дүрт әгзами, рабби:**
**Бере башы, бере колак, бере чәшмә[7], бере лисан[8].**
**Шу дүрт нәрсәне күстәрмә безә дөньяла, йә рабби:**
**Бере фәкр[9], бере дәйн[10], бере мараз[11], бере зиндан.**

Авторы билгесез бу әсәрне С. Рыбаков «Башкорт мөнәҗәте» дип кенә исемли. Ә тикшеребрәк карасаң, бу әсәрнең Утыз Имәнинең «Мөнәҗәт» исеме белән тарихка кергән мәгълүм шигыре икәнлеге ачыклана. Димәк, аның бу әсәре XIX гасырда тәмам җырләшеп, халыклашып киткән дигән сүз.

1973 елгы археографик экспедиция вакытында Башкортстанның Чакмагыш районы, Каран авылында әһәмиятле бер кульязма китапка тап булдык. Ике йөз биттән артык бу иске җыентык, тезмә һәм чәчмә әсәрләрдән гыйбарәт булып, аларның эчтәлеге шәригать кануннарын, халыкның гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүреш низамнарын, холык, әдәп, әхлак мәсьәләләрен шигырь белән бәян итүгә бәйле. Бәяннарында дин әһелләренә, түрәләргә тел тидерү очраклары да бар. Аларда һәйбәт холык, гадәтләр мактала, яманлыклар, явызлыклар фаш кылына.

Бу кульязма китап әнә шул яклары һәм үзенең эчтәлеге, формасы белән дә заманында (1898 елда) Габдерәхим Утыз Имәни авторлыгы белән Казанда чыккан «Китап мөһиммәт эз-заман»ны хәтерләтә төшә. Әмма Ә. Шәрипов «Мөһиммәт эззаман» китабының авторы Утыз Имәни булуына шик белдерә[12], без тапкан җыентык та татар шагыйренә карамый. Аның сәүдә, акча, мал-туар хакындагы чәчмә өлешен, китапта күрсәтелгәнчә, шушы Каран авылы мәдрәсәсе мөдәррисе Карани әл-Сәлими, ә тезмә өлешен Әбухаҗип дигән кеше иҗат иткән булса кирәк.

Утыз Имәни надан муллаларны, аларның ришвәт белән указ алуларын кискен тәнкыйтьләгән кебек, бу китапта да ришвәт белән указ алган надан муллалар фаш ителә. Түбәндәге юллар китапның төп эчтәлегенә һәм авторына да ишарә ясый:

**Бу тәнбиһ[13] әл-кәмалдыр[14] бу,**
**Бу әхсәне[15] әл-мәкандер бу,**
**Бу аузах[16], әл-каләмдер[17] бу.**
**Бу мәксул әл-мәрамдер[18] бу,**
**Әбүәлнурның китабы бу,**
**Әбухаҗип китабы бу,**
**Әбү әл-бәян бәяны бу,**
**Әбү әл-гаян гаяны бу.**
**Сали[19] үтеп бара алтмыш,**
**Гамәл фәрәсендән[20] ятмыш,**
**Хатасы башидин ашмыш**
**Мәхасе[21] бәхеренә[22] батмыш.**

[1] Вәли — түрә, хуҗа; [2] шәррен — явызлыгын; [3] нәммә — ялачы; [4] замйон — эчкече; [5] гаммаз — мәкерле; [6] ачыг — ачу; [7] чәшмә — күз; [8] лисан — тел; [9] фәкр — фәкыйрьлек; [10] дәйн — бурыч; [11] мараз — чир.

[12] «Казан утлары» журналы, 1972 ел, 4 сан.

[13] Тәнбиһ — кисәтү, искәртү; [14] кәмал — тулы, бөтен; [15] әхсәне — күркәмлеге; [16] аузах — ачык; [17] каләм — сүз, фраза; [18] мәрам — теләк, ният; [19] сали — яше; [20] фәрәс — ай; [21] мәхасе — гаеп; [22] бәхер — диңгез.

Күрәсез, автор алтмышны үтеп барган олы кеше, ул туры сүзе белән үзенең гаеп диңгезенә — гөнаһка батып беткәнлеген дә яшерми.

Бу кульязма китапның авторын һәм әсәрләрен махсус өйрәнәсе бар. Бу юлы безнең игътибарны тартканы — кульязманың Утыз Имәни иҗаты белән тыгыз бәйләнештә булуы. Ул татар шагыйренең бигрәк тә «Гавариф эз-заман» әсәре белән аваздаш. Бу кульязма китапта, «Гавариф эз-заман»дагыча, үз заманындагы төрле кимчелекләр тәнкыйть ителә, шәригать кануннарыннан чыгып гореф-гадәт, йола, тормыш-көнкүреш тәртипләре хакында сүз бара. Гаделлек, тугрылык, галимлек мактала, гаделсезлек, яманлык, комсызлык, наданлык фаш кылына. Монда башкорт җырләре хакында да, Стәрлебаш, Нигъмәтулла ишан турында да назымнар килеп чыга. Шиһабетдин Мәрҗани хакында шигъри юллар очрый. Автор Утыз Имәни иҗатының төп мотивларын үзенчә куәтли, кайбер карашларын үзенчә шәрехләп аңлата, үстерә кебек.

Ниһаять, кульязманың 59 нчы битендә гарәпчә язылган шундый юлларга тап булабыз: «Калә әл-имам Утыз Имәни һадә гади әл-мисле фи заманиһи фи гыйлме әлмәсә илә иннәһи саннафа китабән фи хаккый әл-бидгати соммаһи би гавариф әз-заман фи тәгдади әл-бидгати фи әл-гыйбадәт». (Мәгънәсе: «Үз заманының юриспруденция гыйлемен шәп белгән Утыз Имәни яңалыклар хакында бер китап язды. Аны «Гавариф эз-заман» дип атады. Яңалыкларны санап, ул шуны әйтде».)

Автор «Гавариф эз-заман»да Утыз Имәнинең әйткән сүзе дип, шәригать тыйган яман нәрсәләр дигән тезмәләреннән «чыгыр көфер әлиндән ак шикәр баш, кызыл канны салалар дип улуб фаш» дигән юлларын китерә дә, шикәрне ашауның мәсьәләнга ни өчен харам икәне турында 75 юллык шигырь тезә.

Кульязманың 65 нче битендә тагын гарәпчә аңлатма: «Калә әл-имамы Утыз Имәни фи хаккый бәрке-хытай әл-мосаммо би әл-чай». (Ягъни: «Чәй исемле кытай яфрагы хакында Утыз Имәнинең әйткән сүзе».) Янә «Гавариф эз-заман»дан бер шигъри цитата:

**Чыгыбдыр бу заманда вәркъ хитай[1]**
**Йөзең додмош аңа бай, гидай.**

Кульязма авторы ни сәбәптәндер Утыз Имәнинең шигырь юлларын бозыбрак, мәгънәсезләндеребрәк күчерә. Ә Утыз Имәнидә бу юллар түбәндәгечә:

**Чыгыбдыр чәй дигән бәрк хитай[2]**
**Йөзен тотмош аңа бай, гидай.**

Утыз Имәнидә чәй хакында сүз алга таба болай дәвам итә:

**Эчәрләр аны һәр көндә биш бар,**
**Ничек исраф дүгелдер, белгел әй-яр...**

Бездәге кульязма авторы бу фикерне үзенчә әйләндереп алып китә:

**Шу диклү мобталядер[3] боңа һәр наз,**
**Эчәр чәйне ашарга наны[4] булмас.**
**Эчәр улса биш улуб өйдә, я ун,**
**Бишигә илле акча, унга бер сом,**
**Йылыга йөз сиксән, өч йөз алтмыш,**
**Хаҗәте аслиясына[5] күбесе сатмыш.**

Күп чәй эчүнең гаилә бюджетына сугуын, сәламәтлеккә зарар китерүен үзенчә сөйләп кила-кила дә, автор тормышның үзенә, абруйлы кешеләрнең сүзенә мөрәҗәгать итә:

**Төрекмән хәзрәт ишан әвлиә дип,**
**Ишетдем һәм чәй эчмәктән тыя дип,**
**Дәхи Стәрлебашның хәзрәте ишан**
**Тиләр хакъдин бу чәйдән нәфес тыйсам.**

---

[1] Вәркъ хитай — кытай харамы; [2] бәрк хитай — кытай япрагы; [3] мобталя — гадәтләнү; [4] нан — икмәк; [5] хаҗәт аслия — гаиләгә кирәк минимум.

**Алар тыймас мобахтан[1], иншалла,**
**Әкал мәкруһлыгында[2] шәккә калма.**

Монда сүз Төрекмән дигән бер атаклы ишанның һәм Стәрлебаш ишаны Нигъмәтулланың әйткәннәре хакында бара. Ләкин автор бу ишаннарның чәй турында кире сүзенә караганда, аларның үзләренең чәйхурлыгын белепме, ничектер, үзе дә икеләнүгә төшә кебек: чәй ул хәләл дә, хәрам да түгел, эчкәнгә гөнаһы, эчмәгәнгә савабы юк, дигәндәй була.

Шунысы да хикмәтле, Утыз Имәни «Гавариф эз-заман» әсәрендә чәйне эчмәк яман дип кирегә юраса, үзенең «Назым дәр мәдхе чәй-каймак» дигән икенче бер шигырендә чәйне мактап чыга. Бер кульъязмасында ул чәй эчүнең кеше организмына 27 төрле зарарын, йөрәккә бик нык тәэсир иткәнен дәлилләп, чәй эчүдән тыелырга кушса, үзе тормышта бер чәйхур кеше була.

Чәйне бер үк вакытта мактап та, хурлап та язу ул заманнарда бик таралган күренеш. Мәсәлән, С. Рыбаковның баягы китабында ике башкорт бәете урнаштырыла. Икесе дә чәй турында. Берсе чәйне мактый, икенчесе яманлый. Археографик экспедиция вакытында табылган бүтән кульъязма китаплар арасында да чәйне мактап язган шигырь, мәдехләр очрый. Һәрхәлдә, хикмәт коры чәйдә генә түгел, әлбәттә.

Башкортстанның Каран авылында табылган кульъязма китап исә аның авторында Утыз Имәнинең кульъязма әсәрләре булганлыгын яки ул кешенең Утыз Имәни шигырьләрен яттан белгәнлеген сөйли. Алай гына да түгел, кульъязма авторы үзе Утыз Имәнигә ияреп, төп иҗат мотивларын үзенчә дәвам итәргә омтылган шагыйрь, атаклы татар шагыйре әсәрләрен үзенчә шәрехләүче кеше. Аның үз әсәрләрендә Пиргали кебек гарәп философына, татар галиме Шиһабетдин Мәрҗанига мөрәҗәгать итеп язган шигырь юлларыннан заманасының мәгълүматлы кешесе икәнлеген дә тоярга мөмкин.

Әле сөйләгән мәгълүматлардан чыгып караганда, XVIII гасыр ахырында, XIX гасыр башында татар әдәбияты тарихында күренекле урын тоткан шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәнинең тормышы һәм иҗаты Башкортстан белән дә бәйләнгән, аның кульъязма әсәрләре элек башкортлар арасында да таралган, хәтта аның поэтик традицияләрен үзенчә дәвам итәргә омтылган кешеләр булган дип әйтергә мөмкин. Болар исә Утыз Имәнинең тормыш һәм иҗат биографиясенең ике тугандаш халык — татарлар һәм башкортлар белән аерылгысыз булуын, әсәрләренең таралыш сферасының киңлеген, әдипнең үз заманында ук ике халыкка да якын, кадерле икәнлеген дәлилли торган мөһим факторлар ул.

---

[1] Мобах — харам да түгел, хәләл дә түгел; [2] мәкруһ — тыелмаган да, кушылмаган да

# БЕР КИТАПКА ӨЧ КАРАШ

## Әҗәт

Яшь язучы Әхәт Гаффаровның беренче җыентыгы[1] «Язлар моңы» дигән повесть белән ачыла. «Тормыш кыры нәрсәгә охшаш? Бу хакта уйлаганым юк иде әле. Хәзер менә уйларым белән шул кыр буйлап йөгерәм. Серкәләнеп килгән яшел арыш кыры читендә яшен көйдергән карама агачы күреп тукталып калам. Аның тирәли буш калган җирдә мәтрүшкәләр чәчәккә бөреләнеп килә. Тиздән монда җиләктән кайтышлый әбиләр тукталыр». Бу — әсәрнең увертюрасы, аның беренче нотасы, повестьның ачкычы.

Хәзерге татар әдәбиятында мондый башламны Әмирхан Еники белән Рафаил Төхфәтуллин әсәрләрендә очратырга мөмкин. Ләкин ул һәр әдиптә үзенчә бер төрле функция үти. Әйтик, Әхәт Гаффаров әсәрләрендә мондый башлам барыннан да бигрәк авторга тормыш чынбарлыгын каршылыклар берлегендә (яшел арыш кыры, яшен суккан карама, чәчәккә бөреләнгән мәтрүшкәләр, җиләктән кайтучы әбиләр) сурәтләргә булыша. Димәк, үткән гомерне искә төшерү рәвешендә язылган повестьларга хас уртак сыйфатны Әхәт Гаффаров үзенчә борып җибәргән.

Увертюрасы гына түгел, әсәрнең калган өлешләре дә, тормышның үзе кебек, каршылыклы сурәтләр белән тулы. Җидегән авылын автор озын баскычка охшата. «Баскыч»ның югары басмасы басуга алып чыга, түбән очы миләш-балан куаклы зиратка килеп терәлә».

Алга таба вакыйгаларны һәм бигрәк тә персонажларның хис-кичерешләрен, шул рәвешчә, каршылыклар берлеге итеп сурәтләү тагын да үсә, киңәя бара... Үзе дә сизмәстән, укучы «Язлар моңы»ның көе белән урала, дулкынлана башлый. Укый башлауга повесть сине урап ала да әллә кая еракка-еракка — Фәрдәнә белән Сәгыйдулла гармунчының яшьлек мәхәббәтенә, фаҗигале тормыш юлына, ил өстенә сугыш китергән көенечле хәлләр эченә алып кереп китә... Менә инде Сәгыйдулла да гүр иясе. Тормыш кора башлаган беренче елларда ук Фәрдәнә җиде казга алыштырып алып кайткан һәм Сәгыйдулла кулында ничәмә-ничә еллар буе тормышның мәңгелек көен — мәхәббәт һәм нәфрәт көен сузган яшел гармунны Сәгыйдулланың икенче хатыны Сара әби кабат Фәрдәнә карчыкка китереп бирә. Бу — Сәгыйдулланың соңгы васыяте. Яшел гармун — яшьлек, мәхәббәт шаһиты. Шул рәвешчә, үз алдына торганда шактый гади булып күренгән сурәтләр, ахыр килеп, олы фикер, тирән мәгънә һәм нечкә хисләр белән тулы картиналар тудыралар.

Әхәт Гаффаровның бу повесте Фәрдәнә карчыкның үткәннәрне — яшьлек елларын хәтеренә төшерүе формасында язылган. Шуңа күрә әсәрдә аның үз сүзләре, үз интонациясе, гомумән, үз сөйләме күп бирелә. Һәм Фәрдәнә карчыкның сөйләме укучыны ышандырырлык дәрәҗәдә табигый яңгырый. Персонаж сөйләменең эмоциональлегенә ирешү өчен, автор ым-киная белдерүче сүз-сурәтләрне, символ һәм әйтемнәрне күп куллана. Тегеяки бу персонажның интонациясенә төренгән автор сөйләмендә дә шул ук чаралар файдаланыла. Боларның күбесе шигърияте контекстта урынлы булып, ки-

[1] Әхәт Гаффаров. Әҗәт. Повестьлар, хикәяләр. Казан, 1975 ел.

рәк һәм мәгънәле булып яңгырый. Ләкин, һәрбер башка бизәк кебек үк, бу тел бизәкләре дә үзләре белән бик сак мөгамәләдә булуны сорыйлар.

Менә, мәсәлән, «Язлар моңы»ндагы иң тәэсирле урыннарның берсе. Сәгыйдулланың үлгән хәбәре килгәч, Фәрдәнә фронттан кулын өздереп кайткан Ярмигә кияүгә чыга. Бервакыт үиламаганда Сагыйдулла кайтып төшә. Фәрдәнәнең өзгәләнүе автор сөйләмендә бирелә: «Тау астындагы күл ягыннан әче итеп тәкәрлек кычкырганы ишетелде. Әйтерсең лә Фәрдәнәнең күңеле шул тәкәрлек булып аваз салды. Ул җәһәт торып урылмаган арыш эченә ташланды. Авыр башаклар, битенә бәрелеп, күз ачарга ирек бирмәде. Күз алдында кызыл ялкын биеде. Кулына нигәдер урагын эләктергән иде. Ул ялгыш күкрәгенә кадалды. Эссегә күрә, күкрәкчә кимәгән иде — ситсы күлмәкне кан чылатты. Күкрәк астында кинәт үзен сиздергән бала кебек талпынып типкән йөрәгеннән саркып чыкты мәллә соң ул кан? Ни туктарга, ни әйләнеп карарга, ни еларга белмичә куе арышны ярып чапты да чапты. Каршысында әллә кайдан гына бүз тай пәйда булды. Тай, кинәт өркеп, читкә сикерде дә башаклар өстеннән кыска койрыгын тырпайткан килеш чабып китте». Картина, кинокадр кебек, ачык, көчле, ташып торган хисле. Һәм нәкъ менә шул нәрсә — бизәкләрнең күп булуы, аларның эпитетлар белән килүе (кычкырган тәкәрлек, кызыл ялкын, канлы күкрәк, бала кебек типкән йөрәк, ниһаять, бүз тай), риторик эндәшле җөмлә, тиңдәш кисәкләрнең кабатлануы Фәрдәнәнең өзгәләнүен бөтен көчкә ачып бирә дә. Персонажы белән бергә, автор үзе дә өзгәләнә кебек тәэсир кала.

Көндәлек вак күренешләргә, вак сурәтләргә төренеп, вакыйга-сюжет үстерелешенә кетелмәгән яңалык өстәп, әсәргә бик аз сүз белән яңадан-яңа мәгълүмат-тасвирлар өстәлә бара: «Бер җәйне Сәгыйдулланың үлгән хәбәре килде»... «Газиз хәтирәле иде Сара алып менгән яшел гармун. Кайчандыр исеме гәзитләрдән төшмәгән тракторчы Фәрдәнә Басыйрованың яшьлеге. Сәгыйдулла сөюенең ачы васыяте». Менә шундый урыннар, персонажның эчке монологы рәвешендә, шактый талгын аккан әсәрне эчке бер киеренкелек белән тутыра. Вак сурәтләр эреләнеп, катлауланып китә.

Сәгыйдулланың язгы бозлар белән бергә кузгала торган күңел көен яшь егет Хөрмәт отып калган икән, яшел гармун хәзер аның кулында: «Нилектән гомернең чиге бар да, кеше йөрәгендәге моңнар язгы тугай ише гел яшел яки шул ялан шикелле сагышлы — сүнә дә кабына, сүнә дә кабына». Бу — авторның Фәрдәнә карчык сөйләме аша бирелгән үз бәясе, үз фикере. Сугыш китергән афәтләр коточкыч авыр, рәнҗүле булды, ләкин тормыш дәвам итә, ди ул.

...Укытучы кыз Люция белән Хөрмәтулла туенда Сәгыйдулла «гармунчының йөрәгеннән саркып бармакларына җыела килгән дә үзәк өзгеч сагышлы бер көй рәвешендә гармун күрегеннән ташып чыккан» җырын яшь кияү үзе уйный. Фәрдәнә карчык бик бәхетле. Менә шулай, әсәрнең башламы кебек, каршылыклар берлеге белән барлыкка китерелгән тасвирлар әсәрне тәмамлап та куя.

Җыентыктагы икенче повесть — «Яра» исемле. Бу әсәрдәге вакыйгалар, кичерешхәлләр беренче заттан, «мин» исеменнән сөйләнелә. Шулай итеп, сурәтләнә торган хәлләргә карата автор мөнәсәбәте тагын да ачыклана төшә. «Яра» — авторның икенче әсәре. Шуңа күрә аның уңай һәм кимчелекле якларын ачыклар өчен, беренчесе белән чагыштырып карарга кирәк. Һәм нәкъ менә шушы чагыштыру нәтиҗәсендә яшь әдипнең язучы буларак үзенчәлекле якларын билгеләргә мөмкинлек туа да. Әхәт Гаффаров тормыш күренешен эзлекле вакыйгалар рәвешендә түгел, бәлки хис һәм кичерешләр аша, үткәнне искә төшерү рәвешендә тасвир итәргә ярата. Бу хәл иң башлап аның әсәрләренең сюжет-композиция төзелешендә үзенчә чагылыш таба. Сөйләү моментында бара торган хәлләрне беренче повестьта эчке монолог, икенчесендә әдәби әсәр уку рәвешендә бирелгән күренеш-хәлләр, вакыйгалар үстерелеше алып бара. Һәм, әйтеп үтелгәнчә, әсәргә эчке экспрессия бирә, чөнки ул аның төзелешен, тәэсир көчен катлауландыра.

Беренчесе кебек, бу повесть та сүз башы — увертюра белән башлана. Монда да шул ук каршылыклар берлеге — антитезалы тасвирлар: «Сулар ага. Тын инештәй тигез генә тормыш ага.

Тормыш елгалары шаулап ага». Монда да шул ук символик картиналар: прәннек, прәннек утравы. Монда да бер үк вакытта поэтик сөйләмгә дә, җанлы сөйләмгә дә охшаш моңсу-талгын җөмлә тө-

зелеше: «Әтине белгән көннәр ерагая барган саен, өмет, җылы туфракка салынган бодай бөртегедәй, бүртә, үсә генә барды. Күпме шундый өметләре бар бу дөньяның!».

Тик икенчесендә диалогларның күплеге һәм персонажларның, бигрәк тә Галимҗан сөйләменең, индивидуальләшүе яшь авторның бу өлкәдә дә, ягъни вакыйгалар үстерелешен алып бара торган диалогны бирүдә дә осталыгы үсүен күрсәтә.

Бу повестьта, «Язлар моңы» белән чагыштырганда, тормыш күренешләре тагын да катлаулана, тагын да куертыла. «Яра» повестенда авторга, колхоз төзелү елларындагы вакыйгалардан тотынып, сугыштагы соңгы елларга кадәр булган хәлләрне колачларга туры килә. Ул, аларны бер йомгакка чорнап, кешеләр яшәеш, тормыш һәм бер-берсе алдында бурычлы булып калмаска тиеш дигән идеяне ачыкларга омтыла. Төп идея белән бергә, әсәргә күп төрле башка мәсьәләләр килеп керә: туган ил алдында, кешеләр, туганнар алдында намуслылык, йөз аклыгы, аталар-балалар, ир-хатын мөнәсәбәте, мәхәббәт, кешенең кеше булып формалашуы һәм башкалар.

Сәнгать әсәре тирән гомумиләштерү көченә ия. Һәм яшь автор аңлы рәвештә шуңа омтыла. Ләкин, һәр тәңкәнең ике ягы булган шикелле, сәнгатьчә югарылыкка омтылу юлында әдипләр кайбер алымнарны кирәгеннән артык куертып ташлыйлар. Укучыга көтелмәгән эффект бирү өчен, сюжет җепләрен үзенчәлекле төеннәр, яисә юл арасы мәгънәсен кирәгеннән артык көчәйтеп гомумиләштерүгә омтылу — болар бер яктан, укучыга, аның белеменә, аңына ихтирам күрсәтү, аңа ышану, әлбәттә. Шуның белән бергә, икенче яктан, вакыйгаларның кирәгеннән артык куерып китүе, сүзләрнең, җөмләләрнең мәгънәсен, сүз сөрешен дөрес аңламау нәтиҗәсендә катлауландырып җибәрә. «Язлар моңы»ндагы менә бу өзекне, мәсьәләне, мин шактый уйлап торгач кына аңлый алдым: «...Әмма кешеләр күңелендә мүкләнеп, еллар тузаны күмеп киткән бер вакыйга ике кордашның йөрәгенә мәңгегә уелып калган иде. Тезмәсеннән печән исе килгән абзарда ерак еллар җиле уйнаклап узган иде мәллә? Көтүгә китми калган ялгыз тай арата киртәсен кимерә иде. Ул чак Фәрдәнә карчык: «Атлар — безнең хәтер кебек. Тик бер җылы абзар да салып бирмиләр мескенкәйләргә. Бу саман кирпечләрнең измәсен дип уйлап куйган идем». Поэзиядә бу тузә аякларым белән изгән идем ич».— рыда шау-шулы бәхәсләр булып узды, хакыйкать тә берникадәр ачыкланды кебек (иреклә шигырь, традицион шигырь, Р. Фәйзуллин иҗаты һ. б.). Менә хәзер чәчмә әсәрләр мисалында бу турыда сүз башларга вакыт җитә, ахры. Чәчмә әсәр тезмә әсәр түгел, аның үз кануннары бар.

«— Юк, син мине гафу ит... Тик мин сиңа ышанмадым... Ышанмыйм. Аңла, ышанмыйм... Минем әни... синең әни булачак кеше... ышанмыйм. Юк». («Яра».) Яисә: «Яңадан скрипка сызлануын ишеттем. Нинди моң соң бу? Кая дәшә ул мине? Нидән кисәтә? Нигә үгетли? Әллә кулымдагы китапны укыргамы? Бәлки укымаскадыр? Юк, мин укырга тиеш. Тик йөрәгемдә ачу, хәтта үч аласы килү тойгысы булса да, җәллим ич мин Галимҗан абзыйны, кызганам. Шул хис мәллә соң син, сүзсез моң?!» («Яра».) Дөрес, әлеге юлларның мәгънәсе соңыннан ачыклана. Ләкин бу урында укучы аларны тәгаен ничегрәк итеп аңларга дип уйланып кала. Чөнки монда сурәт сәнгатьчә ым-киная бирүдән узып, бер яктан кроссворд дәрәҗәсенә җиткерелгән, ә шунлыктан, икенче яктан, сөйләүченең (һәм автор-ның) кирәгеннән артык өзгәләнүен китереп чыгарган[1]. Шушы фикергә өстәп, «Кояшның салкын чагы» хикәясен дә телгә алырга туры килә. Хикәянең исеме тирән ассоциацияләр уята, ә эчтәлеге үз исеменә караганда сәеррәк килеп чыккан. Хикәянең исеме, шулай итеп, идея-эчтәлекне ачып бирү чарасыннан бигрәк, әдипнең тирән мәгънәле сүз тезмәсе табуга куануы булып яңгырый кебек. Кыз кешенең кул күтәреп кыр казын атып үтерүе дә әллә ничек бик үк ышандырып бетерми... Бәлки мин интуитив рәвештә хатын-кызны яклыймдыр. Ничек кенә булса да, укучы буларак, бу хикәясендә автор мине ышандырып бетермәгән, димәк, дулкынландыра алмаган.

Ә менә әҗәт дигән сүз шул исемдәге хикәянең идея-эстетик эчтәлегенә тирән мәгънә алып килә. Сугышта югалган улын ана соңгы көненә кадәр көтә. Улын озаткан көнне күршедән алынган бер бөтен

[1] Ә язучының максаты, А. П. Чехов әйткәнчә, үзенең кызганлыгыңны, персонажларыңны ярату-яратмавыңны бирүдән бигрәк, мөмкин кадәр объектив рәвештә укучыга тәэсир итү көчен арттыру бит.

ипине, улым кайткач үзе түләр дип, озак еллар бирмичә тора. Солдат кайтмый, әби яңа пешергән ипине кочаклап күршесенә кереп барганда, бүрәнәләр өстенә утырып җан бирә...

Әҗәт сүзе, тулаем җыентыкның исеме буларак, монда тупланган барлык әсәрләрнең идея-эстетик эчтәлегенә тирән мәгънә өсти. «Язлар моңы»нда да, «Яра»да да кеше тормышка, яшәешкә һәм материаль яктан, һәм мораль яктан бурычлы булып калмаска тиеш дигән фикер яңгырый.

Бу җыентыкка тупланган әсәрләрне, исеменнән тыш, авторның чынбарлыкны үзенчә күреп, үзенчәлекле фикер йөртә белүе һәм шуны үзенчә итеп әйтеп бирә белүе дә берләштерә. Яшь авторның иҗат иткән әсәрләре аша үзенең йөзен, тавышын, максатын ачып бирүе — бу инде зур эш, чөнки ул аның әдип-художник буларак өметле икәнлеген, аның кешеләргә әйтер сүзе булуын исбат итә. Без, укучылар, аңа хәерле юл, иҗади уңышлар телибез.

**Илида БӘШИРОВА.**

# Җаваплылык хисе, намус эше...

## ЯШЬ ЯЗУЧЫГА АЧЫК ХАТ

«— Андыйларга үз вөҗданнары белән күзгә-күз очрашу куркынычрактыр, күрәсең, улым,— дип җавап бирде Павел».

А. Иванов.
Шушы гөнаһлы җирдә тормыш. Повесть.

Әхәт иптәш Гаффаров!

Сезнең беренче китабыгызга ике повесть һәм ике хикәягез кергән. Яшь язучының беренче китабына шул кадәр әсәр кертү — зур нәрсә. Бу — безнең әдәбиятта шактый сирәк очрый торган күренеш. Өнә шуңа күрә, басылып чыгу белән, ул игътибарны үзенә җәлеп итте, укучылар арасында зур кызыксыну уятты.

Аннан соң без хәзер әдәбияттән, гомумән, бик күпне көтәбез. Бу, күрәсең, тормышыбызның алга баруы, җәмгыятьнең рухи тормышы нык тирәнәю һәм катлаулану белән, безнең алга килеп баскан мәсьәләләрнең күбәюе, җитдиләнүе һәм аларны чишүдә әдәбиятның әһәмияте тагын да арту белән аңлатыладыр. Чыннан да, соңгы елларда совет әдәбиятында нык алга киткән тормыш таләпләренә җавап бирерлек, замандашларыбызның зур өметләрен аклый алырлык бик күп әсәрләр барлыкка килде.

Әлбәттә, безнең татар әдәбияты да үзенә тормыш тапшырган шушы мактаулы миссияне заман таләп иткәнчә, намус белән үтәргә тырыша. Аның уңышлары — укучылар сокланып укый торган әсәрләр шул хакта сөйли. Ул әсәрләр безнең әдәбиятка булган ышанычыбызны тагын да арттыра. Ләкин, шуның белән бергә, соңгы берничә ел эчендә әдәбиятыбызның заман тормышын, бүгенге көннең олы геройларын сурәтләүдә бирешә төшүе дә шактый нык сизелә башлады. Мәсәлән, соңгы ике-өч елда басылган роман-повестьларны алып караганда, аларның зур күпчелегенең үткән тормыштан алып язылганлыгы күренә. Бу язучыларыбызның әйләнә-тирәбездә барган җанлы тормышка игътибарлары кими төшүе турында сөйли. Дөрес, безнең бүгенге тормыш проблемаларына багышланган роман-повестьларыбыз да байтак. Ләкин аларның күбесе сәнгать әсәре алдына куела торган олы таләпләргә җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел әле. Бу хәл тормыштагы яшь буынга — яңа чор, яңа заман рухында тәрбияләнгән укучыга бигрәк тә ачык сизелә. Ул үзенең күңел дөньясы, рухи омтылышлары белән безнең күп кенә әдәби әсәрләребездә сурәтләнгән геройлардан өстен тора. Ә бит чын әдәбиятның төп бурычы гел хәрәкәттә булган, һәр вакыт алга барган тормышның яңа рухи

биеклекләрен яулау, заман кешеләрен шул өлкәдәге ачышлар белән сокландыру булырга тиеш.

Сезнең бу китабыгыз әдәби җәмәгатьчелек әнә шундый уйлар белән борчылып яшәгәндә, әдәбиятта күренгән һәр яңа исемнән зур яңалык көтеп, һәр яңа китаптан күңелләрне тетрәтерлек давыл өмет итеп яшәгәндә басылып чыкты. Ләкин бу китабыгыз белән Сез безнең өметләрне акламадыгыз. Алай гына да түгел, безне бик нык аптырашта калдырдыгыз, күңелдә зур борчылу хисләре тудырдыгыз. Һәм әлеге хис Сезгә шушы хатны язарга мәҗбүр итте.

Моңа күбрәк Сезнең «Яра» повестегыз сәбәпче булды. Шуңа күрә сүзне шул әсәрдән башлыйк.

Повестьтагы вакыйгалар Рахман исемле егет исеменнән сөйләтелә. Рахман Миләүшә дигән кызны ярата. Ләкин аларның әтиләре гомер буе талашып яшәгән. Миләүшәнең әтисе Галимҗан — Рахманның әтисен нахакка төрмәгә яптырган кеше. Миләүшә исә әтисенең бу эшләре турында берни белми. Рахман кызның күзен ачарга тели һәм шул максат белән әтисе белән Галимҗанның тормышы турында китап яза. Бервакыт, җай табып, ул китабын Галимҗанның үзенә укыта. Үткәндәге әшәкелекләре белән яңадан очрашкан Галимҗан, авыруга сабышып, биш көннән үлеп китә. Бик гадиләштереп, җыйнап әйткәндә, әсәрдә шул вакыйгалар турында сөйләнә.

Танылган рус язучысы Анатолий Ивановның «Шушы гөнаһлы җирдә тормыш» повесте буенча куелган нәфис фильмда да әнә шундый хәлләр тасвирлана. Сезнең әсәрегездәге кебек үк, анда да ике егет бер кызга гашыйк була. Повестьта — Рахманның әтисе Булат белән Галимҗан, ә фильмда — Павел Демидов һәм Денис Макшеев. Туй булыр алдыннан Денис (Галимҗан), Павелның (Булатның) башына тимер белән сугып, ул һушын югалткач, амбарга ут төртә һәм кешеләргә утны Павел (Булат) төрткән дип сөйли. Моның өчен Павелны (Булатны) 8 елга төрмәгә ябалар. Аннары сугыш башлана. Павел (Булат) штрафной ротада сугыша, әсир төшә. Сугыштан соң да тиз генә авылына кайта алмый, Павел (Булат) өч ел Себердә урман кисә. Ә бу вакытта инде Денис (Галимҗан) Марияга (Вәзирәгә) өйләнгән була. Шулай итеп, нахак гаеп белән төрмәгә киткән, немец тоткынлыгының бөтен газабын кичергән Павел (Булат) тормышның тагын бер рәхимсезлеге белән очраша — аның сөйгәне дошманына кияүгә чыга. Кинода Павел Денисны аның янәшәсендә булуы белән — вөҗданына кагылып газаплый. Сезнең китапта исә Булат авырып үлеп китә, бу рольне аның улы Рахман башкара. Ә нәтиҗәләр бер үк — Денис та, Галимҗан да күпмедер вакыттан соң дөнья куялар. Бу фаҗигагә китергән сәбәпләр дә, әсәрләрдәге төп фәлсәфә дә ике авторныкы да сүзгә-сүз туры килә. Аны Сез болай дип бирәсез: «әти дә Галимҗанны шулай иткән. Аны үз-үзе белән ялгыз калдырган. Үз вөҗданы белән күзгә-күз...»

Шулай итеп, Сез үзегезнеке дигән повестьны экраннардан яратып караган фильм белән чагыштырып чыктык. Сез, билгеле, кайбер яңа геройлар керткәнсез. Ләкин алар да Сезнең повестька яңа мәгънә өсти алмый. Шуңа күрә Сезнең бу повестегыз — бер сатылган әйберне икенче төскә буяп яңадан сату гына. Ә, белгәнегезчә, буяуны алыштырудан әйбернең асылы үзгәрми...

Китабыгызга кергән икенче повесть «Язлар моңы» дип атала. Бусы нинди дә булса әсәргә охшаган димим. (Хәер, Г. Николаеваның «Урак өсте» романында шуңа охшашрак вакыйга бар. Үлгән хәбәре килгән Степан сугыштан исән кайта, ә кайтуына хатыны икенче кешегә кияүгә чыккан. Алар бер авылда, бергә яши башлыйлар.) Ләкин бу әсәрдә дә тормыштан үзегез табып алган конфликтлар, үзегез ачкан кешеләр юк диярлек. Повестьтагы картларның барысы да — безнең әдәбиятта бик күп очрый торган картлар. Әнә шуңа күрә, Сезнең повестьтагы геройларның яшәгән урыннары, килеш-кыяфәтләре, кыскасы, автор сурәтли торган күренешләр шактый шома булса да, геройларның үз характерларыннан чыгарга тиеш булган фикерләре, сөйләшүләре чын түгел, аларның үзләренеке түгел. «Язлар моңы»ннан ике геройның сөйләшүен алып карыйк. Сөйләшү Фәрдәнәнең яңа ире чулак Ярми Сәгыйдулланың гармунын пычракка сугып төшергәч бара:

«— Кемгә үч итәсең? Хатыннарның ни гаебе бар? Хатыннар күзен тырнап йөрисең төннәр буе, толлар хәтерен.

— Хәтерләрендә булса да — сафлар. Исләрен иснәтү түгел, якын да җибәрмиләр.

— Шул сафлыкка дегет сылап йөрисең!

— Каракның бүреге яна...
— Үз коеңа төкерәсең.
— Ә син шул коедан су эчәсең. Ничә еллар инде эчәсең. Эчәсең, эчәсең...
— Ник киттең соң? Ник кайтмадың? Янгыннан соң...
— Күмер өстенә кайттым шул, күмер өстенә. Кәлләрне җил очырды. Җан менә пыскый әле. Пыскый, Ярми!
— Фәрдәнәнеке дә пыскысын дисеңме? Ниемә дип кенә кыйнадың соң ул Гитлерны, эх, алла колы! Монда кайтып хатыннар изалап йөрер өчен дәмени?
— Бусы инде минем эш, минем!
— Синеке микән... Синеке микән, Сәгыйдулла...»

Күргәнебезчә, биредә характерлар бәрелеше юк, хисләр, кичерешләр кайнарлыгы җитми. Һәм автор алар урынына адым саен халык мәкале кулланып, хәлне төзәтмәкче була.

Китерелгән мисаллар тагын бер нәрсә турында сөйли: кичерешләр чынлыгы булмаганда, ул бушлыкка үзеннән-үзе төчелек тула икән. Ә кичерешләр чынлыгына бары тик геройларыңның характерын белеп бетерсәң, аларны тулысынча аңлый алсаң гына ирешеп була.

Сөйләшү тел мәсьәләсенә кагылгач, тагын шуны да әйтик: сез геройларның эчке дөньяларына, уй-фикерләренең диалектикасына караганда аларның теленә, сүзләренә артык нык игътибар бирәсез һәм, геройның эчке дөньясы буш икәнлеге сизелмәсен дип куркып, укучының игътибарын кинәт кенә табигатькә, тирә-юньгә күчерәсез. Менә берничә мисал:

«Аның сүгенүен буа ишелүе күмеп китте».

«Ярми гармунны урам уртасына таба тибеп тә очырды. Гармун ялгыз каз кебек каңгылдап куйды да тынды. Елгада бозлар чатнады. Күрәсең, ташкын буаны ашый башлаган, су тавышы көчәйде. Ярминең сүгенеп кычкыруына кайтаваз белән зират агачлары җавап бирде, этләр өрергә тотынды»... «Фәрдәнә әкрен генә аягына басты: и ходаем. Тау астындагы күл ягыннан әче итеп тәкрарлек кычкырганы ишетелде»... «Нишлисең бит. Җинаять кылмады лабаса, Фәрдәнә! Ахыры хәерлегә булсын. Күрәсең, бу сугышның ялкыны тәнне генә көйдермәгән...» «Арыш кыштырдады. Аның озын дулкыннары Тилгән тавы ягыннан өзек-өзек кенә итеп гармун ярсынуын алып килә иде»...

Күрәсез, адым саен я буа ишелә, я арыш кыштырдый, я әче итеп тәкрарлек кычкыра...

«Язлар моңы» повестеннан очраклы төстә сайлап алынган шушы мисаллар да Сезнең әдәбиятта һәм, конкрет алганда, кешеләр, геройлар күңелен ачуда җиңел юлдан — ялгыш юлдан баруыгыз хакында сөйли. Юк, кешенең күңелен тәкрарлек кычкыруы, арыш кыштырдавы аркылы гына ачып булмый, аның өчен язучының үз күңеле бөтен геройларныкыннан тирәнрәк, нечкәрәк, баерак булырга, аның үзенең тормышта кичергән тирән кичерешләре, алган көчле тойгылары булырга тиеш. Шулар аша гына язучы үз геройларын чын кешеләр, ихлас күңелле, рухи дөньялары булган кешеләр итеп бирә ала. Без әнә шундый кешеләргә, ихлас сүзле кешеләргә генә ышанабыз.

Китабыгызда тагын кечкенә генә ике хикәя бар. Берсе — «Әҗәт», икенчесе «Кояшның салкын чагы» исемле. Аларның соңгысын гына әдәбиятта бераз үзегезчәрәк атлап китәргә тырышкан бер адым дип кабул итәргә була. «Әҗәт» исә фикере ягыннан да, образлары ягыннан да безнең әдәбиятта яңалык була алмый.

«Кояшның салкын чагы» исемле хикәядә Әсфән белән Хәдичә мылтык алып урманга, ял итәргә чыгалар. Әсфән кыр казлары күреп, башта атарга уйласа да, ләкин кызганып («Тукта... шулай итеп үзеңә, Хәдичәгә, җиһан тынлыгына, яшәешкә атсалар?!») мылтыгын кире куя. Хәдичә исә, аның мылтыгын алып, казларга үзе ата. («Менә ничек аталар аны, Әсфән! Мылтыгың шәп синең!»)

Хикәянең соңгы юллары мондый: «Әсфән, тынычланырга теләп, болыт тауларына карады. Алар Хәдичәнең йөзе кебек ачык, якты иде. Әсфәнның болытларга кагыласы килде, ләкин алар ерак иде».

Биредә, беренчедән, кансызлыгы белән шаккатырган Хәдичәнең йөзен болытка охшату образга яңалык өстәми, фикерне тирәнәйтми. Икенчедән, нишләп әле Әсфәннең Хәдичәгә (болытларга) кагыласы килә? Ул аннан качарга тиеш иде кебек бит... Кыскасы, биредә ясалма катлауландыру ап-ачык күренеп тора. Шуңа күрә укучы хикәягә ышанмый, аны күңел белән кабул итә алмый.

Сезнең беренче китабыгыз әнә шундыйрак уйлар тудыра. Күргәнегезчә, шактый күңелсез уйлар. Ә ныклабрак, игътибар беләнрәк карасак, без бу уйларны тудырган сәбәпләрнең тамыры шактый тирәнгә

киткәнен күрербез. Юк, сезнең китап очраклы күренеш түгел. Сезнең китап — әдәбиятыбызда соңгы елларда нык сизелә башлаган бер тенденциянең җимеше ул. Аның исеме, кыскача әйткәндә, тормышка битарафлык. Кеше гомерләре, аларның тетрәндерерлек язмышлары булып, кайнап, бөтерелеп ага торган тормышка, аның күңеле сусаган кешеләренә, яндыргыч проблемаларына гаять битарафлык, тормышта йокыга талып яшәү, бүгенге дөнья белән алыш-бирешнең бик тараюы.

Сез мавыктыргыч хәлләр, вакыйгалар белән алдап укучыны үткәнгә, үзегез дә белмәгән, китаплар аша гына таныш булган үткәнгә алып китеп, аны картларга ошатып ясалган, авызларына гаять акыллы, гел мәкальдән генә торган сүзләр салынган курчаклар арасында йөртәсез. Курчаклар дөньясын тереләр дөньясы дип алдыйсыз. Моның шулай икәнен, чын тормыш түгел, алдану икәнен Сезнең повестьларыгызны укып чыгып байтак уйланып торгач, «мин бу әсәрләрдән нинди яңа нәрсә алдым соң әле?» диген сорауга җавап эзли башлагач кына сизәсең. Юк икән, болар барысы да безгә инде күптән таныш кешеләр икән...

Аннан соң, Сезнең әдәбиятта мондый ялгыш юнәлеш тотуыгыз бу китап белән генә чикләнми әле. Күптән түгел «Казан утлары» журналында (1975 ел, 12 сан) «Теге гозер» дип аталган яңа повестегызны укыдык. Сез Эрнест Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» хикәясен бик нык үзгәртеп, ләкин әсәрнең төп фикерен, идеясен үзгәртмичә, Хемингуэй картын татар карты иткәнсез һәм аның кулына балык урынына сыер тоттыргансыз. Тегендә балыкны акулалар ашаса, монда сыерны бүреләр ашый. Тегендә дә, монда да балык (сыер) образы тормышта кеше эзләп торган бәхет, юанычны аңлата. Хемингуэй героен татар тормышына күчерү Сезнең ул повестьны искиткеч нык ясалмалылык, уйлап чыгарылган хәлләр, уйлар, фикерләр белән тутырган. Андагы Җиһангир карт юлында очраган һәр нәрсәдән бөек фикер чыгарырга тырыша. Хемингуэй картының балык артыннан атна буе диңгездә йөргәндә кичергән уйлануларын төсле итәргә тырышу, Сезнең повестьта чынбарлыкны нык кечләү, кешенең реаль уйларын көлкегә әйләндерү, кыскача әйткәндә, бөек Хемингуэй әсәренә кызганыч пародия булып чыга.

Шулай итеп, Сез язучылыкны буячы һөнәре белән алыштырып барасыз. Әйбер — кешенеке, буяу гына үзегезнеке. Моңа кайберәүләр ышанырга да мөмкин, чөнки телегез әйбәт кенә кебек. (Кызганычка каршы, бүген матур тел белән күп гонаһларны каплап була әле.) Ләкин заманыбызның акыллы укучысы моңа алданмаячак. Ул әдәбияттан да тормыштагыча чынлыкны, намуслы көрәшне, яшьлек исеменә лаек булырлык матур батырлык көтә. Әдәбияттагы яшьлекнең тормыштагы яшьлек кебек тынгысыз һәм революцион, акыллы һәм матур, бай рухлы һәм көчле булуын көтә...

Башкалар әдәбиятта, тормышта тырыша-тырыша үз сукмагын салганда, үзе яңа матурлык, яңа рухи дөнья ачу өчен җанфәрман тырышып ятканда, абына-сөртенә алга таба атлаганда һәм бары тик шулай гына тормыш юлын намус белән үтә алачагына ышанып, шул ышанычны ныклы бер таяныч итеп алган бер вакытта, Сезнең шушындый шома, ләкин тайгак юлдан атлавыгыз безне нык борчый. Аннан да ныграк борчыганы тагын шул, Сез үзегезнең каләмдәшләрегезгә, үз урләрен ялый-ялый, үз ачышлары белән укучыны сокландыра-сокландыра, авыр, ләкин намуслы юлдан баручы яшьтәшләрегезгә масаюлы караш ташлап, аларның моңарчы ирешкәннәрен җиңел генә сызып ташларга телисез. «Идел» альманахының 1975 елда чыккан санындагы мәкаләгездә А. Ганиев, Р. Кәрамиев, И. Низамовлар иҗатына булган артык җиңел караш әнә шундый тәэсир калдыра.

Үз каләмдәшләрегез турында шулай өстән генә фикер йөртүегез һәм җиңел кулдан язылган мәкалә бастыруыгыз — бу инде ялгышу гына түгел, бу — ялгыш юлда тынычланып калу, тирә-якка, башкаларга игътибарлы, эзләнүчән карашның булмавы. Әнә шулар Сезне чын әдәбиятны, аның олы максатларын аңламауга китергән. Чын әдәбият олы күңелнең, заман рухы белән, кешеләрнең иң зур омтылышлары, өметләре белән дулкынланган нечкә күңелнең тормыш белән очрашуыннан, акыллы һәм усал дөнья белән бәхәсеннән, ихлас көрәшеннән туа.

Безнең яңа чорның бик күп яңа агымнары, яңа көчләре, яңа юллары бар. Заман әдәбиятының зур бурычы — кешегә ул юлларда, ул көчләр арасында югалып калмаслык, олы кыйбласын югалтмаслык көч һәм зиһен, акыл, гыйбрәт бирү. Шул олы бурычны үти-үти ул үзе дә яңа көч-

ләр, яңа конфликтлар биеклегенә күтәреләә, яңа тормышны өйрәнүче буларак, тәҗрибәсен арттыра. Чын әдәбиятның, чын язучының юлы — шул юнәлештә.

Яшь авторлар... Безнең әдәбияттагы яшьләргә күп нәрсә җитми. Ә шулай да, барыннан да бигрәк, аларга тормыш өчен, аның ничек агуы, кая таба агуы өчен үзендә җаваплылык булдыру җитми. Әнә шундый социаль пассивлык бүгенге көн алдында көчсезлек булып чагыла һәм аларны, ирексездән, үткәнгә, «тәмле» үткәнгә яки «ачы» үткәнгә алып китә. Ә бүгенне аңламаган, аның көрәшләрен, тенденцияләрен дөрес тоймаган кеше өчен, билгеле, үткәннән бүгенгегә дә, киләчәккә дә юл юк. Ул бары тупик кына!

Тормышка яшь, яңа буын кереп бара. Ул — Сезнең, безнең буын, Әхәт иптәш Гаффаров! Ул буын тормышта зур эшләр башкарырга тиеш. Ләкин моның өчен аның юл башы дөрес булу, ышанычлы атлап бару өчен баскан җире нык булу, җилкәгә күпме генә авырлык салганда да, тайдырмый торган, екмый торган булуы кирәк. Яшьлек әнә шулай юл башында торганда тирә-юньгә карана, үзенә җитмәгән тәҗрибәне, акылны башкалардан эзли, яшьтәшләренең, үзенең нинди ялгышлар җибәрүен белеп торырга, тормышның дөрес юллары кайда икәнен белергә тели... Шундый олы өметләр аның карашын әдәбиятка юнәлтә. Бу караш бер буынныкы гына да түгел, ул — бер буын аша бөтен җәмгыятьнең җавап көтүе.

Аңа җавап бирү яшь язучының намус эше, аның яшәү мәгънәсен билгели торган эш!

**Мансур ВӘЛИЕВ.**

# Төптәнрәк уйлаганда...

## ИКЕ КЕШЕ, ИКЕ ФИКЕР

Бер китап хакында капма-каршы ике фикер, яшь автор иҗатына ике төрле караш... Нишлисең, безнең әдәбият практикасында мондый хәлләр булганы бар. Һәм журнал редакциясе, бик хаклы рәвештә, аларның һәр икесен басарга булган, чөнки ул рецензияләр күпмедер күләмдә әлеге китап турында укучы фикеренең дә каршылыклы булуын күрсәтә.

Әдәбият белгече И. Бәшированың искитмәле мәдхиясе белән яшь тәнкыйтьче М. Вәлиевнең артык кискен, хәтта тупас бәясе арасында уртак якларны эзләп карыйк. Чагыштырмача икесе дә яшьләр, берсе дә әдәбиятта очраклы кеше түгел, аларның берсен дә әдәби процесс законнарын белмәүдә гаепләп булмый. Аларның берсеннән дә редакция мәкалә сорамаган, димәк, икесе дә үзләре теләгәнне, күңелләре кушканны язганнар. Бу үзе үк инде Ә. Гаффаровның «Әҗәт» исемле җыентыгы безнең әдәбиятта җитди игътибарга лаек китап булуы хакында сөйли. И. Бәширова бу хакта турыдан-туры яза, сүз тәссез, талантсыз автор турында барса, М. Вәлиев тә бу кадәр тавыш куптарып тормас иде, дип уйлыйм.

Шул кадәресен дә истән чыгармаска кирәк, Ә. Гаффаров — күп кенә күренекле язучыларның, танылган аксакалларыбызның уңай бәясен алган язучы. «Әҗәт» исемле җыентыгы басылып чыккач, ул бертавыштан СССР Язучылар союзына член итеп алынды. Тагын бер кечкенә генә «серне» ачыйк: яшь авторга Союзга керү өчен кирәк булган рекомендацияләрнең берсен мин бирдем, чөнки Ә. Гаффаровны өметле яшь прозаикларның берсе дип уйлыйм һәм хәзер дә шул фикердә калам. Әдәбиятта прогнозлар кую — хәтәр эш, билгеле. Әмма язган кадәр әсәрләреннән чыгып фикер йөрткәндә, Ә. Гаффаров башка яшь прозаиклардан нык аерылып тора: аның үз стиле, чынбарлык күренешләренә үз карашы, үз мөнәсәбәте бар. Нәкъ менә шуңа күрә дә авторга үз вакытында иҗатының көчле һәм көчсез якларын күрсәтеп бирергә, иҗатындагы кимчелекләрдән арынып китәргә, тизрәк үз иҗат йөзен ачыкларга булышырга кирәк.

Ә. Гаффаров иҗатына уңай бәя бирүгә килгәндә мин И. Бәширова белән тулысынча килешәм. Ул аның әсәрләренең ли-

ризмын, экспрессиягә тартымлыгын, аның әсәрләрендә әдәби детальләрнең мөһим роль уйнавын, яшь автор иҗатына хас күп кенә башка үзенчәлекләрне дөрес билгели. Ә. Гаффаровның экспрессив-ассоциатив язу алымы белән хисләр киеренкелегенә корылган шигъри стиль арасында параллельләр уздырганда да И. Бәширова, һичшиксез, хаклы. Чыннан да, Ә. Гаффаров прозада яңа сурәтләү чаралары эзли. Шул чагында, рецензент бик дөрес күрсәткәнчә, ул арттырып та җибәрә, кайчак үз әсәрләренең телен, стилен һәм композициясен артык катлауландырып ташлый.

Мин И. Бәширова белән кайбер вак нәрсәләрдә генә килешеп җитмим. Ул, мәсәлән, «Яра» повестен яшь авторның алга таба үсүе, тормышны бөтен каршылыклары һәм катлаулы яклары белән танып-белергә омтылуы хакында сөйли торган әсәр дип бәяли. Хәлбуки, «Яра» — Ә. Гаффаровның беренче зур әсәре (рецензентны ул әсәрләрнең китапта урнашу тәртибе бутаган, күрәсең). «Яра» повестенда яшь авторның тәҗрибәсезлеге бик ачык сизелә. Бу композицияне юри катлауландыруда да, чит тәэсирләрнең ярыйсы ук көчле булуында да, сюжет алымнарының шактый дәрәҗәдә ясалма булуында да күренә. Яшь авторның үсеш эволюциясе «Язлар моңы»ннан «Яра»га таба түгел, киресенчә, «Яра»дан «Язлар моңы»на таба, уралып беткән сюжеттан гади, ачык сюжетка, юри куертылган буяулардан нечкә, акварель төсләргә таба бара.

Яшь авторның алга таба үсешен аңлау өчен бу бик принципиаль мәсьәлә. Миңа калса, И. Бәширова җыентыктагы «Кояшның салкын чагы» исемле хикәяне дә шактый гадиләштереп, туры сызык буенча аңлата. Игътибар белән укыганда күрерсез, бу хикәядә автор аңлы рәвештә вакыйгаларга үзе катнашмый, укучыга үз хөкемен көчләп такмый, аның үзенә уйларга һәм фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, бәйләнчек настроениеле М. Вәлиев әлеге хикәянең новаторлык характерын нечкәрәк сиземләгән.

И. Бәширова рецензиясенең төп кимчелеге шунда, Ә. Гаффаров иҗатына мөкиббән китү сәбәпле, ул яшь автор иҗатында булган кимчелекле якларны бөтенләй күрми. М. Вәлиев исә үзенең ачык хатында нәкъ менә йомшак якларга басым ясый.

ПЛАГИАТМЫ?..

М. Вәлиевнең хатын укый башлауга аның ачыктан-ачык усал, хәтта, әйтер идем, ярсулы тонда язылган булуы күзгә ташлана. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында булып үткән бер җыелышта ул Ә. Гаффаров иҗаты хакында шундыйрак тонда чыгыш ясап караган иде. Аңа шунда ук каршы чыктылар, Ә. Гаффаров — өметле яшь прозаикларыбызның берсе, аның иҗатында кимчелекләр очрый икән, аларга каршы таяк белән дә, күсәк белән дә түгел, ә нечкәрәк корал белән көрәшергә кирәк, диделәр. Хәзер шул ук сүзләрне мин яңадан кабатларга мәҗбүр. Артык кызып, ярсып китү, ул хәтта чын күңелдән булган очракта да, әдәби тәнкыйтьтә начар киңәшче. Ярый, бу нәрсәләрне тәнкыйтьченең үз намусына калдырып, мәсьәләнең асылына күчик.

Тәнкыйтьче яшь авторны плагиатлыкта, гади тел белән әйткәндә, әдәби караклыкта гаепләргә тырыша. «Әдәби терминнар сүзлеге»ндә, бернинди икеләнүләргә урын калдырмаслык итеп, «үз исемеңнән башка кеше әсәрен, яки аның берәр өлешен бастырып чыгару плагиат дип атала», диелгән. (Мәскәү, «Просвещение» нәшрияты, 1974 ел, 270 бит.) Плагиат зур җинаять санала, андый кешеләр закон тәртибендә җавапка тартыла.

Мин Мансур Вәлиев мәкаләсендә телгә алынган барлык әсәрләрне карап, чагыштырып чыктым һәм бөтен җаваплылыкны үз өстемә алып әйтә алам: Ә. Гаффаровны плагиатлыкта гаепләп булмый... Мин бер генә охшаш абзац та, бер генә уртак фраза да таба алмадым. Дөрес, М. Вәлиев үзе дә сүз турыдан-туры күчереп язу турында түгел, ә ниндидер сюжет сызыкларын, әдәби алымнарны файдалану турында бара, ди. Алай икән, ул чагында плагиатлык турында түгел, ә яшь автор иҗатына әдәби традицияләрнең йогынтысы, тәэсире турында сөйләргә кирәк. Аларның икесе ике нәрсә бит.

Ә. Гаффаров әсәрләрендә шундый тәэсир сизеләме, сизелсә, ул нәрсәдә күренә?

Сүзне «Яра» повестеннан башлыйк. М. Вәлиев хаклы, бу — авторның иң йомшак, иң җитлекмәгән әсәре. Ә. Гаффаров повестенда, чыннан да, А. Ивановның «Шушы гөнаһлы җирдә тормыш» («Жизнь на грешной земле») повесте белән күпмедер аваздашлык та бар. Әлеге әсәр-

ләрнең икесендә дә тискәре персонаж (А. Иванов повестенда Денис Макшеев, Ә. Гаффаровта — Галимҗан), яраткан кызына өйләнү өчен, көндәшен нахак гаеп белән төрмәгә утырттыра. Һәр ике әсәрдә чор уртак (колхозлашу еллары, Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар), әсәрләрнең пафосы, төп идеясе уртак. Һәр ике повестьта кабәхәт җанлы кеше үз-үзе белән, үз вөҗданы белән ялгыз калдырыла, физик җәзадан бигрәк, әхлак җәзасына хөкем ителә. Ләкин авторны плагиатлыкта гаепләү өчен бу фактлар гына җитми. Һәркемгә билгеле бер мисалны китерик. Экраннарга Ю. Нагибин сценариесе буенча эшләнгән «Председатель» исемле нәфис фильм чыккач, барлык милли республикаларда диярлек шуңа охшаш ситуацияне сурәтләгән әсәрләр язылa: артта калган колхозга яхшы председатель килә, зур кыенлыклар белән, күп көч һәм күп тир түгеп, ул колхозны аякка бастыра һәм алдынгылар рәтенә чыгара (В. Нуруллинның «Күпер чыкканда», Ф. Хөснинең «Мәйдан» повестьларын искә төшерү дә җитә). Ләкин бу әле һич тә башка кеше әсәрен үзләштерү турында сөйләми. Аерым ситуацияләрнең охшашлыгына түгел (алар тормышның үзендә шулай булырга мөмкин), ә образларның оригинальлыгына, тормыш материалының никадәр чын булуына карарга кирәк. Беренче әсәре никадәр генә йомшак һәм җитлекмәгән булмасын, Ә. Гаффаровның образлары да, тормыш материалы да — үзенеке. Бу инде плагиатлыкны гына түгел, А. Иванов повестеннан нидер алу, үзләштерү турындагы сүзләрне дә тулысынча юкка чыгара.

Тагын бер факт игътибарга лаек. М. Вәлиев үз мәкаләсенең буеннан-буена Ә. Гаффаров повестен А. Иванов повесте белән түгел, ә шул повесть нигезендә эшләнгән нәфис фильм белән чагыштырып бара. Бу очраклы хәл түгел. Эш шунда, Ә. Гаффаров ул повестьның үзен бөтенләй укымаган икән, ә фильмны караган. Ләкин повесть язылып беткәннән соң караган. Чыннан да, аның повестеның беренче варианты әле 1971 елда (фильм экраннарга чыкканчы) ук язылa. Мин һәм проза секциясенең кайбер башка членнары ул әсәрне шул чагында ук укыган идек. Аннан бирле автор бу әсәрне нык кына эшкәрткән, әмма сюжет сызыгы, төп коллизияләр элеккечә калган.

Бу әсәрнең йомшаклыгы тагын шунда күренә, автор анда сюжетны шактый ясалма итеп кора. Мине, мәсәлән, тискәре герой Галимҗанның вөҗдан газабыннан үлеп китүе һич тә ышандырып җиткермәде. Автор бу хакта әйтеп кенә үтә, ә аның вөҗдан газабын һәм бәргәләнүләрен тирәнтен ачып бирми. (А. Иванов повестенда бу як бик әйбәт ачыла.) Рахман белән Галимҗанның арбага утырып авылга кайтып килүләрен алыйк. Рахман аңа яңа әсәреннән өзекләр укып күрсәтә — Галимҗанның исе дә китми. Күреп торабыз: Галимҗан элек нинди кеше булса, хәзер дә шундый булып калган икән... Аның, урлаган киртәләкләрен күрсәтмәс өчен, туры юлдан китмичә, әйләнеч юлдан кайтуы үзе ук күп нәрсә хакында сөйли. Хәзер туры юлны әйләнечкә алмаштырган кебек, ул гомер буе кыек юлдан йөргән. Әйе, А. Ивановның «Шушы гөнаһлы җирдә тормыш» повестенда язылганча, кайчакларда әшәке, кабәхәт эш эшләгән кешегә иң зур җәза — аны вөҗданы белән япа-ялгызын калдыру. Әгәр кешенең вөҗданы булмаса?.. Ул инде ялганларга, алдарга өйрәнгән, үз файдасын гына кайгыртырга өйрәнгән булса?.. Мондый кешеләргә карата, минемчә, әлеге рецепт ярамый. Иванов повестеның герое Павел Демидов үзенең дошманын аның белән янәшә яшәве белән газаплый, үзенең хаклыгын расларга аның башка мөмкинлеге булмый. Ә. Гаффаров повестенда Булатның шаһитлары бар, эшнең нидә булуын белүче кешеләр бар. Үзенең исемен аклау өчен, Булат нигә көрәшми соң?.. Кыскасы, проблемалары шактый дәрәҗәдә уртак булган «Яра» һәм «Шушы гөнаһлы җирдә тормыш» повестьларын үзара чагыштырып карау яшь авторның кимчелекләрен һәм җитешсез якларын тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Ләкин бу чагыштырып карау һич кенә дә үзләштерү, бигрәк тә плагиат хакында сөйләргә җирлек бирми.

Авторның «Теге гозер» исемле повесте хакында да шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин булыр иде. Ә. Гаффаров яшерми, аның иҗади йөзе формалашуга Э. Хемингуэй шактый көчле тәэсир ясаган. Бу бигрәк тә әсәрләрнең стилистикасында ачык күренә. Күп мәгънәле тыгыз фразалар, фикерне әйтеп бетермәү, ситуацияләрнең драматик киеренкелеге, чәйнәп бирүдән, үз геройларының эш-хәрәкәтләрен тәфсилләп мотивлаштырудан качу — боларның һәммәсеннән шактый дәрәҗәдә Хе-

мингуэй «исе килә». Ләкин монда гаепләрлек берни дә юк, андый характердагы иҗади өйрәнү бөтен заманнарда да булган. Г. Тукай осталыкка А. Пушкин белән М. Лермонтовтан өйрәнгән, Ә. Еники бөек рус язучысы А. Чехов манерасын иҗади үзләштергән, Р. Харисов иҗатында Н. Хикмәт һәм Дәрдмәнд тәэсире, И. Юзеевның беренче шигырьләрендә Һ. Такташ интонацияләре ачык сизелә. Кыскасы, дөнья әдәбияты корифейларыннан шул рәвешчә өйрәнү очраклы нәрсә түгел, ә кагыйдә төсен алган нәрсә. Инде яшь автор тизрәк үз алымын, үз йөзен табарга тиешлек хакында сүз бара икән, бусы — икенче мәсьәлә. Һәм моңа тиз генә ирешеп тә булмый.

Инде тәнкыйтьченең «Язлар моңы» повесте турындагы фикерләре бөтенләй көлке яңгырый. Миңа калса, «Язлар моңы» (җыентыкка исем биргән «Әҗәт» хикәясе белән бергә) яшь авторның иң уңышлы һәм иң үзенчәлекле әсәре. Повесть психологик тирәнлеге, музыкальлеге һәм теленең образлы, лаконик булуы белән игътибарны җәлеп итә. Хәер, бу әсәр И. Бәширова тарафыннан ярыйсы ук тәфсилле һәм ышандырырлык итеп анализлана. Бу повестьта Г. Николаеваның «Урак өсте» («Жатва») романын хәтерләткән берни дә юк. Мондый юл белән китсәң, Г. Николаеваның үзен К. Симоновның «Вичуга шәһәре хатынына» исемле шигырендәге ситуацияне алган дип гаепләп булыр иде. Әдәби әсәрдә ситуацияләр үзләре түгел, ә аларның ничек эшкәртелүе, кеше характерлары, аларның үз-үзләрен тотыш логикасы аеруча мөһим.

## ТИРГӘГӘН КЕШЕ — БАЕТА...

Алда әйтелгәнчә, кызып, ярсып киту аркасында М. Вәлиев талантлы һәм эзләнүчән прозаикның көчле һәм уңышлы якларын күрми калган. Үзенең төп игътибарын тәнкыйтьче кимчелекләргә юнәлткән. Ул кимчелекләрнең кайберләре Ә. Гаффаров иҗатында, чыннан да, очрый, ә күбесен рецензент уйлап чыгарган. Бер урында М. Вәлиев болай дип яза: «Сез геройларның эчке дөньяларына, уй-фикерләренең диалектикасына караганда, аларның теленә, сүзләренә артык нык игътибар бирәсез һәм, геройның эчке дөньясы буш икәнлеге сизелмәсен дип куркып, укучының игътибарын кинәт кенә табигатькә, тирә-юньгә күчерәсез». Үз фикерләрен раслау өчен тәнкыйтьче күп кенә мисаллар китерә. Шуларның берсен без дә карап үтик: «Сәгыйдулла аны-моны искәргәнче, Ярми гармунны урам уртасына таба тибеп тә очырды. Гармун ялгыз каз кебек каңгылдап куйды да тынды.

Елгада бозлар чатнады. Күрәсең, ташкын бозны ашый башлаган — су тавышы көчәйде. Ярминең сүгенеп кычкыруына кайтаваз булып зират агачлары җавап бирде, этләр өрергә тотынды».

Автор геройның хисләрен, ниләр уйлавын язып тормый. Ул үз героеның шул мизгелдәге халәтен нәкъ менә табигать күренеше аша ачып бирә. Урам уртасына тибеп очырылган гармунның ялгыз каз кебек каңгылдап куюы геройның халәтен гади сүзләргә караганда күп тапкыр тирәнрәк ача. Гармун тавышын әсәрнең герое шулай кабул итә бит. Сәгыйдулла өчен гармун — аның тынгысыз, өзгәләнүче ялгыз җаны. Бу төндә ташу китүен сурәтләү дә күп нәрсә турында сөйли. Геройның моңарчы тыелып торган хисләре, буаны ашый башлаган язгы ташкын кебек, киеренкелекнең соңгы чигенә җитә. Буаны ерган язгы сулар кебек, алар тышка, иркенлеккә омтылалар. И. Бәширова яшь прозаик Ә. Гаффаров әсәрләрендәге сүзләрнең, детальләрнең менә шундый күп мәгънәле булуын дөрес күргән. Бу һич тә язучының кимчелеге түгел, ә бәлки аның иҗатының специфик үзенчәлеге. Дөнья әдәбиятының иң яхшы казанышларыннан үрнәк алып, Ә. Гаффаров үз геройларының психологик халәтен, эчке драматизмын бирү өчен яңа мөмкинлекләр эзли һәм күп очракта уңышка ирешә.

Инде «Кояшның салкын чагы» исемле хикәянең ахырына тукталыйк. Чөнки ул И. Бәширова өчен дә, М. Вәлиев өчен дә каты чикләвек булып чыккан. И. Бәшировага хикәядәге кызның кыр казын атып үтерүе сәер булып тоелган, аңа кызның миһербансызлыгы, рәхимсез булуы ошамаган. Автор нәкъ шуны әйтергә теләгән дә бит инде. Дөрес, ул бу фикерне турыдан-туры, маңгайга бәреп әйтми. Шушы бер ату гына герой күңелендәге мәхәббәтне дә сүндереп җиткерә алмый. Әмма аның күңелендә үзенең җуелмас эзен калдыра. Хикәянең соңгы җөмләләре хакында уйлап карыйк: «Әсфән, тынычланырга теләп, болыт тауларына карады. Алар Хәдичәнең йөзе кебек ачык, якты иде. Әсфәннең бо-

лытларга кагыласы килде. Ләкин алар ерак иде». Геройның күңелендә хәзергә үзе дә аңлап бетермәгән давыл кайный. Тынычланырга, үз-үзен тыярга теләп, ул күктәге болытларга карый. Хикәядәге кыз гына үзенең нинди зур җинаять эшләп ташлавын аңламый. Аның йөзе, күктәге болытлар кебек, салкын һәм битараф кала. Әсфәннең кагыласы килгән теге болытлар кебек үк. Нигә? Ихтимал, үз-үзен тикшерү, үз-үзен ышандыру өчендер инде: алар, чыннан да, шулай салкын һәм хиссезме икәнни? Ләкин болытлар ерак. Аның сөйгән кызы кебек үк ерак. Төгәлрәк итеп әйткәндә, аның элекке сөйгәне кебек. Чөнки автор характерлы детальләр ярдәмендә Әсфәннең кыздан торган саен ераклаша баруын күрсәтә алган. Мондый кызны ул ярата алмаячак!

Күрәсез, Ә. Гаффаров прозасы бер мәгънәле генә түгел. Ул укучыдан актив рәвештә иҗади фикер йөртүне таләп итә торган катлаулы, авыр проза. Дөрес, авторның үз принципларын практик яктан нихәтле эзлекле һәм ышандырырлык итеп тормышка ашыра алуы хакында бәхәсләр булырга мөмкин. Әмма авторның дөрес юлдан баруына шикләнеп булмый.

Яшьләр прозасының артта калуын М. Вәлиев яшь авторларның иҗтимагый һәм социаль яктан пассив булуларында күрә. Бу мәсьәләдә ул хаклы. Чыннан да, күп кенә яшь прозаиклар иҗатына темаваклыгы, үзләренең интим хисләрендә казыну, әдәби штампларга ябышып яту хас, бүгенге заманның катлаулы мәсьәләләре хакында җитди фикер йөртә белү җитми. Күпмедер күләмдә бу җитешсезлекләр Ә. Гаффаров иҗатына да хас. Әмма башка яшь язучылар арасында ул иҗади планда да, иҗтимагый планда да иң активы булса кирәк. «Социалистик Татарстан» газетасының әдәби хезмәткәре буларак, ул еш кына республика районнарында була, рецензияләр, тәнкыйть мәкаләләре, очерклар яза, күп һәм нәтиҗәле төстә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. Шуңа да аны берничек тә иҗтимагый проблемаларга битарафлыкта гаепләп булмый дип уйлыйм. Үткән көннәр турында сүз барган өчен генә, аның әсәрләрен файдасыз дип санау — урынсыз.

Ә. Гаффаров кебек үк, М. Вәлиев тә әдәбият мәйданына яңа аяк баса. Полемик рухлы, үткен телле мәкаләләре белән ул үзен сәләтле һәм талантлы тәнкыйтьче, әдәбияттагы яңа, алдынгы алымнарны яклаучы, торгынлыкка, штампларга каршы көрәшүче тәнкыйтьче итеп танытып өлгерде. Бу очракта исә аңа әдәби зәвыгы хыянәт иткән төсле, ә бу — бик кызганыч хәл.

Төп положениеләре дөрес булмагач, М. Вәлиев мәкаләсен нигә басып торырга, диярләр. Хикмәт шунда, ул телгә алган кимчелекләрнең байтагы безнең яшь прозаикларга, чыннан да, хас. Ә. Гаффаровка исә мондый тәнкыйтьнең әллә ни зур зыяны тимәс. Чөнки халык: «Мактаган кеше — талый, тиргәгән кеше — баета», ди. Сүз яшь авторның иҗади үсүенә ярдәм итү, юл күрсәтү турында бара.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# АЛГЫ СЫЗЫКТАН РЕПОРТАЖ

Әгәр тугызынчы бишьеллыкның иң зур объектын — Кама автомобиль заводын язучылар һәм журналистлар да төзеште дисәк, бу әллә ни арттыру булмас төсле. Чөнки әлеге төзелеш үзенең беренче адымнарыннан башлап әдәбият, сәнгать һәм матбугат вәкилләренең игътибар үзәгендә булды. Нибары 3—4 ел вакыт эчендә гигант төзелеш, аның хезмәт сөючә кешеләре турында, Мәскәү нәшриятларында булсын, үзебезнең Казанда булсын, фоторәсемнәр һәм иллюстрацияләр белән бизәлгән дистәләрчә җыентыклар дөнья күрде. Алар арасында уналты авторның КамАЗга багышланган мәкалә-очеркларын туплаган «Чаллы таңнары» дигән татарча җыентык та бар. Төзүчесе — Чаллыда яшәүче танылган язучы Эдуард Касыймов. Рецензенты — Чаллы шәһәре партия комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Галимҗан Сәйфетдинов.

«Чаллы таңнары» җыентыгы мәрхүм язучыбыз Сөббух Рафиковның «Таш билге» исемле очеркы белән ачыла һәм Равил Вәлиевнең «Беренче станок» дигән язмалары белән ябыла. Бу — очраклы хәл түгел, ә бәлки КамАЗ төзүчеләрнең илебез белән бергә үткән зур көрәшенең мәгълүм бер этабы. Бу — борынгы Чаллы җирендә беренче чүмеч җир казылган көннән алып ремонт-инструменталь заводында беренче станок эшли башлаганчы узган җаваплы чор; төзүчеләр коллективының формалашу, ныклап аякка басу, уңыш һәм куандыргыч җиңүләргә ирешү чоры. Китапка тупланган очерк һәм язмалар — шул гаять катлаулы һәм героик чорның тулы картинасын тудыру юлында мактауга лаек омтылыш.

Җыентык әсәрләренең барысы да диярлек КамАЗ темасының зурлыгын, мөһим һәм әһәмиятле булуын аңлап, тормыш материалын, геройларның хезмәтен һәм язмышын тирәнтен һәм җентекләп өйрәнеп, күңел җылысы куеп язылган. Китапның нигезен С. Рафиков, Р. Бикташиров, М. Зарипов һәм Ф. Видрашку очерклары тәшкил итә дияргә була. Бу очеркларда китерелгән күп санлы фактик мәгълүматлар автозавод комплексының зурлыгын, масштаблыгын күзалларга ярдәм итәләр. Башка әсәрләрдән үзгә буларак, бу дүрт авторның очеркы, аерым бер геройның тормыш һәм хезмәтенә генә багышланмыйча, төзүчеләрне дулкынландырган, борчыган гомуми проблемаларны үзәккә, алгы планга куеп, төзелешнең киеренке һәм тулы картинасын, КамАЗ төзүчеләренең коллектив портретын иҗат итәләр.

С. Рафиковның вакыйгаларга бай очеркы «Бу яклар минем язмышым белән бәйләнгән» дигән сүзләр белән башланып китә. Ул безне башлангыч чорда төзелеш мәйданында кайнаган хезмәт шау-шуына алып керә. һәм, әйтергә кирәк, әсәр үзенә аерым бер поэтик аһәң, Чаллы якларына олы мәхәббәт белән язылган. Автор әледән-әле үткән көннәргә экскурс ясап ала, үзенең «киндер ыштан, киндер күлмәк кигән малай чакларын, чабаталы егет чакларын» искә төшерә. Бу исә язучы биографиясенең аерым детальләре генә түгел. Бу — илебез үткән тарихи юл.

Без еш кына КамАЗны фәнни-техник революция казанышларына нигезләнеп төзелә торган гасыр корылмасы, социализмның мөмкинлекләрен, фәнни-техник фикерләүнең сынау лабораториясе дип әйтәбез. Ул Амурдагы-Комсомольск һәм Магнитка, Днепрогэс һәм Тольятти төзелешләрендә ирешелгән һәм җыелап алынган техник казанышларның бүгенге көндә лаеклы дәвамы, үсүе һәм үстерелүе. С. Рафиков әсәрендә әнә шул фикер ярылып ята. Язучы

беренче көннәрдән ук Камадагы төзелешне үзенең язмышы итеп кабул иткән һәм шуңа күрә дә Чаллы җиренең индустриаль пейзажын, аның яңаруын күңеле белән тоеп, заманның колачын, төзелеш мәйданында туган характерлы күренешләрне тотып ала һәм матур итеп тасвирлый алган.

Р. Биктаһировның «Кубик»лар турында баллада» исемле очеркы вакыйгаларының сурәтләнүе ягыннан алда тикшергән «Таш билге» очеркының дәвамы булып тоела. Әсәрдә КамАЗ төзелешендәге вакыйгаларның иң кызган чагы, иң киеренке көрәш көннәре сурәтләнә. Бу очерк безгә төзелештә кулланылган яңа методларны, зур җиңүләргә ирешү серләрен ачып сала, «фәнни-техник эзләнүләрнең глобаль башлангычы» булган эш процессларын җанлы һәм мавыктыргыч итеп тасвирлый.

Очерктагы геройлар — КамАЗ төзелешендәге атаклы экскаваторчы Михаил Носков, автоскреперчыларның танылган бригадиры Умат Наурбиев, скважина бораулаучылар бригадиры Леонид Попов һәм субайчылар бригадиры Виктор Кузьмин, рекордчы бригадирлар Версавий Пан һәм Борис Лопатиннар — безнең күңелләрдә акыл көче белән физик көчне бер дәрәҗәдә иярләгән, эзләнүче һәм фикер йөртүче алдынгы иҗади хезмәт кешеләре булып килеп басалар. Автор аларны хәрәкәттә, эш процессына актив мөнәсәбәтле рәвештә күрсәтә алган, шуңа күрә геройлар барысы да җанлы һәм тормышчан булып чыкканнар, укучыларда ышану һәм соклану хисләре уяталар.

Ф. Видрашкуның «Киләчәккә карап...» исемле очеркы Чаллы шәһәренең партия оешмасы һәм аның беренче секретаре Р. К. Беляев турында. Партия шәһәр комитеты турында язу ул шәһәрдәге башка җитәкче-коммунистлар турында да язу дигән сүз. Чөнки КамАЗ төзелешендәге гаять зур эшләрне башкарганда партия шәһәр комитеты, иң беренче чиратта, урындагы җитәкчеләргә мөрәҗәгать итә, шуларга таянып эшли. Р. Беляевтән тыш, автор үз әсәрендә төзелеш начальнигының беренче урынбасары Е. Н. Батенчук, автозаводның партком секретаре А. А. Родыгин, шәһәр төзелеше идарәсенең баш инженеры М. В. Котвицкий һәм башка җитәкчеләрне ышандырырлык детальләр аша сурәтли. Төзелеш җитәкчеләрен борчыган, алар башкарган йөзләрчә зур һәм кечкенә эшләр аша әсәр КамАЗ тормышының киеренке пульсын, аның кайнар сулышын тоярга ярдәм итә. Әмма, безгә калса, Ф. Видрашку урыны белән һәркайсы үзалдына аерым-аерым яши торган картиналарны үзара бәйли торган җепне ычкындырып җибәрә. Шуның аркасында, үзәк герой белән икенче дәрәҗәдә геройларның элемтәсе, үзара мөнәсәбәте югала. Алар үзәк образны үстерергә һәм тулыландырырга ярдәм итмиләр. Ахыр чиктә, тормышта без белгән Рәис Беляев очерктагыга караганда күп тапкыр җанлырак һәм эшлеклерәк, колачлырак һәм активрак.

Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, язучыларыбызның төзелеш темасына багышланган әсәрләрендә — партия хезмәткәрләренең фидакарь хезмәте тиешенчә чагылыш тапканы юк әле. Фән һәм техника казанышлары чорында партия җитәкчесе белән төзелеш җитәкчеләренең үзара мөнәсәбәте, төзелештә туган яңа идеяләр һәм ысуллар, әр-яңа фикерләрне производствога кертү, тамыр җәйдерү эшенә партия йогынтысы һәм башка шундый әһәмиятле мәсьәләләр үзләренең авторларын көтеп калалар. Ә КамАЗ төзелеше бу өлкәдә уйлану өчен бай материал бирә.

Күп кенә зур төзелешләрдә чыныккан төзелеш җитәкчесе образын тудыру язучыларыбыз өчен шулай ук «теш үтмәслек» каты чикләвек булып кала бирә. М. Зарипов, Р. Биктаһиров, Ф. Видрашку очеркларында, әйтик, төзелеш начальнигының беренче урынбасары Е. Н. Батенчук турында шактый күп мәгълүмат бирелә. Әмма бер генә әсәрдә дә аның тулы канлы образы тудырылганы юк әле. Уйлап карасаң, бу легендар кеше — чын мәгънәсендә киң колачлы һәм масштаблы зур фигура, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе. Бөек Ватан сугышы ветераны һәм Каршылык күрсәтү хәрәкәтендә катнашкан кеше. Күпне күргән һәм кичергән тынгысыз коммунист, атказанган төзүче, фәнни хезмәтләр авторы, күп кенә орденнар һәм медальләр кавалеры, уннарча мең кешедән торган коллективны җитәкләгән төзелеш командиры. Әмма әлегә кадәр чыккан әсәрләрдә Батенчук образы бүлгәләнеп, тараеп, вакланып кала.

Кама автомобиль заводы төзелеше республикабыз тормышына, аның культурасына һәм экономикасына зур йогынты ясады. Шуның белән бергә, ул барлык кешеләргә дә, төрле яшьтәге, төрле милләт, төрле профессия кешеләренең тормышына, көнкүреш-гадәтенә, уй-фикеренә тирән эз

салды. Э. Касыймов, М. Маликова, К. Тимбикова, Р. Хисмәтуллин, К. Тәхәү һәм М. Әмирхановларның әсәрләрендә төзелеш алып килгән яңалыкның кешеләр язмышында чагылышы тасвирлана.

КамАЗ, беренче чиратта, колач җитмәс масштаблары, бай язмышлы кызык кешеләре белән үзенә тарта. Шуның белән бергә, зур төзелеш үзе белән төрле борчулар һәм мәшәкатьләр дә алып килә икән. Ә. Маликов «Язмышлар» исемле әсәрендә автогигант алып килгән әнә шул борчуларны үзенеке итеп кабул иткән, милиция идарәсе каршындагы балалар бүлмәсендә өлкән инспектор булып эшләгән милиция өлкән лейтенанты Рафика ханымның тормышчан, ягымлы образын тудырган.

Һәркайсыбызга билгеле, КамАЗны, беренче чиратта, бетончылар һәм монтажчылар, шоферлар һәм тракторчылар, балта осталары, буяучы-сылаучылар, эретеп ябыштыручылар төзи. КамАЗ корпуслары шул мактаулы һәм тыныч профессия кешеләренең эшчән куллары белән күтәрелә. Әмма Ә. Маликов, М. Маликова, К. Тимбикова һәм башка авторларның әсәрләрен укыгач, гигант автозавод һәм гүзәл шәһәрне шул ук милиция хезмәткәрләре һәм укытучылар, тулай торак тәрбиячеләре, сатучылар, врачлар һәм башка профессия кешеләре дә төзи икәненә ышанасың.

М. Маликованың «Чәчәкләргә бай тормыш» исемле очеркы да безгә беренче карашка артык гади булып күренгән кеше хезмәтенең — тулай торакта тәрбияче булып эшләүче хезмәтенең романтикасын күрсәтүе, аның шигъриятен ачып бирүе белән әһәмиятле. Укучылар аеруча лирик җылылык белән язылган очерктан тәрбияче профессиясе турында файдалы һәм тормыш өчен кирәкле байтак мәгълүмат алалар. Карасана, нинди катлаулы, кызыклы һәм мавыктыргыч икән бит ул тәрбияче хезмәте!

К. Тимбикованың җылы тәэсир калдырырлык итеп язылган «Кыңгырау чыңы» очеркы мәктәпләр тормышына, Чаллы мәктәпләренең берсендә немец теле укытучысы булып эшләүче Җәмһүрият Әхмиевага багышланган. Автор укытучы тормышыннан матур-матур эпизодлар китерә, аның образын шактый тулы ачуга ирешә.

Билгеле булганча, КамАЗ төзелеше Чаллыдагы мәктәп коллективлары тормышына да күзгә күренерлек үзгәрешләр кертте. Берничә ел рәттән инде яшьлек каласындагы һәр мәктәптә беренче сентябрь көнне дәресләр КамАЗга багышлана. Ул дәресләрне төзелеш җитәкчеләре, алдынгы бригадирлар, производство новаторлары алып бара. Әгәр дә очеркта Чаллы мәктәпләрендә туган әлеге матур традицияләр дә урын алган булса, әсәр бермә-бер уңышлырак һәм отышлырак, иң мөһиме, актуальрәк килеп чыгар иде.

М. Әмирхановны КамАЗ темасында уңышлы һәм нәтиҗәле эшләп килүчеләрнең берсе дигән идек. Ул — автозавод һәм аның кешеләре турында дистәләрчә репортажлар, очерклар, парчалар язган автор. М. Әмирхановның йөгерек тел белән язылган очеркында Социалистик Хезмәт Герое А. Б. Новолодский безнең алга Чаллыда хезмәте белән дан һәм шөһрәт казанган, бетон эшләре буенча берничә тапкыр союз күләмендә рекорд куйган алдынгы коллективның җитәкчесе, кыю һәм инициативалы бригадир булып килеп баса.

Журналист К. Тәхәү, Чаллы шәһәрендә яшәүче язучы Э. Касыймов һәм автозаводны салуда турыдан-туры катнашкан М. Газизов, Р. Юнысов, В. Суров һәм Л. Яруллиналарның кыска-кыска очерклары, этюд һәм парчалары да игътибарга лаеклы. Алар КамАЗдагы тормышның кабатланмас бер мизгелен, төзүчеләр тормышының әһәмиятле аерым фактларын тасвирлыйлар. Һәр әсәр көндәлек тормышта очрый торган вакыйгага корылган һәм алар төзүчеләрнең характерларын, олы җанлылыгын аерым тормыш детальләре аша ачып салалар.

Равил Вәлиевне әдәбият мәйданына КамАЗ алып килде, аның әдәбиятта беренче адымы уңышлы булды. Ул төзелештә беренче көннән бирле катнашып шактый бай материал туплады. Равил әсәрдән-әсәргә үсә, ныграк канат җәя бара. «Беренче станок» әсәре дә шул турыда сөйли. Әмма киләчәктә КамАЗ турында яңа әсәрләр язганда, ул публицистик аһәң белән киң гомумиләштерүләргә, лирик чигенешләргә әһәмият бирсен иде, дигән теләк белдерәсе килә. Бүгенге көндә аның әсәрләрендә нәкъ шул нәрсә җитенкерәми.

«Чаллы таңнары» — автозавод төзүчеләренең героик хезмәтен чагылдырган беренче җыентык. Сүз дә юк, китап язучыларның оператив эшләүләре, җәмәгать активлыгы һәм тормыш белән бер аяктан атлаулары турында сөйли. Әмма җыентыкка кертелгән әсәрләр барысы да бер югарылыкта, бер дәрәҗәдә түгел.

Инде әйтеп киткәнебезчә, КамАЗ төзелеше беренче көннәреннән үк язучылары-

бызның даими игътибарын биләп килде. Чаллыда «Новый мир» журналының даими эшли торган посты булдырылды. Журнал редакциясе белән автозавод төзүчеләр арасындагы дуслык, хезмәттәшлек елданел ныгый барып, матур нәтиҗәләргә китерде. Мин «Новый мир» журналында басылган әсәрләрнең «Яр Чаллы» дигән исем белән аерым китап булып чыгуын көзә тотам. Әйе, гигант төзелеш турында әсәрләр ярыйсы күп чыкты һәм чыгып килә. Бу исә гомуми характерда гына булса да, кайбер чагыштырулар ясарга нигез бирә.

КамАЗ турында язылган әсәрләрне чама белән өч төркемгә бүлеп йөртергә булыр иде. Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә яшәүче рус язучылары язган әсәрләр, Казанда, Әлмәттә яшәүче татар язучылары һәм, ниһаять, Чаллының үзендәге язучылар, яшь һәм башлап язучылар тарафыннан язылган мәкалә-очерклар. Белмим, кемгә ничектер, миңа калса, шушы өч төркем әсәрләр арасыннан бүгенге көнгә хәтле басылып чыккан иң яхшы, актуаль һәм масштаблыларын Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә яшәүче рус язучылары бирде. Бу фикерне дәлилләү өчен Екатерина Лопатинаның «Буш урында түгел», Виталий Семинның «Тормыш төзелә», Равил Биктаһировның «Кубик»лар турында баллада» дигән очеркларын мисалга китерү дә җитә. Әсәрләренең иҗтимагый яңгырашы һәм әдәби эшләнеше, укучыларга эмоциональ тәэсир итүе ягыннан алардан соңгы урында үзебезнең Казанда, Әлмәттә яшәүче татар язучылары тора.

Бер уйлаганда, Кама автомобиль заводы турындагы зур әһәмияткә ия булган иң яхшы әсәрләрне Чаллы шәһәрендә яшәгән, автозаводны төзүдә турыдан-туры катнашкан авторлар язарга тиеш иде кебек. Ләкин алай булып чыкмады. Хикмәт нәрсәдә соң? Язучы Э. Касыймов Чаллыга күчеп килү белән роман язарга алынды һәм, ишеткәнебезчә, үзенең зур күләмле яңа әсәрен төгәлләп килә. Шуңа күрә аның очерк һәм публицистика жанрына ныклап тотынырга вакыты җитми булса кирәк. Р. Вәлиев КамАЗ турында уңышлы гына документаль повесть язды, әмма аның үзебездә күп тапкырлар макталган әсәре рус телендә әллә ни зур яңгыраш тапмады. Р. Юнысов, М. Газизов, Л. Яруллина һәм башка иптәшләргә кыюлык һәм тапкырлык, кечкенә күләмле әсәрдә зур проблемалар күтәрә алу осталыгы һәм язучылык тәҗрибәсе җитеп бетми.

Шулай да булсын ди, әмма Ә. Маликов, М. Маликова, К. Тимбикова һәм башка иптәшләрне тәҗрибә җитмәүдә берәү дә гаепли алмас. Укучылар тарафыннан яратып укыла торган дистәләрчә әсәрләр язып тәҗрибә туплаган, актуаль һәм әһәмиятле әсәрләр биргән язучылар. КамАЗга багышланган әсәрләрендә дә шулай алар. Язу осталыгына, сәләтләренә, әсәрләренең теленә тел-теш тидерерлек түгел. Эш нәрсәдә соң? Ә безнең КамАЗ һәм Чаллы турында язучы күп кенә иптәшләребезгә геройлар язмышыннан аз гына югары була белү, герой язмышын ил язмышы белән, ил алдында торган әһәмиятле һәм актуаль проблемалар белән бәйләп бирү җитми... Ә бәлкем безнең язучыларыбызга да илебездәге удар төзелешләрдә күбрәк булырга кирәктер?!. Күп йөргән — күп күргән, күп күргән — күп белгән, диләр бит. Ничектер, КамАЗ турында беренче һәм әлегә иң уңышлы поэманы язган Сибгат Хәким ага, автозавод турында язу безгә, татар язучыларына, шактый җиңел булачак, туган җир, туган туфрак үзе булышачак, дип әйткән иде. Берүк шулай гына була күрсен иде.

Сүзне йомгаклап әйтәсе килгән фикер шул: «Чаллы таңнары» кебек җыентыкларны киләчәктә дә чыгарырга кирәк. Чөнки КамАЗ темасы дежур тема да, берәр төрле кампания чоры темасы да түгел. Ул — даими тема, мәңгелек тема. Төзелештә көн саен диярлек яңадан-яңа геройлар туып тора. Республикабыз тормышына зур социаль үзгәрешләр алып килгән төзелешне һәр язучы күңеле белән, йөрәге белән кабул итеп, үз язмышын төзелеш язмышы белән бәйләп, чорыбызга, гигант төзелешкә лаеклы әсәрләр тудыру өстендә эшләргә, замандашларыбызның героик портретын тудырырга бурычлы!

Яр Чаллы шәһәре хәзер үзенең икенче яшьлеген кичерә. Тагы бер елдан ул үзенең 350 еллык юбилеен бәйрәм итәчәк. Бу датаны төзүчеләр генә түгел, язучыларыбыз да лаеклы эшләр, лаеклы әсәрләр белән каршыларга тиеш. КамАЗ төзелеше — бүгенгесе көндә хезмәт фронтының алгы сызыгы. Төзелеш мәйданы матур әдәбиятның да алгы сызыгына әверелсен иде.

**Равил ЛОТФУЛЛИН.**

# ОФЫКЛАР АРТЫНДА АЧЫШЛАР

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Ак канатлар» исемле беренче китабына язган рецензиясен Р. Гәрәй түбәндәге сүзләр белән тәмамлаган иде: «Бүгенге көндә аның (Рәшит Әхмәтҗановның — Р. Г.) иҗаты күтәрелеш, үсеш чорында. Алда аңа ләззәтле һәм газаплы кичерешләрдән соң туа торган берсеннән-берсе уңышлырак шигырьләр юлдаш булсын. Шагыйрьне поэзия дип аталган чиксез зур дөньяга алып чыккан «йөрәк бәйрәмнәренең кыңгыраулар таккан» аргамаклары ярты юлда арып калмасыннар» [1].

Күптән түгел китап кибетләренә Рәшит Әхмәтҗановның «Гомер чишмәсе» исемле яңа китабы чыкты. Ике җыентык арасында 4 ел гомер. Уйласаң, иҗат кешесе өчен шактый вакыт бу. Күңелдә сораулар туа: аргамаклар юлда армаганнармы? Ак канатлар нинди биеклекләргә күтәрелгән, нинди офыкларга җиткәннәр? Ярты юлда туктап калмаганнармы?.. Дулкынланып «Гомер чишмәсе»н укый башлыйм. Шигырь арты шигырь килә...

Кемдер шигырьләрне энҗе муенсага охшаткан. Кабатлау булса да, Рәшит Әхмәтҗанов шигырьләрен мин дә шундый муенсага тиңләр идем.

Җыентыктагы һәр шигъри энҗе үзенчә ялтырый. Һәрберсе үзенә хас төс бирә. Шул энҗеләр бергә җыелып, үзенчәлекле яктылык хасил итәләр. Ә бу яктылыкны алар яшәүдән, мәхәббәттән, кыскасы, тормышның үзеннән алалар. Әйе, әйе, тормышның үзеннән. «Ак канатлар»да башланган матур адым «Гомер чишмәсе»ндә дә дәвам итә, үзенчә яңгыраш таба. Авторның кайсы гына шигырен алып карасак та, без анда тормыш турында тирәннән фикер йөртү, яшәүнең мәгънәсе турында уйлану күрәбез, тынгысыз җанлы лирик герой белән очрашабыз. Шагыйрь үзе дә, аның лирик герое да үз интим хисләрен җырлау белән чикләнмиләр. Алар ил, халык язмышына бәйле зур мәсьәләләр белән янып яшиләр.

Дошманнар атты илемә —
Уклары миңа тиде,—

ди шагыйрь «Мин һаман шундый» исемле шигырендә.

Авторның ватанны, халкын яратуы ифрат көчле. Һәм бу турыда Рәшит Әхмәтҗанов гади, самими итеп яза. Аның әсәрләрендә ясалмалылык юк:

Без кешелек яклы кешеләрбез,
Җиңүләргә барган нәселдән.
Ә туган җир, мәңге бәхет биреп,
Кайгыларны безнең яшергән.
(«Алма белән кояш арасында».)

Туган ил, туган җир турында язылган шигырьләр бик табигый рәвештә шагыйрьнең әнисенә, сөйгән ярына багышланган әсәрләренә килеп тоташа. Авторның «Әнкәң уйлана», «Карлыган җыя ана» дигән шигырьләрендәге ана образы үзенең эчкерсез, изге булуы белән аерылып тора.

Рәшит Әхмәтҗанов кеше күңеленең нечкә һәм катлаулы кичерешләрен поэтик чаралар белән күрсәтергә омтыла. Бу — аның яхшы ягы. Автор бу максатына кеше һәм табигать, кеше һәм тормыш арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлау аркылы ирешә. Менә тагын дүрт кенә юллык бер шигырь:

Бүген кинәт күк күкрәде...
Нилэр яуды, кая акты?
...Яшь имәнне яшен сукты,
Карт алмагач чәчәк атты.

Аның шигырьләренең төп геройлары барысы да җир кешеләре, безнең әтиләре-

[1] «Казан утлары» журналы, 1973 ел, 4 сан.

без, әниләребез, безнең туганнарыбыз, алар — «җир кызлары, җир уллары».

«Гомер чишмәсе»нең икенче бүлегендә шагыйрьнең мәхәббәт турындагы шигырьләре тупланган. Мәхәббәт турында язу хәзер авыр, әйтәсе сүзләр әйтелгән, диләр. Кемнәр өчендер бу шулайдыр да. Ә менә Рәшит Әхмәтҗановның бу өлкәдә дә табышлары байтак кына. Мисалга «Умырзая төсе кырларда» дигән шигырьне китерү дә җитә. Сөю, сөелү, сагыну, сагыш турында шагыйрь образлы итеп болай ди:

Офыкларда йөри...
Кемдер йөри аны урларга.
Аны мөмкин җырда җырларга тик...
Умырзая төсе кырларда.

«Гомер чишмәсе»ндә табигатькә, кошлар, җәнлекләргә багышланган тирән мәгънәле шигырьләр бар. «Язлар быел соңга калды...» дигән шигырендә, мәсәлән, шагыйрь торналарга карап кешеләр турында уйлана. Тормышта булган тирән драматизмны ул шушы ике юл эченә сыйдыра:

Йолдызлардан азрактыр
без кешеләр.
Без азрак — чөнки бит без
ныграк яндык...

Мондый мәгънәле шигырьләр Рәшит Әхмәтҗановның кыска шигырьләрендә еш очрый. «Таш өстендә гөлләр», «Җыр кирәк җанга», «Ут эченнән...», «Сине уйлыймын да» кебек шигырьләре әнә шундыйлардан.

Таш өстендә гөлләр...
Гөл өстенә
Соңгы йотым суны коясың.

Һәм актарып ташны,
таш астыннан
Тапканым бар елан оясын.

(«Таш өстендә гөлләр».)

Шагыйрь әнә шулай, кыска язып, тирән мәгънә бирә, көтелмәгән нәтиҗә ясый.

Җыентыкта халык инде үз итеп, яратып өлгергән «Сау булыгыз, кыр казлары», «Акчарлаклар» дигән җырлар белән бергә, «Умырзая төсе кырларда», «Миләшләргә киләм...» кебек җыр булып китәрдәй матур шигырьләр күп.

«Гомер чишмәсе»н бер талпыну белән укып чыктым да уйга калдым. Шагыйрьнең «Гомер чишмәсе» тирән, саф икән. Ул гел-гел шулай булсын, шагыйрь аны гел күңеленнән чыгармасын, иҗатын тагын да активлаштырсын, укучыларны күләмлерәк, тагын да тирәнрәк эчтәлекле әсәрләр белән куандырсын иде. «Язлар быел соңга калды...» дигән шигырен укыгач, аның моңа да көче җитәрлегенә ышаныч туа.

Аргамаклар юлда армаганнар, ак канатлар югарырак күтәрелгәннәр икән.

Җыентыктагы «Белмисеңдер...», «Сөймәсәң», «Әллә ни әйтсеннәр» кебек матур гына фикерләре булып та, сәнгатьчә эшләнеп җитмәгән шигырьләр шигъри офыкларны тарайта алмауларына чиксез сөенеп куйдым.

Юлчы һаман да юлда. Алда әле барып җителмәгән ак шәфәкъ бар. Табылмаган, ачылмаган табышлар алда әле!

**Рафис ГЫЙЗЗӘТУЛЛИН,**
**пединститут студенты.**

# ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ИСӘП-ТЕРКӘҮ БИБЛИОГРАФИЯСЕНӘ 50 ЕЛ

Дәүләт исәп-теркәү библиографиясе республикада чыккан китап һәм брошюраларның, газета һәм журналларның, гомумән, барлык төр матбугат басмаларының дәүләт исәбен алып бару, теркәү һәм аның турында библиографик информация җиткерү бурычын куя. Кыска гына итеп әйткәндә, ул — матбугатыбызның елъязмасы. Матбугат тарихын, китап басу эшен өйрәнү үзе мөстәкыйль фәнни тармак тәшкил итә.

Басма әсәрләрне исәпләп-теркәп бару өчен Россиядә инде 1837 елда ук дәүләт библиографиясе барлыкка килә. Бу эшне алып бару махсус учреждение — Петербург китап палатасына йөкләнә.

Россиядә яшәүче күп төрле милләтләр матбугатына дәүләт исәп-теркәү алып бару мәсьәләсе Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына куела. 1920 елның 30 июнендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы кабул иткән һәм В. И. Ленин кул куйган «РСФСРда библиография эшен Наркомпрос карамагына тапшыру»[1] турындагы карар нигезендә Мәскәүдә һәм урыннарда шушы эшне алып бару өчен китап палаталары төзелә.

Мәскәүдәге Үзәк китап палатасы Дәүләт нәшрияты составында төзелү үрнәге буенча Казанда да китап палатасы Татарстан дәүләт нәшриятының библиография бүлеге төсен ала. Бүлекне соңыннан библиография буенча илебездә иң зур белгечләрнең берсе булып танылган профессор Е. И. Шамурин, аннары Казан библиофилы П. Е. Корнилов җитәкли.

Китап палатасына басма әсәрләрне җыю һәм теркәп бару, даими рәвештә аларның исемлеген бастырып чыгару, матбугат күргәзмәсе һәм Татарстанда чыга торган яңа китапларны уку залы, библиографик бюро оештыру, Татарстанга багышланган әдәбиятның картотекасын төзү бурычлары куела.

Китап палатасы бу бурычларның кайберләрен генә үтәргә өлгерә. Мәсәлән, шул ук елны анда яңа китапларны уку залы оештырыла һәм ул шәһәребездә зур популярлык казана. Татарстан дәүләт нәшриятында чыккан китаплар исәпкә алына, китап палатасы аркылы берничә хезмәт басылып чыга[2]. 1921 елның ноябрь ахырында Татарстан дәүләт нәшриятының библиография бүлеге ябыла.

1 декабрьда Татарстанда 1917 елдан бирле чыккан басма әсәрләр фонды Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты карамагына күчә, басылып чыккан әсәрләрне теркәп бару эше туктап кала. Дөрес, ул елларда татар һәм көнчыгыш халыклары телләрендә чыккан китаплар Мулланур Вахитов исемендәге Үзәк Көнчыгыш китапханәсе музеенда тупланып киләләр[3].

---

[1] Ленин и библиотечное дело. Мәскәү, «Книга», 1969 ел, 282 бит.
[2] Мәсәлән, «Бюллетень Казанского отделения Госиздата». 1921 ел, № 1; П. М. Дульский. Книга и художественная внешность. Кара: Советское строительство в Татреспублике за год (1920—1921). Казан, 1921 ел, 260 бит.
[3] Академцентрның 1929 елның 12 декабрь карары белән бу китапханә Татарстанның фәнни китапханәсе составына керә, соңгысы 1932 елда Казан университетының фәнни китапханәсе белән кушыла.

Милли әдәбиятны библиографик теркәү, аның турында информация оештыру эшләре бу елларда Татарстанда гына түгел, башка республикаларда һәм үзәктә дә әле тәртипкә салынып җитмәгән була. Мәскәүдә чыга торган «Китап елъязмасы»нда 1919 елда татар телендә чыккан 5 китап искә алынган, шуларның өчесе 1919 елга хәтле басылган. Татарстан китап палатасы мәгълүматлары буенча бу китапларның саны 185 кә җитә. 1928 елда Дәүләт Үзәк китап палатасы «Китап елъязмасы»ның махсус чыгарылышын бастыра башлый. «Махсус чыгарылыш» илебездә 81 телдә чыга торган милли әдәбиятны исәпкә ала, аны басманың үз телендә тасвирлый. Ул 6 ел буе (1928—1933) квартал саен чыгып килә.

Милли әдәбиятны библиографик эшкәртү һәм аны дәүләт теркәп бару эшләрен башкару өчен егерменче елларның беренче яртысында күп союздаш республикаларда китап палаталары барлыкка килә. РСФСРның автономияле республикалары арасында иң беренче булып бу учреждение Татарстанда (1926 ел), аннан соң Башкортстан (1929 ел) һәм Чувашстан (1931 ел) республикаларында төзелә.

Моннан нәкъ 50 ел элек, 1926 елның 21 декабрендә Татарстан Халык Комиссарлары Советы «ТАССРның китап палатасы турында положение»не раслый. Шушы дата республикабызның дәүләт исәп-теркәү библиографиясенең башлангычы итеп санала.

Китап палатасы 1927 елның башыннан Татар мәдәнияте йортында үз эшчәнлеген башлап җибәрә, аның директоры итеп Г. Б. Ашмасов билгеләнә. Палатага Татарстанда чыга торган бөтен басма әсәрләрнең түләүсез махсус экземплярлары килүдән тыш, көнчыгыш халыклары (мәсәлән, әзербәйҗан, башкорт, адыгей, аджар, дагстан, уйгур, үзбәк, кыргыз, калмык) телләрендә басылган әдәбият та алына. Казан җәмәгатьчелеге бу китаплар белән палата оештырган күргәзмәләрдә таныша[1].

Тиздән Татарстан китап палатасы республикада чыга торган китаплар турында библиографик информация эшенә дә керешә. 1929 елда С. Ш. Таһирова тарафыннан төзелгән «Гыйльми библиография. 1925 елда чыккан татарча әсәрләр өчен» (Казан, Татар мәдәнияте йорты, 1929 ел, 102 бит.) дигән җыентык басылып чыга. 1930 елда исә квартал саен даими «Матбугат елъязмасы» чыга башлый. Бу библиографик күрсәткечтә Татарстанда чыга торган барлык китап һәм газета-журналлар теркәлә. Ләкин елъязманың өч кенә саны чыгып кала, төрле ведомстволарга буйсынган китапханә һәм библиографик учреждениеләрне берләштерү процессы башлану сәбәпле, китап палатасы мөстәкыйльлеген югалта. Ул башта Академцентр каршында төзелгән Татарстан фәнни китапханәсе составына керә, соңыннан Казан университеты фәнни китапханәсе бүлегенә әверелә. 1929 елга хәтле гарәп шрифтында басылган китаплар, газета-журналлар палата архивыннан китапханәнең гомуми фондына күчә (хәзерге вакытта шунда саклана), библиографик хезмәтләр төзү эше туктала.

Бу елларда чыккан китап һәм башка төрле матбугат басмалары турындагы мәгълүматны Крайны өйрәнүчеләр җәмгыяте һәм башка кайбер учреждениеләр чыгарган библиографик күрсәткечләрдә табарга була. Мәсәлән, Татарстан дәүләт нәшрияты 1922 елдан 1936 елга хәтле нәшриятта чыккан китапларның каталогын чыгарып килә. 1926 елда И. Рәмиевнең «Вакытлы татар матбугаты» (1905—1925. Казан, 1926 ел, 332 бит) дигән хезмәте дөньяга чыга. Татарстанны өйрәнү җәмгыяте бастырып чыгарган берничә библиографик кулланманы да (Татарстан библиографиясе, 1 чыгарылыш, 1917—1927, Казан, 1930 ел, рус телендә; Татарстан турында 1928 һәм 1929 елларда чыккан әдәбият. «Татарстанны өйрәнү җәмгыяте хезмәтләре», 1930 ел, 1 том, 182—203 битләр, рус телендә; Татарстан библиографиясе. 1918—1929. Казан, Татиздат, 1930 ел. Төзүчеләр: Тагирова С., Тагиров Р., татар телендә) шундыйлар исәбенә кертергә була.

Ләкин бу хезмәтләрне төзүчеләр, беренче нәүбәттә, Татарстанда чыккан китапларны түгел, ә Татарстанга багышланган әдәбиятны туплауны бурыч итеп куялар.

Татарстан матбугаты турында библиографик информация бастырып чыгару эше 1938 елда, китап палатасы Казан университеты фәнни китапханәсе составыннан чыгып, мөстәкыйль учреждениегә әйләнгәч, яңадан тәртипкә салына. Шул ук 1938 елда

[1] Шундый күргәзмәләрнең берсе турында түбәндәге брошюра басылган: Ашмасов Г. Выставка произведений печати книжной палаты за 1928 год. Казан, 1929 ел.

китап палатасы «Китап елъязмасы» һәм «Вакытлы матбугат елъязмасы»н чыгара башлый. Бу эш Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр дәвам итә.

Сугыш елларында палата эшчәнлеге тарая, матбугат архивын саклау шартлары авырлаша, кайбер район газеталарының махсус экземплярлары килми башлый. Шулай да палата хезмәткәрләре Б. Булатов, М. Бурнашева, А. Бикбаеваларның зур тырышлыклары аркасында, матбугатта чыккан әсәрләрне җыйнау, аны архивта туплау һәм дәүләт теркәп бару эше бу елларда да дәвам итә. Республика матбугаты турында библиографик информация чыгару сугыштан соң яңадан үз җаена керә.

Татарстанда чыккан китап һәм вакытлы матбугат елъязмаларыннан башка, 1953 елдан башлап «Рецензияләр елъязмасы», 1955 елдан «Газета, журналларда басылган мәкаләләр елъязмасы» һәм 1969 елдан «Сынлы сәнгать әсәрләре елъязмасы» басыла башлый.

Укучыларга елъязманы куллануны уңайлаштыру йөзеннән, 1961 елдан бирле барлык төр басма әсәрләр бергә, һәр квартал саен чыгып килә торган «Матбугат елъязмасы»нда чагыла. Бу елъязмада республикабызда барлык телләрдә чыккан китаплар, брошюралар, авторефератлар, ноталар, газета-журналларда басылган мәкаләләр, рецензияләр, сынлы сәнгать басма әсәрләре, библиографик күрсәткечләр теркәлә. 1960 елдан бу елъязмага «Татарстан Советлар Союзы матбугатында» дигән бүлек өстәлде. Бу бүлеккә теркәү өчен материалны китап палатасы В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсе белән берлектә җыйный. Татарстан турында басылган әдәбиятның тасвирламасы башка республикаларның китапханәләренә дә җибәрелә.

1967 елдан башлап «Матбугат елъязмасы» битләрендә Татарстанда чыккан китаплар турында еллык статистика мәгълүматлары бирелә.

Хәзерге вакытта китап палатасы хезмәткәрләре үз эшчәнлекләрен тагын бер әһәмиятле юнәлештә җәелдерәләр. Алар республика матбугатының җыелма библиографик күрсәткечен төзүгә керештеләр. Беренче чиратта, вакытлы елъязмалар чыкмаган еллар өчен җыелма библиография булдыру максаты куела. Димәк, ул, беренче нәүбәттә, 1917—1945 елларда чыккан басма әсәрләрне чагылдырырга тиеш. Шулардан 1941—1945 еллар өчен «Китап елъязмасы» (Казан, 1973 ел) библиографик кулланмалар арасында үз урынын алды инде. 1917 — 1940 еллар өчен мондый җыентык күп томлы булып, аның 1 томында 1917 — 1929 елларда татар телендә чыккан китаплар туплана, икенче томда 1930 — 1940 елларда чыккан китаплар теркәлә. Киләчәктә республикада рус телендә чыккан китапларның һәм башка төр басма әсәрләрнең җыелма библиографик күрсәткечен төзү күздә тотыла.

Әйтергә кирәк, союздаш һәм автономияле республикаларның күпчелегендә мондый хезмәтләр төзелде инде, ә кайбер (мәсәлән, Балтик буе, Кавказ арты республикаларында, Чуваш АССРда) җыелма библиографик күрсәткечләрдә басма матбугат барлыкка килгәннән бирле чыккан әсәрләр тасвирлана. Республикаларның җәмәгатьчелеге бу библиографик күрсәткечләргә югары бәя бирә, аларны мәдәният төзелеше казанышларына йомгак ясау итеп карый. Литва телендә 1547 — 1861 елларда чыккан китаплар җыелма библиографик күрсәткеченең әдәбият өлкәсендә бирелә торган Республика премиясенә лаек булуы шуның бер дәлиле.

Илле ел дәверендә Татарстан дәүләт исәпләү-теркәү библиографиясе зур уңышларга иреште. Автономияле республикалар арасында беренче булып Татарстан китап палатасы төзелде. Республикада чыга торган басма әсәрләрнең палатага килә торган түләүсез махсус данәсе нигезендә Татарстанның матбугат архивы тупланды. Бу архивта хәзерге вакытта 661828 саклану берәмлеге булып, шуларның 34590ы китаплар, 10254 е журнал, 997 се сынлы сәнгать әсәрләре, 101 е нота, 464 814 е газеталар фонды тәшкил итә. Районнарда, завод-фабрикаларда һәм башка предприятиеләрдә чыккан газеталарның иң тулы фонды да шушы архивта саклана. Киләчәктә Казан архивларында, китапханә фондларында сакланмаган басма әсәрләрнең микрофильмын төшерү күздә тотыла.

Квартал саен даими чыгып килә торган «Татарстан матбугат елъязмасы» автономияле республикалар арасында иң тулылардан һәм методик яктан уңышлылардан санала.

Т. ДУНАЕВА, педагогия фәннәре кандидаты.

# Б. СИРИН

*Тууына 80 е*

Татар совет поэзиясендә бер-берсен кабатламыйча, һәркайсы үзенчә балкыган, төрлесе төрле көч, моң, аһәң белән яңгыраган исемнәр күп. Исемнәр һәм әсәрләр, хәтта аерым шигырьләр дә үзләренең матур тарихын, истәлекләрен, чорына лаек рухын саклап кала алган. Менә шундый бер шигырьне искә төшерик:

**Ашлыгыңны җилгәрәмсең, җилгәр, җилгәр!**
**Тормышыңның**
**Чүп-чарларын җилгә җибәр!**
**Бертуган күк**
**Бергә эшлик,**
**Бергә яшик,**
**Машиналы**
**Күмәк тормыш**
**Төзеп җибәр...**
**Аерым-аерым**
**Матур тормыш**
**Булмый, булмый!**
**Булмый, булмый!**

Бу — кем шигыре? Өлкән буын кешеләренең күбесе аны яттан ук хәтерлиләрдер — чөнки бу шигырь заманында бик атаклы булып, авторы һәм артистлар тарафыннан еш укылган (мәшһүр артист М. Мутинның да репертуарында булган ул. Замандашлары аның бу шигырьне гаҗәеп бер кабилият, тирән пафос һәм рух белән башкаруын сөйлиләр), популяр булган. Шигырь — 20—30 еллар поэзиясендә билгеле бер урын тоткан, үзенчәлекле форма, ритм һәм сурәтләү чаралары белән аерылып торган шагыйрь Б. Сирин әсәре.

Б. Сирин (Сирин Хәниф улы Батыршин) Татарстанның Баулы районы Кәрәкәшле авылында 1896 елның декабрендә дөньяга килә. Революциягә кадәр ул Бәйрәкә мәдрәсәсендә белем ала, соңыннан башлангыч мәктәптә укытучы булып эшли. 1921 елда Бөгелмәдәге өчьеллык педагогия курсларын тәмамлый. Беренче шигырьләрен шул елларда, Бөгелмәдә чыккан «Юксыл» газетасында бастыра. 1926 елда үзе дә Бөгелмәдәге «Сабанчы» газетасы редакциясендә эшли.

1931—32 нче елларда Б. Сирин Казан педагогия институтын тәмамлап, шәһәр мәктәпләрендә тел-әдәбият укыта. Казанга килгәч, иҗат активлыгын да үстерә. Ул — шулай ук бик популяр булган «Тегүче кыз» (1926) һәм крестьяннарны күмәк тормышка чакырган, югарыда өзекләре алынган атаклы «Булмый! Булмый!» (1929) шигырьләрен яза. Һади Такташ, Хәсән Туфан, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Әхмәт Фәйзи, Фатих Кәрим кебек шагыйрьләр төркеменә үзенчәлекле, оригиналь шагыйрь Б. Сирин исеме килеп кушыла. Шагыйрь үз шигырьләрендә тормышның җанлы күренешләрен, хәтта хәрәкәтен, ритмын, тавышын, яңгырашын тудырырга омтылган новатор иде. 1931 елда басылып чыккан «Тамчылар» китабы шул хакта сөйли. Аннары башка китаплар... Югары пафослы, оптимистик рухлы шигырьләр, балалар өчен парчалар...

**Якын итеп кенә бер сүз әйтим:**
**Сукалы карт, тормышыңны суксын яшен!**
**Иске тормыш**
**Үлә,**
**Үлә,**
**Үлеп бетә.**

. . . . . . . . . . .

**Машиналар,**
**Шаулый-шаулый,**
**Җырлый-җырлый,**

Бергә-бергә
Эшләргә дип
Безне көтә.

Өзек шул ук «Булмый! Булмый!» шигыреннән. Ә менә бусы — бала чактан ук җыр булып күңелгә кергән «Язгы тамчылар» («Тамчылар маршы») шигыреннән:

Там,
Тамчы,
Там,
Тамуыңны яратам.
Тамчы-тамчы җырларымны
Ак кәгазьгә таратам...
Мин дә тамчыланып тамыйм,
Көрәшләрдә аксын кан.



Әнә шулай яңа тормыш өчен көрәшләрне яньп, ихлас җырлаган шагыйрь Бөек Ватан сугышында катнаша, контузияләр ала... Сугыштан соң ул гади колхозчы, умартачы булып эшли, туган авылында яши.

1959 елда, әле үзе исән чакта, шагыйрьнең автобиографик белешмәсе белән сайланма шигырьләр китабы басылып чыкты.

# ЗЫЯ ЯРМӘКИ

*(1897—1965)*

Яфраклары яшел ак каенның
Хәтфә җәйгән кебек һәр ягы.
Әйлән-бәйлән уйный яшь балалар,
Гөрләп тора һәр көн тау ягы.

Шундый юллар белән башлана торган «Ак каен» җырын күпләр белә торгандыр. Аны нәниләр дә яратып җырлыйлар, радиолардан да еш яңгырый ул — туган якка, аның табигатенә тирән мәхәббәт хисе булып күңелгә кергән аның сүзләре. Халык җыры булып...

Шушы җыр сүзләренең, башка күп шигырьләрнең авторы, унынчы еллар поэзиясендә үзенчәлекле урын тоткан шагыйрь Зыя Ярмәкинең тууына 80 ел тулды.

Зыя Ярмәки (Зыя Шәйхи улы Насыйров) 1897 елның 21 январенда элекке Самара губернасы, Богырыслан өязе (хәзерге Куйбышев өлкәсе, Камышлы районы) Иске Ярмәк авылында туа. Туган авылында, аннары Чистай мәдрәсәсендә укый. 1909 елда исә Уфага килеп, «Галия» мәдрәсәсенә керә. 1912 елда туган авылына кайтып, балалар укыта башлый...

Зыя Ярмәкинең шигырьләр яза һәм басыла башлавы «Галия»дә укыган елларына туры килә. «Шура», «Аң» һәм «Ак юл» журналларында аның исемен еш очратасың. 1912 елда шагыйрьнең «Яшьлек дәфтәрләре» һәм «Күрсәтәм», 1913 елда «Әдәбият гөлләре», «Тойгыларым» исемле дүрт китабы басылып чыга.

Бу китапларга кергән шигырьләр Беренче рус революциясеннән соңгы кара реакция елларында халыкның борчулы-әрнүле хисләре, аһ-зары булып яңгырый.

Гаделсезлекләрне, социаль изүне күрү, демократик идеяләр белән яну шигырьдә аны Тукайга, аның мәктәбенә якынайта. Бу турыда шагыйрь үзе дә:

Кер вә таплардан агардым мин хәзер бер кош кеби,
Ялтырарга уйлыймын күктә матур йолдыз кеби;
Күп авырлыкларга, әнкәй, түзде бәбкәң җилкәсе,
Шул ачы яшьләр, әни, итте Тукайның иркәсе,

— дип язды («Әнкәемә», 1912).

Тукайга ул тел-сурәт чаралары белән дә шактый охшаш. Шулай ук Зыя Ярмәки лирикасында Тукай мәктәбе шагыйрьләренең иң күренеклесе — Шәехзадә Бабич белән уртаклык булуын күрәсең. Балалар өчен язылган, табигать күренешләрен оста сурәтләгән шигырьләрендә шагыйрь телгә сак, сизгер, садә — шуңа да аның «Җәй башы», «Иртә», «Кич», «Кошларга» һәм әлеге — инде халыклашып киткән «Ак каен» кебек шигырьләре күп еллар буе мәктәп дәреслекләренә дә кертелеп килгән. Халык җырлары үлчәве һәм стилен саклаган бу парчалар шагыйрьнең туган төбәген — шактый күп әдипләр чыккан (Халикъ Садрый, Әнвәр Давыдов һәм Рөстәм Мингалимовлар шул Камышлыдан) якның матурлыгын күз алдына бастыра.

Октябрь революциясеннән соң Зыя Ярмәки Богырысланда ачылган укытучылар курсларында укыта. Шулай ук укытучы, китапханә мөдире булып Иске Ярмәктә эшли. 1931 елдан башлап ул Үзбәкстанда яши, анда Ферганә өлкәсе, Ташлак районы советына сайланып, күп еллар секретарь булып эшли.

Шагыйрь Үзбәкстанда яшәгән елларында да шигырьләр язуын дәвам иттергән — аларның кайберләре шагыйрьнең элекке шигырьләре белән бергә, Казанда 1966 елда басылып чыккан «Ак каен» исемле китабына кертелгән.

Татар шигыренда якты бер эз калдырган шагыйрь 1965 елда вафат булды.

# ХЕЗМӘТ — ИҢ ЗУР ЛӘЗЗӘТ

Илле яшь, нәрсә генә әйтсәң дә, илле яшь инде ул. Бу яшьтә кеше узылган юлына борылып карарга, моңарчы эшләгән эшләренә йомгак ясап, кылган кайбер игелекле хезмәтләре өчен мактау сүзләре көтәргә дә хаклы.

Каләмдәшебез Рәис Сабировка да ишекләрне инде ашыкмыйчарак, салмаграк ишәргә мөмкиндер кебек. Чыннан да тормыш һәм иҗат юлы шактый бай аның. Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, ул республика яшьләр газетасы редакциясе хезмәткәре, партия өлкә газетасында әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Мәскәүдә партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, партия өлкә комитетының матбугат секторына эшкә кайта. Аннары ул «Правда» газетасының Татарстан буенча үз хәбәрчесе итеп билгеләнә.

Менә егерме елга якын инде Рәис Сабировны без шушы җаваплы, авыр, мактаулы хезмәттә күрәбез. Ә бит беркемгә дә сер түгел, правдачылар коллективының ихтирамына лаек булу, ышанычын аклау өчен анкетадагы матур юллар һәм кушканны җиренә җиткереп үтәү генә җитми. Монда йөкне журналистикабызның буй җитмәстәй гигантлары белән мичәүгә бер тигез җигелеп тарту сорала.

Нишләмәк кирәк, безнең көннәрдә әле кешенең кем икәнлеген, нинди эшләрдә эшләгәнлеген белү өчен аның анкетасындагы мәгълүматларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Ләкин ул кем генә булып, кайда гына эшләмәсен, безне һәрчак, барыннан да элек, аның ничек эшләве кызыксындыра.

Кайвакытта кемнең дә булса туган көне уңае белән мактау сүзләре язу бик авыр. Бәхеткә каршы, бу очракта мин андый кыенлык кичермим. Юбилярның күңеленә хуш килерлек сүзләр эзләп баш ватып утыруның минем өчен һич кирәге юк. Минем алда торган кыенлык бөтенләй башка төрле: «Правда»ның үз хәбәрчесе Рәис Сабиров кулы белән язылган һәр юлдагы, һәр мәкаләдәге осталыкка ничек ия булырга?



«Һәр юлдагы...» дигән сүзләрне язып мин ялгышлык җибәрмәдем. Кайчагында газетаның бер юлы теге яки бу озын мәкаләгә караганда авыррак языла һәм ул тәэсирлерәк, йогынтылырак була. Әле күптән түгел фәннең чираттагы югары баскычына күтәрелергә әзерләнүче бер кандидат миңа матбугатта элегрәк һәм хәзер басылып чыккан бер кочак публицистик материаллар күтәреп килде.

— Докторлык диссертациясе язып азаплана идем,— диде ул минем алдыма калын гына папка китереп куйгач.— Бу папканың беренче юлыннан соңгы юлына кадәр Рәис Сабиров күтәргән темалар. Нефть... КамАЗ... Авыл... Партия эше... Культура мәсьәләләре...

Ул башкарган эшләрнең бөтенесен дә санап торырга кирәкме икән? Рәис Сабиров татар теленә чорыбызның күренекле очучысы Валерий Чкалов, атаклы химик Гыйлем Камай, партиянең ялкынлы улы Сергей Миронович Киров турындагы документаль повестьларны, Михаил Стельмахның «Кеше каны җирдә ятмый», Сабит Мукановның «Тормыш мәктәбе» романнарын тәрҗемә итте. 1975 елда аның Татарстан шәһәрләре һәм авыллары турындагы документаль китабы басылып чыкты. Рәис Сабиров — журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты. Бу премия аңа нефтьчеләр турындагы очерклар җыентыгы өчен бирелде.

Яшерен-батырын түгел, кулыңа алып: «Минем хезмәтем бит бу!» дип әйтерлек эш эшли алсаң, күңелеңдә нииндидер бер рәхәтлек тоясың. Тик шулай да, минемчә, сиңа дан һәм мал-мөлкәт түгел, ә бәлки иҗади азаплардан соң ләззәт китергән хезмәтнең мәгънәсе зуррак була. Мин бу юлларны язганда янадан Рәис Сабировны күз алдында тотам. Татар телендә язылган әсәрләрне русчага сүзгә-сүз тәрҗемә итүдә, белмим, аңа тагын кем тиңләшә алыр икән?! Үзенә ят булган телнең барлык нечкәлекләрен һәм нюансларын белмәгән тәрҗемәче төрле вариантларга мөрәҗәгать итә алсын өчен, ул кулыннан килгәннең бөтенесен эшләргә тырыша. Һәм менә кайвакытта хәтта игътибардан читтә кала торган шушы хезмәттән ул үзенә әйтеп бетергесез ләззәт һәм рухи канәгатьләнү ала. Кайберәүләр, нинди дә булса әсәрне икенче бер телгә, әйтик, рус теленә сүзгә-сүз тәрҗемә итү өчен әллә ни зур осталык кирәкми, юлын юлга аудар да чык, шуның белән вәссәләм, дип уйлыйлар. Әмма зирәк акыллы Фатих Хөсни, Әмирхан Еники кебек аксакаллар да, әдәби Пегасны кыю иярләүче Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев һәм башка әдипләр дә үзләренә ярдәм итешергә, ни өчендер, нәкъ менә Рәис Сабировны чакыралар, аның автордаш булуын телиләр. Синең белән эшләргә, бергә разведкага барырга теләүчеләр булудан да олырак бәхет бармы икән?!

Беләм, еллар дәвамында ирешелгән биеклекнең билгеле бер ноктасында эшләнгәннәр белән тынычланып калырга, юлның алда узылачак өлешенә түгел, ә узылган өлешенә карарга киңәш биреп, күңелгә вәсвәсә салучылар да булгалый. Дуслары белән очрашканда андыйлар менә болайрак сөйләнәләр:

— Бүген искиткеч шәп эшләнде. Иртән бер җөмләмә өтер куйган идем, кичен, аны төзәткәндә, шул өтерне сызып аттым.

Рәис Сабиров үз иҗатының һәм гомеренең иң җитлеккән чорында сәгатьләрнең һәм минутларның кадерен белә. Эштә авыр һәм шатлыклы мизгелләр кичергән көннәрен ул иң бәхетле көннәрдән саный. Андый чакта ул түзми, телефон аша үзенең шатлыгын уртаклаша.

— Беләсеңме, иртәнге сәгать алтыда торып утырган идем. Язу машинкасыннан төштән соң гына көч-хәл белән аерылдым. Аркалар оеды. Урамнан әйләнеп керәбезме әллә?..

Телдә аңа әйтергә теләгән теләкләр күп. Ул теләкләр арасында беренчесе шул: Рәис Сабировның машинка һәм язылачак ак кәгазь өеме янында уздырган шундый бәхетле көннәре киләчәктә тагын да күбрәк булсын.

**М. ЗАРИПОВ.**

## Зәкия Туфайлова



*Балалар шагыйрәсе, нәни укучыларыбыз яратып укый торган «Фамилиясез Локман», «Нәни капитаннар» кебек кызыклы шигъри китаплар, шулай ук «Бохара-Урал» шикелле киң билгеле җырлар авторы Зәкия апа Туфайловага 70 яшь тулды.*

*Башкортстанның Кушнаренко районы Илморза авылында туып үскән, хезмәт юлын укытучы, тәрбияче булып башлаган, күп еллар Казанда китапханәче булып эшләгән шагыйрә әле һаман да иҗади хыяллар белән янып яши. Шагыйрәне зур юбилее белән котлап, бу санда аның яңа шигырьләрен урнаштырабыз.*

### Ватаным

Күргәнем бар сызылып ал таң атканын,
Зәңгәр күлне ак томаннар япканын,
Шомыртларның ап-ак чәчәк атканын.
Моннан гүзәл нинди ил, дим, бар тагын.
Иң гүзәле минем бөек Ватаным.

Күрсәм әгәр мин Кояшның батканын,
Җир өстенә караңгылык ятканын,
Чишмәләрнең төнлә моңсу акканын.
Тизрәк әйлән, Җир, дим, Кояш тирәли,
Гел кояшлы булсын газиз Ватаным.

●

Иртәсен дә, кичен дә
Песи галош эчендә.
Җайлы урын тапкан ул,
Бөгәрләнеп яткан ул.

Аягы да юк кебек,
Койрыгы да юк кебек,
Китэр сыман тэгэрэп
Йоп-йомры туп кебек.
Әкрен басып, вак атлап,
Йөрим галош тирэли.
Бик кирэк тэ кирэген...
Ничек тартып аласың,
Жэл ич песи баласы.
Тынсыз-тавышсыз гына,
Киттем галошсыз гына.

## Мин утырам тәрәзәдән карап кына

Чәчләремне шома итеп тарап кына,
Мин утырам тәрәзәдән карап кына.
Ашап-эчтек, дәү әнием табын җыя.
Ул бит безнең чисталыкны бик тә сөя,
Чынаякны әллә тагын биш кат юа.
Гөлсем апа ашыга-ашыга тузан сөртә,
Юккамыни «уңган Гөлсем» исемен йөртә?
Әнә, минем урынымны ничек җыйды —
«Ә» дигәнче курчак кебек итеп куйды.
Чәчләремне шома итеп тарап кына,
Мин утырам тәрәзәдән карап кына.
Киң урамнан бертуктаусыз кеше үтә.
Әтием кебек ашыга алар — эшкә китә.
Әнә бер эт китеп бара теге яктан,
Авызына җайлап кына сумка капкан.
Кем өйрәткән диген әле ул маэмайны —
Хуҗасына булышырга җаен тапкан.
Чәчләремне шома итеп тарап кына,
Мин утырам тәрәзәдән карап кына.

## Ачык авызлар

Рәхмәт сиңа, яшел алан,
Рәхмәт сиңа, иманлек.
Шау чәчәкле аланыңда
Җиләк ашап кинәндек.
Әй, аланың ямьле икән,
Җиләк бигрәк тәмле икән.
Шунысы гаҗәп, хикмәт менә,
Җир җиләге иплэп кенә
Үзе авызга кереп тора,
Шикәр кебек эреп тора,
Эреп тора, эреп тора,
Чиләкләр буш — күреп тора...
Ник авызга кереп тора?

Эх, сез ачык авызлар дип,
Кояш бездән көлеп тора.

Зәки Нури

# ЧЫРШЫ БӘЙРӘМЕ УКЛАРЫ

### ЯҢА ЕЛ КАРШЫЛАГАЧ

Маскам— «ишәк». Кайтып җитсәм,
Хатын һичшиксез кертә:
Чөнки бит ул өйдә мине
Гел «ишәк» диеп йөртә.

### КЕМ КЕМНЕ ТАШЛАГАН

— Хатыныңны ник аердың, кордаш?
— Кафеларда була башлады —
Мине эзләп шунда йөри-йөри,
Өй эшләрен тәмам ташлады.

### БАГУЧЫГА БҮЛӘК

— Әйт, әби, ирем кем булыр икән?
— «Чайка»да йөри. Дача салдыра!
«Алайса, мине тапсын!» дип кызый,
Ун сумга өстәп, адрес калдыра.

### ТОТСА... ХАТЫННАР ЯКАҢ

— Хезмәт хакың, ярый, өйгә кайта.
Ә ришвәтне һәм дә бүләкне
Бар диеп тә нигә әйткәнең юк?
Ник ул акча безгә эләкми?

### ЗУРДАН КУБЫП МАКТАНУ

Алма әйтә үзен-үзе зурлап,
Аңламыйча фикере тарлыгын:
Кешеләргә мин бит әйтеп бирдем
Тарту көче җирнең барлыгын.

## БЕРСЕ ДӘ ҮЗГӘРМӘГӘН

Аерылдылар. Хатны бары хатын яза:
«Ник дәшмисең, тискәре һәм кире шайтан?
Алиментың болай ярты-йорты килсә,
Көт тә тор дим, яннарыңа кире кайтам!..»

## УРЫНСЫЗ ЗАР

Уйлый әдип: «Тәмам оныттылар.
Димәк, үстем, димәк, көнлиләр...»
Бер нәрсәне ләкин онытa ул:
Ә бит аны... әле белмиләр.

## МОДАНЫҢ ОШАМАВЫ

Йомыркадан әле генә чыккан Чебеш
Әйтә икән әтисенә, әнисенә:
— Аңлатыгыз, шундый ямьсез каурый кием
Кемнәр текте, әти, синңа, әни, синңа?!

## БИРМӘДЕ

— Мәчегезне, күршем, биреп торсагызчы —
Тычкан басты, чыдар әмәл калмады!
— Ә син җый да тычканнарны безгә китер!—
Диде күрше... Теге китте. Аңлады.

## ҮЗ КҮЗЛЕГЕННӘН КАРАП

Тычкан белән шашып уйный мәче —
Бер чинатып һәм бер тимичә:
«Уен гына,— ди ул, — безнең гомер...»
Нәрсә әйтсен шулай димичә?!

## ЭШЛӘР КӘКРЕДӘН КИТКӘЧ

Ул тормышта атлый алмый кәкре юлын
Мең тарафка әгәр көн дә бормаса.
Тиз кыйшаер кебек хәтта кабер ташы,
Ялагайлар әгәр терәп тормаса.

## Ә АЛАР ЯШЬТӘШЛӘР БИТ

Сакаллы һәм ялпы берәү атлый,
Алма кебек кызны култыклап.
Ялгышалар уйлап: «Димәк, бу карт
Өйләнергә малны мул тоткан...»

## ШТАТ ТУПЛАУ

— Ачалар ди бездә фәнни үзәк,
Штат туплау тиздән башланачак.
— Бер кешегә эш юк икән әгәр,
Ике кеше аны башкарачак.

## БИЛЧӘН ҮЛЧӘМЕ

«Мин кырда ашламасыз да
Шәп үсәм» дисең, Билчән,—
Телеңә тилчә тигере...
Бу бит тик синең үлчәм.

## ТАСМА ТЕЛЛЕ РЕКЛАМА

Суган әйтә: хәтта елап-елап
Ник ярата мине кешеләр?
Һич аңламыйм... Ахры, бу дөньяда
Күп түгелдер минем ишеләр?!.

## ЭЧКЕЧЕНЕ... КИСӘТҮ

«Менә сиңа унбиш себерке!
Китереп куйдык йортның түренә...»
— Унбиш дигән. Никтер миңа бу
Унбиш тәүлек булып күренә.

## ӘЛӘКЧЕГӘ... ПОСЫЛКА

— Ике савыт кара кара салабыз,—
Киңәштек тә килдек шундый фикергә.
Кайчан нәрсә язганнарың билгеле...
Инде язма — шул караны бетер дә.

## АМЕРИКА АЧАРГА ӨНДӘҮ

— Сине монда тагын бер алимент
Эзләп тапты. Дустым, тизрәк кач, —
Бүгеннән дә соңга калмый ычкын,
Тагын берәр Америка ач!

## БАБАЙ БУЛАСЫ КИЛҮ

— Өч тешең төште бер көндә.
Бабаң кебек булдың, балам.
— Әгәр бабай булдым икән,
Димәк, мин пенсия алам!

## ДОКТОРГА КҮРЕНГӘНДӘ

— Кай төшең авырта, бала?
— Белмим. Әни алып килде
Мине монда. Ул аңлатсын!
...Доктор хәйран калып көлде.

## ҮЗЕ ВАТЫЛГАН ЧӘЙНЕК

— Чәйнекне син ваттыңмы, балам?
— Юк! Ул, әни, үзе ватылды.
Мин аны тик чүпкә ташладым,
Чөнки мин бит, әни, акыллы.

## БУШ ВӘГАЗЬДӘН СОҢ СОРАУ

— Беләсеңме, инде өч яшь тулды,
Син дүртенче белән барасың.
Акыллы бул, әйткән сүзне тыңла!..
— Ә мин, әни, кая барам соң?

## УРАМДА УЙНАП КЕРГӘЧ

— Өч мәсьәләң әле, балам, чишмәгән,
Сабагыңа утыр, тизрәк бул, чишен!
— Чишә алмый беттем инде чиләнеп...
Кем бәйләгән аны, әни, шул чишсен.

## ВАКЫТ АРТМЫЙ

— Әткәң-әнкәң синең көндәлеккә
Бер ай инде имза куймыйлар.
— Ник шулай дип сорасагыз, әйтәм:
Телевизор карап туймыйлар...

## ГЕРОЙЛАР ГЕРОЕ, ИМЕШ

Ишәк уйлый: «Мәсәлче күп —
Исәп тә юк, чут та юк...
Әмма иң яхшы мәсәлләр
Миннән башка юк та юк!»

# «ТАШЛАРДАГЫ ЯЗУЛАР»

Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы елларында батырлык үрнәкләре күрсәткән якташларыбыз турында күп кенә җыентыклар бастырып чыгарды. Шуларның берсен — Самат Шакирның «Ташлардагы язулар» дигән китабын — мин аеруча зур кызыксыну белән укыдым. Бу җыентык миңа тирән эчтәлекле һәм фактларга бай булуы белән ошады.

Китапның беренче өлешендә гражданнар сугышы чорында легендар Чапаев дивизиясендә хезмәт иткән Заһидулла Краснов, атаклы Азин дивизиясе пулеметчысы Фәйзерахман Закиров, Буденный Атлы Армиясе кавалеристы Габделвәли Фәйзерахманов, Беренче татар укчы бригадасының батальон комиссары Хәйретдин Хәйбуллин турында язылган очерклар белән танышабыз. Бу очеркларны укыганда безнең күз алдыбызда күңелдә тирән эз калдырган вакыйгалар гәүдәләнә.

1918 елның сентябре. Чапаев дивизиясенә казаклар кул астында калган бер хуторны азат итү бурычы йөкләнә. Сан ягыннан да, корал ягыннан да өстен булган дошманны хутордан бәреп чыгаруда Заһидулла Краснов һәм Имаметдин Хубаев роталары хәлиткеч роль уйныйлар. Комдив Чапаев бу сугышта зур батырлыклар күрсәткән командирларга һәм сугышчыларга рәхмәт белдерә. Хөкүмәтебез Заһидулла Красновны Сугышчан Кызыл Байрак, ә Имаметдин Хубаевны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкли.

1941 елның июлендә Заһидулла ага, өлкән яшьтә булуына да карамастан, үзе теләп фронтка китә һәм фашистларны тар-мар итүдә катнаша. Самат Шакир менә шуларның барысы турында да мавыктыргыч итеп яза.

Әлеге җыентыкта «Алаш Орданы җимергәндә» дигән очерк бар. Көньяк-көнбатыш Казагыстанның Каспий яны комлыкларында менә дүртенче тәүлек инде Татар бригадасының 3 нче полкы авыр походта. Полкның беренче батальон комиссары Хәйретдин Хәйбуллин үзенең батырлыгы, куркусызлыгы, сугышчылары арасында ныклы тәртип урнаштыруы белән башкалардан аерылып тора. Полк командиры аны үз янына чакырып ала һәм алда торган бурыч белән таныштыра. Аннары, полк комиссары Г. Касыймов белән киңәшеп, Хәйбуллин батальонына «Алаш Орда» хөкүмәтенең контрреволюцион штабына беренче булып һөҗүм итүне тапшыра. Батальон бу заданиене намус белән үтәп чыга. Очеркны укыганда күңелне кыю якташларыбыз белән горурлану хисе били.

Китапның икенче бүлегенә Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек булган якташларыбыз Иван Максимов, Ленинград өлкәсендә партизаннар отряды командиры булган Әхмәт Садыйков, Украинада тупчы булып хезмәт иткән һәм Советлар Союзы Герое исеме алган Гимай Шәйхетдинов, Днепропетровск шәһәрендә фашист илбасарларга каршы көрәшү өчен төзелгән яшерен оешма члены Фатыйма Гафурова һәм башкаларга багышланган очерклар тупланган. Ул очеркларда да, илебездәге башка барлык милләт вәкилләре белән иңгә-иң торып, туган илебезне һәм Европаны фашизм коллыгыннан азат итүдә баһадирларча сугышкан якташларыбызның онытылмас батырлыклары шактый тулы гәүдәләнә. Аларның данга бизәлгән тормыш юлы безгә һәм безнең киләчәгебез булган яшь буынга матур үрнәк булып тора.

**САЛИХ ХӘЙБУЛЛИН,**
отставкадагы өлкән лейтенант.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## БАШКАЛАДА ГАБДУЛЛА ТУКАЙ КИЧӘСЕ

21 октябрьда Мәскәүдә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 90 еллыгына багышланган тантаналы кичә булып үтте. Президиумда Ленин премиясе лауреатлары Р. Гамзатов, Ч. Айтматов, РСФСРның Дәүләт премиясе лауреаты Л. Татьяничева, совет әдәбиятының башка күренекле эшлеклеләре урын алды. Кичәне Г. Тукай юбилеен үткәрү комиссиясе председателе урынбасары, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Шундик ачты. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов шагыйрь иҗатына багышлап хөрмәтләү сүзе әйтте. Кичәдә Л. Татьяничева, Ч. Айтматов, С. Липкин, С. Хәким, М. Львов чыгыш ясадылар. Сөекле шагыйребез калдырган мирасның интернациональ әһәмияте, Тукай поэзиясенең үлемсезлеге барлык чыгышларда үзәк тема булып яңгырады. Утырышта КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, язучыларыбыздан Г. Бәширов, И. Нуруллин, В. Нуруллин, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Р. Харисов, М. Хәбибуллин катнашты.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА СЕМИНАРЫ

Татарстан Язучылар союзы идарәсе октябрь аенда, ВЛКСМ өлкә комитеты һәм профсоюзларның өлкә советы белән берлектә, яшь язучыларның өч көнлек семинарын үткәрде. Семинарга республикабыз шәһәрләре һәм районнарыннан, шулай ук Башкортстаннан, Ульяновск өлкәсеннән яшь прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар, әдәби тәнкыйтьчеләр һәм публицистлар — барлыгы йөздән артык кеше килде. Семинар үз эшен Казан шәһәренең Актерлар йортында башлады. Аны кереш сүз белән ВЛКСМ өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Суфия Шәймәрдәнова ачты. Аннары Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов КПССның XXV съезды карарлары һәм яшь язучылар алдында торган иҗади бурычлар турында сөйләде. Яшь әдипләр философия фәннәре кандидаты Р. В. Мөрсәлимовның «Фәнни-техник революция һәм дөньяны эстетик үзләштерү» дигән темага лекциясен, язучы Хәсән Сарьянның «Әдәби әсәрнең теле» дигән докладын тыңладылар. Шул ук көнне яшь язучылар Кырлайга юл тоттылар — анда Г. Тукай мемориале белән таныштылар, ә кичен клубта авыл хезмәтчәннәре белән очрашу булды, яшьләр кырлайлыларны үз иҗатлары белән таныштырдылар, әсәрләрен укыдылар.

Семинарның икенче көне дә докладлар тыңлаудан башланды. Өлкән әдипләребездән Гомәр Бәширов язучы иҗатында туган телнең тоткан урыны, Нәкый Исәнбәт үз иҗат лабораториясе турында сөйләде. Аннары яшьләр Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Еники, Н. Арсланов, Ш. Маннур, Н. Дәүли, Ә. Баянов, Н. Фәттах һ. б. әдипләр җитәкчелегендә аерым-аерым секцияләрдә эшләделәр. Яшь авторларның әсәрләренә тәфсилле һәм төпле анализ ясалды, иҗат мәсьәләләре турында җанлы сөйләшүләр барды. 15 октябрьда секцияләрнең эше дәвам итте. Ә төштән соң яшь әдипләр Г. Тукай клубына җыелдылар. Семинарга йомгак ясап, Г. Ахунов һәм секция җитәкчеләре яшьләрнең иң уңышлы әсәрләрен күрсәтеп үттеләр, әдәбиятка чын тормыш мәктәбе үткән сәләтле алмаш килүенә ышаныч белдерделәр.

Кичен семинарда катнашучы яшьләр Казан авыл хуҗалыгы институтында студентлар һәм укытучылар белән очрашу үткәрделәр, үз замандашларына багышланган әсәрләрен укыдылар.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Октябрьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булды. Әдәби-иҗат көчләре алдына партиябез куйган бурычларны үтәүгә язучыларны туплау буенча партия оешмасы алып барган эшчәнлек хакында отчет докладь белән партоешма секретаре Вакыйф Нуруллин чыкты. Ул әдәбиятның төрле жанрларында язучыларыбыз ирешкән иҗат казанышларын барлады, соңгы елда бигрәк тә прозаик һәм драматургларыбызның нәтиҗәле эшләвен күрсәтеп үтте, партоешманың отчет чорындагы эшчәнлегенә һәм үткәрелгән чараларга анализ ясады. Фикер алышуда әдипләрдән М. Садри, Г. Паушкин, Л. Ихсанова, Г. Ахунов, КПСС өлкә комитеты культура бүлеге инструкторы И. Хәйруллин һ. б. иптәшләр катнашты.

Алар киләчәктә партоешма эшчәнлеген тагын да активлаштыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәр керттеләр, теләкләрен әйттеләр. Җыелышта катнашучылар партия бюросының отчет чорындагы эшчәнлеген уңай бәяләделәр һәм тиешле карар кабул иттеләр. Җыелыш партбюроның яңа составын

сайлады. Яңа партбюроның беренче утырышында партбюро секретаре итеп Вакыйф Нуруллин сайланды.

## ТӘНКЫЙТЬ СЕКЦИЯСЕ УТЫРЫШЫ

Әдәби тәнкыйть секциясенең 26 октябрьда үткән чираттагы утырышы тәнкыйтьче яшьләр иҗаты мәсьәләсенә багышлап уздырылды. Секция җитәкчесе тәнкыйтьче Флүн Мусин утырышны ачып, партиябез Үзәк Комитетының иҗат яшьләре белән эшләү турындагы карары белән бәйләнештә әдәби тәнкыйть секциясенең бурычларын күрсәтеп үтте.

Яшь тәнкыйтьчеләр эшчәнлегенең бүгенге торышы, кимчелекләре, киләчәктәге перспективалары турында яшь рецензентләр түгәрәге җитәкчесе тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин һәм «Идел» альманахы редакторы Мансур Вәлиев доклад ясадылар.

Фикер алышуда катнашкан әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр Б. Гыйззәт, Н. Юзиев, И. Нуруллин, З. Мәҗитов һәм яшь буын вәкилләре тәнкыйтьче яшьләрнең иҗат активлыкларын көчәйтү, оештыру эшләрен һәм чараларын яхшырту буенча күп кенә конкрет тәкъдимнәр керттеләр. Тикшерелгән мәсьәлә буенча утырышта карар кабул ителде.

## ШАГЫЙРӘНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

Күренекле шагыйрәбез Саҗидә Сөләймановага октябрьда илле яшь тулды. Шул уңай белән язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында аның иҗат кичәсе булып узды. Илдар Юзеев кичәдә шагыйрәнең иҗаты хакында хөрмәтләү сүзе әйтте, юбиляр үзенең яңа шигырьләрен укыды, шагыйрәнең әсәрләре, аларга язылган җырлар башкарылды.

* * *

Әлмәттә, нефтьчеләрнең Техника йортында да шагыйрә Саҗидә Сөләйманованың юбилей кичәсе булды. Кичәне кереш сүз белән КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Ә. К. Гыйматдинов ачты. Юбилярның иҗаты турында шагыйрь Илдар Юзеев доклад сөйләде.

Әлмәт район советы башкарма комитеты председателе Г. К. Беляев шагыйрәгә Татарстан Верховный Советы Президиумының Почет грамотасын тапшырды. Саҗидә Сөләйманова шулай ук КПССның Әлмәт шәһәр комитеты, шәһәр һәм район башкарма комитетлары, Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсенең Почет грамоталары белән бүләкләнде.

Татарстан нефтьчеләре исеменнән «Татнефть» берләшмәсенең генеральный директоры урынбасары Үзбәк Саттаров, «Азат хатын» журналының баш редакторы Асия Хәсәнова, Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге исеменнән шагыйрь Гамил Афзал, «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре язучы Ләбибә Ихсанова, Татарстан китап нәшриятының өлкән редакторы Сания Сибгатуллина, язучылардан Ш. Бикчурин, М. Хәсәнов, Х. Хәйруллин һәм нефть районнарыннан килгән кунаклар, Әлмәт шәһәре оешмалары вәкилләре шагыйрәне иҗат бәйрәме белән кайнар котладылар, яңа уңышлар теләделәр.

Юбиляр адресына илебезнең төрле почмакларыннан килгән котлау телеграммалары укылды.

Юбилей кичәсе Әлмәт драма театры артистлары башкаруында әдәби-музыкаль концерт белән тәмамланды. Фойеда юбиляр иҗатына багышланган әдәби күргәзмә оештырылды.

## ОЧРАШУЛАР, ГЫЙЛЬМИ КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

* * *

Үзбәкстан ССРда РСФСР әдәбияты һәм сәнгате көннәре тәмамланды. Шул уңай белән 18 октябрьда Ташкент шәһәренең А. Навои исемендәге Зур театрында тантаналы кичә булды. Әдәбият һәм сәнгать бәйрәмендә Татарстан Министрлар Советы Председателе урынбасары, филология фәннәре докторы профессор Мансур Хәсәнов һәм күренекле рәссам, Дәүләт премиясе лауреаты Харис Якупов катнашты.

* * *

Академик В. А. Гордлевскийның тууына йөз ел тулу уңае белән СССР Фәннәр академиясенең көнчыгышны өйрәнү институты юбилей конференциясе үткәрде. «Владимир Гордлевский һәм татар публицистикасы» дигән темага доклад белән конференциядә профессор М. Гайнуллин катнашты.

* * *

Әдипләребез Г. Ахунов, В. Нуруллин, М. Хәбибуллин В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты тулай торагында студентлар белән очраштылар, яңа әсәрләре, иҗат планнары белән таныштырдылар, сорауларга җавап бирделәр.

## МӘГЪРИФӘТЧЕ Г. КУРСАВИНЫҢ ТУУЫНА 200 ЕЛ

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының чираттагы киңәйтелгән гыйльми утырышы атаклы татар мәгърифәтчесе Г. Курсавиның тууына ике йөз ел тулуга багышлап уздырылды. Утырышта «Күренекле рационалист-галим» дигән темага философия фәннәре кандидаты Я. Абдуллин, «Г. Курсави турында әдәби һәм архив чыганаклары» дигән темага институтның фәнни хезмәткәре Ә. Хәйруллин докладлары тыңланды.

## ЮБИЛЯРГА — БҮЛӘК

СССР Верховный Советы Президиумының 1976 ел, 22 октябрь Указы белән Казан дәүләт педагогия институты педагогия кадрлары хәзерләүдә ирешкән уңышлары өчен һәм оештырылуына 100 ел тулу уңаеннан Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

## ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫ ҖЫЕНТЫГЫ

Татарстан китап нәшрияты «Татар халык җырлары» исемле җыентык чыгарды. Аның төзүчесе — музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов. Китапта Татарстан, Башкортстан һәм Идел буе өлкәләрендә, Себер якларында язып алынган җырлар тупланган. Шулай ук Г. Сөләйманова, З. Басыйрова, И. Шакиров кебек профессиональ җырчыларыбызның кайбер фоноязмалары да урнаштырылган. Җыентыкта «Хезмәт һәм йола җырлары», «Туй йоласы җырлары», «Кодалар, мәҗлес җырлары», «Уен җырлары», «Бәетләр, мөнәҗәтләр», «Лирик җырлар», «Төрле көйләр» дигән бүлекләр бар.

## ЯҢА КИТАП

Тарих фәннәре кандидаты Сәлам Алишевның «Каһарман бабайлар» исемле хезмәте дөнья күрде. Автор крестьяннар һәм башка хезмәт иясе массаларының социаль һәм милли азатлык өчен алып барган күп гасырлык көрәшен, күтәрелешләрнең башында торган каһарман йөрәкле шәхесләр үткән юлны, ирек өчен даулашларда татар, рус, башкорт, чуваш, мари һәм Идел буендагы башка халыкларның бердәм катнашуын күп санлы тарихи чыганаклар нигезендә яктырта, халык күтәрелешләренең күренекле җитәкчеләре хакында яңа мәгълүматлар терки.

## «ИДЕЛ»НЕҢ ЯҢА САНЫ

Яшьләр иҗатына багышланган «Идел» әдәби альманахының җиденче саны басылып чыкты. Альманах битләрендә яшь авторларның шигырь һәм проза әсәрләре, очерк һәм тәнкыйть мәкаләләре дөнья күргән. Тәнкыйтьче Ф. Миңнуллинның алгы битләргә урнаштырылган «Яшьләргә юл киң» исемле мәкаләсе бүгенге иҗади яшьләребез яулыйсы яңа офыклар, алар иҗатының уңышлы һәм кимчелекле яклары хакында сөйли. Проза бүлегендә Марсель Галиевнең «Кар абагалар» исемле повесте, Рөстәм Зарипов һәм Альберт Сафин хикәяләре тәкъдим ителә. Яшь замандашыбыз образын үзәккә алган «Кар абагалар» повесте укучыда зур кызыксыну уятырлык. Җыентыкта Венера Туктарова, Мөдәррис Вәлиев, Рәфикъ Юнысов, Шәүкәт Сибгатуллин һ. б. яшь шагыйрьләрнең әсәрләренә дә шактый урын бирелгән. Равил Вәлиев КамАЗ төзелешендәге бетончылар тормышыннан алып язылган «Кем хаклы?» исемле очеркында кеше һәм техник прогресс мәсьәләсенә мөрәҗәгать итә. Альманахта сәнгать темаларына да аерым урын бирелә. Композитор Фасил Әхмәтов белән яшь шагыйрь Разил Вәлиевнең музыка һәм җыр, композитор һәм җыр язучы шагыйрь хакындагы җанлы әңгәмәсе, Фаил Шәфигуллинның яшь рәссам Эрот Зарипов иҗаты, Фәүзия Кадыйрованың Татарстанның атказанган артисты Равил Шәрәфиев турындагы язмалары укучыга күп кенә яңа фикерләр җиткерә. Тәнкыйть бүлегендә Фатих Макаевның Роберт Әхмәтҗанов шигырьләренә ясаган кечерәк күзәтүе поэзия сөюче яшьләргә бу үзенчәлекле шагыйрьнең поэтик алымнарын, шигырьдәге хис-тойгы нечкәлекләрен төшенергә ярдәм итә. Альманах битләрендә юмор һәм сатира бүлеге дә зур урын алып тора. Җыентыктагы «Юл башы» исемле бүлектә бүгенге әдәбиятыбызның күренекле һәм өлкән вәкилләре Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Мирсәй Әмир, Фатих Хөсни, Ләбибә Ихсанова, Атилла Расих иҗат юлы башында торучы яшь әдипләргә үзләренең иҗат эшчәнлеген кайчан башлаулары, әдәбият мәйданына ничек аяк атлаулары хакында сөйлиләр.

Альманахны бизәүдә рәссамнар да катнашкан. С. Насыйрова һәм Л. Насыйровның әсәрләргә ясаган иллюстрацияләре, Надир Альмеев, Р. Имашев, Э. Зарипов эшләреннән үрнәкләр, шулай ук авторларның һәм очерк геройларының фоторәсемнәре урнаштырылган.

## КӨЗГЕ ПРЕМЬЕРАЛАР

* * *

26 октябрьда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» исемле комедиясе буенча куелган спектакль премьерасы уңышлы үтте. Әсәрне сәхнәгә РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗанов куйган, музыкасын композитор Алмаз Монасыйпов язган, декорацияләрне художник Әхәт Гайнуллин эшләгән. Спектакльдә төп рольләрне РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Шәүкәт Биктимеров, Татарстанның атказанган артистлары Фатих Кульбарисов, Равил Шәрәфиев, артистка Алсу Гайнуллина һәм башкалар уйный.

* * *

В. И. Качалов исемендәге Казан Зур драма театры Уильям Гибсонның «Үлемме, яшәүме?» исемле әсәрен сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссеры — В. Портнов, художнигы — Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты Э. Гельмс.

* * *

М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры яңа сезонны Э. Григның «Сольвейг җыры» буенча сәхнәләштерелгән балет премьерасы белән каршы алды. Балетмейстеры — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе В. Шумейкин. Төп рольләрне ТАССРның халык артисткасы И. Хәкимова, ТАССРның атказанган артисты Қ. Гайнуллин, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты, Г. Тукай премиясе лауреаты Р. Садыйков һ. б. башкара.

* * *

Татар дәүләт күчмә театры И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан» исемле әсәрен сәхнәгә чыгарды. Аны Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай премиясе лауреаты Равил Тумашев куйган. Музыкасын М. Имашев язган, декорацияләрне Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе П. Баландин эшләгән. Спектакльдә Татарстанның атказанган артистлары Ф. Парсин, Л. Парсина, И. Мәхмүтова, Г. Нуруллин һ. б. катнашалар.

* * *

Әлмәт дәүләт драма театры яңа сезонга А. Гыйләҗевнең бүгенге көн темасына багышланган «Кар астында кайнар чишмә» исемле әсәрен әзерләде. Аны сәхнәгә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Г. Хөсәенов куйды. Баш рольләрне артистлар З. Гыйләҗев, Қ. Сәетгәраев, В. Шәриповалар башкара.

* * *

Республика курчак театры да «Пәһлеваннар» спектакле белән яңа сезонны ачты. Спектакльгә кием һәм декорацияләрне художниклар Э. Гельмс һәм Л. Сперанская әзерләгән, композитор И. Якупов музыка язган.

* * *

М. Гафури исемендәге башкорт дәүләт академия драма театрында Т. Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» әсәре сәхнәләштерелде. Режиссеры — Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты Рифкать Исрафилов. Музыкасын композитор Рим Хәсәнов язган, декорацияләрне художник Таң Еникеев эшләгән.

# ТӨП ГЕРОЙ— ХЕЗМӘТ КЕШЕСЕ

ӘДӘБИ КОНКУРС

Зур программаларын партиябезнең XXV съезды билгеләгән унынчы бишьеллыкның икенче елына аяк бастык. Илнең көне авыл һәм шәһәр хезмәт ияләренең яңадан-яңа фидакарьлеге белән, бөек төзелешләрдәге яңа казанышлары белән билгеләп үтелә. Республикабызда яңа бишьеллык планны үтәү өчен киеренке көрәш бара. Казан оргсинтез заводы, Түбән Кама химия комбинаты, Кама буенда төзелә торган авыр йөк машиналары комплексы, нефтьчеләр башкарган героик эшләр, комбайннар гүләгән уңдырышлы басулар — бүгенге көрәш фронтының алдынгы постлары. Зур фикерле, бай рухлы, коммунистик идеалларга чын күңелдән бирелгән заман герое хезмәттә үсә һәм чыныга.

Замандашыбызның хезмәттәге батырлыгын, рухи дөньясының зурлыгын, тормышта, эштә һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрдә чагылган яңа сыйфатларын күп яклы һәм күп бизәкле итеп яңа әсәрләрдә чагылдырырга кирәк.

Әйтелгәннәрдән чыгып, Татарстан Язучылар союзы һәм «Казан утлары» журналы редакциясе иң яхшы хикәяләргә **ачык конкурс** игълан итә. Конкурста яшь авторларның актив катнашачагына ышаныч зур.

Конкурска машинкада басылган һәм күләме бер табактан артмаган беренче нөсхә кульязмалар 1977 елның гыйнвареннан кабул ителә башлый. Аларны тәҗрибәле прозаиклардан төзелгән жюри бәяләячәк. 1979 елның башында Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм «Казан утлары» редколлегиясе конкурска йомгак ясыйлар. Яхшы дип табылган әсәрләр журнал битләрендә басыла, соңыннан аларны бергә туплап нәшриятта аерым китап итеп чыгару да күздә тотыла.

Конкурста җиңүчеләр өчен 1 беренче (150 сум), 2 икенче (100 әр сум) һәм 3 өченче (75 әр сум) бүләк билгеләнде.

Әсәрләрне «Замандаш конкурсына» дигән язу белән «Казан утлары» журналы адресына җибәрергә кирәк: 420066, Казань, Декабристов, 2.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.
«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДКОЛЛЕГИЯСЕ.

*Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның февраль санын Барлас Камаловның «Канатлы кырмыска» повесте белән ачачакбыз.

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы дәвам итәчәк. Диләрә Зөбәерованың «Сызган балдак» хикәясен укырсыз.

Гамил Афзалның «Чияле тау итәгендә» дигән шигырьләр бәйләмен, Зөлфәтнең яңа шигырьләрен, Шәүкәт Галиевнең нәниләр өчен язган шигырьләрен урнаштырабыз.

Очерклар бүлегендә КамАЗ елъязмасының соңгы битләрен бирәчәкбез. Кояш Тимбикованың «Кара юрга» очеркын һәм Зәки Әхмәтҗановның сугыш истәлекләрен яңарткан «Еллар уткәч» дигән язмасын тәкъдим итәбез.

Герой шагыйрь Муса Җәлил исеменә бәйле материаллар журналыбызга килә тора. Бу санда сез немец язучысы Л. Небенцальның «Җәлил рухы», Р. Мостафинның «Соры плитәләрдә ал кан таплары» дигән мәкаләләрен, А. Клабуковның «Онытылмас кешем» дигән истәлеген укырсыз.

Февральдә күренекле татар язучысы Ибраһим Газиның тууына 70 ел, атаклы рәссам Баки Урманчега 80 яшь тула. Шул уңай белән аларның тормыш юллары, иҗатлары турында мәкаләләр, истәлекләр һәм язучының хатларын урнаштырабыз.

Журналыбызның «Төрлесеннән» дигән бүлегендә В. Семеновның «Алексей Толстой Казанда» һәм И. Сибгатуллинның «Капитанның төньяк Одиссиясе» дигән кызыклы язмалар бар.

Һәр сандагы китап күзәтү, сатира-юмор әсәрләре, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары игътибарыгызга лаек булыр.

**«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә. Февраль санынннан башлап, алдагы айларга Сез теләсә кайсы элемтә бүлегендә языла аласыз. Язылганда журналның 73210 номерлы индексын күрсәтергә онытмагыз.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210